

**Фаил Шәфигуллин**

# Бер малай, өч аргамак

*Повестьлар, хикәяләр*



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат-4
Ш 96

Төзүчесе **Эльмира Шәрифуллина**

**Шәфигуллин Фаил**

Ш 96 Бер малай, өч аргамак: Повестьлар, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 272 б.

Бу китаптагы әсәрләр укучыларны яңа дөньяга алып керә. Анда кыюлык, мәхәббәт, эш сөючәнлек, матурлык тиешле бәясен ала.

ISBN 5-298-04073-X © Татарстан китап нәшрияты, 2005

# ТЫЛСЫМ ДӨНЬЯСЫНДА

Кадерле укучым, әлеге китап сезне мавыктыргыч дөньяга сәяхәткә алып китәр. Дөрес, аны картадан эзләп тору файдасыз. Ул дөнья — язучы Фаил Шәфигуллин иҗат иткән хыял дөньясы. Анда кызыклы малайлар һәм кызлар, уйлый-фикерли белүче кош-кортлар, кешеләргә шатлык өләшүче кар бөртекләре, җемелдәшкән йолдызлар эзеннән чабучы ак аргамаклар яши.

Фаил Шәфигуллин күпсанлы шигырьләр, көлкеле юмористик хикәяләр, җитди проза әсәрләре иҗат иткән әдип. Балалар әдәбияты өлкәсендә дә рухланып, илһамланып эшләгән, зур мирас калдырган язучы.

Ул үзенең чыгышларының берсендә балалар әдәбиятына аеруча сак карарга, җаваплылык хисе белән алынырга кирәклеге турында ассызыклап әйтә. Чынлыкта исә, язучы кеше — гасырлар дәвамында җыелган акыл, тәҗрибәне яшь буынга тапшыручы бит ул. Димәк, балалар өчен иҗат иткән кешенең үзенең дә югары дәрәҗәдәге гыйлемгә ия булуы зарури. Ә сезнең киләчәгегез, кадерле укучым, бүген нинди китаплар укуыгызга, нинди тәрбия, нинди белем алуыгызга бик нык бәйле.

Кулына китап алган һәр кеше түбәндәге бер мөһим әйберне белергә тиеш дип уйлыйм. Әгәр дә язучы чынчынлап зур язучы икән, ул күпмедер дәрәҗәдә тылсымчы да. Фикер көче ярдәмендә ул сезне узган гасырларга яки киләчәккә, ерак-еракларга алып китә ала. Җансыз әйберләрне җанландырып, хәтта гап-гади күренешләргә яшеренгән зур серләрне ачып бирә ала.

«Бер малай, өч аргамак» китабын укыганда, сез төрле мавыктыргыч вакыйгалар кичерү белән бергә, киләчәк тормышыгызда файдалы булырлык белем дә алачаксыз.

Фаил Шәфигуллинның тормыш юлы кыска, әмма шуңа карамастан әсәрләре тормыш тәҗрибәсенә бик бай. Чөнки язучылык эшенә керешкәнче, аңа күпне күрергә, шактый белем-тәҗрибә тупларга, илебезнең төрле төбәкләрендә булырга, байтак һөнәр-хезмәтне үзләштерергә туры килә. Булачак язучы Коми республикасында урман кисә, Казахстан далаларында Чирәм җир күтәрә, хәтта

Ерак Көнчыгышка, Тын океанга кадәр барып җитә. Анда балык тоту флотилиясендә матрос булып эшли. Ә инде туган якларына әйләнеп кайткач, заводка эшкә урнаша. Читтән торып башта урта мәктәпне, аннан соң Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый.

Язучы бик матур табигатьле Яшел Үзән районының Карашәм авылында туган. Ул — язучының дөньяга күңел күзе ачылган төбәк. Үзенең әсәрләрендә искиткеч күзәтүчән булырга, әйләнә-тирәне җанлы итеп күрергә дә аны әнә шул туган ягы өйрәткән. Әйтик, дөньяның матурлыгын тану «Фирүзә» хикәясендәге кебек кечкенә кар бөртегенең матурлыгын күрүдән башланырга мөмкин. Яисә «Кырмыска турында баллада», «Актәпи», «Акбай белән Карабай» хикәяләрендәге шикелле шаян натуралистик күзәтүләр аша. Нәни кеше өчен мондый җанлы картиналар бигрәк тә кадерле, минемчә.

Табигать дөньясын тасвирлаган гади сюжет фонында язучы баланың ата-ана алдындагы бурычы, туганлык, дуслык, батырлык кебек тирән төшенчәләрне ачып бирә. Балаларның үзләренә хас тискәре һәм уңай сыйфатлары турында да уйланырга мәҗбүр итә, алар алдына мораль пландагы төрле мәсьәләләр куя һәм үзләре белән бергә җавап та эзли.

«Әнкә күркә һәм аның балалары», «Кәҗәмөгез йолдызлыгы» кебек хикәяләрдә әдип ана мәхәббәте турында сүз алып барса, «Верочка», «Кырмыска турында баллада», «Тау битендә күләгә», «Командир», «Нишләргә тиеш идем?», «Әнфисә кемгә елмая?», «Исемең Ләйсән булыр» исемле әсәрләрендә чын дуслык һәм батырлык хакында уйланырга мәҗбүр итә.

«Чын дус ул нинди булырга тиеш?» дигән сорауга, мәсәлән, «Исемең Ләйсән булыр» исемле хикәянең бер героинясы: «Шундый килешле исемең, шундый әйбәт дустың булганда, ялантәпи дә яшәргә мөмкин ич дөньяда», — дип җавап бирә.

«Әнфисә кемгә елмая?» хикәясенең төп герое Габделбәр яшьтәшләре белән чагыштырганда «кечкенә буйлы, ябык чырайлы». Әмма бозлы суга төшкән көчекне коткарырга шул Габделбәр ташлана. Чибәр Әнфисә аңа, җан иясен коткарган кешегә, матур итеп елмая.

Автор тарафыннан бик кызыклы ассоциация үткәрелә: батыр булу ул — иң әүвәл олы җанлы булу. Димәк, батырлык эшләр өчен зур физик көчкә ия булу алшарт түгел! Бүтән җан иясенең бәхетсезлеген үз бәхетсезлегең кебек, шатлыгын да үз шатлыгың кебек кабул итә белү, ярдәмчел булу гына мөһим!

Әнә «Кырмыска турында баллада» хикәясендә, иелеп карамасаң, күзгә дә күренмәслек кечкенә кырмыска зур батырлык эшли: үзенең дусты Вәли исемле малайны үлемнән коткара. Поезд килгәнен күргәч, рельс өстендә йоклап киткән малайның бармагын тешләп йокыдан уята.

Оста язучы шактый катлаулы төшенчәләрне дә аңлаешлы күренешләр аша аңлаешлы телдә укучыга җиткерә белә. Әйтик, «яшәү», «яшәү мәгънәсе», «шәхес», «җәмгыять» дигән сүзләрне ишеткәч, акыллы абый-апаларыгыз аларны, мөгаен, бу гаять катлаулы фәлсәфи категорияләр, дип әйтерләр. Әмма Фаил абыегызның кар дөньясына алып кереп киткән «Фирүзә» хикәясендә әлеге фәлсәфә әкияти мисалда бик гади, бик матур итеп аңлатыла. «Җирдә һәркайсыбызның үз урыны бар. Шул урынга барып җиткәч тә төшәрбез», һәр кар бөртегенең үз максаты, үз урыны булган кебек, һәркайсыбызның үз урыны, үз максаты бар бит бу дөньяда. Фаил Шәфигуллин геройлары әнә шул максатны ачыкларга, яшәүнең мәгънәсен билгеләргә омтылалар. Һәр герой бу сергә ачкычны үз юлы белән таба. Кечкенә кар бөртеге Фирүзә, мәсәлән, бер кызчыкка куаныч, шатлык бүләк итә. Фирүзә, елап торган нәни кызчыкны күреп, аның учына килеп куна. Әлбәттә, җылы кулда ул эри, ләкин эрегәнче, кызның «чиста күк йөзедәй зәңгәр күзләрен киң ачып, соклану катыш куану белән тулуын күреп» өлгерә. Кар бөртегенең матурлыгы нәни кызчыкның күңелендә куаныч булып кабына!.. Димәк, безнең галәмдә бөтен нәрсә мәңгелек әйләнештә икән, матурлык та җаннан җанга күчеп яши.

Фаил Шәфигуллинның тагын бер төр әсәрләре мәктәп балалары, үсмерләр тормышына багышланган. Аларның геройлары маҗаралы, гыйбрәтле, көлкеле хәлләргә юлыга, төрле кыенлыклар кичерә. Бу очракта да иҗатның асылы бер төп максатка кайтып кала. Һәр герой кешелеклелек ягыннан сынала. Фәкать шушы яктан сынау үткән мәлдә генә ул башкалар арасында хөрмәт казана, үзен бәхетле сизә.

Балаларга багышланган әсәрләр арасында язучының «Солдатлар кайта», «Ислемай», «Бер малай, өч аргамак» (беренче варианты «Ак яллы аргамаклар»), «Ак маңгайлы бүреләр», «Ерык авызлы энекәшем» һәм башка шуның кебек үз тормыш юлын чагылдырган автобиографик әсәрләр барлыгын да күрсәтик. Билгеле булганча, язучының балачагы сугыш һәм сугыштан соңгы авыр елларга туры килә. Гаиләнең төп терәге — этиләре вафат булганга күрә, алар зур мохтаҗлык кичереп яшиләр. Ачлык, юк-

лык, сабый бала җилкәсенә төшкән авыр хезмәт — «Бер малай, өч аргамак» повесте сәхифәләре әнә шул елларга алып китә. Әсәрнең төп герое Рәсим дә, автор кебек үк, унбер яшендә колхозда эшли башлый. Әмма саф күңелле булуы, якты хыяллар белән яшәве, җор телле, тапкыр булуы аңа барлык авырлыкларны җиңәргә, җиңүче булырга ярдәм итә.

Фаил Шәфигуллин үзенең «Нәни планетага сәяхәт» исемле язмасында «Гыйнварның утыз көне утыз төрле иде бала чакта. Февраль кары көн саен төрле-төрле төсләргә кереп җемелди иде. Март кояшын, апрель җилләрен ничек көтеп ала идек без бала чакта», — дип яза. Күрәбез, балачак дөньясы бик якын, бик кадерле булган язучыга. Фаил Шәфигуллин балаларга иҗат иткән һәрбер әсәрендә аларның дусты, сердәше, киңәшчесе булып кала. Тормышның һәрбер нәни ноктасында үзгә бер дөнья күреп, безне шул тылсымлы дөньяга сәяхәткә алып чыккан мәртәбәле язучыбыз ул! Сезнең дә «Бер малай, өч аргамак» китабына ясаган сәяхәт-сәфәрегез күңелле һәм мәгънәле булсын, кадерле укучым!

*Раушания Шәфигуллина*

# Повестьлар



# АК МАҢГАЙЛЫ БҮРЕЛӘР

Безнең авылдан дүрт-биш чакрымнар булыр Каратамак сазлыгына. Гаҗәп урын ул. Сазлыкның бер чите куе урманга барып терәлә, икенчесе адәм үтеп керә алмаслык әрәмәлек, — анда кыргый колмаклар белән чорналып беткән зирекләр, таллар, каеннар, баланнар үсә. Ләкин Каратамак сазлыгына урман ягыннан да, әрәмәлектән дә тиз генә үтеп керермен димә: йомшак урман сукмаклары да, әрәмәлектә бер-берсе белән кисешеп, әле уңга, әле сулга боргаланып йөргән караңгы сукмаклар да ни өчендер Каратамакны урап узалар.

Авыл ягыннан Каратамак әйтерсең лә, юри кешеләрдән саклану өчен, үзенә үзе киртә ясап куйган. Кизләү үреннән үк сөзәкләнеп башланган тарлавык, яшел ярларын күпертеп, басулар түренә китә-китә дә кинәт кенә тауга барып терәлә. Тауның авыл ягы артык текә түгел әле. Ә менә сазлыкка караган ягы!.. Анда менеп тә, төшеп тә йөргән кеше юк. Без бала чакта, озын сүс бауларга тотынып, керәшәләр, яр карлыгачлары шәһәрчеген карарга тауның яртысына кадәр төшкәли идек, хәер. Бала чакта бит ул. Бала чакта шайтан муенын сындырырлык урыннардан да хәвеф-хәтәрсез үтәсең.

Тауның яртысын узгач, ишелә торган ялангач кызыл яр башлана. Язгы су чорында моннан гөбердәп шарлама ага. Әмма тау башыннан шарлама үзе күренми. Аның әллә нинди серле һәм шомлы авазлар чыгарып, мәгърур бер көйгә шаулап торганы гына ишетелә.

Ярар, инешләрдә бозлар агып беткәч, ташулар тынгач, бер очы иптәшләрең кулында калган бауга ябышаябыша, түбәнгә дә төштең ди, шарлама казаны төбендә җыелып калган көмеш суны да урап уза башладың ди... Үзле ләмгә тездән кереп батканыңны сизми дә калдыңмы? Аягыңның берсен суырып алырга өлгермәдең, икенчесе батты. Тирә-юньдә бер генә таш та, бер генә агач төбе дә юк. Ташлар өстә, синең баш очыңда асылынып тора. Ничек кирәк алай, көч-хәл белән котылдың дуен әсирлегеннән. Каты ярга баскач, әле генә сине төпкә суыра башлаган мәкерле урынга әйләнеп карадың. Гүяки

син бөтенләй анда аяк басмаган, инде бөтен җир тип-тигез, шоп-шома. Дуен өстендә бер генә эз дә, бер генә җыерчык та юк. Шарлама казанындагы су гына болганчыкланып, солы кесәленә охшап киткән. Син сыек үзән читендәге җикән-камышларга соклану катыш шомланып карап алдың да, тирләгән битеңне сөртә-сөртә, ташлар арасыннан тирбәлеп торган арканга барып ябыштың...

Әй, нәрсәсе кызык соң моның, сазлык тек сазлык, андый сазлыклар беткәнмени җир йөзендә, диярсез инде сез. Анысы шулай. Ләкин Каратамак сазлыгының нәкъ уртасында усак урманы бар. Ерактан ул зәңгәр су уртасында сырты белән утыртып куелган олы таракка охшап күренә. Урман уртасында дөя өркәчләредәй кабарып-кабарып торган калкулыклар. Калкулыклар арасында ярлары чикләвек куаклары белән капланган тирән ермаклар. Без бу урынны Тирән Чокыр дип йөртәбез. Тирән Чокыр борыла-борыла олы урманга кадәр сузыла. Анда чикләвек уңа, балан уңа. Ә калкулыклар арасындагы иң-күлектә җир җиләге... Чөнки монда көтү керә алмый. Сазлык читендәге усаклар җәй буе тез тиңентен суда утырганлыктан, урман уртасындагы атау һәрвакыт кеше күзеннән читтә, аулакта үзенең тыныч һәм кыргый тормышы белән яшәп ята.

Бу атаудагы кошларны әйтерсеңме! Әле яңарак кына күкәйдән чыккан, сары томшыклы, чыршы күркәсе кадәрле генә саз чыпчыгыннан алып, корыган агач ботагында: «Килделәр дә киттеләр, килмәгән тик булдылар», — дип, үзе яшәгән чорда дөньяга килеп киткән җан ияләре турында уйланып утыручы, гомеренең инде, мөгаен, өченче йөзен ваклаган карт козгынга кадәр яши Каратамак атавында. Каратамак бакалары никадәрле генә бердәм бакылдашмасыннар, барыбер баса алмыйлар кошлар хорын.

Ат та, машиналар да, җәяүле дә керә алмагач, сез ничек керә идегез соң ул атауга, дисезме? Маймыл кебек, агач башыннан. Тауның сөзәкләнебрәк сазлыкка барып тоташкан битендә, куе ябалдашлары белән болытларны терәп, куш карама үсә. Шул караманың бер кәүсәсе сазлык өстенә авышыбрак зирек куакларына кадәр сузылган. Зирек куаклары арасында кәкре каен. Куш карама белән кәкре каен арасында сазлыкның иң мәкерле төше, диләр. Бу урында (әле без туганчы ук) дулап килеп кергән үгезне мәкерле сазлык күз ачып йомганчы салкын куенына алган, диләр.

Баскач азрак сәленсә-тирбәлсә дә, кәкре каен төбендә шактый тотрыклы түмгәк бар. Түмгәктән соң инде саз-

лык үзе дә юашлана, аякларны суырмый башлый. Әмма барыбер тиз-тиз атлавың хәерле. Кулыңдагы чалбарыңа, чабуы күкрәгеңә кадәр күтәреп куелган күлмәгеңә су чәчрәр дип куркып торма, аякларыңа камыш төпләре, әкәмтөкәмнәр кадалганына да игътибар итмә. Колак төбеңнән генә юка, нәфис канатларын зеңгелдәтеп узган энә караклары арасыннан чупырдат та чупырдат суны.

Җәй башында әлеге юлдан Каратамак сазлыгын кичмәгән малайны кеше чутына кертмиләр иде безнең авылда.

Әниләр дә:

— Фәлән кеше малае Каратамак аланыннан җиләк җыеп кайткан икән, күр әле син аны, кай арада үсеп җиткән, — дип, теге малайны, башсызлыгы өчен бераз битәрләгән сыман, әмма күбрәк гаҗәпләнеп, алай гына да түгел, хәтта күпмедер дәрәҗәдә мактап сөйлиләр иде.

Ничә тапкыр кичтек икән без бала чакта Каратамак сазлыгын? Хәтердә сакланмаган. Ә менә беренче тапкыр Каратамак атавына чыгуыбыз онытылмый.

Көннәрдән бер көнне миннән ике-өч яшькә олырак абыем миңа Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр» әсәрен кычкырып укыды. Ул китапта тасвирланган сазлык нәкъ безнең Каратамак сазлыгын хәтерләтте миңа. Әсәр укылып беткәндә инде, абый да, мин дә Валазама күперен шартлатырга баручы кыю, тәвәккәл разведчиклар халәтендә идек. Икебезнең дә күңелләр иләс-миләс, икебезнең дә йөзләр кызарган, күзләр ялтырый. Уйларыбыз да бертөрле булган икән.

Абый, урыныннан сикереп торып:

— Внимание, товарищи! — дию белән, мин чатнатып:

— Ечь, внимание! — дип ярып салдым.

— Каратамак сазлыгын кичеп, усак урманы уртасындагы Валазама күперен шартлатырга!

— Ечь, шартлатырга!

Инде көн кичкә авышып килүгә карамастан, тиз генә җыенып, агач мылтыкларыбызны асып, чолан ишеген көрәк сабы белән терәтеп, капканың келәсен төшереп, юлга чыктык.

Бәрәңге басуын да, арыш, арпа кырларын да марш атлап узган идек, әмма тау итәгендәге кәҗә сукмагы буйлап теркелдәгәндә, минем сугышчан дәртем кими төште, башка дөньяви уйлар килде.

— Әни эштән кайтыр вакыт җитә бит, әнигә ни дип әйтербез соң? — дидем мин, уңга-сулга карамыйча, куш карамага таба сыпырткан абыйның алдына төшеп.

— Җиләккә бардык, диярбез.

— Ә кайда савыт? Савыт алмадык ич.

— Кузгалак яфрагына җыярбыз. Каратамак аланындагы кузгалак яфракларының берсе-берсе өстәл чаклы...

Сазлык өстенә ятып үскән карама кәүсәсе буенча йөгереп кенә уздык. Каен кәүсәсенә күчәр алдыннан, мылтыкларыбызның бауларын кысыбрак бәйләдек. Күгелҗем су уртасындагы яшел ястык кебек кабарып торган түмгәк өстенә беренче булып абый сикереп төште. Төште дә чалбарын салып муенына урады, һәм, башын югары тотып, сазлыкка кереп китте. Ә мин кәкре каенга атланып калдым. Бөтен тирә-якта су. Сикерсәм, әлеге түмгәк тирбәлеп кенә калмас, су астына китәр сыман.

— Абый! — дип кычкырдым мин, сазлык эчендә ялгызым гына калудан котым очып.

Абый туктады. Борылып карады. Минем әле һаман да кәкре каен кәүсәсенә атланып утыруымны күргәч, мылтыгын югары күтәреп болгады.

— Внимание, товарищи!

— Ечь, внимание!

— Җиргә сикерергә!

— Ечь, сикерергә!

Күзләремне йомып, түбәнгә омтылдым... Бернәрсәсе дә юк икән лә. Мендәргә төшкән кебек йоп-йомшак. Мылтык түтәсенең тез капкачын авырттыруын исәпләмәгәндә, «десант» уңышлы ясалды.

Бер кулга чалбарны, икенче кулга мылтыкны тотып, суга кереп киттем. Мышный-мышный абыйны куып җиттем. Башымда ифрат та борчулы уйлар кайный иде минем бу вакытта.

— Абый, абый! — дидем мин, еларга җитешеп.

— Нәрсә тагын?

— Ә кайтканда, кайтканда ничек менәбез каенга? Каен төбендә тирән су. Камышлары да күренми әнә.

Абый серле генә елмаеп куйды да:

— Менә шулай тәпи-тәпи су ерып барабыз да каен янына, үрмәләп менәбез, — диде.

— Анда суыра торган сазлык ич.

— Кем әйтә?

— Алайса, нишләп шуннан гына килмәдек?

— Хәрби сер, — диде абый һәм, артыннан болганчык эз калдырып, чапыр-чопыр усаклыкка таба китеп барды. Мин сүзсез генә аңа иярдем.

Усаклыкка хәвеф-хәтәрсез генә килеп җиттек. Агач араларындагы су шундый тонык — анда агачлары түбәнгә карап, тагын бер урман үскән сыман. Зәңгәр күк тә, чит-читләрен кичке кояш нурлары алсуландырган мамык болытлар да бар су төбендә. Көзгедәй якты су өстен-

нән җитез хәрәкәтле, озын ботлы суүлчәр шуып узгач, су асты урманының агачлары чайкалып куйгандай булды. Серле дөнья, шомлы дөнья.

Кояшы кызарып байый, бакалары сагаеп кычкыра, кошлары хәвефләнеп сызгыра.

Әллә ничә мәртәбә: «Абый, борылыйк, кайтыйк, иртәгә килербез», — дип әйтергә ниятләдем. Тик телем әйләнмәде. Ни генә дисәң дә, разведкага барабыз бит. Хәер, әйтсәм дә тыңламас иде абый. «Хәрби» мәсьәләләрдә бик үҗәт ул. Үзе әйтмешли, таш яуса да, «приказ»ны үтәргә тырыша. Приказ бирүчесе дә үзе инде югыйсә...

Манма тиргә төшеп, ялт та йолт әле бер, әле икенче якка караштыргалап бара торгач, коры җиргә аяк басканымны сизми дә калдым. Әнкәчем, мондагы үләннең биеклеген күрсәң! Мондагы куакларның тыгызлыгын, тулылыгын күрсәң! Үзләре әллә нинди үрмәле, чәнечкеле сабаклар белән чорналып беткәннәр, ә үзләре, шул сабаклар әсирлегеннән котылырга теләгәндәй, югарыга омтылып үскәннәр.

Баш очында усак яфраклары вак тәңкәләр сыман челтери. Җил йөгереп узган саен, арыш кырыдай тип-тигез, тапталмаган алан өстеннән кара-кучкыл дулкыннар бөтерелеп уза да, уйдык-уйдык аллы-гөлле чәчәкләр җемелдәшә. Кая китте соң әле абый?

— Абый!

Очы кызгылт нурда коенып утырган чикләвек куагы төбеннән кепкалы баш калыкты. Иреннәре, иякләре, борыннары кып-кызыл.

— Җиләк! — дип, бер генә сүз әйтте дә кызыл иренле баш янә, җилдә сибелгән үләннәр арасына чумып, юк булды.

Шул якка таба берничә адым атлагач, мин дә үлән төбенә чүгәләдем. Әнкәчем! Җиләк, җиләк, җиләк! Җыярга да куркыныч иде бу кадәр эре, бу кадәр күп җиләкне, ашарга да. Абыйның тамагыннан ничек үтә торгандыр!

Дию яисә сихерче карчык яши торгандыр бу атауда. Шуларның берсе алдап китергәндер безне монда. Китергәндер дә, менә хәзер җиләк белән алдап, безне адаштырырга тели торгандыр... Куллар калтырый. Җиләкләре дә учка сыймый бит аның, ичмасам. Учка сыйганнарын да авызга туры китереп булмый. Әйтәм абыйның бөтен бите кызылга буялган. Ул да җиләкләрне авызына туры китерә алмыйча интегә торгандыр, күрәсең.

Таптарга ярый микән соң мондагы үләнне, ашарга ярый микән җиләкне? Башка бертуктаусыз шундый со-

раулар килә. Печән арасында бөркү. Кояш усаклар артына кереп яшеренгәч, алан өстенә күләгә җәелде. Әллә нинди, бөтен тәнне чемер-чемер китерә торган сәер күләгә...

Авызга учлап-учлап җиләк тутырам, тәмен сизмим... Бу саесканга ни кирәк инде тагын? Монда алар, монда! Печән таптыйлар, җиләк урлыйлар дигәндәй, коточкыч гауга куптарды.

Абый да, мин дә үләннәр арасыннан берьюлы диярлек башларыбызны калкыттык. Кояш югалгач, карасу-күгелҗем төскә кергән алан күңелсезләнеп калган. Куакларның да очлары гына яшел, калган төшләре карасу-соры төскә манчылган. Саескан үзе күренми, әмма шомланып тыкырдавы бөтен тирә-якны яңгырата. Мин авызымдагы изелгән җиләкне көч-хәл белән йотып җибәрдем дә абыйга карадым. Ул миңа карамый, кояш төшеп киткән якка, еландай бормалана-бормалана олы урманга таба сузылган ермакка — Тирән Чокырга текәлеп каткан. Мин дә карашымны шул якка юнәлттем һәм... «әни» дип кычкырудан чак кына тыелып калдым.

Тәнем бер туңды, бер кызышты. Тез буыннарым сыегаеп, җиргә чүктем.

Бозаунык чаклы башын авыл ягына борыбрак нәрсәдер иснәгәндәй, Тирән Чокырга төшә торган сыртның нәкъ түбәсендә сын кебек хәрәкәтсез басып торган җанварның Каратамак бүресе булуында шик юк иде. Безне күрде микән ул, сизде микән? Хикмәт әнә шунда иде хәзер. Абый, бүредән күзен алмыйча гына, арт белән чигенә-чигенә, минем янга килде, бармакларын сукыр кеше кебек кыймыл-кыймыл китереп, минем кулны эзләп тапты, чытырдатып кысып алды һәм мине куак артына сөйрәде. Икебезнең дә кулларыбыз калтырый иде. Бүредән күзләребезне алмыйча чигенә торгач, икебез дә берьюлы сөртенеп киттек, ләкин егылмадык. Әле дә ярый, сазлыктан чыккач, чалбарны киеп куйган идек...

Сыртны куак ябалдашлары томалагач, абый минем кулны тагын да ныграк кысып тотты һәм, җиләккә буялган иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып:

— Калма! — диде.

Кайда инде ул калу! Абыйның үзен сөйрәп йөгердем бугай әле хәтта. Аяклар тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк! Су читенә килеп җиткәч кенә, алга чыкты абый. Суга керер алдыннан, тагын бер мәртәбә артыбызга борылып карадык та муртайган усаклар арасыннан сазлыкка томырылдык. Алдан абый йөгерә. Аннан бер адым да артка калмаска тырышып — мин. Сырт ягына күз са-

лып аласы килә — куркыныч. Кай урында тубыктан гына су, кай урында билгә менеп җитә яза. Анысы, муенга менеп җитсә дә, туктады юк инде. Бүре генә куып җитмәсен арттан.

Шул рәвешчә бата-чума, шапыр-шопыр байтак йөгергәннән соң, су саекты, һәм озакламый без коры җиргә аяк бастык. Аптыраган кыяфәт белән бер-беребезгә, аннары әйләнә-тирәбезгә карадык. Чү инде! Каратамак сазлыгын буйдан-буйга йөгереп үткәнбез түгелме соң без?! Әнә кайда ук калган кәкре каен, әнә куш карама. Карамага карамаганбыз да хәтта. Ничек батмадык икән, ничек төпкә суырмады икән безне сазлык? Менә сиңа пәрәмәч — уртасында бер калач! Хәер, абый артык гаҗәпләнмәде бу тамашага. Мөгаен, тәпи-тәпи беренче генә кичүе түгелдер сазлыкны аның. Югыйсә шулкадәр ышанып кереп китә димени кеше дегет кебек кап-кара дәрьяга?! Бүредән курыктым дигәч тә, ул кадәр...

— Күрдеңме? — диде абый, ярга чыгып егылгач, сулышын еш-еш алып.

Ике куркыныч турында берьюлы уйлаганга, мин авыз ачып сүз әйтерлек хәлдә түгел идем. «Ие» дигән мәгънәне аңлатып, башымны гына селектем.

— Каратамак бүресе! Күрдеңме муенындагы акны?

Мин, әле генә үзебез йөгереп үткән хәтәр сазлыкның теге ягында менә шундый инде мин дигәндәй вәкарь катыш горурлык белән кукраеп утырган усак урманына текәлеп:

— Хәрби сер чишелде, — дидем.

— Ниткән хәрби сер? — дип сорады абый, бүре турындагы сүзләренә илтифат итмәвем өчен үпкәләгән шикеллерәк.

— Каратамак сазлыгы суырмады ич безне, тубыктан гына икән бит Каратамак.

— Котың ботыңа җитсә, диңгез дә тубыктан була, акыллым, — диде абый, сер бирергә теләмичә. — Әллә оныттыңмы, сөзгәк Чурнук куып килгәндә, озын Гариф шопшома телеграм баганасына ничек җайлы гына менеп китте. Күн итек белән бит әле. Ул төшкәч, Әптәзәр, Хәсәннәр, Бәхтиярлар яланаяк килеш тырышып карадылар шул баганага менәргә. Менәлделәрме соң? Менәлмәделәр. Берсе дә менәлмәде. «Ничек мендең?» — дип сораган кешеләргә Гариф абый үзе дә: «Белмим, әллә тагы... Һушыма килгәндә, багана башында утыра идем», — дип җавап биргән, диләр.

Абый китергән мисал, чынлап та, уйланырлык иде. Кем белә, шәт, без су өстеннән генә йөгереп үткәнбездер. Безнең аяклар бөтенләй дә су төбенә тимәгәндер, шәт.

Алай дисәң, чалбарлар лычма су, аяк битләре камышларга киселеп беткән.

Сазлык турындагы уйларым ирексездән бүрегә барып ялганды. Сөзәк тау астында зәңгәр эңгергә төренеп авыл күренеп торганда, куркыныч түгел иде инде хәзер ул бүре безгә. Ак маңгайлы бүре булмагандыр ла ул. Азрак төтен җибәрә торгандыр абый. Ул безнең якка карамады ла, маңгаен күрергә. Мин эчемнән генә шулай фикер йөртсәм дә, уйларымны абыйга сиздермәдем. Булсын, әйдә, ак маңгайлы бүре булсын! Аннан кемгә зыян. «Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин» дигәндәй, без уйлап чыгарган бүре түгел лә ул...

Бу вакыйгадан соң без, тагын Каратамак сазлыгын кичеп, әллә ничә мәртәбә кердек Каратамак атавына. Әмма кергән саен яшерен юлдан, ягъни куш карама кәүсәсе буйлап кәкре каенга, кәкре каеннан коры түмгәккә... Кайтканда да шулай.

Каратамак бүресенә килгәндә, башка очрамады ул безгә, бүтән малайларның да күргәннәре ишетелмәде. Өлкәннәрнең: «Эт булгандыр ла ул, ялгыш күргәнсездер», — дип, сүзебезне шик астына алуларына бөртек тә үпкәләмәдек без. Курыкканга куш күренә, диләр ич, бәлки, чынлап та, эт булгандыр әле ул. Эт булса, бигрәк тә яхшы. Каратамак атавына җиләккә яисә чикләвеккә кергәч, куак кыштырдаган саен, тирә-ягыңа алан-йолан каранмыйсың...

Без абый белән шулай сөйләшәбез дә соң... Тик бозау чаклы теге җанвар һаман тора бит күз алдында. Маңгаенда агы булдымы икән соң аның? Әллә абыйга баеп барган кояш нурында гына шулай агарып күренгәнме аның маңгае?

Авыл картлары болай сөйлиләр. Имештер, Сангар алпавыты Филипсонның ау этләре бик тә затлы нәселдән булган. Илдә революция җилләре исә башлагач, Филипсон аларның кайберләрен саткан, кайберләрен таныш-белешләренә бүләк итеп биргән. Ә берсен, сунарга чыккач, теләсә нинди йөгерек җәнлекне куып тотып, ботарламыйнитми генә хуҗасына алып килеп бирергә гадәтләнгәнен, чит илгә качканда, үзе белән алып китәргә ниятләгән.

Этнең чын исеме ничек булгандыр, алпавыт утары Сангарда ничек атап йөрткәннәрдер аны, анысын берәү дә хәтерләми, әмма безнең авыл кешеләре, олысыннан кечесенә кадәр, маңгаенда нәни генә ак йолдызчыгы булганга, Филипсонның яраткан этенә Акмаңгай дип эндәшкәннәр. Монысын авыл картлары бик яхшы хәтерли. Картлар тагын бер вакыйганы бик тәфсилләп сөйләргә яраталар.

Күрше авыл малайлары алпавытның күченеп китәсен ишетәләр дә, анда хәзер алма кайгысы түгелдер, безгә дә хәрам булмас буржуй алмасы дип, бер кичне утар бакчасына төшәләр. Ләкин, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, Филипсонның нәкъ бакчасы белән хушлашып йөргән чагы икән. Бакчада кеше барын сизеп, алпавыт управляющие Акмаңгайны өстереп җибәргән. Аю чаклы Акмаңгай җил уйнатып, һау-һаулап атылып барган да куркуларыннан тораташ булып каткан малайларның әле берсен, әле икенчесен иснәп чыккан һәм, монда бернинди дә җәнлек юк ич дигәндәй, яңадан хуҗалары янына йөгереп килгән. Филипсон управляющий кулындагы чыбыркыны тартып алган һәм: «Әле син дә шул бетле каргалар яклымы, әле син дә хыянәт итәсеңме миңа?!» — дия-дия, Акмаңгайны чыбыркы белән чаж да чож ярырга керешкән. Малайлар бакчаның теге ягындагы әрәмәлектән карап торганнар. Акмаңгай чыбыркыдан куркып качып китмәгән. Бары тик, җиргә ятып, олы гәүдәсе белән кура җиләге куакларын изә-изә, ауный-ауный шыңшыган-елаган гына.

Иртәгесен, китәр сәгате җиткәч, Акмаңгайны таптыра башлаган Филипсон — юк теге. Бөтен утарны күтәреп эзлиләр, чакыралар, сызгыралар, ыгы-зыгы киләләр — юк Акмаңгай.

Шуннан нишләсен, Акмаңгайсыз гына китәргә мәҗбүр булган инде Филипсон.

Соңрак, революция давыллары шаулап узгач, шәрә кыр уртасында караеп торган ялгыз утар хәрабәләре урынында ак яулыклы карабодайлар, ал бүрекле тукранбашлар йөгереп уйнаган җәйләрнең берсендә, урман каравылчысы Мирхәт Акмаңгайны бүре көтүе башында күргән. Муенын сузып, башын һәм койрыгын югары чөеп, колакларын уйнатып бара, ди, шулай, аның артындагы бүреләр моның гайрәте, моның бәдәне, моның кыяфәте янында йолкыш көчекләр кебек кенә күренәләр, ди.

Шуннан соң әллә кайсы елларның зәмһәрир җилле, чытырман суык кышларында әллә кем абзыйларга, әллә кем апаларга Чагын тегермәне тавында, Соры урманында яисә Ишгилде болынында ак маңгайлы бүреләр очраштыргалаган.

Тегермән тавында таш карьеры ачылып, җир, известь катламнары гөрс тә гөрс һавага оча башлагач, җәнлек-җанварлар, кош-кортлар безнең якларны ташлап киткәннәр. Бүреләр генә түгел, кырларда сукыр тычканнар да беткән. Каратамак сазлыгында хәтта бакалар да тынган... Аннары сугыш.

Сугыш вакытында бүреләр күрше район авылларының сарыкларын гына түгел, этләрен дә күтәреп киткәләделәр. Ә безнең төбәктә, көтүдән адашып калган хәлсез, авыру бәрәннәрне исәпләмәгәндә, ник бер генә терлекне ботарласын бүре.

Этләр инде, этләр. Нурлыгаян әби әйтмешли, пан булып яшәделәр этләр. Бүредән курыккан эт өч көн өрә, диләр бит. Ә безнең төбәк этләре һич тә юкка-барга өрмиләр иде. Кояш баегач та, рәхәтләнеп авыл башына чыгып йөриләр, капка төпләрендә бөгәрләнеп төн уздыралар яисә, таң атканчы, ферма артында шытыр-шытыр сөяк кимереп яталар.

Сугыш чоры бүреләре тарафыннан безнең төбәк этләренә бирелгән мондый хөрриятне авыл кешеләре Акмаңгайдан гына күрәләр иде. Шуның нәселе, затлы нәсел, ачка үлсә үләр, туган ягына зыян-зәүрәт салмас, дип сөйләшәләр иде картлар, бергә җыелгач.

Сугыштан соң бик күп бүреләрне кырдылар безнең якларда. Җәяү дә, машиналарга утырып та, хәтта самолет белән бүре көтүенең өстенә үк очып кунып та кырдылар аларны. Әмма бүреләрнең тереләре арасында да, үлеләре арасында да ак маңгайлысын күрүче булмады шикелле. Һәрхәлдә, мин ишетмәдем.

Аннары авылларга техника кайта башлады.

Очлары болытларга тигән тимер баганалар тезеп, электр кертүчеләр узды.

Берәр асыл нәрсә табылмасмы икән дип, җирнең һәр «кесәсен» капшап, геологлар узды.

Без бала чакта соклану катыш курку белән карап йөри торган җәнлек-җанвар сукмаклары өстеннән, бөтен тирә-юньгә мазут, дегет, ташкүмер исләре аңкытып, чуен юл сузылды.

Кая монда Каратамак кайгысы, кая монда бүре кайгысы! Хәер, чылбыр белән бәйләп куйсаң да түзмәс иде бүре мондый шау-шуга, мондый ыгы-зыгыга.

Әгәр бүген бик тә сәер төш күрмәсәм, мин дә хәтер чоңгылларыннан актарып чыгармаган булыр идем, мөгаен, онытып бетерә язган вакыйгаларны.

Ә төш болай иде.

Сугыш вакыты, имеш. Һавада самолетлар гүләп оча. Юл буйларында кисәү башлары пыскый. Миңа Каратамак капкасын сакларга кушканнар икән. Торам, имеш, мылтык тотып сакта. Шунда берәү абый тавышы белән:

— Внимание, товарищи! — дип кычкырмасынмы.

Карасам, каршыма дошман солдаты килә. Иңендә агач мылтык, билендә чыра кылыч. Кулындагы гранатасы гы-

на чын бугай. Күзләрен Каратамак бакалары сыман шарландырган.

Мин карама артыннан чыктым да моның юлына аркылы төштем.

— Стой, — мин әйтәм, — кая юл тотасың?

— Фюрер приказын үтәргә! — ди, күзләрен дә йоммый, мөртәт.

— Нинди приказны? — мин әйтәм.

— Акмаңгай һәйкәлен шартлатырга, — ди.

Үзем Акмаңгайга һәйкәл куелганын һич кенә дә хәтерли алмыйм, шулай да сер бирергә исәп юк.

— Ул һәйкәлне шартлатырга ярамый, архитектура истәлеге бит ул, — мин әйтәм.

— Алпавыт этеме? — дип көлә, имеш, бу.

— Булса соң! — дим моңа. — Алпавыт үзе качса да, эте калды.

— Бүрегә әйләнгән этме? — ди бу, тагын мине мыскыл итмәкче.

— Киресенчә, — мин әйтәм, — аның белән бергә йөргән бүреләр эт кебек акыллыланып беттеләр. Каратамак бүреләре барысы да Акмаңгай нәселеннән. Берсенең бер зарар салганы юк халыкка.

Шунда кулындагы гранатасын кесәсенә тыгып куйды да бу, кочагын җәеп, минем өскә килә башлады. Күрми дә торганмын: иягендә күсе колагы кадәр генә очлы сакалы да бар икән хәсиснең.

— Әллә танымыйсыңмы? Мин Сангар алпавыты Филипсон бит, — ди.

— Ник кайттың? — мин әйтәм. Дошман солдатыннан курыкмаган идем, ә Филипсон ни өчендер куркыта. Акрын-акрын карама кәүсәсенә елышам.

— Чит җирнең ашлы туфрагы да ташлы, туган җиремне сагынып кайттым, — ди. — Акмаңгай белән бергә бүреләр арасына качасым калган икән аны теге заманда. Иту бу кадәр кыен булмас иде, — ди.

Моның йөзе кинәт агарынып китте, шарланган күзләре минем җилкәм аша Каратамак сазлыгына текәлде. Мин дә ихтыярсыз шул якка карадым: кояш нурлары белән яктыртылган сырт өстендә, колакларын тырпайтып, безнең якка борылыбрак бозау кадәр бүре басып тора иде. Маңгаендагы ак табы гаҗәп түгел. Ә менә ни өчен аның муенында кызыл шарф?

Филипсоннан шул хакта сорарга авыз ачкан идем, ул үзе, күсе колагына охшаган сакалын чәнти бармагы белән сыйпаштыргалап, газета сүзләре белән сөйләргә керешге:

— Кызыл китапка кертелгән. Әйе, без икебез дә — мин дә, ул да, — Филипсон җилгә каршы очкан карга канаты каурыйлары сыман озын бармакларын тау сыртында хәрәкәтсез торган җанварга таба суздыы, — без икебез дә сирәк очрый торган экземплярлар, без икебез дә Кызыл китапка кертелгән.

Карасам: Филипсон муенында да кызыл шарф.

Шунда уянып киттем. Радио сөйләп тора, ачык форточкадан машиналар гөрелтесе, шәһәр шау-шуы ургылып керә.

Бөтен тәнем шабыр тир. Кан басымым да күтәрелгән бугай: йөрәк, бер цилиндры сафтан чыккан мотор сыман, озын-озын тәнәфесләр ясап тибә.

Фу, шайтан алгыры! Нинди әкәмәт төш булды соң әле бу?

Кызык, ничә ел булды икән инде туган якларга кайтмаганга? Ни хәлләрдә икән хәзер Каратамак сазлыгы? Беткәндер әллә кайчан, астын өскә китереп, кукуруз чәчкәннәрдер инде. Мин килгәндә, бу якларда да никадәрле яшел сазлыклар, камышлы күлләр бар иде бит. Хәзер берсе дә юк. Бөтен җирдә дегетле тимер баганалар да салкын бетон стеналар. Койма буйларында кычыткан да үсми, ичмасам. Төтендә ысланган, корымда каралган чыпчыклар гына тимер-бетон шаукымына бирешергә теләмиләр. Яз килдеме, телеграф чыбыкларына тезеләләр дә, кайчандыр әле скрипка кылларыдай зеңләгән, әле көмеш шөлдерләрдәй челтерәгән сихри аһәңнәр — тургай моңнары белән мөлдерәмә тулып торган, ә хәзер ак мамык болытларын бик югары күтәреп, тынып, бушап калган күк гөмбәзенә күз аткалап, үзара нәрсә турындадыр салкын гына чыркылдашалар, көлү тәмен оныткан бәхетсез кешеләр шикелле җитди генә сөйләшәләр. Хәер, без күреп үскән чыпчыклар түгел шул инде болар. Болар — шәһәр чыпчыклары. Төзелешнең икенче ягыннан бакча ясап киләләр инде килүен. Ләкин гөлләре нинди генә матур булса да, ул бакча өстендә тургайлар тирбәнеп тормас шул инде. Тургай ул иркен басуларны, иксез-чиксез иген кырларын, яшел атласы тапталмаган үзәннәрне ярата.

Бер яманның бер яхшысы була дигәндәй, аның каравы теләгән җиреңә күз ачып йомганчы барып җитәсең хәзер. Теләсәң — поездга утыр, теләсәң — пароходка, теләсәң — самолетка.

Теге төш тәмам алгысыткан иде мине. Шуңа күрә самолет белән кайттым туган якларга...

Мин таный торган агачларның күбесе юк икән инде. Йортларның да күбесе таныйрлык түгел. Калай, шифер

түбәләр, алты почмаклы нарат йортлар, телевизор антенналары, мотоцикллар, машиналар. Бакчаларда алмагач, чия, кура җиләге. Кайчандыр алгы сызыкта мәйдан тоткан үлемсез бәрәңге, лаеклы ялга чыккан ветерандай, чәчәк түтәлләре камалышында калган.

Җизни, яңа трактор алырга, Белоруссиягә киткән икән. Юлдан соң юынып, ашап-эчеп алгач, эшеннән сорап кайткан дәү ападан авыл хәлләрен сораштырдым. Бераздан, сүз иярә сүз чыгып, әңгәмәбез, үзебезгә дә сизелмичә, Каратамакка борылды. Дәү апа ялындырып тормады, белгәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Кама күтәрелгәч, су астында калыр, дигәннәр иде, калмады. Башка сазлыклар кебек кипмәде дә. Киптереп көтүлек ясыйбыз дип йөргәннәр иде берчакны. Хәтерлисеңдер, ул елны син дә кайткан идең. Себер төзелешләренә китәр алдыннан. Әле председатель белән даулашып та йөрдең, авылның яме ул Каратамак, сандугачлар шәһәре, тимәгез аңа, дип... Син әйткәнгә карамадылар, билгеле. Берничә ел шунда машиналар, тракторлар белән дөбершатыр мәш килделәр. Әле берсе: «Олы юл салам мин сезнең Каратамагыгыз аша», — дип җилләнеп кереп киткән дә бульдозеры белән батты. Тракторчысын эзләп таптылар. Тракторы әле һаман да шунда, сазлык төбендә ята, ди. Шуннан бирле машина-фәлән кергәне юк сазлыкка. Аннары Фразый, Гыймади абыең малае, агрономлыкка укып кайткач, корылык елны Каратамак тирәюньдәге басуларга дым биреп тора, үзебез дә тимибез, башкаларга да тидерттермибез, дип, мәсьәләне район күләмендә күтәреп чыкты. Хәзер Каратамакка пионерлар хуҗа.

— Пионерлар?

— Ие. Үзләренчә каравылда торган булалар шунда.

— Нәрсә каравыллыйлар соң алар?

— Агачларны, кош-кортларны. Колхоз заповедниги дип йөриләр хәзер Каратамак атавын. Бөтен көннәре Шәмгун белән көрәшеп үтә.

— Кайсы Шәмгун?

— Идрис Шәмгуны соң. Укытучылар килсә, колхозда эшлим ич, бригадир килсә, укыйм ич мин, дип җавап бирә торган Шәмгун. Укуының да рәте булмады, эшләп тә кинәндермәде колхозны. Ауга йөри. Мылтыгы бар. Әле күптән түгел генә ак маңгайлы бүре аткан, дип сөйләделәр.

— Ак маңгайлы бүре?

— Ие шул, әллә ялган, әллә чын, синең ишеткәнең бар ич инде алпавыт эте нәселеннән килгән ак маңгайлы бүреләр, Каратамак бүреләре турында. Колхоз запо-

веднигыннан аткансың, дип, дружина советларына, башкарма комитетларга чакыртып йөрделәр үзен.

— Ак маңгайлы булганмы соң чынлап та Шәмгун аткан бүре?

— Кем белә инде аны, кешегә-карага күрсәтмәгән бугай ул аның тиресен, каядыр аткарган бугай...

Шәмгун! Шәмгунны хәтерләмәскә! Хәтерлим. Бик яхшы хәтерлим Шәмгунны.

Бәләкәй чагымда шулай беркөнне йокымнан карга тавышына уянып киттем. Тилмереп, ачыргаланып һәм шул ук вакытта буылып-буылып кычкыра иде карга. Якты ишегалдына йөгереп чыктым да тирә-якка күз салдым. Карасам — Шәмгуннар бакчасында озын колга. Колга башында исә аякларыннан мунчала белән карга баласы асып куелган. Мескен кош, ара-тирә хәлсезләнгән канатларын җилпештергәләп, җан ачысы белән ярдәм сорап кычкыра да, арып, алҗып, дәрманы бетеп, тагын хәрәкәтсез кала. Әткә карга белән әнкә карга, ничек коткарыйк соң, кулларыбыз юк бит безнең дигән шикелле, хәвефләнеп, борчылып, хәсрәтләнеп бөтен җиһанга аваз сала-сала, колга тирәсендә очып йөриләр, әле өскә күтәреләләр, әле, җиргә үк төшеп, ыгы-зыгы киләләр.

Киртә өстеннән генә сикереп төштем дә колганы акрын гына бәрәңге буразнасына аудардым, баштүбән асылынып торганлыктан, түгәрәк, мөлдер күзләренә кан сауган карга баласының аякларын чиштем. Бер аягы каерылган да бугай, ахры — басарга омтылуы булды, бөтен тәне тартышып, буразна арасына тәгәрәп төште. Бераз хәл алгач, тернәкләнде тагын үзе. Әткә карга белән әнкә карга бакча өстеннән очып әйләнүгә, кыр-ра, дип, миңа рәхмәт әйтте дә, канатларын җилпеп, һавага күтәрелде. Каргаларның да больницалары бардыр, шәт, авырткан аягын шунда дәвалар әле дигән сабый өмете белән юанып озатып калдым мин карга баласын.

Бераздан бакчага, күзләрен челәйтеп, Шәмгун йөгереп чыкты.

— Нигә тиясең кеше әйберенә, карак, — дип кычкырды.

— Ә син кошларны рәнҗетмә, — дидем мин, күз яшьләремне күрсәтмәс өчен читкә борылып.

Аннары мәктәп янындагы койма артыннан Гайшә әби тавышы ишетелде:

— Алай кансыз булма, Шәмгун улым, кеше ярдәменә мохтаҗ җан ияләре бит кошлар, каргышларыннан курыкмасаң, бәндәдән оялыр идең.

Гайшә әби сүзләреннән, чынлап та, оялды бугай Шәмгун.

— Мин аны тилгән куркытырга аскан идем, әни бәбкә сакларга кушып китте, — дип, чебиле аякларына карады.

Чыннан да, каргалар каргышы төштеме, әллә бүтән сәбәпме, ни генә булса да, ул елны Шәмгуннарның бер генә бәбкәләре дә каз булып үсеп җитмәде. Кайсы чирләп үлде шунда, кайсын тилгән алды, кайсыберләре Каратамак сазлыгына кереп юкка чыкты.

Инде күп еллар үтеп, Шәмгунның ул чактагы кансызлыгы онытылган иде. Аннан соң бала чакта бергә уйнап үскән дус-ишләрне күрәсе килү теләге биләп алды күңелне — дәү апа фермага киткәч, өс-башымны алыштырдым да Шәмгуннарга кердем.

Лапас астында куян тиреләре белән мәш килә иде Шәмгун. Әле берсен, әле икенчесен лапас почмагындагы ярыкка куеп карый, мине күрми, авыз эченнән генә ниндидер җыр көйләп маташа, әмма яңа тирегә иелгән саен, көе өзелеп, салынкы иреннәре арасыннан юеш пыяланы бармак белән ышкыганда чыга торган тавышка охшаганрак шыгырдавык авазлар гына коела. Ниһаять, ул мине шәйләде. Кулына ала башлаган тирене кире ташлады, тураеп миңа текәлде. Йөзенбитен төк, маңгаен, күз тирәләрен җыерчык баскан. Мин дә үзгәргәнмендер, күрәсең, аны-моны дәшмичә, минем йөзгә озак карап торды Шәмгун. Мин түзмәдем, тиреләре яныннан кузгалырга теләмәгән Шәмгунга үзем барып кул суздым. Күрештек. Гадәти тәкбирләр белән хәл-әхвәл сорашкач, мин, сүз юктан сүз булсын дигән кебегрәк:

— Эштә түгелмени? — дип сорадым.

Шәмгун авызын ачмыйча гына елмайды, такта өстендә яткан тире күченә ымлап:

— Эшлим ич менә! — диде.

— Колхозда эшләмисеңмени?

— Колхозда? — дип, кесәсеннән тәмәкесен чыгарды Шәмгун. — Колхозда механизаторларга гына хәзер эш. Механизаторлар өлгерә алмаса, шәһәрдән кайталар булышырга. Былтыр урак өстендә сиксән кеше кайтты, бәрәңге алырга да йөздән артык студент җибәрделәр. Тартасыңмы? Өйгә кереп утырыйк, дияр идем, вакытың юктыр.

— Вакыт юграк шул, — дидем мин, төп сүзгә күчәргә җай чыкканга сөенеп. — Синнән шуны сорармын дигән идем — быел син Каратамакта бүре аткансың икән. Сөйлә әле, нинди бүре иде ул?

Шәмгунның чырае сытылды, төк баскан яңаклары тартышып куйды.

— Бүре генә булмады инде ул, арыслан булды, — дип, караңгыланган йөзен тәмәке төтене белән урады ул. — Беренчедән, Каратамактан атмадым мин аны, олы урман-

нан аттым, икенчедән, маңгаенда ак табы да, күк табы да юк иде аның, өченчедән, эт еккырлары, минем нинди бүре атуда кемнең нинди эше бар? Мылтык тотарга хокукым бармы? Бар! Сунарчылык җәмгыяте кайчан, нинди җанварны атарга рөхсәт бирәме? Бирә!

— Мин сине гаепләргә килмәдем ич, авылдаш, — дидем мин, Шәмгунның тиктомалдан шулай кызып китүен ничек юрарга да белмичә.

— Йөриләр монда юкка вакыт уздырып, аяк киеме туздырып, — диде Шәмгун, дорфа кылануы өчен аклангандай тавышын йомшарта төшеп, — авыл җирендә заповедниклар ясаган булып, кыланып... Заповедник түгел ул, җәфабитник, карга оясы. Бер аксак куяннары бар, эт еккыры. Сиңа нигә сөйләп утырам соң әле боларны. Кайткансың икән раз, үз күзләрең белән барып кара.

— Анысы качмас. Мине бүре кызыксындыра. Ниндирәк бүре иде ул, шулай да?

— Ана бүре. Каратамак артындагы урманда аттым мин аны. Беренче атуда тидерә алмадым. Тимәгәнен үзем дә күрдем. Ә теге хитруш нишләде? Мылтык тавышы ишетелүгә, сузылды да ятты җиргә. Тимәгәнен беләм бит инде, үз күзләрем белән күрдем юкса. Шулай да мылтыкны яңадан корырга ашыкмыйм, барам әкрен генә моңа таба. Шунда сикереп тормасынмы бу. Сикереп тә торды, мин мылтык корганчы, син күр дә мин күр — әллүр әрәмәлеккә!

Ә мин, мин хәйләгә килгәндә, шайтанның үзеннән дә уздырам. Иртән үк күргән идем чирәмдә мин моның эзләрен. Урман ягыннан Каратамакка ермак уелып керә бит әле. Менә шунда, — Шәмгунның эчкә баткан күзләре очкынланып китте, — тар гына сукмак бар. Башка бер генә җәнлек тә йөрмәгән. Бүреләр генә такырлап бетергән. Иртә белән Каратамактан киткән эзе бар моның, ә кайтканы — юк. Димәк, иртәме-соңмы шул сукмактан кайтырга тиеш. Дөрес, кешедән курыккан бүре өнен әллә ничә чакрымнан урап-урап йөри. Ахырдан, өнендә балалары булса, барыбер кайта, барыбер кайтмый түзәлми. Шул менә. Значытсы, мин засадыга кереп яттым. Өстә яшел кием, мылтык та яшел ситсыга уралган. Минем бәхеткә, җил бүре кайтасы яктан исә. Ятам шулай керфек тә какмыйча, ятам. Берзаманны күземә күренәме әллә дип торам, нәкъ каршымда пәйда булды бу, маңгаенда... — Шәмгун кинәт кенә тотлыгып калды, аскы иреннәрен тешләп, кулындагы тәмәке төпчегенә текәлеп торды.

— Йә, йә? — дидем мин түземсезләнеп.

— Шуннан маңгаена төзәдем дә мин моның, ипләп кенә гөрселдәттем.

— Аннары заготконторага илтеп күрсәттеңме?

— Юк, тиресен генә салдырып алдым.

— Нишләп илтеп күрсәтмәдең? Бүре аткан өчен бүләк бирәләр ич.

— Мәшәкатьләнеп йөрмәдем. Наратлыда бүрек тегүче танышым бар минем. Шул сораган иде тиресен, шуңа бирдем.

— Ә нишләп ак маңгайлы бүре аткансың дип бәйләнделәр соң сиңа?

— Миңа башта, чынлап та, аның маңгаенда ак табы бар сыман күренгән иде. Авыл кешеләренә дә шулай сөйләп йөрдем.

— Аннары?

— Кычытмаган җирне кашып йөрүче эшсез адәмнәр кәнсәләргә чакыртып допрос ала башлагач, исемә төште аннары: маңгаенда ак тап та, күк тап та юк иде аның... Өйгә кереп утырыйк, ник монда гына сүләшеп торабыз соң?

Мин рәхмәт әйттем.

Шулчак, бакча рәшәткәләренә сырышып диярлек, озын торыклы, салпы колаклы ала эт йөгереп үтте. Имчәкләренең җиргә тияр-тимәс чайкалып баруыннан абайладым — һичшиксез, яшь көчекләре янына ашыга иде бу алабай (соңыннан белдем: исеме дә Алабай икән). Шәмгун да игътибар итте этко.

Башта:

— Алабай, Алабай, маһ, маһ, — дип кычкырды. Алабай әйләнеп карамагач: — Һәй, әрәмтамак! Тончыкмадың да, — дип, күз ачып йомганчы карлыганнар арасына кереп югалган эт артыннан утын пүләне атып калды.

— Көчекләре бармыни? — дип сорадым мин, бакчаның Алабай китеп югалган ягына ымлап.

— Балаларын күптән тончыктырдым инде, — диде Шәмгун һаваланыбрак. — Кирәк бит, ау сезоны җиткәч балалады. Болай да кәеф китеп йөри иде. Бишесен тиң үрдәк җәдрәсе белән капладым. Эт диген син аны. Үпкәләде шуннан соң миңа. Ауга йөрергә теләми минем белән. Әле тегендә посып кала, әле монда. Чакыргач та килми. Малай яклый, малай якламаса, җанын күптән җәһәннәмгә җибәрәсе идем әрәмтамакның.

Шәмгунның сөйләгәнен башка бер генә минут та тыңлый алмас дәрәҗәгә җиттем һәм тиз-тиз саубуллаша башладым.

— Каратамактан кыр тавыгы атып кайтсак, рәхәтләнеп сыйланыр идек, — диде Шәмгун, минем хушлашу сүзләрен бөтенләй ишетмәгәндәй, — теге фетнәләр керт-

миләр. Сиңа керергә ярый, син — кунак. Мылтыгы булмаса, кунакларны кертәләр. Мин сиңа аксак куян гына бар Каратамак утравында, дидем. Аксак куян гына түгел, тагын нәрсәдер бар анда. — Шәмгунның маңгай җыерчыклары ишәеп, йөзе көн бозылыр алдыннан шадраланган су өстенә охшап калды. — Әйдә болай итәбез. Син бүген разведка ясап кайт: нәрсәләр бар, нәрсәләр юк, оялары кайда, ничегрәк барасы и таки дали. Таң сызылгач ук, урман ягыннан әйләнеп керәбез дә җаныбыз теләгән киекне чүпләп чыгабыз. Теге юеш танаулар уянганчы, ай күрде, кояш алды булыр безне.

— Юк, — дидем мин һәм, Шәмгунның тәкъдименнән котылыр өчен, тезәргә керештем: — Бер-ике көнгә генә кайттым мин. Әле авылдашларны да күрәсем бар, колхоз хәлләре белән дә танышмаган, җизнигә йорт эшләрендә дә булышырга кирәк. Ярый, Шәмгун, хуш, киткәнче күрешмәсәк, бигайбә.

Төпләре дегеткә буялган имән баганалы капканы каерып ачкач, битемә саф җил килеп сырышты, каршыдагы бакчалардан яфраклар алкышы ишетелде.

Каратамак буена бик барасым килсә дә бармадым мин ул көнне. Идарәдән урап кайттым. Ләкин анда беркем дә юк, халык печәндә иде.

Дәү апаларның ишегалдында ничә елдан бирледер ярылмыйча яткан ботаклы имән тумраннарын ярып ыргыттым, әле карлар киткәч кенә бәрәнләгән сарыкка яшь печән чабып алып кайтып ашаттым. Каратамак турында да, Шәмгун турында да уйламаска тырыштым.

Кичтән мунча кереп, соң гына ятканлыктан, йоклап калырмын дип курыккан идем. Ләкин, шөкер, кошлар белән бергә уяндым. Дәү апа сыер сава бугай — ачык тәрәзәдән иртәнге саф һавага кушылып, җылы сөт исе сөзелеп керә, чиләк читенә бәрелеп сөт тамчылары зеңгелди.

Мич буендагы бәләкәй караватта дәү апаның төпчек кызы Гөлгенә йоклап ята. Аның юрган читеннән чыгып торган алсу тәпиенә елышып мыр-мыр килгән шома йонлы кара песи, күзләрен алмаш-тилмәш ачып карый-карый, әллә Гөлгенәнең йокысын саклый шунда, әллә дәү апаның сыер савып бетергәнен көтә...

Мин гимнастика ясап кергәнче, дәү апа чәй өлгертте, йомырка кыздырды, өстәлгә сөт, катык, корт турасы кебек төрле тәм-томнарын тезеп куйды. Чәй эчмәдем. Җылы сөт белән бер телем йомшак ипи ашадым да, басу-кырларны әйләнеп кайтырга әле бүген ният дип, урынымнан кузгалдым.

— Җизнәң дә кайтып җитәргә тиеш инде, бик озаклама, сакланып кына йөр, алай-болай Каратамак сазлыгына төшеп китә күрмә, — дип сөйләнеп калды дәү апа минем арттан.

Кечкенә чагымда әни дә гел шулай үгет-нәсихәтләр биреп озата торган иде өйдән, бигрәк тә әнигә охшаган инде бу дәү апа. Гөлгенәсе дә үзенә охшаса, тиз генә сүнмәс әле авылда әни рухы, тиз генә сүрелмәс әле әни сурәте, әни төсе.

Авылны чыккач та, иң беренче шуңа игътибар иттем — тарлау аша салынган Каенлык күперен, таш субайларга утыртып, тимер борыслар белән ныгытып эшләгәннәр икән.

Күперне чыгып, карт карамалар яныннан бормаланып сузылган сукмак буенча күтәрелә башлауга, күңелне ярсу хисләр биләп алды, карашым алга төбәлде, күзләрем тау итәгендәге куш караманы эзләде. Бәлки, ул аугандыр инде, бәлки, аны кискәннәрдер. Шул чагында колак төбендә «Внимание, товарищи!» дигән тавыш ишетелеп киткәндәй булды. Ялт итеп артыма борылдым. Берәү дә юк. Еракта зәңгәр томан белән өртелгән авылның бөдрә башлы агачлары гына шәйләнә. Тирә-ягымда яшеллек диңгезе, дулкын-дулкын булып, күзләремә агып керә. Иртәнге җил түгел бугай бу, шул яшеллек диңгезе дулкыннары бугай. Әллә күк йөзе дә яшел инде? Күзләремне йомып, кояш ягына борылдым. Күзләремне ачтым — зәңгәр, күк йөзе зәп-зәңгәр.

Ниндидер кош түбән атылып төшә дә әрәмәлектә югалып тора. Аннары тагын уктай атылып өскә күтәрелә, тагын түбәнгә омтыла. Нишли икән ул шулай? Күк зәңгәрлеге турында сер сөйләп, җирне сөендерүе, җир яшеллеге турында җыр көйләп, күкне шатландыруыдыр инде, күрәсең, ярсу йөрәкле кошның.

Каршыма тулы ябалдашлы куш карама күтәрелеп чыккач, тыным кысылып, адымнарым салмакланды: шул, шул үзе. Яшь таллар өстеннән сазлыкка таба сузылып киткән кәүсәсе дә исән. Монда бернәрсә дә үзгәрмәгән сыман. Ташларын чыгарып бетергәннәрме, әллә кирәге шуның кадәр генә булганмы — тауның сөзәк ягындагы карьерны япканнар. Кызыл хан үләннәре арасында ак авызлы чокыр гына убылып күренә. Шул гына карьердан калган бердәнбер истәлек. Тимер баганалар да яшеллеккә җайлашып, бил тиңентен яшел агачларга чумып, йокымсырап утыралар.

Сазлыкта су арткан түгелме соң? Әйе шул, куш карама төбенә килеп җиткән су. Әрәмә итәгендә дә су ялты-

рый. Ә мин Каратамакны кибеп беткәндер дип уйлаган идем. Димәк, су Кама күтәрелгәч арткан инде.

Карама төбенә кадәр керер өчен аяк киемнәремне салырга, чалбар балакларын сызганырга кирәк иде. Ләкин аңарчы минем, тау түбәсенә менеп, шарлама казанын күрәсем килде. Тирә-ягыма карана-карана, акрын гына өскә күтәрелә башладым. Арткан су, арткан, Каратамак атавындагы усак урманы көзгедәге кебек кенә чагылып күренә.

Яр ашалган. Ташлар бу кадәрле ялангач түгел иде бит әле без бәләкәй чагында. Яр читенә килдем дә аска сузылып карадым. Кайчандыр гөбердәп төшкән ташкын эзендә, карт кеше тәнендәге сөякләр шикелле, коры ташлар гына тырпаешып тора иде.

Яз көне дә акмаган инде шарлама болай булгач. Кипкән шарлама, шарлама кипкән. Ә аста, моннан дистә еллар элек миңа бик серле һәм бик куркыныч булып тоелган шарлама казанында, тояк эзләре күренгәли. Димәк, моннан көтү уза инде хәзер. Димәк, Каратамакның бер капкасы җимерелгән.

Әнә шундый моңсурак уйларга бирелеп торганда, каршымда, җир астыннан чыккандай, башына кырынрак салып яшел пилотка, өстенә шундый ук төстәге толстовка кигән бер малай пәйда булды. Борын тирәсендәге сипкелләре иләк йолдызлыгына охшаган, зур күзләрендә тау яшеллеге чагыла иде аның.

Мин баштанаяк күзәтеп, карап чыкканчы, кычкырып та өлгерде малай:

— Пароль?!

— Мин шушы авылныкы, нинди пароль, сез кем? — дидем мин, җитди булырга тырышып.

— Сез Шәмгун разведчигы, сезне монда Шәмгун җибәргән дә. Кичә сез Шәмгуннарда булгансыз, ничек итеп Каратамак атавына кереп, корткычлык итү турында планнар коргансыз, — дип, бер сулыштан тезеп китте малай.

— Туктагыз әле, — дип бүлдердем мин аны. — Сез кем? Нишләп әле сез чит кешеләр сөйләшкәнне тыңлап йөрисез?

— «Тукай» колхозы заповеднигына шефлык итүче пионер дружинасы члены Нәзир Курамшин мин. Без сезне тыңлап йөрмәдек. Махсус разведка хәбәр итте. Мин бүген постта торам. Усал ният белән йөрүчеләр Каратамак атавына кертелми. «Яшел патруль» штабы начальнигының приказы шундый.

— Урман ягыннан әйләнеп керүчеләргә дә кагыламы ул приказ? — дидем мин, малайны сынарга теләп.

— Кереп карагыз! — диде малай. Аның әле генә минем күзгә сабыйларча беркатлы булып күренгән сипкелле йөзенә астыртын көлемсерәү җәелде.

Димәк, малай биредә үзе генә түгел инде. Димәк, аның белән бәхәсләшүдән берниндидә мәгънә юк. Мин, берәрсе килеп ярдәм итмәсме икән дигәндәй, гаҗиз калып, якягыма карандым. Шунда күзләремә тагын куш карама чалынды. Югарыдан кәүсәләре күренми дә, тоташ ябалдашлардан гына торган сыман.

— Ә ничек кереп йөрисез атауга? — дидем мин, читкә карап сызгыргаларга керешкән малайның күңелен йомшарту уе белән.

Малай җавап бирмәде, елмайды гына.

— Әнә теге куш карама кәүсәсе буенча, шулаймы?

— Анда хәзер су тирән, аннан кереп булмый, — диде малай, сызгыруыннан кинәт туктап. — Ә сез, абый, чынлап та, Шәмгун разведчигы түгелме?

Малайга кемлегемне, нишләп йөрүемне кыскача гына аңлатып бирергә туры килде. Шунда берочтан Шәмгун белән булган әңгәмәне дә искә төшердем. Шәмгун атып кайткан бүре хакында сүз чыккач, малай нәфрәтләнеп:

— Ялганчы ул, аның бер генә сүзе дә дөрес түгел, — диде. — Башта ак маңгайлы бүре аттым, дип сөйләп йөргән, аннары ак маңгайлы түгел иде, дип ышандырган халыкны. Без ачыкладык инде: ак маңгайлы бүре аткан булган Шәмгун, ана бүре...

— Ничек ачыкладыгыз?

Малай, артыгын сөйләп ташлавы өчен үкенгәндәй, минем күзгә туп-туры карап торды.

— Анысы хәрби сер, — диде ул көттереп һәм тагын читкә борылып сызгырырга тотынды.

— Шулай күрмичә китәмме икәнни инде мин Каратамак атавын?

— Ярар, — диде малай бераздан, кискен карарга килгәндәй, — агач ботакларын сындырмасагыз, үләннәрне таптамасагыз, кош-кортларны, җәнлек-җанварларны куркытмасагыз, керергә мөмкин. Мин сезне озатып йөри алмыйм ләкин. Ике кеше бергә йөрү тыела безнең заповедникта. Сусар күрәсеңме анда, кондыз-мазармы — чыккач Шәмгунга сөйләмәскә сүз бирсәң генә рөхсәт итәм. Монда күргән монда калсын!

Мин күргәннәремне Шәмгунга сөйләмәскә сүз бирдем.

— Пароль — «Яшеллек» безнең. Алдагы постларда күрше авыл малайлары тора. Онытмагыз, «Яшеллек»!

Бары тик шунда гына мин текә ярның Нәзир Курамшин пәйда булган урында бау баскыч шәйләп алдым.

— Чишенмәсәгез дә була, анда кичү бар, — дип, түбәнгә ымлады Нәзир.

Бераз шүрләп калсам да, Нәзиргә аны-моны сиздермәдем, егетләрчә җитез кыланып, баскыч буенча төшеп киттем. Тирә-ягымда вак ташлар, балчык кисәкләре шыбыр-шыбыр коелды. Ниһаять, төшеп җиттем. Кайчандыр шарлама суы җыелып торган казан кипкән, кояш нурларында телем-телем яргаланып, крокодил тиресенә охшап калган иде. Тояк эзе дигәннәрем ни сәбәптәндер балчыкка уелып кергән ташлар икән. Кыяк үләннәр арасыннан берничә адым атлагач ук, аяк астында су чыпырдады, мүкле җир иңеп, су аяк битенә кадәр күтәрелде.

Кичү аз гына уңнанрак, зирек куаклары артыннан башлана икән. Имән казыкларны тал чыбыкларыннан үрелгән җиңел салларга бәйләп, кабыгы төшерелгән юкә агачларыннан нык итеп эшләгәннәр. Баскан саен сыгылса да, җимерелеп суга төшәрлек түгел. Беренче казыкка, фанер кисәге кадаклап, «Каратамак заповеднигы, «Яшел патруль» штабы, 1 нче пост» дип язганнар.

Артыма борылып, тау башына карасам — яшел пилоткалы малай күренми иде. Һаваны кисеп-кисеп, яр карлыгачлары оча. Су читендә бик җитди, көяз кыяфәт белән ике тәкәрлек йөри. Әле иртә — әле монда кояш нурлары да төшеп җитми. Кояш нурлары мин керәсе атау агачларын һәм тау түбәсен генә яктырта.

Үзләре генә салмаганнардыр балалар бу кичүне, колхоз яисә авыл советы булышкандыр. Үзе нинди озын, ә үзе читтән караганда күренми дә. Кичү читендә су өсте бака ефәге белән капланган, төнбоеклар яшел чирәм өстендә үскән шикелле. Кара, элек үсми иде бугай ич монда төнбоеклар...

Бакалар хоры да сагындырган икән. Аларның шулай бер-берсен уздырырга тырышып, үзләренчә бик моңлы итеп гөлдерәүләре, үзләренчә көйләүләре-җырлаулары, бер-берсенә эндәшүләре еллар ташкыны күмеп китә язган әллә нинди татлы хатирәләрне уята.

Акчарлаклар элек тә күренгәли иде. Ә хәзер минут саен, һаваны ярып, ак шәүлә уза. Тавышлары да көр, күңелле. Димәк, балык та бар инде монда хәзер. Заповедник булгач, балык тоту да тыела торгандыр. Күр әле син, рәхмәт төшкере балаларны! Шәп нәрсә уйлап тапканнар бит. Һе, заповедник, «Тукай» колхозы заповеднигы. Матур яңгырый, заманча яңгырый.

Усак урманы бөтенләе белән диярлек су эчендә калган. Кичү аны урап уза икән дә туп-туры ике сырт арасындагы үзәнлеккә килеп чыга икән.

Йа, табигатьнең кешегә рәхмәте. Мал-туарга, машина дигән тимер албастыларга таптаттырмагач, нинди генә үләннәр, нинди генә чәчәкләр котырып үсмәгән монда? Хуш исле әнис үләне, татлы кузгалак, су кузгалагы, какы. Ромашкаларның да нindиләре генә юк: яфрагы каз тәпиенә охшаган казтабаннар, эре таҗ яфраклы пәйгамбәр чәчәкләре, парланган көзгедәй тонык кына ялтырап утырган болан күзләре, актәтәй, алма үләннәре, үзәге вак кына ак керфекләр белән уратылган сыер күзләре. Су читендә уйдык-уйдык су бөтнекләре, кояш нурларында күзләре йомыла язган төн миләүшәләре, йөнтәс күрәннәр. Ә менә бусы, җәй башы гына булуга карамастан, чәчәген коеп та өлгергән нәүрүз гөле бугай. Зирек төпләрен тутырып, күке тамагы үскән. Күке тамагы дигәннән, әнә күке үзе дә тавыш бирде. Дәртле дә, моңсу да, ямансу да күке тавышы, күке моңы. Агачлардан агачларга күчә-күчә, еракларга тарала. Сары зирек ботагына килеп кунганы нинди кош тагын? Тукран, матур тукран. Кызыл ыштанлы, ак күлмәкле, кара җиңле тукран. Әллә бар мин аңа, әллә юк, озын томшыгы белән тук та тук тукылдата да башлады агачны.

Нәрсә соң бу баядан бирле борынны кытыклый? Ә-ә, җиләк чәчәге исе. Җиләк турында уйлагач, артымда тагын «Внимание, товарищи!» дигән тавыш, нинди дә булса кызыклы эш яисә мавыктыргыч сәфәр көтеләчәген хәбәр итәргә ниятләгән абыйның җанны кытыклый торган тылсымлы тавышы ишетелеп киткәндәй булды. Саескан икән, хәерсез. Нәкъ теге чактагы, Каратамак атавына беренче кат аяк баскан көнемдәге кебек гауғалана бит бу. Ялт итеп сырт өстенә күтәрелеп карадым. Берниндидә җан иясе күренми, талгын җил уңаена яшь усаклар гына бөдрә башларын чайкаштыргалап алалар.

Юк, кайдадыр якын-тирәдә генә ниндидер җан иясе бар. Саесканнар бу кадәр тавышланырлар идемени югыйсә? Нурлары күзне чагылдырмасын өчен, кояшка ян беләнрәк борылдым. Әнә бит! Әллә Шәмгун әйткән теге аксак куянмы икән? Алай дисәң, шактый озын гәүдәле бит бу. Башы да, койрыгы да күренми. Үләннәр өстеннән ала сырты гына йөзеп бара. Яфракларны кыштырдатмаска тырышып, куак артына елыштым. Ләкин ул сизде, сөрлеккәндәй кинәт туктап калды. Башын минем якка борды. Шәмгун эте Алабай түгелме соң? Шул бит! Салпы колаклары белән төшемә кереп җәфалаган иде лә төнлә, тагын очрашырга булган икән. Борынын күтәреп, берничә секунд тирә-якны иснәп торды, шик-шөбһә тулы күзләрен тутырып, мин посып утырган куакка да карап ал-

ды, кырау суккан яфрактай шәлперәеп төшкән колакларын селкеткәләп, саесканнар тавышын тыңлагандай итте дә тагын үләннәр арасыннан йөзеп китте. Бер генә өн дә, бер генә кыштырдау да ишетелмәгәч, чынлап та, йөзеп барадыр сыман тоелды ул миңа.

Шәмгунны ничек үткәрделәр икән соң посттан? Шәмгун килмәсә, Алабае берьялгызы гына нишләп йөрсен?

Беркавым куак төбендә тирә-юньдәге тавышларга колак салып утырдым да, акрын гына торып, Шәмгун эте киткән якка атладым. Тиздән мылтык шартлавы ишетелер сыман тоела иде миңа. Ләкин дымлы үлән өстеннән Шәмгун Алабае салып узган эз буенча ике сырт арасындагы ермакка килеп җиткәнче, андый-мондый ят, шикле тавыш ишетелмәде. Инде саесканнар да артта калдылар. Ермак битендәге үги ана яфраклары арасыннан бармак башы чаклы гына бака баласы сикереп чыкты да мүкләнеп беткән алсу таш астына кереп посты. Тагын бераз баргач, ермакның ике ягында да куе һәм озын булып үскән чикләвек куаклары күренде. Куакларның очлары бер-берсе белән чуалып, колмак тәлгәшләренә уралып беткәнлектән, озакламый ермак төбендәге коры инеш өстендә караңгы чатыр хасил булды. Әйтерсең лә мәгарәдән барам. Яфраклар арасыннан ара-тирә кояш нурлары елтырашып алгаласа да, тирә-як шомлы. Ермак борылган урында артка күз салдым. Анда да яктылык мәгарә авызындагы кебек кенә шәйләнә иде.

Байтак вакыт узды лабаса инде. Олы урманга кадәр барамы икән соң бу ермак, әллә берәр җирдә... Әнә ич, анда да якты өлге күренеп китте бугай. Аяк астында вак ташлар кимеде, үләннәр калынайды. Эһе, кайбер урыннарда су чыпырдый, димәк, инеш кибеп җитмәгән икән әле. Әллә булмаса, сазлыкның бер читеме икән инде монда? Алай дисәң, ни тәкәрлекләр, ни акчарлаклар тавышы ишетелми.

Яр аз гына сөзәкләнгәч, ермак төбеннән чыгып, чикләвек куакларына ябыша-ябыша, өскәрәк мендем. Җил көчәйгән икән. Кошлар тавышын җил алып китәдер, мөгаен. Бераз менгәч үк, ермак ярында олы яшел мәйданчыкка охшаган алан күренде. Аланны уратып алган куе куаклар бертуктаусыз дулкынланып торганлыктан, яфраклар кырпак кунгандай агарып, көмешләнеп ялтырый. Урман ягыннан шалама итәкләрен агач башларыннан сөйрәп, күгелҗем болыт күтәрелеп килә.

Җил тынып торган арада, аланчык читенә күзем төште. Эте шунда, куак астында сузылып ята, ә Шәмгун үзе тагын юк иде. Туктале, тукта, эт кенә түгел ич монда. Алабай тирәсендә куак күләгәсе төсендәге җан ияләре

кыймылдый түгелме соң? Ничек кенә сиздермичә якынрак барырга? Үләннәр арасына поса-поса, артка чигенә-чигенә, яңадан ермак төбенә шуып төштем дә тавышсыз-тынсыз гына аланның Алабай аунап яткан турысынарак үрмәләп мендем.

Менә алар бөтенләй якында. Өчәү. Бернинди хафасыз-борчусыз чалкан әйләнеп төшкән Алабай өстенә юантык, йонлач тәпиләре белән тезелешеп басканнар да рәхәтләнеп имәләр. Сөт тәменнән ләззәтләнеп, авызларын чапылдаталар. Әллә күзләре дә ачылмаган инде? Юк, ачылган. Әнә берсе, сыңар күзен елтыратып, Алабайның әле тегеләйгә, әле болайга чайкалып яткан тынгысыз койрыгына карап куйды. Әнкәй генәм икән! Маңгаенда нәни генә ак тап! Әнә бит, тегеләрнең дә маңгайларында ак төймәләр елтыраша. Көчекләр түгел ләбаса болар, болар теп-тере бүре балалары. Ак маңгайлы бүре балалары ләбаса болар! Алабай сиздеме икән әллә — башын күтәреп, колагын тырпайтты, як-якка каранып алды. Аннары сикереп үк торды, имидән аерылырга теләмәгән нәниләрне борыны белән тәрткәли-чөергәли, котырып үскән тәти көпшәләр арасына алып кереп китте.

Бу искиткеч иде, бу гаҗәп иде. Мин, табигый ки, кире кайтканда, ак маңгайлы көчекләр турында гына уйладым. Бәлки, Алабайның үз нәниләредер алар? Юк, бәләкәй чагымда эт балаларын күп күрдем мин. Эт балаларының тәпиләре нәзегрәк, башлары кечерәк, колаклары җыйнаграк, йоннары шомарак була. Ә болар нинди йөнтәсләр, килбәтсезләр. Бүре балалары болар, шик тә юк, бүре балалары...

Кичүне чыгып җиткәч, күргәннәремне Нәзир Курамшинга да сөйләдем.

— Ш-ш, — дип, имән бармагын иреннәренә куйды Нәзир. — Ничек сөйләштек әле, абый? Монда күргәннәр монда калсын, яме!

— Ә мин Шәмгунга әйтергә җыенмыйм, — дидем мин, үпкәләгән булып. — Синең белән генә сөйләшәм. Бүре балаларымы соң алар чынлап та?

Нәзирнең иреннәре дерелдәп куйды, карашы уйчанланды.

— Бүре балаларының әниләре юк, ә Алабайның — балалары. Үстерә инде менә хәзер мескен эт бичара ятимнәрне.

Маңгайларындагы ак тапларны тәгаен күрсәм дә, күңелемдә шик-шөбһә калмасын өчен, Нәзирдән:

— Чынлап та ак маңгайлы бүре балаларымы соң алар? — дип сорадым.

— Анысы сер, абый! — диде Нәзир, күңеле йомшаса да, чишелеп китәргә нияте юклыгын сиздереп. — Күргәнсез икән инде, шаулап йөрмәгез. Монда күргән монда калсын!

— Монда күргән монда калсын! — дидем мин саубуллашканда, җитди чырайлы малайның кулын кысып. — Туган ягыбызны этләре, бүреләре белән бергә әкият дөньясыдай серле итеп саклавыгыз өчен рәхмәт сезгә!..

Яшел бишегең өстенә серләр чатыры корып, этләреңне дә, бүреләреңне дә, кызыл галстуклы энекәшләребезне дә үзара дус яшәтүең өчен рәхмәт сиңа, Каратамак!

Хуш! Ак маңгайлы бүреләреңне күрергә мин әле сиңа тагын кайтырмын.

# БЕР МАЛАЙ, ӨЧ АРГАМАК

### Он күктән яумый

Уянып киткәч, иң элек өстәлгә күзем төште. Ялгыз самовар бөтен өйгә җан өшетерлек салкын нур чәчә. Көн дә кояшлы бит инде, нигә салкын соң аның нурлары? Әһе. Ашыйсы килә икән. Кичтән дә такы-токы гына ашап яткан идек шул. Әни, эштән кайтканда, бәрәңге юнәтеп булмасмы, дигән иде дә кана. Кайчан кайта әле ул. Бернәрсә дә калдырмады микәнни инде ашарга? Әһе, искә төште. Йомырка пешереп ашарсың, дигән иде. Ә йомырка кая була инде? Ояда дигән иде түгелме соң?..

Урынымнан сикереп торып, керосинкага ут кабыздым. Кәстрүлгә су салып, кайнатырга утырттым да чолан ишеген ачып җибәрдем.

Читән буендагы карга миләшеннән бер көтү чыпчык пырылдап һавага күтәрелде. Күр инде бүрек-бүрек кызарып утыруын. Карга миләшен әйтәм. Ашарга яраса, болай котырып уңмас иде әле.

Әнә ашарга ярый торган миләш дүрт күз белән көтеп тә кызармый. Шомырт та уңмады быел. Пешә башлауга, тармакларын пәрәвез сарып, бөрешеп, коелып бетте.

Амбар ишеген ачып керүгә, салкынча җил белән бергә күңелне билгесез шик биләп алды. Шыгырдавык баскычтан печәнлеккә менгәндә, шик үсте, баш миенә, бөтен тәнгә җәелде.

Шикләнүемнең сәбәбен төшенеп җитмәсәм дә, печәнлектә мине нindидер күңелсез хәл көтеп торуы көн кебек ачык иде инде.

Әйтәм бит. Беркайчан да тиктомалга шикләнмим мин. Караңгы, бөркү печәнлеккә менеп җиткәч, кулымны тавык оясына таба суза гына башладым — утлы күмер китереп бастылармыни бармакларыма — чак мәтәлеп төшми калдым печәнлектән.

Харап кына итте кулымны ябалак алып киткере тавык! Бәхилләш инде хәзер йомыркалар белән. Үтерсәң дә чыкмаячак ояdan. Бакчы, ничек кырылдый. Якын-

рак барсаң, сикереп күзеңне чукып алыр. Көз генә җитсен, бүрегең бар дип тормам, Гарифулла абзыйга алып кереп кых мин сине. Бик тәмле шулпа пешәчәк синнән... Җә, китеп тор инде, Чуаркай, ә! Бер генә йомырка алам. Ти-ти-ти-ти... Мин ич бу, әллә танымыйсыңмы? Әйе, Рәсим абыең мин... Алыйм инде бер генә йомырка, ә?! Ничәү соң анда? Карыйм әле хет. Барысын да син салмагансыңдыр әле... Көш, көш, дим, көш-ш... Ашыйсың килә булыр, бар, азрак чүпләнгәләп, тирес актаргалап мен, утырма саргаеп. Чеби чыгаралармы соң инде хәзер? Урак өсте җиткәч... Җә, җә, тимим, берне генә алам... Ал-лай!.. Бетерәсең бит кулны, киребеткән кош... Бирмәсәң, утыр шунда көне буе ашамыйча. Су да эчермим мин сиңа төшкәч...

Ачуымнан шартларга җитешеп, якты ишегалдына чыктым. Инде нишләргә? Кәстрүлнең суы да кайнап беткәндер. Ни пешереп ашарга инде хәзер? Җилләнеп бәрәңге бакчасына юл тоттым. Чуалып беткән бәрәңге сабаклары арасына кереп, берсенең төбен казып карадым. Борчактан аз гына зуррак ике-өч бәрәңге сырышкан зәгыйфь тамырларны җиргә күтәреп бәрдем. Үсми бит аның бәрәңгесе дә быел. Башка елларда бу вакытта йомырка сарысы кадәр була торган иде анда бәрәңге. Яңгырлар яумады шул кирәк чагында. Әнә ничек корыган буразналар, тузан уйнап тора.

Буразна арасыннан бакча читенә кадәр бардым. Читән буенда тәгәрәп яткан кабакка күзем төште. Сөенечемнән башымдагы уйларым чуалып китте хәтта. Чуар тавык чукыган бармагымны үләннәргә тидермәскә тырышып, сары корсаклы кабакны җирдән кубарып алдым. Тик сабагыннан тиз генә өзеп булмый икән аны. Тартам, тартам — дилбегә кебек һаман сөйрәлеп килә артымнан. Сукмакка чыгып җитәрәк, ныклабрак тарткан идем — кабагым бер якка тәгәрәп китте, үзем икенче якка барып төштем. Кабагы да йомшаграк икән әле — абзар почмагындагы ташка бәрелеп чәлпәрәмә килде. Өйдән табак алып чыгып, кисәкләрен җыеп керергә туры килде.

Әйбәтләп әрчедем кабакны, эчләрен чистарттым, юдым, турадым да дөбердәп кайнап утырган кәстрүлгә салып җибәрдем.

Инде хәзер баздан сөт алып чыгасы гына калды. И, юләр дә инде мин — ашарга сөт бар лабаса безнең. Сөт була торып, теге киребеткән тавыкка ялынып йөрим.

Әни һәр көнне иртәнге сөтне, чүлмәккә салып, базга куеп калдыра. Кичке сөттән аш пешерәбез... Пешерә идек, димәкче булам инде. Кичә пешермәдек. Бәрәңге дә, он

да, ярма да бетте, диде әни. Сөткә кузгалак турап, йомырка сытып тәбә пешердек. Хәйран тәмле була икән, әй. Көн дә, көн дә шулай ашап торсаң, юләр...

Салкын базга төшеп, кулны чүлмәккә суздым — чүлмәк урынында юк иде. Ни галәмәт булыр бу? Баскыч астында да юк. Күзләрем дә караңгыга ияләшеп җитте бит инде. Ә баз төбендә ни чүлмәк, ни кәстрүл күренми. Әллә кәҗәне саумыйча куды микән бүген әни көтүгә? Гомердә алай булганы юк иде. Әнидән иртә көтү куучы юктыр да әле авылда.

Төшүен бик җиңел төшкән идем базга. Менгәндә буаз мәче кебек сөйрәлеп кенә мендем. Баздан чыккач, беркавым җып-җылы йомшак бәбкә үләне өстенә капланып ятып тордым.

Тып-тын. Баш очында шөпшәләр безелдәве дә, карлыгачларның һаваны телеп очулары да ишетелеп тора.

Бераздан ишегалдына ниндидер бик тәмле ис җәелде.

Кабак исе бит бу, кабак исе, ура!.. Көз көне, әни кабак бәлеше пешергәч, өйгә шундый ис тарала торган иде.

Йөгереп өйгә кердем. Кәстрүлне ачып, кабак кисәкләрен кашык белән төрткәләп карадым. «Пешкән бу, изелеп кенә пешкән», — дип сөйләнә-сөйләнә, кәстрүлне уттан алып, капкачын аз гына ачык калдырып, суын агыза башладым. Әллә кәстрүл капкачын зуррак ачып җибәрдем инде шунда, әллә кабак телемнәрен ваграк тураганмын — берзаманны кәстрүлдә күпме кабак бар — лыштыр барысы да идән юа торган чиләккә.

Авызымны ачып, мич кырыена барып сөялдем. Теземне буш кәстрүл төбе пешереп тора, ә мин аңа игътибар итмим. Күзләрем болганчык су өстендә йөзеп йөргән кабак телемнәрендә. «Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» — менә шул буладыр инде ул.

Кәстрүл төбендә калган саргылт сыекчаны күтәреп эчтем дә керосинканы сүндердем. Ашарга ризык табам дип, үз-үзеңне хур итеп йөргәнче, лутчы сәкегә ятып ач үл...

Юк шул, ач үлә алмыйм мин. Хәтта бер көн дә ашамыйча тора алмыйм. Барыбер ни булса табып ашыйм. Әни әйтә, егерме беренче елгы ачлыкта икешәр, өчәр көн ач тора идек, түзә идек, ди. Алар түзгәннәрдер, ә менә мин түзалмыйм...

Барыбер нәрсә дә булса табып ашыйм бит инде. Юкка гына ач тотарга тырыша мине бүгенге көн... Һич булмаса, Хәбирләргә кереп ашыйм.

Шулай уйлап бетерергә өлгерә алмадым — әллә нинди генә яшерен эчке көч мине җилтерәтеп ишектән алып чыгып китте.

Әллә кайчан керәсе калган аны Хәбир күршеләргә. Ир заты була торып, тавыклар белән сугышып, кабаклар белән булышып йөрмәсәм...

Хәбирнең әтисе сугышта үлгән. Шуңа күрә аларга пенсия чыга. Шуңа күрә аларның оннары да, ярмалары да бетеп тормый. Ипи пешермиләр, хәер, алар да. Ипи пешерергә он каян җиткермәк кирәк ди? Әни сөйләгәнен тыңлап торганым бар — ипи салыр алдыннан, онны су кушып болгаталар икән. Аннары күәс камыры салып ачыталар. Аннары иртә белән тагын он салып басалар. Аннары он сибеп әвәлиләр. Менә бит никадәр он кирәк. Он кар түгел ул, күктән яумый. Шуңа күрә Хәбирләр дә онны ипи салып әрәм итмиләр. Умач яисә салма гына пешергәлиләр. Умач тәмле инде, умачка нәрсә җитә! Һәр көнне катулы умач ашап торсаң, тазарыр идең соң, ай-яй... Үсеп тә китәр идең.

Бик татлы өметләр белән аяк баскан идем дә Хәбирләр ишегалдына кана. Борын яфракларына катулы умач исе килеп бәрелмәгәч, аптырабрак калдым. Шулай да ачтым ишекләрен.

Хәбир сәке башында чырадан җил тегермәне юнып утыра. Бөтен идән, бөтен өстәл йомычка белән тулган. Әнисе каядыр киткән, күрәсең. Югыйсә болай иркенәергә ирек бирми ул Хәбиргә.

Хәбир, кабаклары салынып торган күзләрен күтәреп, миңа бер генә карады да кулындагы чырасын тагын да тырышыбрак юнырга кереште.

Борын яфракларын киереп, өй эчен дә иснәштергәләп чыктым, юк, килми умач исе.

Хәбир янына уздым.

— Тегермән ясыйсыңмыни, малай? — дип сорадым.

— Әһе, — диде Хәбир, башын күтәрмичә генә.

— Нигә учакка җыеп якмыйсың бу йомычкаларны?

— Нигә?

— Умачыгыз тизрәк пешәр ие.

— Кая умач?

— Казаныгызда юкмыни?

— Бар сиңа! Әни кичә үк Агыш тегермәненә киткән ие. Бүген кайтса ярый әле.

— Нигә йомырка пешереп ашамыйсың алайса?

— Апа базарга җыеп киткән.

— Эремчек аша соң. Сөт белән эремчек.

— Баз бикле. Ачкычын яшергәннәр.

— Аңа калгач, оннан боламык та болгатып ашап була инде, — дидем мин, Хәбирләрдән буш корсак белән чыгып китәргә теләмичә.

Хәбир исә өстәлләргә, идәннәргә чырт-чырт йомычка аттыруын белде.

— Апа кайткач пешерер әле...

Тамагы тук бу тана колакның дип уйладым мин, өметсезлеккә бирелеп. Тамагы ач булса, чыра юндырып кына ризалатырсың Хәбирне. Тавышы бөтен Элмәлегә җәелер. Әнисе белеп каезлый аны. Каезламасаң, юньсез малайдан үскәч тә юньсез кеше чыга, ди. Бакчы, бакчы, сүзне бөтенләй икенчегә борырга маташа, тана колак...

— Рәсим, синең әтиең сугышта үлмәгәнмени?

— Өйдә үлгән. Шуннан нәрсә әйтмәкче буласың?

— Әйтмим бернәрсә дә. Сорыйм гына. Сугыш вакытында председатель булган икән ул синең әтиең.

— Булган шул. Нигә аңа эчең яна?

— Председательләр бай яшиләр бит. Ә сез...

— Нишләгән без?

— Нигә әтәч шикелле сикереп кунарга гына торасың әле син? Сезнең өегез дә иске, оныгыз да юк. Шуңа аптыраым.

— Минем әти җәмәгать микенә тырнак очы белән дә орынмаган, акылым әйтә. Үзенекен дә кешеләргә биреп бетергән.

— Кешеләр бирәме соң сезгә хәзер?

— Нәрсә авыз эченнән ботка пешерәсең соң син? Әйтсәң, өзеп әйт... Әллә синнән ашарга сорарга кергән дип уйлыйсыңмы? Акылым әйтә, әни бер капчык бәрәңге алып кайтачак бүген.

— Ә без, әни тегермәннән кайткач, ипи салабыз, — диде Хәбир, йомычкаларын аның саен еракка рак аттыра-аттыра.

— Салмагаегыз... без дә салырбыз әле.

— Кайчан?

— Качкан чак... Кайчан булсын, көзгә... Гарифулла бабай әйтә, ярты килодан да ким тимәс быел трутдингә, арыш хәтәр уңган, ди.

— Эрләмәгән, сукмаган Мәчтүрәгә ыштанлык, — диде Хәбир, ниндидер миңа аңлашылмаган сүзләр белән. Мин дә сер бирәсе итмәдем.

— Эрләгән дә, суккан да, акылым әйтә, бирәләр булгач бирәләр, — дип, Хәбирнең авызын томалап куйдым.

Хәбир кулындагы тегермән канатын күгәргән кадакка тыгып әйләндереп карады да минем авырткан җиремә китереп тондырды:

— Ни ашадыгыз соң әле бүген иртә белән?

— Әлбә.

— Тәмледер кәҗә сөте белән?

— Безнең кәҗә сезнең сыерыгыздан күбрәк бирә сөтне.

— Әйтәм сөт-май сатудан туктамыйсыз... Ызба салырга җыясыздыр инде акчасын...

Күзгә карап мыскыл итә бит бу тана колак. Әллә чыра тегермәнен сындырып чыгып качыйм микән? Шулай дип уйлавым булды — башым әйләнеп егылып китә яздым. Әле дә ярый сәке чите бар иде тотынырга.

— Синең белән пачна сатып торырга вакытым юк минем, — дидем мин, сәке йөзлегенә тотынып, ишеккә таба атлый-атлый. — Алты йомырка куйган идем пешерергә, ярылып бетә торганнардыр...

## Качабыз, малай!..

Хәбиргә юри генә әйткән идем бит. Баксам, юраганым юш килде. Төш җитәрәк, ярты капчык чамасы бәрәңге күтәреп, әни кайтып керде.

Алҗыган, тирләгән булса да, карашы ягымлы, күңеле күтәренке иде аның.

— Бар бит әле дөньяда яхшы кешеләр, — диде әни, бәрәңгесен дөпелдәтеп басма алдына куйгач. — Бәрәңге бетте, дип әйткән идем агранум Никулай дәдәңә, сөйләштереп тә тормады. Эштән кайтышлый үзләренә ияртеп керде дә күтәртте дә җибәрде ярты капчык бәрәңге. Настачасы да бик әйбәт аның. Күпме кирәк, ал, Хәят апа, дип кенә тора. Булмый тормас әле сездә дә, бәхилләшербез, ди. Никулай дәдәң этиеңне белә икән. Душа кеше иде, мунча кергән саен пуминайть итәм, ди.

«Кайчан пешә әле бу бәрәңге?» — дип әйтергә авызымны ачкан идем дә, кылт итеп сөт исемә килеп төште.

— Сөт тә калдырмагансың бүген, — дидем мин, авызымны турсайтып.

— Калдырмадым шул, калдырмадым, — диде әни, күзләремә туры карап. — Сөт налогың тулмаган, штраф салам, дип теңкәмне корытты бит инде Гаязетдин... Ачулансаң ачуланырсың, улым, — барыбер без түлисе, Гаязетдингә илтеп бирдем иртәнге сөтне.

Гадәттә, әни ашарга әзерләгәндә, мин утыннар кертешә торган идем. Керосинкада пешерсә, филтәләрен тигезләп, тәрәзәләрен сөртеп куям. Ә бүген кыл кыймылдатырлык та хәлем юк. Әни, бәрәңге әрчеп, казан астына ут ягып җибәргәч тә, бәрәңгегә кайнау кергәч тә, бүлем тактасына сөялеп, сөт налогы турында уйлап тора бирдем.

— Әни, Хәбирләрнең сыерлары да бар, сөтне бездән азрак түлиләр.

— Хәбирнең этисе фронтта үлгән. Скидка аларга, улым.

— Безгә дә скидка булсын ие. Минем дә сөт эчәсем килә...

Сүрелә башлаган учакны өреп дөрләткәндә, әни кызарган битләренә яргаланган учларын тидергәләп алды.

— Кечкенә әле син, улым. Күп нәрсәне аңламыйсың.

Озак ашамыйча торгач, ашыйсы килүе онытыла башлый икән.

Иртә белән бөтен дөньяны йотарлык булып йөргән идем, алдыма табагы белән бәрәңге килеп утыргач, теләр-теләмәс кенә, авыз пешкәнгә ачуым килебрәк кенә ашадым.

Бәрәңгедән соң мендәр конфет белән мәтрүшкә чәе эчтек. Шунысы рәхәт, ашарга ризык беткән чагында да мендәр конфеты бетми әнинең. Чынаяк саен бер конфет чыгара тора. Дүрт чынаяк эчәм икән — дүрт конфет. Хәер, әни үзе бер конфетны өч чынаякка җиткерә.

Ике чынаяк чәйне тәгәлләп, өченче конфетка карап торганда, капка келәсе шылтырады.

Бригадир Мөнәвәрә ападыр инде. Төш вакытында бик еш керә ул безгә чәй эчәргә. Хәят апаның чәе тәмле, мин аларда гына эчәм чәйне, дип, бөтен авылга сөйләп йөри аннары.

Тәки шул шыркылдык. Өйалдыннан ук шаулап керә әнә.

— Мәйтәм, Хәят апаларның да төтене зәңгәрләнде, чәй эчәләр булыр, мәйтәм, туктале, бер чынаяк кына булса да эчеп, янган йөрәкне басып чыгыйм, мәйтәм...

— Әйдүк, әйдүк, Мөнәвәрә, — диде әни, ачык чырай белән, һәм өстәл астыннан биш аяклы табуреткаsuccessful (шыгырдый башлагач, ныграк булсын дип, мин кыландырган идем) тартып чыгарды. — Әллә нишләп керми йөрдең әле бу арада. Юксынып та беткән идек үзеңне. Иләшкән инде сиңа, үз кызым кебек.

Әни Мөнәвәрә апага чәйне куерак итеп ясады. Конфет савытын аның ягынарак шудырды.

— Маебыз юк, гаеп итмә, Мөнәвәрә. Әнә бәрәңге аша, суынмагандыр әле.

— Рәхмәт, Хәят апа. Ашыйсым килми. Эсселәдем. Берике чынаяк чәй генә эчәм...

Чәен берничә мәртәбә шапырдатып суырды да Мөнәвәрә апа, тәлинкәсен өстәлгә куйды, сытылырга җиткән шомырт кебек йомшак кара күзләрен миңа төбәде.

— Йә, Рәсим, зур егет буласыңмы инде?

Нәрсә тиктомалдан гына миңа бәйләнә әле бу? Башка көннәрне әни белән генә сөйләшеп утыра торган иде ич.

— Оялчан, Хәят апа, егетең. Безнең заманда чекерәеп,

күзгә кереп торсаң да таманга килә әле... Дүртне бетердеңме быел?

— Дүртне.

— Бишенчегә Агышка барамы?

— Барып карасын иде дә соң... Авылда яхшы укыды үзе. Өстенә-башына, тамагына дигәндәй, юнәтеп булса, бик барып карасын иде...

— Галиулла абзыйга әйттем әле беркөннәрдә. Мәйтәм, Хәят апага ярдәм фондыннан он яздырып бирик: малае кечкенә, үзе көне-төне колхозда эшли, мәйтәм. Ярдәм фонды солдаткаларга гына каралган, дип, тәмәкесен пыскыта да утыра, Хәят апа җаным.

Мөнәвәрә апаның Галим абзыйны хурлавы ничектер мактау кебегрәк яңгырады. Әллә эссе чәйдән, әллә эчендәге уйларының кайнарлыгыннан тәмам пешеп чыкты Мөнәвәрә апа.

Әни, әй, бирмәсә тагын дигән мәгънәне аңлатып, кулын селкеде. Мөнәвәрә апаның чәен яңартты.

— Эч әле, эч, Мөнәвәрә. Тарсынып утырма, ят кеше түгел.

Мөнәвәрә апа тагын минем якка борылды.

— Ат яратасыңмы син, Рәсим?

— Бик яратыр иде дә, — диде әни елмаеп, — ат җигеп йөрүче кешебез юк шул безнең. Ат тагын безгә!

— Егете булса, ат кына түгел, аргамагы да табылыр иде әле... Очтакка барасың килмиме соң, Рәсим?

Иреннәренә тидергән чынаягын әни кире өстәлгә куйды, Мөнәвәрә апага озак итеп, аптырап карап торды.

— Син чынлап әйтәсеңме, Мөнәвәрә?

— Чынлап, Хәят апа, чынлап. Уйнап сөйләшергә вакыт калмады. МТС нибарысы бер комбайн бирә. Калганын — син дә, мин дә, кем әйтмешли, шул Мөхәммәтәмин инде — ат машинасы белән урабыз.

— Сабира малае кая киткән тагын?

— Кунакка киткән, ди. Әллә ялганлый энисе, әллә дөресен сөйли. Мәйтәм, тапкан кунакка йөрер вакыт...

Әни каш астыннан гына минем якка карап алды.

— Синең күз алдыңда менә, Мөнәвәрә. Бар, дип әйтмим мин аңа, барма, дип әйтмим. Тели икән, барсын. Инде көне буе эссе басуда әлсерәп йөрисе килми икән, көчләмим. Укырга кергәнче уйнап калсын. Бала вакытлар ике килми бит беребезгә дә... Аннары, үзең беләсең, балалар түгел, олы кешеләр дә бик атлыгып тормыйлар Борһан белән эшләргә...

Мөнәвәрә апа миңа сынаулы караш ташлады.

— Йә, Рәсим энем, син үзең ни әйтерсең?

— Белмим, — дидем мин, ишетелер-ишетелмәс кенә.

Әмма мин әле менә хәзер нишләргә тиеш икәнлегемне белмәсәм дә, «очтак»ның минемише яланаяклы малайларны дер калтырата торган сүз икәнен бик яхшы беләә идем.

Кызык инде бу Мөнәвәрә апа. Үзе безгә кереп чәебезне эчеп утыра. Үзе мине Борһан Кукамай янына очтакка димли.

— Нигә шулай усал итеп карыйсың миңа, Рәсим энем? Әллә бер-бер килешмәгән сүз әйттемме?

— Юк ла, — дидем мин һәм, Мөнәвәрә апага берни дә җавап бирмичә, өстәл яныннан торып киттем.

Бөтен авылны яңгыратып чаң кактылар.

Мөнәвәрә апа, сүз белән мавыгып утырабыз, мәйтәм, дип сискәнеп, урыныннан кузгалды. Ашык-пошык кына рәхмәт әйтеп, бер кулына кыек яулыгын, икенчесенә чолан почмагында сөялеп торган саженен эләктереп, урамга чыгып йөгерде.

Аның артыннан әни дә озакламады. Теге киребеткән тавык оясыннан йомыркаларны җыеп төшкәч үк, алъяпкычын бәйләп, эшкә китәргә әзерләнә башлады. Бүген ул ни өчендер, тегесен болай итәрсең, бусын тегеләй итәрсең, дип, мине өйрәтеп тә маташмады. Ишегалдында бәләкәй балта белән чыбык туравымны сүзсез генә күзәтеп торды да тирән итеп көрсенде, тырмасын иңенә салды һәм, капкадан чыгып, болын ягына борылды. Койма өстеннән аның тырмасы тирбәлеп барды, койма ярыкларыннан күлмәк чәчәкләре агарып-агарып күренде.

Шаккатарсың уйлап баксаң — ничек армый икән бу әни? Шул ашап-эчкәндә генә утырып тора бугай ул. Үзенә урын җәйгәнен дә, җәйгән урында йоклап ятканын да хәтерләмим мин аның...

Әни турындагы уйларымны Хәбир бүлдерде.

— Ишеттеңме? — диде ул, капкадан өермә кебек атылып кереп. Аның колаклары элеккегедән дә битәррәк тырпайган сыман күренде миңа. — Фәхерли очтактан качкан икән быел.

— Ишеттем, — дидем мин, чыбык туравымнан туктамыйча.

— Бригадирлар авыл борынча яңа малай эзләп йөриләр.

— Миңа да әйтеп карады Мөнәвәрә апа, — дидем мин эре генә.

— Бер бәйләнсәләр, әйтеп кенә калмаслар алар, малай. Бер бәйләнсәләр, арбага салып бәйләп алып китәргә дә күп алмаслар. Былтыр Фәхерлине шулай алып киткәннәр әнә.

— Алып китсәләр, эшләрбез. Фәхерли эшләде ич әле былтыр, үлмәде.

— Әһе, үлмәде! Син күрмәгәч тә. Былтыр Дими тоба-

сында бергә су коендык. Утыра торган җире веч суелып беткәние. Ботларының тырналмаган урыны да югые. Җүнле эштән качамы соң инде адәм баласы?! Ә Фәхерли былтыр өч тапкыр качты, өч тапкыр тотып киттеләр. Быел игеннәр саргая башлагач ук, Кошмандагы җизнәләренә чыгып сызган әнә. Баганага терәп атсалар да, очтакка бармыйм, дип әйткән, ди.

— Харап икән! Беткәндер колхозда Фәхерлидән башка кеше...

— Кем бар? Йә, кем бар? Икенче класслар кечкенә. Өченче класстан Габдулла да дүртенче класстан синең белән мин. Бишенче класс малайлары бармыйлар да бармыйлар очтакка. Алар, ат җигеп, көлтә ташыйлар.

Бакчы, чыннан да, шулай бит әле. Барысын да уйлап, исәпләп кергән бу тана колак безгә. Мөнәвәрә апа бер әйтер, ике әйтер дә председатель Галимулла абыйны ияртеп килер. Тыңламасаң, ат белән килеп бәйләп алып китәрләр аннары. Әни дә нишләптер дәшми-тынмый гына чыгып тайды эшкә.

— Качабыз, малай, — диде Хәбир, минем эчкә пошаман кергәнне сизеп, — печәнлеккә оя ясыйбыз да шунда кереп ятабыз. Эзләсәләр дә, кычкырсалар да, чыкмыйбыз.

— Ә ашарга?

— Ашарга алабыз үзебез белән. Бәрәңге пешереп алып менәбез, тоз... Безнең солы ярмасы да бар.

— Юк, качмыйм, — дидем мин, Хәбирнең чыра юнган чактагы кыяфәтен күз алдыма китереп. — Мөнәвәрә апа безгә чәй эчәргә кереп йөри, акылым әйтә. Үзем бармасам, мине беркем дә көчләп алып китмәячәк... Кем беләшәт, мин үзем теләп тә барырмын әле очтакка. Борһан да ипләнгәндер әле быел...

Хәбир тешен ыржайтып көлде.

— Борһан Кукамаймы? Кояш кире яктан чыксын, Борһан Кукамай ипләнсә. Ипләнә торган кеше сугышка да бара ул... Саулыгым юк, дигән булып, тылда качып ятмый. — Болары инде Хәбирнең үз сүзләре түгел. Әнисе сүзләрен сөйли хәзер Хәбир. Безгә керсә дә, башка күршеләргә керсә дә, гел шундый сүзләр генә сөйләп тора Хәбирнең әнисе Нәфисәттәй.

Гомере озын булыр әле әнә. Урамда арба шыгырдавы, тояк дөпелдәве һәм Нәфисәттәйнең: «На, үшән!» — дип, ат куган тавышы ишетелде.

Безнең ишегалдыннан ай күрде, кояш алды Хәбирне. «Әни тегермән тартып кайтты, әллә-ли!» — дип, капканың әллә бу ягында кычкырды ул, әллә теге ягында — абайламый да калдым.

## Ачуланмасаң, барып карар идем

Күкнең көнбатыш ягында алсу болытлар тынып калган. Вакыт узган саен, аларның алсулыгы куера бара. Чатыр тау башындагы агачлар караеп, ничектер шомлы булып күренәләр.

Эштән кайтып ашап-эчеп, әни чәй суына китте. Ә мин ишегалдындагы чирәм өстендә уйланып ятам.

Тәслимәнең әтисе Борһан турында уйлыйм. Ни өчен шулай усал булды икән соң ул, дим. Шәмәхә-зәңгәр күзләре дә Тәслимәнекедәй ягымлы шикелле бит инде беренче карауга. Йөзе дә Тәслимәнеке сыман түм-түгәрәк, бит алмалары күпереп тора. Мыегын кырып атса, бөтенләй юаш кешегә охшап калыр иде ул, мөгаен.

Ничек җилтерәтеп алып кереп китте теге вакытны, тау шуганда, Тәслимәсен... Тәслимәнең чанасы зур — ялгызы гына тауга тартып менә алмый. Йә көрткә кереп бата, йә таеп егыла. Аның шулай азапланганын карап-карап тордым да, икәү утырып шуарга ризалык бирсә, булышырга булдым. Риза булмаган кая — сөенечтән салават күпере кебек балкыды Тәслимәнең күзләре. Сүземне әйтеп бетергәнче, чана бавын китереп тә тоттырды кулыма.

Чанага аллы-артлы атланып, колак төбендә күңелле җил сызгыруын ишетергә, тизлек рәхәтен тоярга, тирә-якта бөтерелеп калган кар өермәсе аша нәни йолдызчыклар күреп сөенергә җыенганда гына, ниндидер көчле кул Тәсләмәне чанасы-ние белән югарыга алып менеп китте. Шул ук кул мине көрт эченә күтәреп атты. Башымны калкытып карасам — Борһан. Мыегының бер очы өскә, икенчесе аска тырпайган. Бияләе сарык бәрәне хәтле генә түгелдер. Шундый зур, йонлач бияләйле кулын миңа табарак сузып, каршы искән җил кебегрәк ышылдады ул кызына:

— Тагын бер мәртәбә Рәхимнең шушы елак малае тирәсендә чуалганыңны күрсәм, чәчеңне бөртекләп йолкып бетерермен... Чана шуасы килсә, бау таксын да әнисенең кер тигәнәсен тартып чыксын...

Бик гарьләндем инде мин бу хәлгә. Шул ук сәгатьтә әнигә кайтып әләкләдем.

— Мәрхүм булса да әйтим инде, әтиең белән тыныша алмадылар, — диде әни, үпкәле тавыш белән. — Борһан абыең колхоз болыныннан үз хуҗалыгына печән төяп кайта икән дә, әтиең — председатель бит инде — юлына аркылы төшкән моның. Олавын да, үзен дә кәнсәләргә алып кайткан. Суд ясап, Пермь ягына урман кисәргә җибәрделәр Борһанны. Елдан артык эшләп кайтты... Бик кызу канлы иде шул әтиең, дөреслек дигәндә, күрше хакын да, туган ха-

кын да хуплап тормый иде. Авыр туфрагы җиңел булсын, ул яшәми менә хәзер кеше белән, без яшибез...

Әлеге вакыйгадан соң биш-алты ай гомер узгач, мондыйрак хәл булды. Бүгенгедәй хәтерлим, юл читендәге үләннәрдә көмеш кырпак җемелди иде. Борһан, атын җай гына атлатып, яшелчә җиреннән кайтып килә. Сабагы-ние белән кишер төягән. Кишере дә кишер дип әйтерлек түгел инде. Печән арасында йөргән кызыл тараканнар кебек тегендә бер, монда бер генә ялтырап күренгәли.

Олау артына Тәслимә менеп кунаклаган. Кулында да кишер моның, авызында да кишер.

Безнең яннан узганда, Тәслимә, кулындагы кишерен изәп, мине арба янына чакырды. Атылып кына бардым инде. Тәслимә, күзләре белән генә елмаеп, кулындагы кишер бәйләмен миңа ыргытты. Эләктереп тә алдым яшелле-кызыллы бәйләмне, Борһан арбадан сикереп тә төште, күн итек белән йомшак җиремә китереп тә типте.

Алга таба карап сызгырынып баргач, мин аны бернәрсә дә күрми дип торам. Астыртын гына күзәтеп барган икән, албасты.

Бөтерелеп кенә төштем. Тәслимәнең: «Әти, тимә аңа», — дигән сүзләре әллә кайдан, җир астыннан ишетелгәндәй булды. Каттым да киттем. Елау түгел, сулыш та алып булмый хәтта.

Мин еларлык хәлгә килгәндә, арба шактый ераклашып өлгергән, олаудагы кишерләр, Тәслимәнең карасу-соргылт кофтасы, Борһан Кукамайның имән яркасыдай киң аркасы, иләк кадәрле кепкасы — барысы-барысы бергә буталып, тонык инеш төбендә таралып яткан төрле төстәге чуерташларга охшап кына күренәләр иде инде.

Дөньяга шулай күз яше аша карап торганда, капкаларыннан, кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә, Нәфисәттәй килеп чыкты һәм, рәхәтләнеп еларга да ирек бирмичә, «һай кансыз, һай миһербансыз» дип сөйләнә-сөйләнә, мине әни янына җилтерәтеп алып керде.

— Әллә бакчагызны басканмы? — диде әни, кәҗә савып утырган җиреннән сикереп торып. Аның кулындагы чүлмәге кыегаеп, сөте җиргә түгелә язды.

— Менә Борһан Кукамай көпә-көндез малаеңны типкәләп ташлады... Чәнчә бармак кадәрле кишер өчен үтерә язды нарасыйны... Куй чүлмәгеңне, әйдә, хәзер үк кәнсәләргә барабыз... Ирсез хатын дигәч тә, безне теләгәнчә мыскыл итәргә, күз карасы кебек кадерләп үстергән балаларыбызга кул ягарга ни хакы бар аның?! Сугыш вакытында фронтовиклар өлешен ашап симерүе җитмәгән... Инвалид, имеш, бу. Сугышка бармыйча кем инвалид бу-

ла инде, җә? Әйдә, хәзер үк авыл советына чакырсыннар. Үзем свидитель булам...

Әни, чүлмәген күкрәгенә кысып торкан көе, безгә якынрак килде. Керфеген дә кыймылдатмыйча, кызгану тулы күзләрен миңа төбәп торды, аннары Нәфисәттәйгә борылды:

— Бармыйм, күрше. Теләсәң ни әйт, бармыйм кәнсәләргә. Кеше белән булышып, кеше көлдереп йөрисем килми... Ә Борһанга җае белән үзем әйтермен мин. Рәхмәт яклашып йөрүең өчен, мәгәр кәнсәләргә бармыйм.

Нәфисәттәй Тәслимә биргән кишер бәйләмен дә кулына тотып кергән икән. Аны ачу белән әнинең аяк астына ташлады, ярсуын көчкә тыеп:

— Әй, ник чәнчелмисез тагын... Берәү аңа яхшылык итеп йөри... Кеше көлдермим дип, имгәтеп ташласыннар тагын малаеңны... Үз кайгым үземә җитмәгәнме соң?.. Мин тилегә нәрсә кирәктер шулар арасына кысылып йөрмәсәм, — диде, капканы шапылдатып ябып чыгып китте.

Әни, кулындагы чүлмәген кая куярга белмәгәндәй, тегеләй таба барды, болай килде дә шыр ачык торган чолан ишегеннән кереп югалды. Кире чыкканда, кулында чүлмәге юк иде инде аның.

Яулыгын төзәтеп бәйләгәндә дә, сукмак буенда чәчелеп яткан кишерләрне җыйганда да, ул аны-моны дәшмәде. Җыйган кишерләрен минем кулга тоттыргач кына:

— Әйдәле, улым, — дип, мине буш кулымнан җитәкләде.

— Кәнсәләргәме? — дип шыңшыдым мин.

— Кәнсәләргә түгел, Борһан абыеңа кишерләрен илтеп кайтабыз.

— Урламадым ла мин ул кишерләрне...

— Күп сөйләшмә, әйдә, дигәч, әйдә син...

Әни мине, чаптыра-йөгертә, урам буенча җилтерәтеп китте.

Тәслимәләрнең биек койма белән уратып алынган ихаталарына җитәрәк, мин тагын тыпырчынып, тартышып карадым — әмма кая ычкыну — әни шундый чытырдатып кыскан кулымны, гүяки караңгы урман арасыннан барабыз да, гүяки ул минем адашып калуымнан курка.

Капкалары янгын сарае биеклеге булса да, бик җиңел ачыла икән. Ат ишегалдында. Арба да шунда. Кишере генә күренми. Кеше затыннан Борһан үзе генә, ахры. Безне күргәч, ул да лапас астына кереп китә башлаган иде, әмма нишләптер кире чыкты. Бер якка кыңгырайган кепкасын турайтып, борын астыннан гына нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана, ат янына килде, тезгенен тарттырып бәйләргә теләде, ләкин ат һаман да чирәмгә ымсына, тезген очын дуга

алкасына киерттерми иде. Борһан, һи, бирән корсак, туймассың икән, дип, дөпелдәтеп атның аяк астына типте. Ат, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп, ялларын туздырып, сбруйларын шалтыратып, башын күтәрде; менә шундый инде минем хуҗам дигәндәй, күзен мөлдерәтеп безгә карап алды.

Борһанның саллы итек башын кабат татып карыйсым килми иде — ничек кирәк алай әни кулыннан ычкынып, капка баганасына сыендым.

Әни Борһанга якын ук килде. Яфраклары шиңеп өлгергән бәхетсез кишерләрне аның борын төбендә үк селкеп:

— Алып килдек менә. Малай берсенә дә кагылмады, барысы да шул килеш, — диде.

Борһан әни кулындагы кишерләрне җиргә бәреп төшерде. Әнинең йөзенә карамыйча гына чәпчергә тотынды:

— Әй, йөрмәсәгез лә монда эч пошырып, сару кайнатып, мәшәкать юктан мәшәкать ясап... Укасы коелмагандыр әле малаеңның... Бик кадерле булгач, биләүгә билә дә бишектә үстер...

Урамда чагында әни тыныч кебек иде. Артка шуып киткән яулыгына, маңгаена тузып төшкән чәчләренә, рәхимсез ялтыраган күзләренә карагач, мин аның үз-үзен чак кына тыеп торганлыгын аңладым.

— Син миңа шуны әйт, нигә тиясең ул малайга, нигә кыйныйсың аны? — диде әни, әле бер яктан, әле икенче яктан Борһанның алдына төшә-төшә. — Әтисе үчен баладан алмакчы буласыңмы? Бер генә тапкыр тотмады бит сине, колхоз малын урлаганда, аның әтисе, бер генә тапкыр кичермәде. Әллә мине бернәрсә дә белми бу дип уйлыйсыңмы? Оятсызлыкның, намуссызлыкның соңгы чигенә җиттең бит син ул чагында. Көпә-көндез җәмәгать милкенә кул яккач, нишләтсен ул сине? Аның урынында булсаң, син нишләгән булыр идең менә? Читтән генә күзәтеп торыр идеңме аның урынында булсаң? Сугыш вакыты иде бит, башың белән уйлап кара.

Борһан, кулларын калтыратмаска тырышып, тәртәгә аркалык очын бәйләгәндә, авызын кыйшайтып көлде.

— Бик рәхәт күрде инде үзе... Инвәлитне рәнҗетеп... Сезгә дә алтын сарайлар салып калдырды әнә... Авыз тутырып ипи ашыйсыз... Һи, мин аның урынында булсам...

Әни, бер кулы белән тәртәгә тотына-тотына, ат белән Борһан арасына кысылып керде, юка иреннәрен тешләштергәләп, башын селкеп торды һәм кинәт кенә тач итеп Борһанның йөзенә төкерде.

— Менә сиңа кабердәге иремә тел тидергән өчен...

Мин бу хәтлесен көтмәгән идем. Сискәнеп, челтәрле тәрәзәләргә күтәрелеп карадым — кыймылдаучы күрен-

мәде. Тәслимә дә юк, эниләре дә. Әллә Борһан базга ябып куйды микән барысын да...

Борһан да көтмәгән булгандыр, күрәсең, бу хәтлесен. Ул, артка тайпылып бастырык юанлыгы җиңе белән йөзен каплап торды. Әнинең кабат һөҗүм итмәячәгенә ышангач кына тураеп басты, учы белән йөзен сөртеп алды һәм сыер чаклы гәүдәсе белән сүзсез генә әнине капкага таба кысрыкларга кереште.

Борһан әнине этте, әни — мине. Йомычка кебек кенә очып чыктык биек капканың теге ягына.

Безне чыгарып җибәргәнче түзде Борһан. Безне чыгарып җибәреп, капканы шартлатып бикләп куйгач кына рәхәтләнеп сүгенде...

— Үсеп җитәр әле, Аллаһы боерса, минем малай да, — дип кычкырды әни, мин кулыннан тотып йолкыган саен, капкага таба ныграк тартылды. — Типкәләтмәс әле ул синең ишеләргә генә...

Әни башка сүз әйтмәде. Ачуланмады, күз яшенәме буылып, тынып калды.

— Синең ул тегәрҗеп муенның, норсыз салам сыйрагың адәм рәтенә кергәнче, ахырзаман җитәр әле, — дип кычкырып көлде теге якта Борһан. — Үсеп җиткәч тә, сиңа рәхәт күрсәтәсе юк аның. Күсәк хәтле булганчы, синең җилкәңне кимереп ятачак та шәһәргә чыгып таячак, менә шул җүләр әйткән ие диярсең... Колхозда эшли торган малай башка камырдан әвәләнгән була ул... Урамнан узган атларга капка астыннан гына карап ятмый ул колхозда эшли торган малай...

Колакларым күмер кебек көйри. Әнине узып йөгерергә дә, артта калырга да белмим. Борһанның күн итек белән тибүе чүп кенә булган икән... Менә бу сүзләре белән үтерде ул мине, маңгайга типте, суйды, урамга чыгарлыгымны калдырмады. Тәслимәсе ишетеп торган булса тагын... Тегәрҗеп муен, ди бит. Үләрсең хурлыгыңнан.

Айравык тыкрыгына борылгач, муенrealма бармакларны тидереп карадым. Алай ук нәзек түгел лә инде. Арттыра Борһан Кукамай...

Ә Мөнәвәрә апа очтакка барасыңмы, ди. Әнә шундый хәлләрдән соң ничек барасың инде Борһан янына... Их, үсеп китәсе иде хәзер. Борһан аты Каенлык күперенә кереп батсын иде, әһ тә итмичә, аты-ние белән тигез юлга чыгарып куясы иде тегене. Әйтеп карасын иде аннары Борһан тегәрҗеп муен, дип.

Ничек була икән соң ул очтак? Бер генә көнгә барып карасам, нәрсә булыр икән соң? Нигә, кыен булса, качармын. Фәхерли качкан ич әле әнә...

Әни судан кайтты. Чиләкләрен басма алдына утыртып, фанер кисәкләре белән каплап куйганы ишетелде. Чолан почмагында көянтә шылтырады. Хәзер өй ишеге ачылачак. Юк, ялгыштым. Өй ишеге урынына яңадан чолан ишеге ачылды. Баш очымда гына чирәм кыштырдады.

Әни көндез мин чыбык тураган бүкән өстенә килеп утырды. «Бигрәк бөркү киче дә, яңгыр явар, мөгаен», — дип, яулыгын чишеп бәйләде. Тирән итеп көрсенде. Уйга талып, бармакларын минем чәч араларымда йөртергә кереште.

— Каты чәчләрең... Нәкъ әтиеңнеке төсле.

Тавышы моңсу-моңсу иде әнинең.

— Әни, врачлар салкын тигән кешеләрне дәвалыйлар бит. Әтине ничек дәвалый алмадылар икән соң?

— Бармады врачка. Әйткән саен сузды. Әлек тә авырган булган ул үпкә авыруы белән. Врачлар әйтеп чыгарганнар бульнистән. Салкын тидермә, дигәннәр. Ә бу колагына да элмәде. Корык-корык йөткерсә дә, колхозда теге эш бетмәгән, бу эш төгәлләнмәгән, дип йөри бирде. Районнан рәзнәрәткә килгәч, шулай корык-корык ютәлләгән көе, окоп казырга кешеләр җыеп китте. Үзе бармаса да була иде югыйсә... Шуннан өзлегеп кайтты.

— Елама, әни. Әти турында сөйләсәң, син һаман елый башлыйсың. Мине кулына алган чакларда ни дип әйтә торган булган әле ул? Шуны сөйлә миңа.

— Хәере белән үсеп җиткәнен күреп буламы, юкмы шул малайның, дия торган иде...

— Тагын ни дип әйтәдер ие?

— Тавышы-тыны юк ла бу баланың, дип, төненә әллә ничә торып карый торган иде синең бишегеңне. Төшемдә гел ак яллы аргамаклар тирәсендә чуалганын күрәм, улыбыз бәхетле булыр әле, дип әйтә торган иде аннары.

Әни моңсу тавыш белән сөйли дә сөйли. Мин ул сөйләгән сүзләрнең мәгънәсен аңламыйм да инде. Төн пәрдәсе ябынырга өлгергән каеннарның серле шавына, Түбән урамнан күтәрелеп чыккан ялгыз гармун тавышына, чирәм исенә кушылып эри аның сүзләре. Күңелем болыннарына ак ялларын туздырып, башларын югары чөеп, алмачуар атлар чабып чыга. Атлар якынайган саен, фикерләрем дә ачыклана бара. Бүген көне буе җанны борчып, бәгырьне авырттырып йөргән газаплы сораулар-га җавап тапкандай, җиңеләеп калам. Эчемдәге билгесез шикләрне, яшерен куркуларны чәлпәрәмә китереп, ак яллы аргамаклар чаба. Әллә кичке һаваның сафлыгыннан, әллә әни кулларының җылылыгыннан, әллә хыялларымның яктылыгыннан тәнемдә көч артканын тоям.

Күңелемдәге үзгәрешләр йөземә дә чыккандыр, ахры. «Ни булды сиңа, улым?» — дип сорады әни, бераздан сөялле учлары белән яңакларымны йомшак кына кысып.

— Син ачуланмасаң, барып карар идем мин очтакка, әни.

Әни яңакларымнан кулларын алмый гына караңгы эңгер эчендә югалып барган каеннарга йөзен борды.

— Ни әйтергә дә белмим инде, улым. Көне буе шул хакта уйлап йөрдем үзем дә. Күнегеп, иyләшеп тә китәр идең, шәт... Уракчысы кеше төсле булса...

— Кайгырма, әни... Иyләшермен, күнегермен... Беренче генә тапкыр атлану түгел атка...

Без инде сөйләшмибез. Төнгә карап, төнне тыңлап кына утырабыз.

Ерак басулар өстендә ялт-йолт аҗаган уйный.

Әнинең сөялле учлары һаман да яңакларымны җылытып тора.

Хыялымда тавышсыз-тынсыз гына ак яллы аргамаклар уйнаклап йөри...

## Булмас, ахры...

— Кыерсытма, кара аны, Борһан абый, егетнең иң кәттәсен алып килдем.

Борһан Мөнәвәрә апага авызын кыйшайтып, көлемсерәп карап торды да минем якка борылды. Аның мыскыллы карашы иң элек кулымдагы төенчекне капшады. Аннары чалбарымның ямауларына тукталып торды, җиң очлары чукланган күлмәгем буенча шуып үтте, янә түбән төшеп китте. Чебиле аякларым арасында адашып йөрде. Аннары тагын өскә күтәрелә башлады. Муеныма, аякләремә менеп җитте.

Хәзер, менә хәзер очрашачак безнең күзләребез. Күтәрә алсам гына ярар иде аның мыскыллы карашын. Елап җибәрмәсәм генә ярар иде.

Әмма минем тырышуым бушка гына булды. Карамады Борһан күзләремә. Борыныма карады, маңгаема, хәтта түбәтәемә чигелгән чәчәкләргә дә көлемсерәп карап торды сыман, ә күзләремә карамады.

Мыегының аска салынып төшкән очын кырт итеп тешләп җиргә төкергәч, бер читтәрәк елмаеп торган Мөнәвәрә апага нәрсәдер әйтмәкче булды да кире уйлады. Киң кепкалы башын алачык ягына кыйшайтып алды.

— Әйдә, башта пычкы кайрыйбыз...

Учагында аксыл күмерләр елтырашып яткан алачык бусагасын атлап кергәндә, Мөнәвәрә апа минем арттан:

— Хәерле сәгатьтә, Рәсим, — дип кычкырып калды.

Ай-һай озак кайрыйлар икән урак машинасының пычкысын. Чарны башта уң кул белән әйләндерәм, анысы арыгач, сулы белән. Аннары ике куллап әйләндерергә тотынам.

Борһан пычкы тешләреннән гөжләп атылып торган очкыннар өстенә иелгән. Әллә бар мин аның өчен, әллә юк. Электр кайрагы көйләп куйган диярсең. Кулларым талып, эш акрынайса, кайраудан туктап, чарның кызурак әйләнә башлаганын көтеп тора. Кайчагында әллә юри баса инде кайракка пычкы тешләрен — олы тәгәрмәчкә ике потлы гер таккан кебек авырая чар... Бер, ике, өч... Ничә теше бар икән соң бу пычкының?.. Йөз мең генә очкын чыкмагандыр инде үзеннән, ә үзе һаман кайралып бетми... Борһанның муены нинди юан. Ат муены шикелле... Алачык стенасында чөйләр. Чөйләрдә дагалар, алкалар, аеллар... Берсендә минем төенчек. Төенчектә биш бәрәңге, өч йомырка, бер чәкүшкә сөт. Хәзер үк ашыйсы килә башлады. Төшкә кадәр күзең күгәрер әле... Бер, ике, өч... Маңгай тирен җиң белән дә сөртеп алып була, арка тирләве яман икән. Тау буендагы әнә теге колын кебек ятып ауныйсы иде чирәмгә... Бер, ике, өч... Олы тәгәрмәч куәтлерәк әйләнгән саен, очкыннар мулрак сибелә... Бер, ике, өч... Борһан киемнәренә сеңгән инде әллә кипкән көнбагыш исе?.. Бер, ике, өч... Дүрт, биш... Хәл дә бетте, Борһан да пычкысын кайрактан алды.

Урамга чыктык. Борһан кулындагы пычкы тешләре, җем-җем килеп, кояш нурларында уйный.

Амбарлар тирәсендә халык арба майлау, ат җигү белән мәшгуль.

Амбар эчендә Гыйззәт бабай камыт төзәтеп утыра иде. Безне күргәч, камытын бер якка куеп, аяк өстенә басты.

Борһан Гыйззәт бабай белән баш кагып кына исәнләште дә пычкысын амбар ишегенә сөяп куйды; түргә узып, шүрлектән ике камыт сөйрәп чыгарды, камытларның икесен дә бер беләгенә кидерде, буш кулы белән искиткеч оста кыланып, шул ук шүрлектән дилбегә, шлея, йөгән ише сбруйлар алды.

Амбардан чыгып барышлый, минем якка ымлап:

— Очтакка бара... Карлыгач сбруйларын җыеп бир шуңа, — диде.

— Агач авыз, гомер буе кеше белән адәм рәтле сөйләшә белмәде, — дип, кулындагы каеш кисәкләрен әрҗәгә ташлады Гыйззәт бабай, Борһанның аяк тавышлары ераклашкач. — Карлыгач — сылу хайван, улым. Камытлыгына суктыра күрмә, карап йөртә күр... Ничә көнгә килдең соң?

— Белмим әле.

— Качмасаң, яңа йөгән бирәм менә. — Гыйззәт бабай, күн исе аңкып торган сары каеш йөгәнне минем каршыма ук китереп, чылтыратып алды. — Качмыйсыңмы?..

— Белмим. Эшләп карыйм әле...

— Шулай диген. Турысын әйтеп сөйләшкән егетләрне яратам мин. Туктале, Рәхим малае түгелме соң син?

— Шуныкы.

— Менә син, әй... Колхоз эшенә ярый башладым диген. Бик хуп. Әтиең күрсә, сөенер иде. Вакыты белән корырак булса да, гадел кеше иде әтиең. Иң авыр елларда бергә эшләдек. Сынатмады, соңгы чиккә җитеп, урынга егылганчы, колхозны ташламады... менә син, әй... Исемең ничек дисең әле?

— Рәсим.

— Рәхим — Рәсим. Бик хуп, бик хуп... Алайса, без болай итик, Рәсим. Ал да менә яңа йөгәнне, Карлыгачны тотып чык. Ә мин шул арада сиңа башка сбруйларны әзерләп куярмын.

— Рәхмәт, Гыйззәт бабай...

Ул да түгел, тышкы яктан Борһанның ачулы тавышы ишетелде:

— Әй, син, кая олактың? Басуга төш җиткәч кенә барырга уйлыйсыңмы әллә? Алып бир пычкыны...

Атылып чыксам — Борһан Урал белән Җирән байталга камытлар да киереп куйган. Әллә атланганын күрсен дип, юри чакырып чыгарган инде мине — кай арада Уралның тезгенен Җирән байтал йөгәненә китереп бәйләде, кай арада Җирән байталга менеп атланды, кай арада минем кулымнан пычкыны тартып алды.

Борһан тезгенгә орынгач ук, эре сөякле күндәм атлар тигез адымнар белән ферма ягына юыртып киттеләр.

— Казаклар кырында урдырабыз, куып җитәрсең, — дигән сүзләре генә ишетелеп калды Борһанның.

Карлыгачны чак кына эзләп таптым. Ат абзарының иң аргы башындагы аранда икән. Карасу-көрән төстә булганга, ерактан күренми дә.

Башта миңа игътибар итмәскә тырышты. «Һәй, әйдә, борыл әле монда, киеп җибәр әле яңа йөгәнне», — дип, авызлык тимерен чылтыраткач та исе китмәде. Утлыгыннан тукранбаш умырып капты да ачуланып минем өскә селкеп ыргытты. Куркыттым микән дигән сыман, колакларын шәмрәйтеп, кырын күз белән генә миңа карап торды һәм янә утлыгына авызын төртте.

— Юк инде, Карлыгач, алай булмый. Эшкә барырга кирәк, уракка, — дип көйли-көйли, күршедәге буш аран

аша Карлыгач утлыгына якынлаштым. Киртә астыннан иелеп кереп, маңгай ялыннан әләктереп алдым дигәндә генә, Карлыгач миңа артын борып куйды. Өстәвенә койрыгы белән яңагыма да сыдырып җибәрде. Кергән юлдан кире чыга башлаган идем — Карлыгач утлыгына борылды.

— Һайт, наян!

Кем кычкыра икән дип борылып карасам — Гыйззәт бабай елмаеп тора.

Аның тавышын ишеткәч үк, Карлыгач, мине санга сукмавы өчен уңайсызланган сыман, башын иеп, дөбер-дөбер безнең якка борылды. Муенын алга сузып, тыныч кына йөгән киерткәнне көтеп торды.

— Ат янында бераз кыюрак бул, — диде Гыйззәт бабай, Карлыгачны шулай бер әйтү белән тыңлата алуына кәефе килеп. — Атлар алар, чытлык кызлар шикелле, каты куллы егетләрне яраталар...

Карлыгачка атланып ферма артына килеп чыгуга, яшел уйсулыкның инеш белән коры елга килеп кушылган турында аклы-кызыллы шәүләләр күземә чалынып китте. Борһан атлары.

— Әйдәле, Карлыгач, куып җитик әле Борһанны... Башыңны иеп чапма алай. Җә камытыңны чыгарып төшерерсең. Әнә нинди биек быел арыш. Башаклары да шактый эре күренә. Кем белә, көзгә, шәт, авыз тутырып, ипи ашарбыз быел. Ипле генә йөрсәң, сине дә сыйлармын ипи белән. Ишетәсеңме, Карлыгач... Минем төенчеккә күзеңне тозландырып барма алай. Нибарысы биш бәрәңге анда. Һам итәргә дә җитми сиңа...

Шактый кызу юыртса да, Урал белән Җирән байталны куып җитә алмады Карлыгач. Артык ашыктырмадым да, хәер. Куып җитәргә тиеш булсам да, куып җитәсем килми иде минем аларны.

Борһан инде, кичә үк Казаклар басуын бер кат әйләнеп, карта алып куйган икән. Юл буенда бәйләнеп ташланган, ләкин әле чүмәләгә куелмаган көлтәләр тәгәрәп ята. Басуның урылган өлеше бөтен җиренә тигез итеп сары кадак кагылган бормалы юлны хәтерләтә.

Зәңгәр канатларының дүртесен дүрт якка сузып торган урак машинасы янына килеп туктадым. Борһан пычкыны беркетеп тә куйган. Атларын җигеп маташа. Мин килеп туктагач, авызын бөгерәйтеп көлде:

— Адашып йөрдең, ахры, басу белән авыл арасында.

Аны-моны әйтмәдем. Камыл тапталганрак урынга шуып төштем дә Карлыгачны дүртпочмаклап юнылган озын тәртә башына алып килдем. Читкә караган булып кына, Борһанның атларын ничегрәк җиккәнен күзәтеп-чама-

лап алдым. Берние дә юк икән лә. Ике постромка бавы да бер вәлүк. Эләктерденң куйдың...

Борһан, дилбегәсе белән озын саплы сүс чыбыркысын тотып, төбенә печән җәелгән тимер утыргычка менеп кунаклады. Мин, ничек кирәк алай, Карлыгач сыртына үрмәләдем.

— Куала! — дигән тавыш ишетелгәч үк, тезген очын болгап җибәрдем — Карлыгач капылт кына алга тартылды һәм юыртып диярлек басу читенә таба элдерде.

Әйләнеп карасам — Борһан атлары урыннарыннан да кузгалмаган...

Мин Карлыгачны кире борып килгәндә, Борһан чыбыркысын тез арасына кыстырып куйган, дилбегәсен бушаткан, ә үзе рәхәтләнеп айгылдый иде.

Тагын камыл өстенә шуып төштем. Карлыгачны тагын тәртә башына китереп борып куйдым. Әй, әллә ни булмаган икән лә, постромка бауларын вәлүк очына керткәч бәйләп куярга гына оныткаммын.

Бу юлы җиренә җиткереп җиктем. Карлыгач та бу юлы тезген очын селкегәч үк җилкенеп китә алмады. Башта артындагы йөкнең авырлыгыннан бөтен мускуллары калтыранып куйды. Бары тик Урал белән Җирән байтал кузгалып, ургыч канатлары әйләнә башлагач кына җиңеләебрәк атлап китте.

Белмим, ургыч канатлары ничә тапкыр гына җилпенеп калгандыр. Артта «тыр-р» дигән тавыш ишетелде. Карлыгач лып туктады. Мин, ат башы аша җиргә мәтәлеп китмәс өчен, камытка ябыштым.

Озын саплы чыбыркысын селки-селки, Борһан килеп җитте. Йөзендә дә, сүзләрендә дә рәхим-шәфкать юк иде аның.

— Күзең чыкмагандыр ич синең, малай актыгы. Кая бер чакрым читтән алып барасың атыңны. Якынрак тот арышка...

Артта урак машинасы шылдырый, атлар пошкыра. Канатлар пычкы кискән учмаларны лафетка аударып киләләр дә, авырая башлагач, камыл өстенә этеп төшерәләр...

Инде мин дә Карлыгачны арышка якын ук тотып куалыйм. Хәер, барыбер сыртында кем утырганын сизә бугай Карлыгач. Биш-алты адым атлый да, башын арыш арасына тыгып, үлән каба. Тезгенне кире якка тартсам, постромкалар бушый.

Ялан аякларымны селкеп, Карлыгачка үлән каптырмаска тырышуым бушка гына. Тыңламый мине Карлыгач. Колакларын шомартып, арыш арасына сузылуын белә.

Шул рәвешчә Карлыгач белән тарткалашып бара торгач, тагын җиргә мәтәлеп төшә яздым. Атлар тагын туктап калды. Ниләр генә әйтеп сүгәр икән инде Борһан бу юлы дип, артка карарга куркып, дерелдәп утыра бирәм.

Берзаманны минем яннан җил-җил килеп үтеп тә китте Борһан, чыбыркы сабы белән Карлыгачның борынына китереп тә орды. Карлыгач, чигенә-чигенә, Җирән байтал белән Урал арасына барып керде. Аягымны күтәреп кенә калдым. Югыйсә тәртә белән Урал камыты арасына кысылып харап була иде.

Ә Борһан аны-моны карамый. Кепкасының алдын артка әйләндереп кигән, күзләре чыгып төшәргә җитешкән, үзе мыек очын чәйни, үзе эһелди. Суккан саен Карлыгачның нәсел-нәсәбен искә ала.

Карлыгач, авыртуга чыдый алмыйча, аякларын күтәрә башлагач, аның сыртында озак утыра алмаячагымны чамалап, Җирән байтал аша җиргә тәгәрәп төштем.

— Тор, йә сиңа да сыдырырмын берне ачу ара, — дип җикерде Борһан, минем яннан үтеп барышлый. — Мәми авыз, пешмәгән. Ат тотарга хәлеңнән килмәгәч, пычагыма кирәгең бармы синең монда?! Урак урдыруны кәҗә артыннан йөгерү дип уйлаган, ахры...

Кызык, күпмегә җитәр икән сабырлыгым. Бер генә сүз каршы әйтим, бер сүз әйтсәм, тәпәләп ташлаячак инде ул мине. Аннары барысы да үзеннән-үзе хәл ителәчәк. Беркем дә Рәсим очтактан качып кайткан димәячәк. Борһан кыйнап кайтарган, бетте-китте...

Кичә кич, җиләс ишегалдында, йомшак чирәм өстендә ятканда, барысы да ачык кебек иде, барысына да түзәрмен дип ышандырган идем үземне. Уй-хыялларымны яктыртып, тавышсыз-тынсыз уйнаклап йөргән ак яллы аргамакларым кая качты соң әле минем?.. Кичә әни бармакларыннан сөт исе килә дип уйлаган идем мин. Ялгышканмын, кызган камыл исе булган икән ул...

— Торасыңмы син, юкмы?..

Бу юлы Борһанның тавышында янау да, куркыту да ишетелмәде. Киресенчә, үзе шүрләбрәк калган сыман иде ул. Ат өстеннән егылып имгәнде дип уйлый микән әллә мине.

Борһан ягына карамаска тырышып, аяк өстенә бастым, җил белән бер читкә тәгәрәп киткән кәләпүшемне алып кидем, каядыр сыдырылып канаган аягымны чалбар балагына ышкыдым; куркуыннан дер-дер калтырап, Борһан ягына тасраеп-тасраеп күз аткалап торган Карлыгачка таба атладым.

Карлыгач миннән дә курыкты. Тезгененә үрелгәч, ба-

шын кинәт бер якка борып, артка чигенде. Ләкин тезген очы минем кулда иде инде. Карлыгачны акрын гына алга әйдәдем. Вәлүк аша атлатып, постромка бауларын рәтләдем һәм, бөтен көчемне беләкләремә туплап, ни булса, шул дип, Карлыгачның сыртына сикердем. Аягымны постромка элмәкләренә куеп маташмасам да, егетләрчә килеп чыкты бу юлы. Сөенечемнән бөтен гәүдәм буенча салкынча рәхәтлек йөгерде.

Күрде микән минем егетләрчә сикереп атлануымны Борһан, юк микән — бу хакта уйларга вакыт калмаган иде инде — Урал белән Җирән байталның тынычсызланып пошкыруыннан кузгалырга сигнал бирелгәнен төшендем.

Инде Карлыгач та башын уңга-сулга боргалап маташмады, нәкъ үз вакытында, менә мин ничек тә тарта беләм дигәндәй, җилдереп алып китте.

Көтеп кенә барам инде хәзер — кайчан «тыр-р» дип кычкырыр тагын Борһан. Карлыгачка тезген очын күрсәтәм, арыш ягына ымсындырмаска тырышам.

Хәвеф-хәтәрсез генә шактый җир киттек бугай. Чикләвек куаклары белән уратылган чокыр яныннан урып уздык та үргә килеп мендек... Без урасы басу ай-һай зур икән. Дими тобасы кебек кара-кучкыл. Бөтерелеп-бөтерелеп дулкынлана арышы.

Күл басуына ялгыз комбайн килеп туктаган. Ургычы киң дә инде. Моннан шулай күренә әле. Янына барып карасаң, хәйрандыр...

Кайчан бөтен басуларны комбайннар гына ура башлар. Иллә рәхәт булыр иде. Малайларның теңкәсен корытмаслар иде очтак дип... Хатын-кызлар көлтә бәйләүдән, чүмәлә куюдан котылырлар иде...

Әйбәт барабыз бит әле, күз генә тимәсен. Каршыдагы урман без якынайган саен яшәрә бара. Урман буенда җиләс булыр иде инде, шәт. Бик яман кыздыра башлады бит әле югыйсә. Карлыгачның да бөтен тәне ялтырап, дымланып чыкты. Аякларымны селкетмичәрәк барсам, түзәр хәл юк — пешерә. Үземнең дә түбәтәй астыннан, чигәләремне кытыклап, кайнар тамчылар тәгәрәшә. Мин аларны бертуктаусыз җиңнәрем белән сөртеп, корытып барам. Күлмәк тә кызып җитте. Салып атасылар килә. Нәкъ калак сөяге астына, кул җитми торган җиргә бер кылчык кереп оялады, җитмәсә. Азрак кыймылдадың исә, ата кырмыска тешләгәндәй чеметтерә. Көне дә иртә бит әле. Сәгать сигезләр бар микән, юк микән? Төшкә таба ниләр күрсәтер әле бу кояш миңа...

Артта урылган арыш өемнәре тоташ сары чылбыр булып еракларга тезелеп киткән. Куак ышыгында утырган

булганнардыр, ахры, бераздан басу өстендә чуар киемле хатын-кызлар пәйда булды. Арыш учмаларын бөтереп, көлтә бавы ясыйлар, тезләре белән баса-баса, көлтә бәйлиләр.

Борһанның күзләре пычкыда. Мыек очлары салынып төшкән. Түгәрәк йөзендә салкын көлемсерәү катып калган. Дилбегәсе буш, чыбыркысын итек кунычына тыккан. Аның атлары нишләптер тирләми әле.

Урман өскә аварлык булып якынайгач, борынга дымлы үлән исе, имән кайрысы исе, гөмбә исе һәм тагын әллә нинди тәмле исләр килеп бәрелде. Их, атка атланган көе урман ешлыгына кереп китәргә иде... Юк шул, борылырга вакыт җитте... Борылыйм дип, тезгенне ныгытып тартуым булды — артта чыбыркы сызгыруы ишетелде. Карасам, Борһан, атларын турыга ярдырып, урманга таба выжылдата, ә минем Карлыгачым машинага яны белән әйләнеп баскан. Ягъни ул машинаны түгел, машина Карлыгачны тартып бара...

Постромкалар чуалып, чөелдерек чишелеп киткәч, бушап калган вәлүк ыргагы-ние белән тәртәдән суырылып чыкты. Карлыгачны чүт кенә бер якка тайпылдырып өлгердем. Күзләрен машина пычкысына терәп, көлемсерәп утырган Борһан мине тәртә башы белән бәрдереп китә язды.

Тезгенемне тартып, җиңеләеп пошкырынган, рәхәтләнеп башын чайкаган Карлыгачка атланган килеш, басу почмагында торып калдым мин. Борһан, мине дә, Карлыгачны да бөтенләй күрмәгәндәй, атларына чөңгергәли-чөңгергәли ары урдырып китте.

Монысын инде ни дип тә әйтеп булмый иде. Монысы инде чамасыз кылану иде. Болай мыскыл итүгә еламыйча да түзәрлек түгел иде.

— Әй, тукта! — дип кычкырдым мин, еларга җитешеп, һәм елап та җибәрдем.

Борһан һаман саен ераклашты. Машина шылтыравы ишетелми башлагач, ачуыма, гарьлегемә чыдый алмыйча, җиргә төштем. «Нога, нога», — дип дөнья кубарып кычкыра-кычкыра, Карлыгачның аягын күтәртеп, тояк эзенә изелеп кергән чөелдерекне тартып алдым, ике якка җәелеп киткән камыт меләшәләрен җыеп бәйләдем, вәлүкне җилкәмә салдым да, Карлыгачны җилтерәтеп, урман буенча титакладым.

Басуның урман ягы киң түгел. Яшь туйралар шаулап утырган борылышка якынлашкач ук агачлар арасыннан аклы-кызыллы пар ат һәм төрлесе төрле якка тырпайган зәңгәр канатлар күренде.

Борһан да җиргә төшкән. Ак кофталы хатын-кызга, кепкасын селки-селки, нидер аңлата.

Килеп җитәрәк кенә таныдым: Мөнәвәрә апа икән. Бер кулы белән чәч үремен чорнап тоткан, икенче кулында сажень. Күзләреннән хәтәр очкыннар сибелә. Шактый җилле сөйләшәләр бугай болар.

Ишетсеннәр дип, юри кычкырып туктаттым атны:

— Тыр-р, тыр-р... Кая өскә киләсең. Күзең чыкмагандыр ич, норсыз хайван...

Исләрендә дә юк, әйләнеп тә карамадылар. Ничек инде? Нәрсә ди, ничек ди Борһан Кукамай? Кирәкми миңа очтагыгыз чуртыма да, диме? Ничек инде кирәкми? Мөнәвәрә апаны да шул сүз аңгырайткан, ахры. Бер-ике авыз сүз әйтә дә чәч үремен тарта, бер-ике авыз сүз әйтә дә чәч үремен тарта.

— Мәйтәм, синең белән мин дә, Мөхәммәтәмин дә чыгарган карар түгел, Борһан абый... Идарә чыгарган карар... Белдеңме? Очтак җигеп урдырырга кушканнар икән... очтак җигеп урдырабыз... Комбайнга ышанып булмый... Бүген бирә аны МТС, иртәгә башка колхозга алып китә. Мәйтәм, ике ат белән урырсың син анысы... Бер көн урырсың, ике... Өч көн урырсың... Ә дүртенче көнне, атларың иләс-миләс йөри башлагач, узган елгы кебек, даваегыз очтак дип разбой салырсың... Уракка төштек кенә бит әле, мәйтәм...

— Бирегез соң очтакка рәтлерәк малай, — дип, кулындагы кепкасын пар күтәрелеп торган баш түбәсенә чәпеп куйды Борһан һәм минем якка ымлады. — Бу чырайсызның барыбер эшкә өйрәнәсе юк. Ике дөнья бер кәнфит аңа... Борылышта шестерняларны кырдырта язды әнә.

— Әй-әй-әй, Борһан абый. Әллә син, мәйтәм, барысын да белеп тудыңмы? Өйрәнер. Эшләргә дип килгән икән — өйрәнер.

Мөнәвәрә апа, чәч үремен бушатып, миңа күз кысып алды, сүзен дәвам итте:

— Әйе бит, Рәсим энем. Адәм баласы өйрәнмәгән эш юк дөньяда.

— Буласының буыннан билгеле... Ә бу мокыттан Аллага да, муллага да юк.

— Туктале син, туктале, Борһан абый. Кире ягың белән тормагансыңдыр ич йокыңнан, мәйтәм. Майланмаган арба тәгәрмәче кебек шыгырдыйсың да торасың... Күңелен төшерерсең баланың...

Борһан, читкә карап, мыек очын тешләде.

— Очтаксыз урдырам мин.

— Мәйтәм, ни өчен очтаксыз урдырырга тырышканыңны чамалыйм мин синең, Борһан абый... Очтакка тиешле хезмәт көннәрен үзеңә яздырырга өйрәнгән син...

Быел да шулай булыр дип уйлыйсың... Өметләнмә, язмыйбыз.

Борһан башыннан янә кепкасын йолкып алды.

— Ә кемгә язасыз аны?

— Кемгә булсын, очтак малайга язабыз.

— Очтаксыз гына урдырсам дамы?

— Очтаксыз урдырмыйсың, мәйтәм.

— Эшләгән хезмәт көннәрен башкаларга яздырттырмабыз, анньк кына грамотабыз бар, — дип, һаман да үз сүзен тугылады Борһан, Мөнәвәрә апа белән килешергә теләмичә. Ә үзе, башын аска кадап, атлар-атламас кына машинага таба кузгалды.

Борһанны ярсулы караш белән машинага кадәр озаткач, Мөнәвәрә апа миңа якынрак килде, иреннәрен ачарачмас кына елмаеп:

— Үз атлары, үз машинасы, үз басуы түгел, бер дә исең китмәсен аңа, Рәсим энем, — диде. — Вәлүгеңне ыграк эләктереп, атыңа менеп атлан да куалавыңны бел. Басу почмакларында текә борма атыңны. Лафет чыгып җиткәнен көт.

Мөнәвәрә апа киткәнче, тизрәк атка атланып калырга кирәк дип уйладым мин, урак машинасы янына бармас өчен аяк терәп тартышкан Карлыгачны җан-фәрманга алга сөйрәп.

— На-на, на, хайван...

— На-на, — дип, үчекләп каршы алды утыргычына менеп кунаклаган Борһан Кукамай мине, — арттан куганда гына «на-на» була... Һи, мәнсез. Шуны да белмәскә... Урманда туган диярсең...

Басуны бер мәртәбә дә әйләнеп өлгермәдек бит әле... Ниләр күреп, ниләр генә ишетермен икән инде тагын? Булмас, ахры. Таш бәгырьле, тимер күңелле кеше дә чыдамас монда... Ярар, төшкә кадәр түзеп карарга кирәк тә... Ашагач качармын...

## Әй, министр, атларны эчерергә вакыт!

Иң авыры беренче әйләнеш булган икән. Әллә үзем шулай тиз генә күнегеп киттем инде, әллә Мөнәвәрә апа сүзләре күңелгә дәрт бирде — куалыйм да куалыйм гына бит Карлыгачны. Борһанның да тавышы-тыны ишетелми. Кырын гына каерылып карап барам үзем: канатлар әйләнәме, лафеттан кочак-кочак арыш учмалары ишелеп каламы — димәк, урабыз... Постромка баулары кылдай тартылган, Карлыгач бөтен гәүдәсе белән алга сузылган. Димәк, Борһанның миңа сүз әйтергә хакы юк.

Бишенче әйләнешкә киттек. Астында инструментлар сумкасы белән ашамлык төенчекләре яткан көлтә турысыннан бишенче тапкыр узабыз.

Басуда чүмәләләр ишәйгәннән-ишәя бара. Ара-тирә көлтә бәйләүчеләрнең бер-берсенә шаярып кычкырган, көлгән тавышлары колагыма килеп керә.

Алтынчы әйләнештә Карлыгач мескен кара тиргә төште. Үземнең дә хәл әйбәттән түгел анысы. Бот төпләренә ике яктан да кайнар пычак ышкылып бара шикелле. Ләкин сизәм, Карлыгачның хәле минекеннән мөшкелрәк. Әллә камыты тия микән муенына? Колакларын да уйнатмый хәзер. Ничектер басылып, тынып, бөтен куәткә тырышып тарта.

Урал белән Җирәннең дә сыртлары ялтырый ялтыравын, әмма алар Карлыгач кебек үк тирләмәгәннәр. Сулыш алулары да тигез, адымнары да җиңел...

Алтынчы әйләнеш тәмамланып килгәндә, авыл ягыннан тимергә тимер бәрелгән тавыш яңгырап ишетелде. Чаң түгелме соң? Чаң бит, чаң кагалар... Борһан әллә ишетми, әллә ишетеп тә ишетмәгәнгә салыша, утыргычында киерелеп баруы бару...

Ишеткән икән. Нәкъ мин теләгән урында, астында төенчекләр яткан көлтә турысында туктатты атларны.

— Шабаш. Әбәт җитте...

Борһан авызыннан да рәтле сүз ишетергә язган икән бүген. Хәер, миңа әйтмәгәндер лә ул рәтле сүзләрен, атларына әйткәндер... Кояш кире яктан чыгамы әллә иртәгә, югыйсә миңа эндәшә бит Борһан, җир упсын, миңа эндәшә:

— Чирәмгә илтеп тышаула үләтеңне... Аннары өчесен бергә заказникка алып барып сугарып килерсең...

— Ярар, — дип кыймылдаттым мин иреннәремне.

Борһан ишеткәндерме, юктырмы, хикмәт анда түгел. Башта мин: «Ярар, Борһан абый», — диярргә уйлаган идем. Чүт кенә тыелып калдым. Яхшы сүз нишләтә кешене. Юк, болай ук җебеп төшәргә ярамый. Югыйсә күз төпләре тагын йомшый башлады.

Борһан нәрсә кыланса, мин дә шуны эшлим. Камытны салдырдым. Тезгенне, ат муенына урап, йөгәнгә бәйләп куйдым.

Борһанча ук кыланып булмый икән шул. Аның эш ходта — бер дилбегә ике атын да тышауларга җитте. Ә мин, Карлыгачны йөгәненнән тотып, тик аптырап торам.

Чүмәлә төбеннән мине Нәгыймә апа күзәтеп утырган икән. Күлмәк итәкләре белән камыл өстен себереп килеп тә җитте.

— Болай ит син аны, наным, — дип, тезгенне ат муе-

нынннан чишеп алды да, кып-кыска итеп, Карлыгачның ал аягына чорнап бәйләп куйды. — Тезгеннәре кыскаргач, аяклары да кыскара атларның...

Нәгыймә апа китә башлагач кире әйләнеп килде.

— Тагын шуны әйтим әле, наным, болай куалап, бер көндә эштән чыгарасың син атыңны. Әнә Борһан абыең атларының төкләре дә селкенмәгән, ә синеке көчкә сулап тора.

Нәгыймә апага рәхмәт әйтергә дип ачылган авызым ябылмыйча калды. Бәкәлләренә кадәр тирләгән Карлыгачны кызганудан күңелләрем әрнеп, ашыйсы килүләрем онытылып китте.

Ашыга-кабалана барып, тезгенне озайттым. Иркенләп йөрсен, ичмасам. Карлыгач качып китсә, мин дә озак тормамын, шыпыртын-шыпыртын сыпырту җаен карармын.

Борһан, чикләвек куаклары ышыгындагы чирәм өстенә кызыл шакмаклы тастымал җәеп, ашамлыкларын таратып маташа.

Күлтә астыннан үз төенчегемне алгач, Борһан янына барыргамы, әллә башка җиргә китеп ашаргамы дип икеләнеп торганда, ул үзе кычкырып өлгерде:

— Сорхантай кебек селкенеп йөреп уздырасың бит син тәки әбәт вакытын. Утыр да аша инде җәтрәк. Атларның эчәселәре килә булыр...

Борһан янына барып җиткәнче үк, ниндидер баш әйләндергеч татлы бер ис тоеп чайкалып киттем. Үлән исе дә түгел бу, чәчәк исе дә... Теге вакыт миңа кишер бәйләме сузганда, Тәслимәнең киемнәреннән дә шундыйрак ис килгән иде түгелме соң?..

Теләмәсәм дә, ихтыярсыз, Борһанга якынрак елыштым... Ипи! Җирләр генә йотсын, ипи! Ике бармак калынлыгы гына түгелдер телеме. Өске ягы ап-ак. Кар сипкән шикелле. Асты, авыз суларын китереп, кызарып тора. Алары гына җитмәгән, май ягылган бит әле телемнең бер ягына. Минем тасраеп, шаккатып карап торуымны килештермәде бугай Борһан — борын астыннан гына нәрсәдер мыгырданып, ипиен тастымал белән томалабрак куйды. Мыек очларын бәләкәй чүлмәк авызына тидерә-тидерә, сөтле токмач чөмерергә кереште.

Мин, аңа ян беләнрәк утырып, төенчегемне чиштем. Хәер, чиштем дигәч тә, бөтенләй чишеп ташламадым билгеле. Эчендә ниләр барын күрмирәк торсын әле Борһан! Иң алдан фасон өчен бер йомырка ашап куярга кирәк. Күзе янсын Борһанның. Йомырка гына ашыйлар икән болар, дисен. Аннары ике бәрәңгене. Аннары ике йомырканы... Аннары калган өч бәрәңгене. Аларын инде сөт белән...

Ипи исенә кушып ашагач, бик тиз бетә икән йомырка. Тоз сибәргә дә өлгермәдем хәтта. Әллә Борһан күрми дә калды инде йомырка ашаганны. Чүлмәген бушатып, чүлмәк төбен сөрткән ипи катысын авызына кабып җибәргәч кенә, башын минем яккарак борды. Авызын кыйшайтып:

— Йомырканы ипи белән ашыйлар аны, — диде.

Әһе, йомырка ашаганны күргән икән әле барыбер. Шуңа эче яна инде хәзер. Ничек тә булса иплерәк җавап бирәсе иде бит Борһанга. Һаман-һаман авызга су кабып йөрмисе иде.

— Ә без йомырканы бәрәңге белән ашыйбыз, — дидем мин, шактый күтәреп, — бәрәңге белән тәмлерәк тә әле ул, акылым әйтә.

— Ипиеңне сөт белән ашыйсыңмыни?

— Ипинеме? Ипине иртә белән ашыйбыз без... Аннары кич.

Күзенә төтен җибәргәнемне сизде, ахры, Борһан — кабарынкы бит алмаларына мыскыллы елмаю җәелде.

— Төш вакытында тамакка утырыр дисезмени ипине?.. Сөтең дә әчегән бугай әле әнә анда...

— Әчемәс, — дидем мин, чәкүшкәле шешә авызына телемне тидереп карагач. — Кайнатып салды аны әни.

— Кәҗә сөте булганга шулай зәңгәрләнгәндер инде әтү.

— Безнең кәҗә сөте сыер сөтеннән дә тәмлерәк, акылым әйтә.

Борһан беравык аны-моны дәшмичә ашады. Аннары, онытылган сүзе исенә төшкәндәй, тиз-тиз сөйләнеп алды:

— Элек синең ише тәти егетләр сыер асрый торганнар иде. Кәҗә койрыгына карап тук булып булмый ул.

— Курмы ничек җиткермәк кирәк сыерга?

— Ә без ничек җиткерәбез соң?

Борһан белән әреплашәсем килмәгән иде. Үзе телемне ачтырды, хәерле булсын. Куса, куып кайтарыр, дөресен әйтеп калыйм.

— Сез колхоз болыныннан урлап ташыйсыз.

— Син дә ташы, хәлеңнән килсә...

— Җәмәгать милкенә тырнак белән дә кагылмыйбыз без, акылым әйтә.

Төш вакытында ипи тамакка тыгыла, дип, дөрес әйтте, ахры, бая Борһан. Күр әле, ничек йотыкты. Ә йотыккач авызы да турайды, йөзе дә җитдиләнде. Күзләрендә генә мыскыллы салкын очкыннар бетеп җитмәде.

Борһан рәттән берничә тапкыр, голт-голт итеп, чәй йотты, йодрыгы белән күкрәгенә сугып куйды һәм:

— Берәр начальник-мазар булырсың инде син дә ус-

кәч, — дип, сүзне бөтенләй көтелмәгән якка борып җибәрде. — Телең дә ничава икән... Әтиеңнекеннән ким түгел... Йә, кем буласың инде үскәч?

— Министр, — дидем мин, соңгы бәрәңгегә сөт җитми калуына ачуым чыгып.

Шаркылдап көләр дип уйлаган идем Борһанны, әмма ул, минем сүзне чынга алгандай, авызын кыйшайтмый гына:

— Министр, — дип кабатлады да кесәсеннән янчык чыгарды. Ашыкмыйча гына тәмәке төреп кабызды, чирәм өстенә сузылып ятты, пыф-ф итеп һавага төтен өргәннән соң, тагын бер мәртәбә «министр» диде һәм күзләрен йомды.

Мин аның йөзеннән Тәслимә чалымнарын эзләдем. Охшаган да, охшамаган да кебек. Нигә генә Тәслимәнең әтисе булды икән соң бу кеше? Гарифулла бабай яисә Гыйззәт бабай, яисә Никулай дәдәй кызы булсын иде Тәслимә...

Шулай уйлап та бетермәдем — Борһанның маңгай җыерчыклары кинәт тирәнәеп, йөзенә авыру кыяфәт чыкты. Ул тәмәкесен бер читкә атып бәрде һәм буыла-буыла йөткерергә тотынды.

Мин аның шулай капылт кына үзгәреп китүеннән курка калдым, аяк өстенә сикереп тордым.

Ютәле басылгач, Борһан зур ачылган күзләрен төпсез зәңгәрлеккә төбәп, озак кына тынып ятты, берничә мәртәбә тирән итеп көрсенде, үзалдына борчылып:

— Җитәдер, ахры, — диде, зур учы белән тирләгән каш арасын сөртеп алды.

«Борһан абый, авырыйсыңмы әллә?» — дип сорарга ымсындым мин бу минутта. Әмма телем әйләнмәде.

Әле дә ярый сорамадым: күз ачып йомганчы чырае элеккеге хәленә кайтты Борһанның. Нишләп әле бу малайны тиргәмичә торам дигәндәй, ашыгып миңа кычкырды:

— Әй, министр! Атларны эчерергә вакыт...

## Мендәр конфет бәрәкәтле ул

Күзләремне ачарга телим — ачып булмый. Аякларымны кыймылдатмакчы булам — авырта.

Акрын-акрын кичәге көнне хәтергә төшерәм. Ат өстендә йоклап кайттым бит. Әле ярый Борһан күрмәде — арткарак калган идем. Бигрәк күп урдык шул төштән соң. Урман буенда кигәвеннәре теңкәгә тиде, җитмәсә. Әллә аяклар кигәвен тешләгәнгә авырта микән?.. Качам, качам дип йөри торгач, тәки кичкә кадәр түздем бит

кичә! Ә бүген юкка гына уятып маташа әни. Бармыйм очтакларына. Фәхерли әйтмешли, баганага терәп атсалар да, бармыйм...

Әни табак-савыт шылтырата, кашык белән кытыр-кытыр нәрсәдер кыра.

— Йә, улым, уяндыңмы инде? Уракка барасы кеше уянгач та урында тәгәрәп ятмый ул... Көтү куганда, Нәфисә күрше белән сөйләшеп тордык әле. Сине җәлли. Үзе теләп бармагандыр инде Борһан Кукамай янына, елатып алып киткәннәрдер, ди. Юк, мин әйтәм, беркем дә көчләмәде, үзе теләп барды, әтисенә охшаган ул, эшлим дигәнен эшләмичә калмый, мин әйтәм. Хәбир, очтакка алып китүдән куркып, качып ята икән. Бүген дә барамы малаең, ди, Нәфисә әйтә. Бара, мин әйтәм, бармый теге... Башлаган эшен ярты юлда калдырмый ул безнең Рәсим, мин әйтәм.

Учак тирәсендә йөргәнгәдер инде — әнинең йөзе кызарып-алсуланып тора. Мин аның йөзенә текәлебрәк карыйм: салам кыстырамы, әллә чынлап сөйлиме?

Чынлап сөйли. Шаярып сөйләсә, беркайчан да миңа туры карап сөйләшми ул.

Шулаен шулай әйтәдер дә бит Нәфисәттәй, бик авыр шул урыннан кузгалулары. Бакчы, камыл ничек сыдырып, сызгалап бетергән аякларны. Балавыз тидергәч төзәлә, дигән булды тагын әни кичәгенәк. Төзәлмәгән әле бер дә...

Кояшы да таң тишегеннән кыздыра башлый бит аның. Ярамас иде шунда сәгать сигезләргә кадәр булса да болытлап, яңгыр явып торса. Юк, яумый. Учак янында эссе. Тәрәзә янында тагын да эссерәк.

Сытык чырай белән ишегалдына чыктым. Күләгәдә салкынча икән.

Юынганчы иелеп булмаган иде, юынгач, тураюы мең бәла... Сөртенергә дип, кулымны сөлгегә сузган идем — кинәт кенә читән артында бер кабак кыймылдады. Сискәнеп киттем хәтта. Күзләремне кояштан качырыбрак карасам — җир йотсын, Хәбир тана колак. Читәнгә чорналып үскән кабак яфраклары арасыннан такыр баш түбәсе генә ялтырап күренә.

— Әллә бүген дә барасыңмы, малай? — дип пышылдады ул, кычкырып әйткәнгә караганда да ераккарак ишетелерлек итеп.

Әле дә ярый, яңа товар, алай-болай югалып китүе бар, кичкә кадәр түзгәч, иртәгә дә киләсең инде син, дип, йөгәнне өйгә биреп җибәргән иде Гыйззәт бабай. Хәбир тавышына игътибар итмичә, ачык чолан ишегеннән үрелеп кенә алдым да мин аны, авызлык тимерен чылтыр-чылтыр китерә башладым.

— Рәсим, — дип «пышылдады» Хәбир, әйләнә-тирәдәге кош-кортларның котын очырып, — әллә саңгырауландыңмы?

Йөгәннең «эшен» бетереп, читән буенарак елыштым, артык гаҗәпләнми генә, син икәнсең әле, дидем.

— Әллә бүген дә барасыңмы, малай?

— Һи, бармый тегеǃ.. Очтакта йөрүнең берние дә юк икән лә аның. Шундый рәхәт басуда. Менә Гыйззәт бабай яңа йөгән бирде. Камытым да яңа, акылым әйтә.

Хәбир, читән арасыннан кулын тыгып, йөгән каешын тотып карады.

— Борһан Кукамай ачуланмыймы соң?

— Бөртек тә ачуланмый. Кичә төш вакытында ярты телем ипи сындырып бирде әле. Май яккан ипи...

— Эсседер, малай, басуда?

— Ат өстендә тирләтми. Карлыгачны беләсең инде, йөгертеп кенә йөртә...

Минем сүзләрдән Хәбирнең авыз сулары килә башлады инде әллә — кояшта янган кулларын читән арасыннан асылындырып катты да калды. Күзләре иләс-миләс елтырый. Иреннәре, менә елмаям, менә елмаям дип, мимылдап тора. Читәннең бу ягына чыкса, кулымнан йөгәнне тартып алып, очтакка йөгерер, билләһи.

Әни, басма алдына чыгып:

— Кая йөрисең тагын, чәең суына ич, — дип кычкыргач, йөгәнне иңемә салып, эре кыяфәт белән өйгә таба атладым.

— Хәзер керәм, конфет савытын ала тор...

Бәрәңге боламыгын шактый мул пешергән бүген әни. Мендәр конфетны да савыт тутырып куйган. Шулай да чамасыз кыланмадым.

Чәй эчеп бетерәрәк, әни бер төргәк күтәреп килеп таратып җибәрде. Чем-кара материя...

— Менә чалбарлык алдым сиңа, — диде әни, миннән битәр үзе ныграк сөенеп. — Кыр эшләре беткәч тегеп куярмын да, боерган булса, мәктәпкә киеп йөрерсең... Кибетче Мәрьямгә рәхмәт. Унбиш йомырка илткән идем, сатулашып та тормады... бирде дә җибәрде. Калганын үз җаеңа карап түләрсең, ди...

Кибет исе, ислемай исе, баллы прәннек, тәмәке исләре аңкып торган материяне төреп сандык артына кыстыргач, әни, ничектер гаепле кеше сыман, башлаган сүзен әйтә алмыйча, өстәл җәймәсе читен бөтергәләп утырды, көрсенеп аяк өстенә басты. Ишекле-түрле йөреп килде. Аннары гына ялгап китте:

— Бүген әбәтеңә йомырка булмый инде, улым... Ир-

тәдән бирле сакладым тавыкларны. Берсе-бер ояга утырмады. Әллә җыйган түлләре бетте инде җәй уртасында. Бөртек чүпләмәгәч, бетсә дә гаеп түгел.

Әни тынып калды. Мин дә тынып утыра бирдем. Борһан кулындагы май ягылган калын ипи телеме, Борһанның мыскыллы карашы күз алдыма килде. Күңелем тулганын әнигә сиздермәс өчен, читкә борылдым.

— Бәрәңге генә була инде бүген, алайса.

— Бәрәңге, сөт. Аннары менә конфет төреп тыгам бераз...

Конфет булгач, ярый. Мендәр конфет бәрәкәтле ул. Тешкә тиермичә генә суырып йөрсәң, берсе дә көне буена җитә мендәр конфетның...

Капкадан чыгып ун-унбиш адым атлагач ук, бот төпләрем язылып киткәндәй булды. Аркамда яңа йөгән чылтырый. Кулымдагы төенчектән җылы бәрәңге исе килә.

Амбар алдында да, кичәге шикелле курка-курка гына түгел, хуҗаларча нык басып, «Без авылда өчәү идек» көенә сызгыра-сызгыра, Гыйззәт бабайны шаккатырып барып керергә иде исәп... Тик келәтләр почмагыннан борылгач, каушап калдым. Амбар алдына җыелган хатын-кыз, хатын-кыз. Базар диярсең. Ара-тирә яшүсмер егетләр, сирәк-мирәк ир-атлар да күренгәли.

Өстенә яшеле уңа башлаган хәрби кием кигән бер агай арба өстенә менеп баскан. Шаулашкан хатын-кызларны тынычландырырга тырышып, фуражкасын селки.

Колхоз председателе Галим абый да арба янында гына тора икән. Хром итекләрен шыгырдата-шыгырдата, арба алдынарак чыкты да юан гәүдәсенә тап-таман гөрелдәвек тавыш белән бөтен амбар алдын яңгыратты.

— Туктагыз әле, җәмәгать. Бака туе ясамагыз әле. Район вәкиленә әйбәтләп аңлатырга ирек бирегез. Йә, кайсыгыз нәрсә сорый анда тагын? Берәм-берәм генә түлке.

Амбар ишеге төбендә тәмәке пыскыткан ике-өч бөртек ир-ат арасыннан Борһан тавышы ишетелде:

— Безнең шул бер сорау инде һаман да. Кайчан туйганчы ипи ашый башлыйбыз? Өченче ел хезмәт көненә ике йөз грамм да тимәде. Узган ел өч йөз грамм белән калдык...

Район вәкиле, ялтыр башын ап-ак кулъяулыгы белән сөрткәли-сөрткәли, бик ерактан урап җавап бирде бу сорауга.

Ватык-җимерек шәһәрләр, яндырылып кара күмергә калган авыллар бик күп икән әле безнең илдә. Сугыш кораллары ясарга җайлаштырылган заводларны яңадан үзгәртеп корасы бар икән. Шуннан соң гына МТСларга яңа тракторлар, яңа комбайннар кайта башлаячак икән.

Сугыш афәте тигән якларда йортсыз-җирсез, бер кабым ризыксыз калган кешеләр бик күп икән әле. Бөтен халык бердәм булып, алны-ялны белми тырышып эшләсәк кенә, әнә шул кыенлыкларны җиңеп чыга алачакбыз икән.

Бик аңлаешлы сөйләде кебек районнан килгән вәкил, миңа калса. Борһан гына берни дә аңламаган, күрәсең. Баягыдан да ярсыбрак кычкырып җибәрде:

— Ипи кирәк безгә. Урак та урып булмый, илне дә аякка бастырып булмый, ипи бирмәсәгез...

Борһанга кушылып шаулаша башлаган хатын-кызларны тагын Галимулла абыйның гөрелдек тавышы туктатты:

— Әйттем бит мин сезгә, җәмәгать, саф татар телендә әйттем. Игеннәрне әйбәт кенә җыеп алсагыз, хезмәт көненә ярты килодан да ким бирмим быел, дидем. Берлинны алган старшина сүзе бу... Аңлашылдымы?.. Ә хәзер эшкә! Даваегыз, давай, бетердек җыелышны. Барыгыз да басуга!

Биек колга башына кызыл флаг күтәрелде. Даң-даң китереп чаң кагарга тотындылар. Чуар киемле кешеләр сөйләшә-сөйләшә төрлесе төрле якка таралышып киткәч, амбар алды сабан туе мәйданына охшап калды...

Борһан артыннан ат абзарына кергәндә дә, аран киртәсенә басып Карлыгачка йөгән кидергәндә дә, миңа бер уй тынгылык бирмәде: «Авыз тутырып ипи ашый торып, нигә ипи бирегез, дип кычкырды икән соң бу Борһан? Коры килеш кенә түгел, май ягып ашый бит әле. Булса да булыр икән ач күзле адәмнәр дөньяда. Үзе туйса да, күзе туймый, дип, шундый кешеләр турында әйтәләрдер инде...»

## Бәндә — тамак колы

Бүген басуга кичәгегә караганда иртәрәк килеп, иртәрәк урдыра башладык. Үзебез өчен дә, атларга да рәхәт, салкынча... Мәгәр урак машинасы өчен алама икән иртәнге сәгатьләр. Сөрлеккән арыш буенча ун-унбиш адым китәргә өлгермибез, ургыч канатлары шып туктап кала. Берөзлексез «тыр-р, тыр-р» дип кычкырып торган көне Борһанның. Канат белән лафет арасына тыгылган үләнле арыш сабакларын йолкый-йолкый, кәҗә майларың чыга.

Борһан үзе йолыкмый. Миңа гына йолкыта үләнле арышны. Үзе тимер утыргычында тәмәке пошкытып, канатларны тегеләй-болай селкеткәләп кенә утыра.

Бер түтәрәм җир киткәнче, атыма ничә атланып, ничә тапкыр җиргә сикереп төшкәнмендер, анысын әйтә ал-

мыйм, тик бер атлануымда, Борһан «тыр-р» дип кычкыргач, артыма борылып карамадым.

— Нәләт суккыры малай, — дип кычкырды Борһан ачуына буылып, — дошман. Төш ат өстеннән. Нәрсә кукраеп утырасың... Күр, менә нишләттең машинаны...

Аттан төшеп, курка-курка гына машина янына килдем. Канатлары, пычкысы, тәгәрмәчләре исән-сау. Нәрсәсе генә ватылды икән соң нәләтнең?..

Борһан тәмәке төпчеген камыл арасына төкереп ташлады да миңа чыбыркы сабы белән кизәнде.

— Акай күз... Кая карыйсың? Әнә шатунга кара.

Шестернялар тартмасы белән пычкы арасында урталай сынган кәкре тимерне күргәч, йөрәгем жу итеп китте. Бетерә икән бүген мине Борһан. Басудан исән-сау кайтармый икән...

Шушы кәкре тимерне ялгамый торып, урып булмаячагын төшендем мин. Әмма аны ничек сындырганымны гына аңлый алмадым.

Борһан да авыр гына кузгалып җиргә төште. Чыбыркы сабы белән сынган тимергә төрткәләп карады, үзе бертуктаусыз мине тиргәде:

— Пешмәгән нәрсә... Урырсың монда синең ише мәнсезләр белән уракны, тутырырсың норманы. Ничек кирәк алай сөйрәтеп йөрергә анаңның кер тигәнәсе дип белгәнсеңдер аны, урак машинасын. Каш астыннан карап торма монда миңа... Ат өстендә кукраеп йөреп кенә урылмый ул арыш. Нәрсә күзле бүкән кебек катып торасың тагын... Йөгер тизрәк. Алып мен инструментларны.

Бер күнеккәнче генә авырттыра икән камыл аякларны. Йөгерә-йөгерә бернәрсә дә сизми башлыйсың.

Камыл арасында тычкан өннәре күренгәләп кала. Йомшак инде ул өннәр, бик йомшак. Тик йомшак туфракта озаклап басып торырга вакыт юк — урак өсте. Камыл өстеннән сузаеп күләгәм йөгерә. Күктә, шактый биектә, мин йөгергән якка, мине узып, канатларын җилпеми генә, ялгыз тилгән оча. Чүмәләләр белән чуарланып өлгергән камыллы кырның бер ягында бөтерелеп-бөтерелеп арыш дулкынлана, икенче ягында туйралар яшәреп утыра.

Тамак төбендә кайнар төер. Аны йотып җибәрсәм, күземнән яшь атылып чыгар сыман. Үзем йөгерәм, ә үзем: «Кичә качмаганны, бүген качмыйм инде», — дип такмаклыйм.

Мин, шабыр тиргә төшеп, инструментлар сумкасын китереп җиткергәндә, Борһан, Урал белән Җирәнне туарып, басу читенә чыгарып тышаулаган иде. Карлыгач кына, мескен, һаман да постромка арасында. Борынын

камылга төрткән. Койрыгы белән чебеннәр куган булып, күңелсезләнеп тора.

Сынган шатунны сүтеп алу юкәдән сыбызгы төшерәсеннән дә җиңелрәк икән лә. Сүтеп тә алдык, Борһан, ике тимер кисәген бер бауга бәйләп, миңа сузып та өлгерде.

— Атыңа атлан да сыпырт әйдә авылга. Складта яңасы булмаса, МТСта ялгатып кайтырсың... Йоклап йөрмә. Бер аягың анда, икенчесе монда булсын...

Урал белән Җирән байтал янында яшел үләнгә рәхәтләнәм дип уйлагандыр инде Карлыгач — басу читенә кадәр бик кәефле килде. Тезгенне олы юлга таба тарткалый башлагач кына, адымнарын акрынайтты.

— Куала, куала, — дип кычкырып калды Борһан минем арттан.

Тезген очы белән уңлы-суллы чирттереп җибәрдем. Алып торып китте шуннан Карлыгач, алып торып китте. Кул буш булса, бик рәхәт икән дә кана болай җилдереп барулары. Кул буш түгел. Юырттырып кына чапсаң инде... Бот төпләре авырта. Тыймыйм шуңа күрә Карлыгачны. Ялына ныгытып ябыштым, очып төшеп калмам әле... Җил битләрне кисә, ачык изүдән кереп, күлмәк аркасын кабарта, тәнне кытыклый... Тән генә түгел, җан да, кан да кытыклана сыман. Биек агач башына үрмәләгәндә, нәкъ шундый хис кичергәнем бар. Югарырак менгән саен рәхәтрәк һәм шул ук вакытта куркыта да.

Ферма тавына килеп җиткәч, Карлыгач тыела төште. Ләмгә кереп яткан ата дуңгызга карый-карый, тау менеп киләм шулай — әллә күземә күренәме дип торам — Тәслимә. Бәләкәй сеңлесен җитәкләгән. Икесе дә кулларына кечкенә чиләкләр тотканнар, икесе дә башларына яшел чәчәкле ак яулык бәйләгәннәр. Икесенең дә йөзләре әле генә әрчелгән яңа бәрәңге шикелле ап-ак. Үзе өйдә чагында кызларын урамга уйнарга да чыгармый Борһан. Шуңа ак йөзлеләр инде алар.

Әллә мин туктаттым Карлыгачны, әллә үзе туктады — ничектер шулай килеп чыкты инде — тагын бераздан без тауның сөзәгрәк җирендә, кара-каршы торган килеш, сөйләшеп киттек.

— Тыр-р-р, тыр-р, дим. Нәрсә тыпырчынасың, — дип сүз башладым мин кымшанырга уйлап та карамаган Карлыгачның тезгенен тарткалап. — Басуга барасызмыни?

Тәслимәнең сеңлесе курку катыш кызыксыну белән Карлыгачка гына карап торды. Сөйләшүен Тәслимә үзе сөйләште.

— Басуга бармыйбыз. Төлке чатында җиләк пешкән, диләр... Төлке чатына җиләккә барабыз.

— Пешкәндер, пешми тагын. Әнә ничек кыздыра. Җиләгең түгел, җелегең пешәр...

— Нигә ул тикле чаптырып кайттың, Рәсим? Әтигә бер-бер хәл булмагандыр ич?

— Шатун сынды. — Мин Тәслимәгә кулымдагы тимер кисәкләрен селкеп күрсәттем. — Складта булса, яңаны алып киләм. Булмаса, МТСтан ялгатып кайтам. Шатун сынмаса, Казаклар басуы күп калмый иде бүгеннән.

— Әти нишләп калды?

— Җырлап.

— Һи, ялганчы, — диде Тәслимә, күзләрен түгәрәкләндереп. — Гомерендә дә җырлаганын ишеткәнем юк мин аның...

— Ә басуда җырлый ул. Ат җиккәндә дә, урдырганда да җырлап кына йөри...

— Һе, тыңлап торасы иде... Әллә нинди генә ул безнең әти. Беркөннәрдә, исереп кайткач, идәнгә ятып елады... Мине бөтен авыллары белән дошман күрәләр, әйтерсең мин гаепле фронтка бара алмавыма, ди... — Тәслимә, күңелсезләнеп, кулындагы чиләгенә карады. — Авырый ул безнең әти. Врачлар операция ясатырга кушалар. Әти теләми... Һе, кызык... Басуда да өйдәге кебек ачуланып кына йөри дип торам тагы мин әтине.

— Ачуланмый. Җырлый да көлә, җырлый да көлә генә ул анда.

— Алай булгач, син очтактан качмыйсың инде, име, Рәсим?

— Юләр түгел лә мин.

— Ә мин тагы әти ачуланыр да, Фәхерли кебек качарсың дип уйлаган идем... Ай-яй каты да чаптырып килдең инде. Башта кем икән дип торам. Таныгач, егылып төшмәсен дип котым очты.

— Кулым буш булса, чабып күрсәтер идем дә мин сиңа... Кул буш түгел.

— Һи, мактанчык...

— Мактанчыкмы? Мактанчыкмы? Менә күр алайса...

Карлыгач, тезген очын селкегәнемне генә көткәндәй, тагын алып торып китте. Тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк тояклары. Ике ак шәүләнең артка чигенеп, тау астына төшеп күмелгәннәрен күрми дә калдым...

Ферма ызбасы алдында мине Мөнәвәрә апа туктатты.

— Кая чабасың, ни булды, Рәсим энем?

— Шатун сынды, Мөнәвәрә апа, шатун кирәк.

Мөнәвәрә апа беркавым кулымдагы тимер кисәкләренә, бернәрсә дә аңламагандай, аптырап карап торды. Аннары кара күзләреннән хәтәр очкыннар чәчрәтеп:

— Мәгънәсез! — диде.

Мин каушап төштем. Ашыга-ашыга акланырга керештем.

— Аның ничек сынганын да күрми калдым мин, Мөнәвәрә апа.

— Сине әйтмим лә мин. Борһан мәгънәсезне әйтәм. Урак өстендә шултикле җирдән ат куып... Мәйтәм, былтыр булды, былтыр шулай теңкәне корытты. Соң, үзе белән запас шатун алып китсә, кулы череп төшәме инде, йә?! Их, Рәсим энем, мәйтәм, кайчан сез үсеп җитәрсез. Ялынмас идек шуның ише киребеткәннәргә...

Йөзе колга очындагы флагтай кызарган Мөнәвәрә апа амбарга кадәр Карлыгач яныннан теркелдәп барды да складтан берьюлы ике шатун алып чыгып бирде.

— Бар, Рәсим энем, куала. Әй, тукта, карале, шатунның берсен генә бир син башта Борһан абыеңа. Икесен дә бергә бирсәң, кычытмаган җирне кашып йөрисең, дип сүгеп атар үзеңне. Мәйтәм, ул дуамалга ышанып булмый. Болай ит син, Рәсим энем. Басуга җиткәч, шатунның берсен үзең белә торган урынга яшереп калдыр. Алай-болай кирәге чыкса, кабат ат чаптырып йөрмәссең.

Мөнәвәрә апа әйткәнчә эшләдем дә. Басуга җиткәч, шатунның берсен чүмәлә төбенә яшереп калдырдым һәм эссе кыр буйлап машина янына менеп киттем.

Борһан күләгәгә ятып черем иткән, ахры, күзләре кысылып бетә язган. Йөзе йокылы, хәрәкәтләре сүлпән...

Тирә-як тып-тын. Карлыгач тавышсыз гына койрыгын селки. Арыш та дулкынланудан туктады хәтта. Борһан шатунны беркетеп куйды да муенына җеп тагылган кара шешәдән шестернялар тартмасына май агызырга кереште.

Әбәт ашап алганда да әйбәт булыр иде кана. Атта чапканда, ашказанымның төбе тишелде микән әллә? Бөтенләй бушап, эчкә ябышып калган шикелле.

Уйлаган идем лә аны җикеренмичә түзә алмас әле дип. Тәки рас килде. Атларны җигә тор, янәсе, нәрсә син бүген бүкән кебек катасың да каласың, катасың да каласың...

— Ярарсана, кычкырып тормасана һаман-һаман, әйтмәгән саен, — дип мыгырдадым мин, Урал белән Җиранкәй сахра кылып йөргән кишәрлеккә чыгып җитәрәк.

Атлар, безгә әйтәсеңме соң син дигәндәй, икесе дә берьюлы миңа борылып карадылар.

Борһан атларын тышаулап та, җигеп тә була. Икесе дә акыллы, күндәм атлар. Әмма ләкин Уралга камыт кидертүләре бик яман. Каланча биеклеге бит ул. Күзләренә кадәр күтәрәм камытны, аннары аяк очларыма баскач та

буй җитми. Кичә әбәттән соң җелегемә төшкән иде шул камыт. Борһанга нәрсә, аңа рәхәт. Минем кулымнан эш килмәсә, йә ачулана, йә авызын ера. Хәер, бик тиз җаен таптым бүген. Машина тәгәрмәченә басып киерттем. Майлаган шикелле кереп кенә утырды...

Атларны җигеп бетереп кузгалып киттек. Шома гына келтерәтәбез...

Көн тәмам эсселәнеп җитте. Арыш сабаклары ат аягы орынгач ук шартлап сына.

Урман буена җитәрәк, кигәвеннәр ябырылды. Атларга да тынгылык юк, үзебезгә дә. Үзебез түзәбез. Ә менә атлар... Кигәвен тешләгән саен дерт итеп сискәнеп китәләр, башларын аска каерырга теләп ымсыналар да, сбруйлары ирек бирмәгәч, иреннәрен калтыратып, күзләрен йомалар. Нигә генә бөтен тәннәре озын ял белән капланмаган икән бу атларның? Кигәвен дә талый алмас иде ул чагында, чыбыркы да үтмәс иде.

Карлыгачны чаптырып өшәндердем инде әллә? Басуны өч-дүрт тапкыр әйләнгәч үк, кара тиргә төште. Борылышларда сөрлегеп-сөрлегеп китә. Ә Борһан аны-моны карамый, чыбыркысын болгап кычкыруын белә.

— Һәй, куала, диләр сиңа! Йоклама, куала!

Мин куаламыйча да тырыша бит инде Карлыгач. Постромка баулары кылдай тартылганнар. Вәлүк ыргагы тәртә алкасын кисеп кергән анда әнә.

Борһанның нияте мине ачка тарыктыру, ахры, бүген, чаң тавышы ишетелгәч тә туктатмады атларын. Әбәт ашый торган куаклык турысын чыбыркысын болгап узып китте.

Көлтә бәйләүчеләр эшләрен ташладылар әнә. Алъяпкычларын чишеп, җиңсәләрен салып, чүмәлә төпләренә таралыштылар.

Ике мәртәбә узып киттек яшел куаклыкны, өч мәртәбә. Җиргә машина канатларыннан да, атлардан да күләгә төшми. Басу өсте яңа гына күмере төшкән мич авызы кебек сөремләнеп тора...

Әллә әбәт вакытында ургач акырып елар бу дип уйлый тагын мине! Ур! Кичкә кадәр ур! Караңгы төшкәч тә ур! Көне-төне ур! Карлыгач кына кызганыч. Ярый ла синең атларың ял итте. Ә, туктыйсыңмыни?! Нибуч, туктарсың, тамагың кычытса...

Атларны үләнгә җибәргәч, Борһан табынынннан баш әйләндергеч татлы ис чыкканын көтеп тормадым бүген. Эссе икән монда, күләгәрәк җир эзлим дигән булып, куаклар арасына кереп киттем.

Борһан күзен кыздырырлык ризык юк иде шул бүген

минем төенчектә. Юкса ипи исеннән ләззәтләнеп утырудан баш тартмас идем дә соң...

Ике кабып бер генә йоттым ун бәрәңгене. Кичә сөте җитми калган иде, бүген бәрәңгесе җитмәде.

Якын-тирәдә җиләге-фәләне дә күренми бит, ичмасам... Тәслимәләр җиләк ашап рәхәтләнгәннәрдер бүген.

Туктале, арыш уып ашап карасаң ничек була икән? Йомшагын йомшаграк та әле бөртекләре... Шулай да ашарга ярарга тиеш.

Борһанны читтән урап, саллы гына бер көлтәне күләгәгә сөйрәп кердем. Уч төпләре дә авырта башлады — кылчыклы яшькелт бөртекләр белән түбәтәй тулып та китте. Учтан учка коя-коя, өргәли-өргәли җилгәргәннән соң да ярты түбәтәйдән артыграк чиста арыш чыкты.

Нигә, хурларлык түгел, минемчә... Бик тәмле. Май яккан ипиең бер читтә торсын. Тегермән тартканда, ашлыкка тузаны, тегесе-бусы кушылып бетә. Ә бу арыш агачыннан яңа гына өзеп алынган җимеш кебек, ичмасам. Туклыклы да үзе. Моңарчы нишләп авыз ачып, ашказанын елатып йөрткәнмендер, тиле...

Куак чыштырдагач, сискәнеп башымны күтәрдем. Авызын кыйшайтып елмаеп торган Борһанны күргәч, кәләпүшем кулымнан төшеп китеп, арышы үләнгә түгелде.

— Күрдем барысын да, — дип кешнәде Борһан, тын басуны яңгыратып. — Җәмәгать милкенә тырнак очы белән дә орынмыйбыз дигән идең түгелме соң кичә? Бәндә — тамак колы. Тамак сорагач, тырнак очы белән генә түгел, кул белән, кәләпүш белән, хәтта, әйтер идем, капчык белән орынасың. Ат белән дә төяп кайтасың.

— Мин ни, мин теге ни... өлгергәнен-өлгермәгәнен белер өчен генә...

— Аша, миңа димәгәең. Басуда арыш бетәсе юк. Колхоз добрасы өчен авылдашын күрәләтә Себер җибәрүчеләр нәселеннән түгел мин...

Безнең бакчага таш атып маташуы иде Борһанның.

Арыш уып ашау белән печән урлап кайтуның икесе ике нәрсә икәнен дә төшенәм үзем. Әмма Борһанга шуны аңлатып бирә генә алмыйм.

Көчсезлегемә, булдыксызлыгыма, Борһан белән ирләрчә сөйләшә алмавыма гарьләнеп йөри-йөри, атларны ничек эчереп кайтуымны да, ничек җиккәнемне дә, ничек кузгалып киткәнебезне дә сизми калганмын.

Үз-үзеңә ачуланып йөргәч, көн тиз уза икән... Атыңны да кызганмыйсың, эссене дә тоймыйсың...

Кояш инде көнбатыш якка тәгәрәп бара. Әмма көн сүрелми. Инде үз-үземә булган ачуым да басылды. Үте-

реп эчәсе килә башлады. Авызга кайнар ком кереп тулган диярсең — тамчы дым юк. Көлтә бәйләүче хатын-кызлар ничектер томан аша, камыл арасына таралып киткән ак казларга охшап күренә күземә. Карлыгачның кайнар тәненә ябышкан кигәвеннәрне куарлык та хәл калмады.

Эссегә кинәнеп ялтырашкан канатлар, «безгә су кирәкми, безгә су кирәкми» дип, шыгыр-шыгыр күтәреләләр дә төшәләр, күтәреләләр дә төшәләр. Кайда гына барсам да, алар шулай, үзләренең агач сабырлыклары белән масаеп, мине үртәп, эзәрлекләп йөрерләр шикелле.

## Кырындык ипи нинди була?

Ак яллы аргамаклар яшел болын өстендә ак өермәдәй йөрделәр дә, тавышсыз гына кешни-кешни, минем якка борылдылар. Мин качарга телим, әмма аякларым җиргә берегеп калган. Ярдәм сорап кычкырырга телим — әйләнә-тирәдә кеше-кара күренми. Аргамаклар, ак ялларын туздырып, һаман миңа якынлашалар... Шул чагында чикләвек куаклары арасыннан авызын кыйшайтып Борһан килеп чыга. Кулында каерып киселгән ипи телеме. Май якмаган, май яккан булса, аргамаклар ипи исен сизмәсләр иде, болай таба йөгермәсләр иде дип уйлыйм мин. Үзем Борһанга кычкырам: «Ипиеңне яшер, яшер ипиеңне!» Борһан селкенми дә.

Ак яллы аргамаклар тирә-ягымны ак буранга күмеп килеп тә җиттеләр, минем өстән йомшак җил кебек үтеп тә киттеләр... Борһан да аргамаклар артыннан йөгерә. Аның кулында ипи телеме түгел, имеш. Аның кулында урак машинасы канаты. Атлар җиңел генә узып киткән иде... Ә Борһан бөтен гәүдәсе белән килеп капланды. Сулап та булмый.

— Әни, үләм!

— Чү, нишләп кычкырасың, улым? Яман төш күрдеңме әллә?

— Эчем, әни, эчем... үләм.

Төш түгел бит инде бусы. Борһан да юк, аргамаклар да... Ян тәрәзәдән өстәл читендәге самоварга сүрән генә сирпелеп яктылык төшкән... Ә эч бөтереп-бөтереп авырта. Кузгалыр да хәл юк.

Эчемне кулым белән тотып карыйм — үземнеке түгел кебек.

— Йөзтүбән ятып кара, улым.

— Әйләнеп булмый ич.

— Су күп эчтең шул, улым. Әйттем бит мин сиңа... Күп эчмә, дип.

— Уф, үләм, әни. Ярты кәләпүш арыш уып ашаган идем кичә басуда.

— Әй бала, бала!.. Борһан абыең да әйтмәгән икән шунда... Яктыра бугай. Асиягә йөгерим әле, булмаса. Эч даруы юк микән.

— Кирәкми, әни. Йөрмә эче таңнан. Кулың белән кыс кына, менә шулай... Җиңеләйде дә инде. Баягы кебек борып-борып авыртмый. Сулкылдап кына тора.

Самоварга төшкән яктылык һаман киңәя бара. Акрын-акрын түшәмнәр яктыра башлады. Тагын бераздан яктылык мичкә, урын-җирләргә төште... Шунда гына мин әнинең, өске күлмәкләрен, оекларын да салмыйча, коры сәкедә тәгәрәп ятуына игътибар иттем.

Икенче мәртәбә уянуымда өйгә гадәти ямь кергән иде инде. Тәрәзәләрдә кояш. Мич янында әни. Җылы бәрәңге, кайнаган сөт исе... Төнлә күзләремә боз кебек салкын күренгән самовар, «эчемә ут салып торсагыз, шулай инде менә мин» дигән сыман, ап-ак йомшак пар бөркеп утыра.

— Эчең нихәл, улым?

Әнинең беренче соравы шул булды.

Мин эчемне бармакларым белән баскалап карадым да, авырту-фәлән сизелмәгәч, урыннан сикереп торып, тиз генә юынып кердем.

Күңелем күтәренке иде. Басуга Борһаннан алда барыйм әле дип, ашап-эчүне җәһәтрәк тоттым. Ашык-пошык төенчегемне, йөгәнемне эләктереп, якты урамга атылдым.

Ат абзары төбендә мине Мөнәвәрә апа каршы алды.

— Өшәнебрәк киткән бит, Рәсим, Карлыгач... Солысын да рәтләп ашамаган...

— Кичә бик нык арыды шул ул, Мөнәвәрә апа.

— Син, куам дигәч тә, артык кума аны, Рәсим энем. Төптәге атлар уңаенарак йөрт...

Менә сиңа кирәк булса! Кызык икән болар. Куаларга да ярамый, куаламаска да...

Абзардан Карлыгачны җитәкләп чыктым. Чынлап та күңелсез, бик күңелсез иде ул бүген. Иртәнге сәгатьләрдә шулай боегып торгач, көн эссесендә нишли инде бу...

— Син карап кына йөрт, Рәсим энем. Карап кына йөртсәң, бернәрсә дә булмас. Берәр көн ял иттергәндә ярар иде дә соң, мәйтәм. Нәрәттән бер генә ат та артып калмады. Колынлыйсы бияләрне дә җигеп бетерделәр, — диде Мөнәвәрә апа, минем уйларымны сизгәндәй.

Һе, кызык кына. Карап кына йөрт, имеш... Йөртерсең карап кына! Әнә, басуга килгәч, атларны җигеп ярты

җир буе киттек микән, юк микән — куала, нишләп йоклап барасың ат өстендә, дип кычкырып та өлгерде Борһан.

Ишетмәгәнгә салыштым. Җитте, һаман-һаман Борһан кубызына биеп йөрергә димәгән. Ярар, мин үзем пешмәгән булыйм, норсыз, чырайсыз, күзле бүкән, салам сыйрак, тегәрҗеп муен булыйм... Ә Карлыгач Урал белән Җирәнкәй шикелле әйбәт ат лабаса. Нигә җәберли ул аны, нигә кыерсыта?..

Борһан «тырылдап» атларны туктатты. Чыбыркысын селкеп, мышный-мышный минем янга килде.

— Нигә куаламыйсың, нигә йоклап барасың?

— Куалыйм ич...

— Алай куаламыйлар аны, менә болай куалыйлар...

Борһан, әһелди-әһелди, чыбыркысын сызгырта-сызгырта, Карлыгачны кыйнарга кереште. Карлыгач бер урында тыпырдап торды да бар хәлгә алга ыргылды. Урал белән Җирәнкәйне дә урыннарыннан кузгатты. Борһан үзе исә, канатлар әйләнә башлагач кына, машинасына сикереп менеп утырды.

Карлыгач урак машинасын урман буена кадәр берүзе диярлек сөйрәп менде. Аның артыннан җитә алмыйча, Урал белән Җирәнкәйнең камытлары да бушап-бушап китә иде хәтта кайчагында. Урман буеннан әйләнгәндә, мин Карлыгачны тыярга теләдем. Ләкин ул тәмам ярсыган иде. Тезгенне тарткач та, адымнарын акрынайтмады, башын бер хәлгә сузып, гыж-гыж килеп, алга омтылуында булды. Борһан «тыр-р» дип кычкырса да, туктамас шикелле иде ул хәзер.

Ләкин күпкә җитмәде Карлыгачның ярсуы. Текә борылышларның берсендә ул тигез җирдә сөрлегеп китте. Егыла язып туктап калды. Мин камыл өстенә очып төштем дә сикереп торып Борһанның чыбыркы күтәргән кулына барып асылындым.

— Кыйнама, сукма! Күрәсең ич ничек калтырана... Хәл җыйсын бераз, сугасы булма! — дип кычкырдым.

Борһан мине камыл өстенә төртеп екты. Карлыгачның дер-дер килеп торган бот башына зур учы белән шапылдатып сукты да аңа үзе менеп атланды. Сыгылыплар гына төште инде мескен Карлыгач.

— Пешмәгән нәрсә! Утыр әнә машинага. Тот дилбегәне...

Ниләр генә күрсәтергә уйлый икән Борһан миңа тагын? Үзе нишләмәкче була икән шул гәүдәсе белән бәләкәй генә атка атланып? Бакчы инде, аяклары җирдән сөйрәлеп бара.

Борһан урынында да рәхәт түгел икән. Канатлар бер-

туктаусыз йөзгә кылчык, тузан, салам кисәкләре сибә. Кулымдагы дилбегәне тартырга да, тартмаска да белмим. Өстәвенә лафетка урылган арыш килеп өелде.

— Тукта, әй, тукта! — дип кычкырдым Борһанга. Ә ул әйләнеп тә карамый.

Шул чагында көлтә бәйләүче хатыннарның кайсыдыр, кулын болгый-болгый, «аш пешер» дип кычкыра сыман тоелды. Яхшылабрак тыңласам, «Бас, төшер!» дип кычкыра, имеш, ул.

Әһә, әнә бит, бәләкәй генә педале бар икән. Сыңар аяк белән басып карадым, басылмый. Утыргыч артына аркамны терәп, ике аяк белән баскан идем — сырлы тимер зыңгылдап эчкә батып керде, һәм канатларның берсе лафетка җыелган арышны чыштырдатып камыл өстенә шудырып төшерде.

Җем-җем килеп елтырашкан пычкы тешләренә, шылтырап әйләнгән шестерняларга карап бара торгач, борылышка җиткәнебезне сизми дә калганмын. Әле дә ярый Урал акыллы. Урылган җир башына чыккач, үз белдеге белән уңга каерып алып кереп китте. Почмакта аз гына урылмаган арыш калды калуын. Андый гына гаеп мулла кызында да була, диләр. Көлтә бәйләүчеләрнең ураклары бар әле. Урып алырлар.

Борһан дилбегәне еш селкеми иде. Мин дилбегә кагарга да вакыт таптым әле. Урал белән Җирәнкәй дәртләнебрәк атлап киттеләр.

Борһан, моны күреп, Карлыгачны тагын да ныграк куаларга тотынды. Канатлар әйләнүе, пычкы елтыравы ешайды. Бөтен машина өстен тузан каплап алды.

Үр менгәндә, Карлыгач берничә мәртәбә тукталып-тукталып торгандай булды. Әмма Борһан аңа сулыш алырга да ирек бирми, озын аяклары белән кабыргаларына тәрткәли, бертуктаусыз чыбыркысын сызгырта иде.

Үр менеп җиткәч җиңеләер иде инде дип уйлап кына бетердем — Карлыгач барган уңайга кинәт гөрселдәп җиргә ауды.

Дилбегәне ташлап, Урал белән Җирәнкәй алдына йөгереп чыктым.

Борһан!.. Ниләр генә кылыйм икән инде, әнкәчем! Борһанның бер аягы Карлыгач астына кереп калган! Чырае көл кебек. Үзе ыңгыраша. Кепкасы читкә тәгәрәгән.

Карлыгач, күзен ачар-ачмас, көч-хәл белән тын алып ята. Камыты муенына аркылы килгән.

Икесе бергә үләләр икән дип дерелдәп үк төштем инде. Ярдәм эзләп тирә-якка күз салдым. Берәү дә юк — көлтә бәйләүчеләрне урман борылышы каплаган иде.

Ничекләр генә чыгарыйм икән инде Борһанның аягын ат астыннан? Йөгәненнән тотып сөйрәп тә карадым Карлыгачны. Юк, кымшанмый гына түгел, аның саен Борһан ягынарак авыша.

Еларга җитешеп, Борһан ягына йөгереп чыктым. Камылга тезләнеп, кулларым белән, күкрәгем белән Карлыгачның кайнар сыртыннан этеп карадым. Юк, кузгатып та булмый Карлыгачны.

Шыбырдап тир аккан битемне күлмәк җиңенә ышкып алдым да, үлми микән дип, Борһанга әйләнеп карадым. Аның газап тулы күзләрен күргәч куырылып килдем. Бигрәк ярдәмчесез, бигрәк кызганыч мөлдерәп карап ята иде Борһан бу минутта миңа. Нишләячәгемә дә хисап биреп тормастан, битләремне камылга тырната-тырната, башым белән, аркам, иңнәрем белән ат астына керергә тырыша торгач, әллә Карлыгач үзе күтәрелде инде, әллә чынлап та мин үземдә аны күтәрерлек көч таптым — ниһаять, Борһан аягын тартып алды.

Инде авыз тирәләре күбекләнә башлаган Карлыгачны коткарырга кирәк иде. Абына-сөртенә, егыла-егыла дигәндәй, каударланып барып, калтыранган кулларым белән чөелдерек элмәген тарттым — камыт җәелеп китте. Карлыгач җиңел сулап җибәрде.

Борһан, шуны гына көтеп яткандай, тешләрен шыгырдатып аяк өстенә басты, аксый-аксый Карлыгачның башы турысына әйләнеп килде һәм, кизәнеп сугар өчен, чыбыркы сабын югары күтәрде.

Күз алдымнан Карлыгачның курку катыш ялвару тулы карашы чагылып узды. Мин, үз-үземне белештермичә, ат белән чыбыркы арасына барып кердем һәм шунда ук, авыртуга чыдый алмыйча, бөгелеп төштем.

Борһанның теш шыгырдатуы да, Карлыгачның шаулатып тын алуы да, Урал белән Җирәнкәйнең кигәвен талауга чыдый алмыйча тыпырчынулары да текә ярдан инеш суына шыбырдап балчык коелуы аша гына ишетелә сыман тоелды миңа.

Авырту кимегәч, кулларымны колак артыннан алып, акрын гына күзләремне ачтым. Борһан, бер якка кыйшаебрак, ютәлли-ютәлли үр астына төшеп бара иде.

— Борһан абый, кая барасың? — дип кычкырдым мин, берсе егылып яткан, икесе тыпырчынып торган атлар янында ялгызым гына калудан куркып. — Китмә, Борһан абый, авыртмады минем бер җирем дә...

Борһан туктады. Борылды. Артык кычкырмыйча гына, ләкин миңа ишетелерлек итеп, өзеп-өзеп әйтте:

— Кайтам... Хәлем юк... Йөрәгем кага... Урдыра тор

ике ат белән... Алҗысалар, алыштырып җик... курыкма, урдыр...

Борһан, тагын нәрсәдер әйтергә теләгән сыман, башын иеп уйланып торды. Ютәле кузгалгач, кулын селкеп, чайкала-чайкала чүмәләләр арасына кереп югалды.

Карлыгач та хәйләкәр икән. Борһан киткәч үк, муенын сузып, әле бер яктан, әле икенче яктан үләннәр тешләп өзде. Үләннәргә буе җитми башлагач, сыртына ятып аунады һәм, берни дә булмаган сыман, аяк өстенә сикереп торды, тузан туздырып кагынды.

Басуда Борһанның киң кепкалы башы күренмәгәч, тирә-якта аның ачулы тавышы, чыбыркы сызгыртулары ишетелмәгәч, башта ничектер сәер, хәтта нәрсәдер җитмәгән кебек тоелды миңа. Аннары, акрын-акрын, ялгызлыкка күнектем.

Әйләнә икән ләбаса машина канатлары Борһаннан башка да. Борһан берөзлексез чыбыркы селкеп бармаса да урыла икән арыш...

Шулай да иң күңеллесе — берүзең өч ат белән уraktан кайту. Бөтен кешенең күзе синдә. Ә син ике яктан йокымсырап кайткан атларыңа аны-моны сиздерми генә тезген очы белән чирткәләп аласың. Атлар, сискәнеп, башларын күтәрәләр, авызларыннан ут чәчеп торган ак яллы аргамаклар кебек, кырын-кырын атлап китәләр, колакларын шәмрәйтәләр. Ә син, аларга бөртек тә игътибар итмәгәндәй, уртадагы атыңа атланган көе, сыныңны туры тотып, юл уртасыннан узасың.

Авылга кергәч, ерак та китеп өлгермәдем, «Рәсим, әй, Рәсим» дигән тавыш ишетеп, тезгенемне тарттым. Тар сукмак буенча нәрсә тәгәрәп килә дисәм — Хәбир икән.

— Рәсим, дим... Шулкадәр кычкырып та ишетмисең...

— Тыр-р!.. Нәрсә булды? Кече морҗагызга ут капмагандыр ич?

— Берсенә мин атланып барыйм әле дворга кадәр, Рәсим, ә?

— Кайсына атланасың? Уралгамы, Җирәнкәйгәме?

— Урал биек ич. Җирәнкәйгә атланам. Алып кил әнә теге таш янына.

Мин атларны Гарифулла бабайлар йорты каршында аунап яткан олы таш янына китереп туктаттым. Хәбир, җайсыз гына үрмәләп, Җирәнкәй сыртына менеп ятты.

— Ятма син, утыр. Атланып утыр.

— Нүжәли үзең генә урдырдың, малай, бүген?

— Һи, нәрсәсе бар дип беләсең соң син урак урдыруның?!

— Мөнәвәрә апа минем янга да килеп китте әле... Оч-

такка чакыра. Председатель рөхсәт итсә, урак машинасын Рәсимгә ышанып тапшырырга торабыз, бик булдыклы, тырыш малай, ди. Сине мактый, Борһан абые белән күгәрчендәй гөрләшеп эшли башлаганнар иде кана. Борһан абые чирләп киткән, ди... Син ничек уйлыйсың, малай, эшли алырмын микән мин очтакта?

— Эшләми ни? Эшлисең, — дидем мин, Хәбирнең күңелен төшермәскә тырышып. — Атыңа атланасың да басу буйлап куалыйсың... Менә сиңа очтак!

Өйдә әни мине бусагадан ук елмаеп каршы алды.

Җыерчыклары шомарып, алсуланып киткән йөзен эссе мич ягынарак борып:

— Сизәсеңме? — дип сорады.

— Кызунымы?

— Кызуны сиңа! Исне.

— Басу исе... Камыл исе... Чәчәк исе... Юк, әни, бернинди дә ят ис сизмим мин.

— Тиле. Ят ис түгел. Мөнәвәрә апаң бер пот он китереп китте. Төш вакытында ук изеп куйган идем. Бодай камыры кебек кабарган. Басып, әвәләп мичкә дә тыктым инде. Сиңа кырындык ипи пешердем. Бар, юынып кер дә тизрәк, ашарсың.

— Күрсәт әле, әни, нинди була икән кырындык ипи? — дидем мин түземсезләнеп.

Әни сәке читендә яткан җитен тастымалны ачып җибәрде: кырыйлары кызарып килгән, йөзе алсуланып яргаланган... Татлы исе борыныма килеп тә керде, күзләремнән яшь атылып чыгып, яңакларым буенча агып та китте.

— Ипи, — дип шатланып типте йөрәгем.

Бу кадерле аваз тәрәзә артындагы тубылгы куаклары аша, эти төшләреннән минем хыялларыма күчкән ак яллы аргамаклар эзе буйлап, тын басулар өстендә җемелдәшкән көмеш йолдызларга кадәр менде дә, кичке җыр булып җиргә әйләнеп кайтты, кайтаваз булып яңадан йөрәгемә килеп керде:

— Ипи!

# Хикәяләр



## СОЛДАТЛАР КАЙТА

Әй, көне-төне солыда гына тотасы иде шушы Акъялны. Тазарып, чибәрләнеп китәр иде атна-ун көн эчендә. Көндез генә җигәсе иде аны. Төнлә йокласын, ял итсен иде. Күр инде, аяк өстеннән йоклап бара, бичара. Кабыргалары мичкә кыршаулары кебек бүселеп-бүселеп чыккан. Ыңгырчак астындагы ярыклардан кош очып чыгарлык. Камыты да буш. Таудан түбән төшкәндә, муенына аркылы килә.

Кабык төпле арбада ике малай һәм бер тимер мичкә. Арба тәгәрмәчләренең өзлексез ыңгырашуларына карaганда, мичкә ярыйсы ук авыр булырга охшый.

Малайларның икесе дә яланбаш, яланаяк. Сүс дилбегә уң яктагы малай кулында. Анысы буйга да зуррак, төскә дә олымсарак күренә. Йөзе җитди. Күзләре уйчан.

Сул яктагы малай лаеш шулпасын азрак эчкән, ахры, тирә-юньне илтифатсыз гына күзәтеп бара. Чебиле аякларын селки, курнос борынын югары чөеп, төпсез зәңгәрлектән тургайлар эзли, йә булмаса, ерак басудагы ялгыз трактор гөрелтесенә колак салып бара, яисә, чыбыркы сабын тидереп, тәгәрмәч тырнакларын кырдыра, ара-тирә ат тоткан малайга сүз ката. Тегесе теләмичә генә җавап кайтара. Яисә иптәшенең сүзен бөтенләй колак яныннан уздырып җибәрә.

— Хәмис, дим, карале, Хәмис, бер-ике пот солы ашатсаң, мин әйтәм, танып та булмас иде Акъялны, ә!..

— Һе, әйттең, бер-ике пот солы...

— Ярты пот булса да әле, әйеме?..

— Соң... На, Акъял, на... Бөтенләй йоклады, кара!

— Арыган ул, Хәмис. Төнлә тырмага җиккәннәр аны.

— Беләм.

— Ярый инде крачинны апкайтып җиткерәлсә...

— Апкайта.

— МТС тагын бер трактор бирсә, чәчү ике-өч көндә бетәр иде инде, име, Хәмис?

— Бирер, тот капчыгыңны... Син генә иең ди...

— Әле берсен ничек бирделәр диген, име?

— Син бик күп сөйләшәсең, Бәхи. Җитәр инде.

— Саруны кайнатасың, диген...

— На, на, Акъял, кара инде, бөтенләй йоклады...

— Ишеттеңме, Хәмис, Кайбычта солдатлар кайта башлаган, ди.

— Кайбыч район үзәге бит ул...

— Шунда әтиең кайтып килсә, нишләр идең, Хәмис?

— Үлгән кеше ничек кайтсын...

Хәмис дилбегәне тарткалаган була. Аның керфекләре арасыннан берничә яшь бөртеге сыгылып чыга да ябык яңаклары буйлап иягенә тәгәри...

Һавада берөзлексез тургайлар сайрый. Әле яңарак кына нәфис яшел бөркәнчек ябынган каен урманы артында моңлы итеп поезд кычкырта. Арба тәгәрмәчләре авыр шыгырдый.

— Нимесне дә дөмектерделәр дөмектерүен, безнең әтиләр генә...

— Җитәр сәнә, Бәхи... На, на, Акъял, на!..

Корыган инешкә килеп җиткәч, малайлар, ярым җимерек күперне «хут» белән чыгып китәргә уйлап, икесе ике яктан Акъялны ашыктырырга керештеләр.

Акъял ныгытып баскан саен, күпер такталары шыгыр-шыгыр килде, субайлар чайкалды, бүрәнәләр дерелдәде. Ниһаять, Акъял, күпернең теге ягына чыгып, каты җиргә басты. Ал тәгәрмәчләр дә юл тузанында. Малайлар күперне хәвеф-хәтәрсез исән-сау чыгып җиттек, дип сөенгәннәр иде дә, булмады, иртәрәк шатланганнар икән: һич көтмәгәндә, күпер башындагы нәзек бүрәнәләр дөбер-шатыр берсе өстенә икенчесе килеп өелде, һәм арт тәгәрмәчләр икесе дә дырык итеп күпер ярыгына төшеп утырды. Акъял җилләнеп атлаган җиреннән чак кына егылмый калды. Камыт бавы суырылып чыкты, аркалык шартлап өзелде...

Бригадир ашыктырган иде. Тизрәк кайтырга карагыз, малайлар, тракторны гәрүчидән өзмәгез, дигән иде.

Малайлар Акъялны туарып яңадан җиктеләр. Арба артына күсәкләр тыгып, тәгәрмәчләрне кузгатырга тырышып карадылар.

— Менә шулай, менә шулай, — дип, тешләрен кысып, күсәкне каерды Хәмис.

Бәхи:

— Шулай булса була, диген, — дип, ябык иңбашы белән бар хәлгә арбаны этте.

Ал тәгәрмәчләр җиргә тимичә тартылдылар, камыт баулары шыгырдады. Дуга бөгәҗәләнеп килде. Акъял, әле генә су коенып чыккандай, манма су булды. Аның һәр мускулы кигәвен талаган чактагы шикелле дерелди, калтырана иде.

— На, Акъял, на, дим...

— Сукма, Хәмис, сукма. Күрәсең ич, хәле юк... Лутчы мин авылга йөгерим, кешеләр чакырып килим.

— Син әйләнеп килгәнче...

— Караңгы төшәр, диген... Әй, Хәмис, никләргә генә олы юлдан китмәдек икән?.. Анда кешеләр дә очрар иде. Әйләнгеч булса да, олы юл яхшы, дип, тикмәгә генә әйтми шул минем әби...

— Телеңә салынма әле, Бәхи, ачу килгән чагында. Әйдә, күтәр... На, Акъял, на...

— Хәмис, Хәмис, дим, карале, кара!

Малайлар икесе дә артларына борылдылар: яшь имәннәр күпереп утырган сөзәк үр өстеннән болайга таба яшел киемле бер солдат төшеп килә иде. Пилоткасын салып кулына тоткан. Аркасында капчыкмы, шинельме... Ялтыр итекләре тузанга буялган... Кем булыр бу? Малайлар бер минутка бар дөньяларын оныттылар. Күзләре зур ачылып, керфекләре хәрәкәтсез калды, аяк бармаклары тынычсызланып кыймылдады.

Менә солдат күпергә керде. Адымнары нинди нык, куллары нинди зур аның. Шулай буладыр инде ул фашистларны чәнчелдергән чын солдат! Шәмәхә күзләрендә йомшак елмаю. Маңгаенда җәрәхәт эзе. Әллә нәрсә дип кенә эндәште ул, малайлар искәрми калдылар. Капчыгын юл читенә салып куйды. Борыннары йомшаган малайларның башларыннан сыйпап узды, баткан тәгәрмәчләрне иелеп карады.

— Нык утыргансыз, — дип, бил каешын төзәтеп куйды. Аннары Акъял янына килде. Учын җәеп атның авызына шикәрме, сохари кисәгеме каптырды. Акъял да гаҗәпсенеп чит кешенең гимнастеркаларын, погоннарын иснәде һәм, ияген тәртә башына салып, «сез дә йөрисез ир кеше булып» дигәндәй, малайларга тешләрен ялтыратып алды. Малайлар, эчләре-тышлары белән балкып, көлеп җибәрделәр. Солдат көлмәде. Дымланган күзләрен кысып, аз гына уйланып торды да җитез хәрәкәт белән арба астында аркылы-торкылы яткан нәзек бүрәнәләрнең берсен суырып чыгарды. Аны күчәр астына тыкты, бер башын, күпернең кай җиренәдер терәп, аска таба кaера башлады. Баткан тәгәрмәчләр бер карыш чамасы күпер өстенә күтәрелделәр. Акъял, шуны гына көткәндәй, арбаны җан-фәрманга алга сөйрәп алып китте. Малайлар, ура кычкырып, солдатка рәхмәт әйтергә дә онытып, Акъял артыннан ташландылар.

— Дилбегәгезне карагыз, тәгәрмәчкә уралмасын, — дип кычкырып калды солдат алар артыннан.

Тургай тавышы белән мөлдерәмә тулы яшел иңкүлек буенча, ак ялларын сибелдереп, ябык ат юырта, тимер мичкә дөбердәп бара, арба артына ябышып, такыр башлы ике малай йөгерә.

Әллә тургай җырыннан, әллә тугай яшеллегеннән, әллә малайлар көлүеннән исергән инде солдат — атлаган уңайга чайкалып-чайкалып китә. Үзе бертуктаусыз елмая, зур учлары белән әледән-әле күзләрен сөрткәли.

Офыклар зәп-зәңгәр. Бинибая якты кояш төшлек турысына якынлашып килә.

## КӘҖӘМӨГЕЗ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Таң алды йокысы белән изрәп йокыга гына китәсең — чолан ишеген дөбердәтәләр. Кем икән дип чыгасың — сакалын сәлперәйтеп, вакытында ашарга бирмәсәгез, менә шулай була ул дигәндәй, күзләре белән көлемсерәп, үзебезнең кәҗә басып тора. Тагын абзарны үзе ачкан, хәерсез. Карга батып беткән. Күренеп тора — тагын күршеләр бакчасын айкап чыгарга өлгергән. Болай күп йөрсәң, аягыңны сугып сындырырлар әле бер. Ничә әйтте күршеләр әнигә: «Йә сатыгыз, йә суеп ашагыз шул явызны», — дип. Юк, якын да килми әни. Җәйгә чыккач, кечерәк сыер кадәр сөт бирә, имеш. Мамыгы да бик җылы, бик йомшак, имеш. У-у! Оятсыз! Карап торуларын күр син аның! Ай-яй ярата вак печәнне. Печәнлек баскычына аяк басуыма, теркелдәп ул килеп җитә. Элегрәк болай мул итеп төшерми идем әле мин аңа печәнне...

Узган көз, Шуалан башына тегермән карарга баргач, тегермәнче малае Нәгыйм миңа этен өстереп җибәрде. Корсагы җирдән сөйрәлеп йөрсә дә, бик тешләк иде аның эте. Тукай бабай әйтмешли, ул куадыр, мин чабамын, мин чабамын, ул куа. Үзе яман да каты ырылдый, үзенең тешләре итек үкчәләремә тиеп-тиеп ала. Инде үзебезнең тыкрыкка борылгач та, арттан калмый бит бәйләнчек нәрсә. Шул чагында куркудан томаланган күзләремә ниндидер бер карамчык күренеп киткәндәй булды. Каршыма тагын бер эт йөгереп чыкты дип торам. Исемә-акылыма килгәнче, юл читеннән кар туздырып узды бу карамчык һәм... минем артта нәрсәдер дөпелдәде. Ул да түгел, аяк астында эт чинаганы ишетелде. Куркуымны көч-хәл белән генә җиңеп борылып карасам — үзебезнең мамык кәҗәсе чината-чината Нәгыймнәр этен куып китеп бара.

Менә шул вакыйгадан соң мулрак эләгә инде кәҗәгә печән.

Февраль ахырларында — көннәр шактый салкын тора иде әле — өйдә ни турында гына сөйләшсәк тә, сүз арасына һаман кәҗә кысыла башлады.

Абый шәһәрдән кайткач та, әни кәҗә турында сөйләшә, теге малай (ягъни мин булам инде) курманы бик бәрәкәтсез сала, язга тикле җитсә ярар иде инде дип кайгыра.

Күрше апалар керсә дә, быел тагын икене китерер, ахры, кәҗәбезнең эче кибән чаклы, күз генә тимәсен, дип мактанып ала.

Өйдә икебез генә калган чакларда да — әллә минем белән киңәшә шунда, әллә уйларын шулай кычкырып әйтә — һаман мыдыр-мыдыр сөйләнеп йөри:

— Бигрәк иртә була бит әле бу быел, Ходаем... Бигрәк иртә була... Катырып үтермәсәк кенә ярар иде. Төнлә ешрак чыккалап карарга кирәк... Көннәрен дә җылытмый, ичмасам...

Мин сөенеп бетә алмыйм — димәк, озакламый кәҗә бәтиләре белән уйнаячакмын. Гаҗәп шаян, гаҗәп шук була бит ул кәҗә бәтиләре. Җитмәгән җирләре калмый аларның — ян белән терт-терт уйнаклап киләләр дә урындыкка сикереп менәләр, урындыктан — өстәлгә, өстәлдән — мич авызына. Бер салкын кышта кайсыдыр кәҗә бәтиенең хәтта мич башына менеп йокларга гадәтләнүе хәтердә калган.

Өйдә олы ир-ат булмаганлыктан, фонарь-фәлән юк иде безнең. Шуңа күрә әни, ишегалдына чыккач, кәҗәнең бәтиләгәнен-бәтиләмәгәнен белер өчен, озак кына тыңлап тора. Бәтиләсә — назлы тавыш белән мекер-мекер килеп, бәтиләренә дәшә инде ул кәҗә. Аннары ялаган тавышы да ишетелә икән.

Шулай бервакытны төн уртасында чыгып китте дә әни, ишегалдында озак кына тавышланып йөрде. Аннары өй дә, ихата да беразга тынып торды. Тагын бераздан ишегалдында кар шыгырдады, чолан ишеге, аннары өй ишеге тупсасына кадәр каерылып ачылды. Бусага төбендә болганып торган салкын томан эченнән әнинең бүрекле башы һәм печән кочаклаган куллары килеп чыкты. Әни печәнне сүзсез генә идәнгә мич буена китереп салды. Үзе тагын тышка чыгып китте.

Ул арада мин дә сикереп тордым. Печән өстендә өсләре бәсләнергә өлгергән нәни генә ике кара бәти кыймылдап ята иде. Берсе нәзек тавыш белән кычкырып та куйды һәм тезләнгәндәй итенде.

Тышта әнинең, төнге тынлыкны сискәндереп, кәҗә чакырганы ишетелде:

— Кәҗ-кәҗ-кәҗ, мә, кәҗ-кәҗ-кәҗ. Нишләдең соң, йөзең ак булгыры? Нигә киреләнәсең, нигә кермисең өйгә?..

Өстемә этидән калган иске тунны элеп, мин дә ишегалдына чыктым. Февраль суыгы ялангач муеннарымны, тезләремне чеметкәләп алды. Күз караңгылыкка ияләшә төшкәч, кулына чыбык тотып амбар почмагында торган әнине күреп алдым.

Бераздан караеп торган абзар авызыннан кәҗә атылып чыкты. Чолан ишеге янына барып мекердәп алды да, койрыгына ут капкандай, тагын абзарга атылып кереп китте.

— Тот, Фәһим, тот, җибәрмә, — дип кычкырып калды сулышы капкан әни аның артыннан. — Котырган микән әллә бу хайван. Кара инде, гомердә кыланмаганны, бәтиләре янына керми... Кәҗ-кәҗ-кәҗ!

Әни, кар шыгырдата-шыгырдата, караңгы абзарга таба юнәлде. Бераздан аның стена буйлап капшанып йөргәне һәм леңгер-леңгер кәҗә белән сөйләшкәне ишетелде.

— Әй, улым, — дип, сөенечле тавыш белән сөйләнә-сөйләнә, әни янә ишегалдына килеп чыкты. — Тагын бер бәтие булган икән ич кәҗәбезнең, шуны салкында калдырып керергә теләмәгән икән ул... Ә без аны орышабыз да орышабыз... Акыллы шул минем кәҗүгем, бик акыллы... Әйдә, әйдә, кәҗ-кәҗ-кәҗ...

Әни кулындагы печәннән бөтен ишегалдына җылы сөт исе таралды. Мин, абына-сөртенә барып, ишекләрне ачып җибәрдем. Әни өченче бәтине дә печәне-ние белән мич буена кертеп урнаштырды. Күр әле, монысы бигрәк матур икән — маңгаенда бөрчек кадәр генә ак табы да бар.

Әмма ни хикмәттер, өченче бәтиен алып кергәндә дә, безгә иярмәде кәҗәбез.

— Яхшы галәмәт булмады инде бу, — диде әни, борчулы тавыш белән, — бер-бер төше авыртадыр монын, әйдә, улым, чыгып сөйрәп керик инде, булмаса... Бәтиләрен рәтләп яламаган да бит әле...

Караңгы абзардан башын чыгарганын гына сагалап торды да әни кәҗәне мөгезеннән эләктереп тә алды. Мин чыбык белән арттан кудым. Басма такталарына аякларын терәп киреләнгән кәҗә, өйгә кергәч тә, мич буенда тыпырдап яткан бәтиләрен аннан-моннан гына ялаштыргалап алды да янә ишек төбенә килде. Әни аптырап миңа карады. Мин, әни күрмәгән арада, мич кашагасыннан шырпы үрелеп алдым һәм, кәҗә үзенең бәтиләре ягына борылгач, шыпырт кына ишектән чыгып киттем.

Әни сизгән икән.

— Нишлисең тагын шырпы белән? Абзарда яндырып, саламга төшерә күрмә, хараплар итәрсең, — дип кычкырып калды.

Ишеге ачык торганлыктан шактый җиләсләнгән абзарга кереп шырпы сызгач, чак кына кычкырып җибәрмәдем. Абзар почмагында тагын бер ак маңгайлы бәти дер-дер килеп салам түшәктән каты җиргә шуып төшеп бара иде...

Колак очлары катып өлгергән юеш бәтине кулыма кысып тоттым да өйгә йөгердем.

Ишекне ачуга, кәҗә, атылып диярлек, минем янга килде һәм, кулымдагы бәтине идәнгә куярга ирек бирмичә, үрелеп яларга кереште.

Әни, ни көләргә, ни еларга белмичә, башын селкеп, мичкә сөялеп тора иде...

Ул төнне мин төшемдә тегермәнче малае Нәгыймне күрдем. Ике бармакчалы солдат бияләйләрен салып култыгына кыстырган. Кызарган бармаклары белән якты күк гөмбәзенең нәкъ уртасына төртеп күрсәтә-күрсәтә: «Әнә Кәҗәмөгез йолдызлыгы. Әнә Кәҗәмөгез йолдызлыгы!» — дип кычкыра. Мин дә, башымны күтәреп, югарыга карыйм. Анда биектә-биектә, ак болытлар төркеменә кушылып, дүрт бәтие белән бергә безнең кәҗә йөзеп бара, имеш.

## КЫРМЫСКА ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Кырмыска күз чите белән генә кояшка карап алды. «Үләннәрне дә җылытмый, әллә көзгә авышып бара инде көннәр» дип уйлады ул. Тик бу күңелсез уен шунда ук онытты. Чөнки сукмактан, портфелен селки-селки, Вәли килә иде. Иреннәре селкенә — димәк, якты күзле малай нидер җырлый. Анысы әйбәт. Димәк, аның кәефе яхшы. Гомумән бик әйбәт ул якты күзле малай. Тимер юл буендагы тар сукмактан үткәндә, Кырмысканың үзенә түгел, тәпиенә дә басканы юк. Әле бервакыт хәтта ул, Кырмысканы учына алып, күзләренә якын ук китерде. Кырмыска шаккатып тел шартлатты — күзләре кояш кебек зур һәм якты икән аның. Ә тешләре?! Шулай да курыкмады Кырмыска, Вәлинең изге ниятле малай булуын елмаюыннан сизде. Җылы уч төбендә әрле-бирле йөрде дә кул аркасына чыкты. Вәлинең кул аркасында тырналган урын бар иде — Кырмыска аны әйләнеп узды. Ин-

де Вәли шаккатып тел шартлатты, башын чайкады, Кырмысканы саклык белән генә үлән яфрагына җибәрде.

Әнә шул көнне танып калды инде Кырмыска Вәлине, һәм нәкъ шул көнне аның күңелендә кояш кебек якты күзле малайга нинди дә булса яхшылык эшләү теләге уянды.

Вәли мәктәпкә йөри торган сукмакка иелеп үскән үлән башларын борып куйды Кырмыска, җил очырып китергән сары яфракларны сукмак читенә сөйрәде.

Күрәдер якты күзле малай, күрми үтмидер Кырмысканың болай тырышып йөрүен — йөзе һәрвакыт җиргә, сукмакка төбәлгән була ич аның — тик иелеп карарга вакыты гына юктыр.

Ә бүген — менә бәхет! — күрде бугай ул Кырмысканың тирләп-пешеп сукмакны чистартуын — чүгәләде. Кырмыска әле генә үзе сөйрәп килгән чәчәк орлыгына менеп басты. Вәлинең игътибарын алай гына җәлеп итә алмагач, якындагы үлән яфрагына күчте, сыгылмалы сабак буенча чәчәк таҗына йөгереп менде, алгы тәпиләрен югалап алды һәм үзенә дә чак кына ишетелерлек тавыш белән Вәлигә эндәште:

— Исәнмесез, якты күзле малай!

Вәлинең иреннәре сизелер-сизелмәс кенә кыймылдап куйды.

«Исәнләшүедер инде» дип уйлады Кырмыска һәм Вәлинең күзләренә карады.

Ул да түгел, Вәли, портфелен шпал өстенә ташлап, тимер юл буена сузылып ятты, колагын рельска куйды. Күптән, бик күптән кызыгып йөри иде инде ул ерактагы поезд шавын әнә шулай, колагын рельска куеп тыңларга. Бүген теләген тормышка ашырды, ниһаять. Тик бөтен игътибарын биреп тыңласа да, таныш гөрелте ишетелмәде.

Кырмыскага бер дә ошамады Вәлинең мондый кыланышы. Ул акрын гына җиргә төште, Вәлинең ботинкасыннан сукмакка кадәр салынып торган бауларның ялтыравыклы очларын күздән кичереп чыкты. Аннары, бик озак йөгерә торгач, тәпиләрен тидерер-тидермәс кенә Вәлинең колак яфрагына, яңагына, аннары йомшак иягенә менде. Вәлинең якты күзләре йомылган, болай да озын керфекләре тагын да озынаеп киткән, ул татлы йокыга талган иде.

Кырмыска бөтен җаны-тәне, үзенең кырмыска акылы белән сизде — якты күзле малай монда йокламаска тиеш. Ә Вәли Кырмысканың уйларына төкереп тә бирми — мышнавы мышнау.

Баш очыннан, бик яман фырылдап, чыпчык очып узды. Кырмыска Вәлинең колак артына кереп шылды, югыйсә ышаныч аз ул борчак күзләргә — эләктерде китте, ычкынып кара аннары аның килбәтсез томшыгыннан!

Әллә уяна инде якты күзле малай. Киерелде, терсәген язып җибәрде. Бер кулы кояш җылытып өлгергән рельс өстенә үк барып җитте. Кырмыскага бусы бигрәк тә ошамады. Бер дә күңеле тартмый иде Кырмысканың шул ялтыравыклы озын-озын тимерләрне. Иртән бик салкын була, көндез ут кебек кыза — тәпиләреңне тидерер хәл юк.

Кырмыска Вәлинең җиңе буйлап йөгереп китте, җиң җыерчыкларыннан менә-төшә бара торгач, уч төбенә килеп җитте. Учы теге көнге кебек җылы түгел иде бүген Вәлинең. Ә рельс ничегрәк икән? Кырмыска рельсның җылымы, салкынмы икәнлеген белер өчен, бармаклар арасыннан гына тәпиен сузып караган иде — рельс ерак булып чыкты. Кырмыскага ике бармак арасына бөтен гәүдәсе белән керергә туры килде. Әллә Вәлинең кулы кытыкланып китте инде шунда — ул кинәт кенә бармакларын бергә укмаштырып куйды. «Әни!» — дип кычкырды Кырмыска, муены авыртуга чыдый алмыйча. Ишетте бугай якты күзле малай, ишетте Кырмыска тавышын — йокы аралаш нәрсәдер мыгырданып алды да бармакларын җәйде. «Уф! — дип иркен сулады Кырмыска. — Якты күзле малай мине ялгыш кына кыскан булган, күрәсең. Колаклары да әрекмән яфрагы кадәр шул аның, минем тавышны гына түгел, борча кычкырганын да ишетер».

Карасана, тимердә икән инде аның тәпиләре. Каушавыннан рельска төшкәнен сизми дә калган икән Кырмыска.

Бераздан Кырмыска, Вәлинең нечкә бармагына менеп, офыкка карады. Башта ул, күзләре чагылганлыктан, берни дә күрмичә торды, аннары бөтен гәүдәсе белән калтыранып куйды.

Семафор борылышыннан, олы кара тап булып, тавышсыз гына поезд шуып килә иде.

Кырмыска, якыная, зурая барган кара таптан бигрәк, рельс дерелдәвеннән сизде эшнең нәрсәдә икәнен. Озаклламый сукмак буенда, коточкыч җил куптарып, кырмыска шәһәре кадәрле тәгәрмәчләр тәгәрәп узачак.

Кырмыска ал тәпиен каш өстенә куеп, инде шаулавы да ишетелә башлаган куркыныч машинага берничә секунд карап торганнан соң, тиз генә Вәлинең уч төбенә менәргә теләгән иде, тәпие таеп китте дә янә ике бармак

арасына егылып төште. Сикереп торгач кагынып та тормыйча — кагынырга вакыт калмаган иде инде — шома тимер буенча йөгереп үтим дигәндә генә, Вәли янә бармакларын кысып куйды. «Беттем, — дип уйлады Кырмыска. — Якты күзле малайга бер генә яхшылык та эшләмичә үләм икән!»

Рельсның калтыравы көчәйде. Кара шәүлә якынайды, урман өстенә күтәрелгән кояшны каплады. Ләкин Кырмысканың үз хәле хәл иде. Вәлинең бармаклары арасыннан ычкынырга тырышып, бар көченә тыпырчынды ул.

«Әллә юри кыса инде» дигән кыска гына уй үтте Кырмысканың нәни башыннан. Ниһаять, ул түзмәде, үз-үзен белештермичә, Вәлинең бармак буынын тешләп алды.

Вәли җәлт итеп кулын язды, күзләрен ачты, тиз генә сикереп торды, бөтенләй якында гына поезд тавышы ишеткәч, портфелен эләктереп, тимер юлдан читкә тайпылды. Рельсның әле генә Вәли кулы яткан турысыннан, токы-токы килеп, олы чуен тәгәрмәчләр уза башлады.

Поезд җиле басылгач, Кырмыска, үләннәр арасыннан чыгып, озаклап Вәли киткән якка карап торды.

— Үпкәләмәс микән инде, ялгыш тешләгәнне аңлар микән? — дип борчылды ул һәм, якты күзле малайга кабат нинди дә булса яхшылык эшләү турында хыяллана-хыяллана, поезд җиле белән сукмакка очып төшкән үлән сабагына барып ябышты.

## ТАМГАЛЫ БҮРЕ

Буранлы кич. Мин коедан су алырга чыктым.

Безнең авылга әле электр кереп җитмәгән. Утлы тәрәзәләр анда-санда гына. Аларның да яктылыгы зәгыйфь. Җил аз гына көчлерәк исте исә, сүнеп китәрләр сыман.

Кое бурасының тирә-ягы бозлы, тайгак. Җил үзе себереп алып килгән карны үзе үк очырып тора.

Бозланып каткан кое чиләге «Үги кыз» әкиятендәге агачка элеп калдырган тукмак шикелле берөзлексез чайкала, доң-доң килеп, бурага бәрелә.

Чиләкләрне сукмакка утыртып куйдым. Коега төшеп китмәсен өчен, этидән калган олы бүрекне басыбрак кидем. Бозлы, шома чылбырны ике куллап эләктердем дә аска сөйри башладым.

Кое эче җылы, караңгы һәм шомлы иде.

Ниһаять, чиләкнең чупырдап суга тигәне ишетелде.

Чылбыр берьюлы тыгызланып тартылды. Чиләк, салмак кына чайкалып, бура стеналарына бәрелә-сугыла, өскә күтәрелде.

Шул чагында минем күз алдымда гына ниндидер ут ялтырап киткәндәй булды. Чылбырдан кулларымны алмыйча, буранлы урамга карадым. Башта мин Шәңгәрәй бабайның тәмәке утыдыр бу дип уйлаган идем, ләкин дикъкать беләнрәк карагач, ялгышканлыгымны аңладым. Дүрт-биш көнгә бер кардоннан безнең авылга төшеп йөри торган овчарка Җиган икән бит. Шул булмыйча тагы — мондый зур этнең безнең авылда гомер булганы юк. Шактый әлсерәгән, ахрысы — мине бар дип тә белми. Тамак төбеннән әллә нинди сәер тавышлар чыгара. Як-ягына карана-карана, ашыгып-ашыгып боз ялый.

Эчәсе килгән икән бичаракайның дип уйладым мин һәм, үз-үземә хисап биреп тормастан, чыгарган суымны бозлы сукмакка аудардым.

Җиган тавышсыз гына бер читкә сикерде. Миңа тасыраеп карап торды, һәм бераздан тавышсыз адымнар белән янә миңа якынлашты. Авызын карга төртте. Утлы күзләрен миннән аермыйча, карлы суны эчә башлады.

Шул чагында кинәт мин аның уң колагы яртылаш киселгән булуын шәйләп алдым. Җиганның колаклары очлы һәм озын иде бугай ич дигән уй йөгереп узды минем башымнан...

Шулай күпме вакыт узгандыр — авыл башыннан буран улавы аша кешеләр сөйләшкәне ишетелде. Ферма ягында капка шыгырдап алды. Тавышларны миннән алда ишеткән булгандыр, күрәсең, Җиган бу мизгелдә — ничектер югарыга омтылып, сузылып, сурәтле китаплардагы таш сынга охшап тора иде.

Кеше тавышлары якынлашты. Җиган башын минем якка борды. Иснәгән кебек итте. Күзләрен ялт-йолт уйнатып алды һәм, шәүлә кебек кенә шуып, болганчык эңгер эченә атылды. Әйтерсең лә минем яннан гына карга тияр-тимәс биниһая зур төн кошы очып узды.

Бераз вакыт үткәч, коймалар ышыгыннан иңнәренә мылтыклар аскан ике чаңгылы кеше аерылып чыкты. Сөйләшүләреннән үк танып алдым, безнең авылныкылар түгел иде болар.

Берсе адымнарын акрынайтты, бияләйләрен култык астына кыстырып, тәмәке кабызды. Икенчесе, туктап, аны көтеп алды, борчулы тавыш белән:

— Авылга кермәс инде, — диде.

Кое чылбыры шалтырагач, алар икесе дә минем якка борылдылар.

— Әй, малай, моннан бернәрсә дә үтеп китмәдеме? — диде зур бүреклесе.

— Моннан әле генә Җиган узып китте, — дидем мин, чаңгылы кешеләрнең мылтыкларына кызыгып карый-карый, аларның игътибарын җәлеп итәргә теләп.

— Җиганны Митрәй дәдә бәйгә куйган, юкны лыгырдый бу малай, — диде зур бүрекле кеше.

— Уң колагы китек түгел идеме?

— Китек...

Тегеләр бер-берсенә карашып алдылар.

Баштанаяк ак кием кигәне:

— Шул инде, шул, тамгалы бүре, — дип, мылтыгына ябышты. Зур бүрекле иелеп кое тирәсендәге эзләрне тикшерде.

Миңа кинәт бик куркыныч булып китте. Чынлап та, Митрәй дәдәйнең Җиганы болай ук зур түгел иде ләбаса...

Тып-тын авылны яңгыратып этләр өрә башлагач, мин тагын да ныграк куркуга төштем.

— Ишетәсеңме, ишетәсеңме? — диде ак киемле кеше иптәшенә. — Якын-тирәдә бүре барын сизәләр, этләр беркайчан да болай котырмый — шым гына яталар. Димәк, ул инде авылдан чыгып сыпырткан.

Мылтыклы кешеләр кузгалып киткәч, мин чиләкләремә ашык-пошык су тутырдым да йөгерә-чаба, абынасөртенә өйгә элдердем. Капканы бастырык белән терәттем. Чолан ишегенә җиткәнче, суларым яртылаш кына калды. Чолан ишеген ныгытып бикләдем. Кабалана-кабалана өй ишеген ачтым.

Җиделе лампаның филтәсен көйләп маташкан әни эшеннән туктады да:

— Нишлисең? Егылдың мәллә? Артыңнан кумыйлардыр ич, ярты суыңны түгеп бетергәнсең, — дип, мине битәрләргә кереште.

— Тамгалы бүре... — дидем мин, сулышымны көчхәл белән генә алып, һәм бозланган чиләкләремне чайпалдырып идәнгә утырттым.

Ул чагында безнең ише бала-чагаларны урманга берьялгызыбызны гына җибәрергә куркалар иде. Имеш, анда бозау кадәр тамгалы бүре йөри икән, имеш, һәрвакыт узгынчыларның юлларына аркылы төшеп, теш шыгырдатып тора икән.

Менә бу юлы да хәлнең ничек булганлыгын сөйләп биргәч, әни, коты очып:

— Кит аннан! — дип тәшвишкә төште. — Каһәр генә суккан нәрсә икән, инде авылга да килеп йөри башлады

микәнни?.. — Аннары үзен дә, мине дә тынычландырырга тырышып, ахры, болай диде: — Бүре алай кыланмас, улым. Эт булгандыр ул, күзеңә генә күренгәндер...

Әни генә түгел, иртәгесен күршеләр дә ышанмады миңа. Ничек инде, имеш, бүре боз ялап, су эчеп торсын...

— Шыттыра Хафиз малае, — дип көлделәр күпләр, — бозау булгандыр ул...

Мин үзем дә күземә генә күренгәндер дип ышанып йөри башлаган идем инде. Ләкин...

Карлар эреп, сулар акты. Җирләр кибеп, дөньялар яшәрде. Сабан туйлары якынлашты. Шундый матур көннәрнең берендә без, өч малай — Рәхим, Инсаф һәм мин, урманга киттек. Каен җиләгенең яңа пешеп килгән чагы. Талгын гына лебердәшеп торган яшь усаклар арасында үлән тапталмаган. Куак яфраклары сусыл яшел.

Җиләкнең тәмам пешеп җиткәннәре кояш төшә торган аланлыкларда гына. Без шулай аланлык күренгән саен, «уйдык таптым» дип куаныша-куаныша, муеннарына җеп бәйләгән ярты литрлы банкаларга җиләк тутырабыз. Ара-тирә, ихтыярыбыз төкәнеп, «кызыл чүлмәкләргә»дә шудыргалыйбыз.

Шулай дөньябызны онытып чикләвек куаклары тирәсендә йөргәндә, Инсаф бөтен урманны яңгыратып чәрелдәп җибәрде:

— Малайлар, тамгалы бүре!

Рәхим белән без аңга килгәнче, Инсаф, җыйган җиләкләрен җиргә чәчеп, якындагы усакка үрмәли дә башлады.

Без дә, шарланган күзләребезне челт-челт йомгалап, Инсаф артыннан ташландык. Тик икебез дә бик каушаган идек, ахрысы, — чәбәләндек, сикергәләдек, әмма җирдән аерылып китә алмадык. Рәхим тотынган нәзек ботаклар чырт-чырт сынды, ә минем аяклар тыңламады...

Ниһаять, без дә аны шәйләп алдык. Ун-унбиш адымдагы тыгыз куаклар арасыннан башы гына күренә иде аның. Куркуыбыздан дер-дер килеп, телдән язып, икебез ике яктан бер үк усак кәүсәсен кочкан көе, зәңгәрсу-соры күзле, сыңар колаклы җанварга карап тора башладык...

Юк, безгә һөҗүм итәргә җыенмый иде бугай ул. Киресенчә, аның күзләрендә курку катыш гаҗәпләнү катып калган иде.

Шунда хәтеремә кылт итеп кышкы буранлы кич килеп төште һәм мин җиңел сулап куйдым. Кулларымны усак кәүсәсеннән ычкындырып, тел очыма килгән беренче сүзне кычкырдым:

— Әй!.. Әй! Ни карап каттың... Бар, юлыңда бул!

Ул арада Рәхим дә, үз-үзен кулга алып:

— Күсәк сындырып алып маңгаеңа тондырганчы, китәсеңме, юкмы? — дип гайрәт чәчте.

Безгә җансыз агачка карагандай илтифатсыз гына карап торган бүрегә тагын әллә нинди сүзләр кычкырсак та, ул кымшанырга ашыкмады. Бары тик Инсаф югарыда чыртлатып ботак сындыргач кына, борынын сузып, тирә-якны иснәп алды һәм тавышсыз гына яфраклар арасына кереп югалды.

Мин тамгалы бүрене тагын бер тапкыр күрдем. Көзен, ике урман арасындагы уҗым басуында атып киткәннәр иде аны. Әллә самолеттан атканнар инде — тирә-ягында кеше-фәлән күренми. Ядрә тигәч тә, байтак йөгергән, ахрысы — ямь-яшел уҗым диңгезе өстендә кызыл таплар шактый еракка сузылган...

Бу вакыйгадан соң авыл тирәсендәге урман-кырлар күңелсезләнеп, бушап, моңаеп калгандай, бөтен кызыгын, табигый серен югалткандай тоелды миңа. Әгәр дә атып китмәсәләр, тамгалы бүрене кулга иялэштереп булыр иде дип, әллә күпме көннәр уйлап йөрдем. Тик иске кое сиртмәсе генә, андый уй-хыялларның беркайчан да тормышка ашмаячагын исемә төшерергә теләгәндәй, олы мылтыкка охшап, урман ягына төбәлеп торды.

## АКТӘПИ

Шәмсекамәр апа, шәһәргә олы малае янына күчеп киткәндә, җир бетереп эзләгән, диләр, ак тәпиле кара песиен. Әллә бакчалар артында тычкан аулап йөргән инде Актәпи, әллә, шәһәргә китәсе килмичә, юри берәр караңгы почмакка качып торган, — күпме генә эзләсә дә, табалмаган шул, табалмаган Шәмсекамәр апа иркә песиен. Сызланып-сызланып булса да, песисез генә китәргә туры килгән аңа шәһәргә.

Әнә хәзер көн саен елап йөри Актәпи. Аркылы-торкылы такта кадакланган тәрәзәләргә карап елый-елый да ул, муртайган киртәләр өстеннән тып-тын ишегалдына сикереп төшә. Нигез буенда котырып үскән кычытканлыктан урап уза да бикле ишек янына килә. Ишек астындагы ярыкка борынын төртеп ала, такта башларына сырпалана. Аннары тагын кычкырып елый башлый.

Гөлфияләрнең өйләре Шәмсекамәр апалар каршысында. Урам аша гына чыгасы. Шуңа күрә бүтән күрше-тирәләргә караганда Гөлфияләргә ныграк ишетелә мәче елавы.

— Мур кырса кырмады, иртән шуның тавышы, кич

тагын, — дип сукрана еш кына Гөлфиянең әтисе, эштән кайткач.

Әнисе алай ачуланмый. Тыңлап-тыңлап тора да Актәпинең елавын: «Бичаракай, — дип куя, — бичаракай! Әбисе бик ярата иде шул аны. Иртә-кич җылы сөт белән сыйламый калмый иде. Кәҗә генә асраса да, сөтен кызганмый торган иде песиеннән».

Гөлфиянең бабасы дөм сукыр. Шулай да ул ни өчендер матур келәм кадакланган стенага түгел, якты тәрәзәгә карап утырырга ярата. Тәрәзәдән карап нәрсә дә булса күрә диярсең. Хәер, күрә бугай ул, чынлап та күрә бугай. Күңел күзе белән үткен күзле Гөлфия күрә алмаган нәрсәләрне күрә бугай ул.

— Бар, кызым, Шәмсекамәр киленнең мәчесе кайтты, карыны ачкандыр, — ди ул, шулай тыныч кына ачык тәрәзәгә карап утырганда.

— Тавышы ишетелмәде ич, каян беләсең, бабай? — дип гаҗәпләнә Гөлфия һәрвакыт.

Бабасы аны-моны дәшми. Җыерчыклы йөзен серле елмаю белән балкытып, тәрәзә каршысында утыра бирә.

Гөлфия, сапсыз чүмечкә сөт салып, урам аркылы йөгереп чыга да, купкан койма тактасын авыштырып, Шәмсекамәр апаларның моңсу, буш ишегалларына керә; күрә: ак тәпиле кара песи чынлап та кайткан, үзалдына мыр-мыр килеп, азык көтеп йөри. Гөлфия басма алдына якынлашкач, ул бер аңа, бер йозаклы ишеккә карап мияуларга тотына. Нәзек сыйраклы, каратут йөзле, кыска күлмәкле кызчык ишекне, Шәмсекамәр өйдә чаклардагы кебек, очыртып кына ачып җибәрер дип өмет итәдер, ахры.

Гөлфия сапсыз чүмечне тамчылар чокырайткан басма тактасына куя, үзе дә шунда иплән утыра, Актәпинең комарланып сөт эчүен кинәнеп күзәтә, үзе бабасы турында уйлый. Ничек сизә икән соң ул? Көндез еламый да ич Актәпи. Өй артындагы тупыл ботагына кош килеп кунганын да сизә, хәер, Гөлфиянең бабасы. Алай гына да түгел, нинди кош кунганын да әйтеп бирә. Һәм мәчене дә Гөлфиядән ким кызганмый ул. «Тамагын туйдырдыңмы әле бүген Актәпинең, кызым?» — дип сорашып кына тора. Туйдырмыйммы соң инде Гөлфия, әтисе ачуланмаса, Актәпине үзләренә генә алып кереп яшәтер иде дә әле ул, әтисе ризалык бирми. «Бетмәс монда ябага мәчеләр», — ди. Җәнлек-җанварларның үзләрен яратмый шул Гөлфиянең әтисе, тиреләрен генә ярата. Төлке, тиен, бурсык тиреседер — бөтен читлек тулган анда.

Актәпи Гөлфиягә тәмам ияләшеп җиткән иде инде. Ләкин ул көннәрдән бер көнне һич көтмәгәндә юкка чык-

ты. Гөлфия бик кайгырды бу хәлгә. Ашы аш, уены уен булмады. Төннәрен йокысыннан, «пес-пес» дип, мәче чакырып уянган чаклары күп булды аның.

Күз үтте, кыш җитте.

Гөлфия менә бүген дә, тимер чанасын сөйрәп Инеш тавыннан менгәндә, Шәмсекамәр апаның тоташ ак җәймә ябынган ишегалдына, киртләч-киртләч сырынтылар зәңгәрләнеп яткан басма такталарына карап узды. Бер генә эз-фәлән дә юк иде кар өстендә. «Бүген дә кайтмаган Актәпи, — дип уйлады Гөлфия, — йә урманга киткәндер дә, авылга юл таба алмыйча, адашып йөри торгандыр. Йә берәр ерткыч тырнагына юлыккандыр, йә ачыгып, туңып үлгәндер. Юк, үлмәгәндер. Бик тә җитез, шаян, акыллы песи бит ул, үлмәгәндер».

Гөлфия кайтып кергәндә, өйдә бабасы ялгызы гына иде. Сумалалы җепләрдән кулларына буй-буй эзләр чорналган. Киез итеккә олтан салып утыра. «Күзле кешедән дә җыйнаграк тегә итекләрне Каюм бабай», — дип мактый аны бөтен күрше-күлән. Дөресен дә дөрес инде. Җепләрен шулкадәр тигез атлата олтан буенча — машина белән чигү чигә диярсең...

— Бабай, бүген дә кайтмаган Актәпи, — диде Гөлфия, бусагада басып торган килеш, туңган бармакларына өргәли-өргәли.

— Кайтыр, кызым, кайтыр, кайгырма, — дип, сумалалы җепне зыңлатып тартты Каюм бабай, — төшемдә ак юл күрдем бүген, кайтыр...

— Кайткач этидән качырып кына өйгә алып керербез Актәпине, яме, бабай.

— Әтиеңнән качырмыйча алып керербез, кызым, кайтсын гына.

Гөлфия чишенеп түргә узды, идәндә чәчелеп яткан киез кисәкләреннән Актәпигә урын әзерләргә керешге.

Озакламый Гөлфиянең әтисе белән әнисе кайтты. Алар үпкәләшкәннәр иде, ахры, тавышлары бозлы тәрәзәгә җил орынып китүен хәтерләтте.

— Ни булды тагын? — дип, тегелеп бетмәгән итеген табуретка өстенә ташлады Каюм бабай.

— Әй, шушы, — дип, карлы шәлен салып селкеде Гөлфиянең әнисе, — кыланып йөри шунда! Үлгән елан күтәреп кайтты.

— Кайтса ни! — дип көлде Гөлфиянең әтисе. Үзе җәһәт кенә ике көпшәле мылтыгын почмакка сөяп куйды. — Җебегәч кабыгын салдырам мин аның, берәр әмәлгә ярар әле.

Гөлфия «елан» сүзеннән бик курыккан иде, әмма карлы чиләккә сузылып карагач, тынычланды. Еланның тәңкә-

ләре бөтенләй күренми дә диярлек, ул бәсләнеп кенә түгел, бозланып каткан һәм кара пыяла сыман ялтырый иде.

Нәкъ шул чагында Каюм бабайның караңгылана башлаган чырае ачылып китте. Ул башын келәмле стенага таба борды, берникадәр сагаеп, тынып утырганнан соң, йомшак кына итеп, Гөлфиягә эндәште.

— Актәпи кайткан, кызым, безнең ишекне тырный. Бар, чык, алып кер...

Гөлфия, сөенеченнән сулышы кабып, ишеккә ташланды.

— Кая барасың? Йөрмә юк белән, — дип, аның юлын бүлде әтисе. — Бетмәс монда! Безгә генә димәгән урам мәчеләрен җыеп асрарга...

— Алып керсен, баланың теләгенә каршы килмә, әнә син үзең үлгән елан күтәреп кайткансың ич әле, җаның теләгәч... Ә Актәпи тере җанвар, акыллы җанвар, — дип яклады Гөлфияне бабасы.

Гөлфия шулкадәр каушый, ашыга иде, шуңа күрә өйдәгеләрнең нәрсә турында сөйләшкәннәрен дә аңлап бетермәде ул. Башын бабасының колакчын бүрегенә чумдырды да атылып-бәрелеп өйалдына чыкты, карлы басма төбендә ак тәпиләрен алмаш-тилмәш селкеп утырган кара мәчене күргәч, күңеле тулып елап җибәрә язды. Гәүдәсе ябыгып, кечерәеп калган ятим мәченең моңсу күзләре Гөлфиягә курку катыш өмет белән карый иде.

— Мескенем, кайларда югалып йөрдең соң, каракаем, Актәпием, мамыккаем, — дип, мыек очлары бәсләнгән песине күтәреп алды да җылы куенына кысты Гөлфия.

Актәпи, рәхмәт сиңа дигән кебек, туңган борынын Гөлфиянең җылы иягенә төртеп алды, иркәләнеп мыр-мыр килде.

Өйгә алып кереп идәнгә җибәргәч, Актәпи, яклаучысының кем икәнен сизгәндәй, туп-туры Каюм бабай утырган урындык астына йөгереп керде, кыска гына итеп мияулап куйды. Гөлфиягә аның мияулавы «мин бу» дигәндәй ишетелде. Гөлфиянең бабасына да шулай ишетелгәндер, күрәсең, ул:

— Ә-ә, синмени бу? — диде һәм, дәү кулы белән капшана-капшана, Актәпине тотып алды, тезенә бастырып, аның юешләнгән йоннарын сыпырды. — Кешеләргә иялəшкәч, читенмени урман-кырларда яшәүләре? Өйне сагындыңмыни? Җылы аш ашыйсың, җылы урында йоклыйсың килдемени?

— Мырый, мыр-р-р, мыр, мырый, — дип җавап биреп барды Каюм бабайның һәрбер соравына Актәпи.

Кичке аштан соң Актәпи мич буендагы урындык астына, Гөлфия әзерләп биргән йомшак урынга бөгәрләнеп

ятты. Гөлфия көндәгечә бабасы янына үрмәләде. Әмма ул, ут сүнгәч тә, бик озак йокыга китә алмыйча интекте. Тышта җил сызгырган саен, Актәпинең япан кырда туңып йөрүен күз алдына китерде ул. Актәпи турында уйлаган саен, елыйсы килде аның. Инде йоклап киттем дигәндә, бабасы эндәште:

— Гөлфия кызым, син йоклыйсыңмы?

— Нәрсә, бабай? Йөрәк даруың кирәкме? — дип, сискәнеп башын күтәрде Гөлфия.

— Бар әле, аш өендә Актәпи нәрсәдер җимерә, әниеңнәр ишетми, ахры...

Гөлфия, йокламас өчен җай килгәненә сөенеп, идәнгә шуып төште. Бабасының дәү башмакларын сөйрәп, чаршаулы ишек төбенә килде, ут яндырды, яртылаш ачык ишектән эчкә үтте, йомры кара бауга чорналып идәндә тәгәрәп йөргән Актәпине күргәч, ул көлеп җибәрүдән чак кына тыелып калды. Тик кара бауның песи кыймылдамаган чакта да бәргәләнүен шәйләгәч, артка чигенә-чигенә, әле генә үзе атлап кергән бусагага менеп басты, куркуыннан дер-дер калтыранып, үз-үзен белештермичә:

— Әни! — дип кычкырды. — Әни, әти! Елан! Елан терелгән!

Әтисе белән әнисенең атылып диярлек йокы бүлмәсеннән чыгуларын да, стенага елыша-елыша ишек төбенә килүләрен дә күз чите белән генә күрде Гөлфия. Аның бөтен игътибары идәндәге тамашада иде.

Ә идәндә йоннары тырпайган, күзләре утлы күмер шикелле ялтыраган Актәпи тәгәрмәчләнеп-тәгәрмәчләнеп бөтерелгән кара еланның муенына тешләрен батырган да ачулы мырлый, корбанын хәлдән тайдырырга тырышып, уңга-сулга селтәнә, үзен чолгап кысарга маташкан шома кыршауны тырнаклары белән каптырырга чамалый.

Ниһаять, елан хәлдән тайды. Хәрәкәтләре салмакланды, аннары бөтенләй тынып, идән буенча сузылды. Ләкин Актәпи, тешләрен язу белән, башын күтәрде, зәһәр ысылдап, һөҗүмгә әзерләнде.

Актәпи, шуны гына көткәндәй, еланны янә җәлт кенә муеныннан каптырып алды, янә елан белән бер йомгакка әверелеп, идән буенча тәгәрәп китте.

Гөлфиянең бабасы кыштыр-кыштыр килеп җиткәнче, әтисе чоланнан көрәк күтәреп кергәнче, Актәпи, еланның эшен бетереп, читкәрәк китеп утырды. Шулай да корбанын күздән ычкындырмады, ак тәпиләре белән мыекларын төзәткәндә дә, колак артыннан ук битләрен югалаганда да, еланның хәрәкәтсез салкын гәүдәсенә күзләреннән яшькелт очкыннар чәчеп алгалады.

Өйдәгеләрнең берсе-бер авыз ачып сүз әйтмәсә дә, һәммәсенең уйлары бу йортка кунак булып түгел, хуҗа булып кайткан ак тәпиле песинең сизгерлеге, җитезлеге, батырлыгы турында иде.

## КЫЗЫЛ МӘРМӘР

Хәтерлисеңме, Әминә апа, узган ел, — син әле вожатый булып эшли генә башлаган идең, — рәсем укытучысы Харис абый пионер лагеренда сиңа мәрмәр чәчәк бүләк итте туган көнеңдә. Ул чәчәкнең таҗ яфраклары синең бармакларыңа охшаган иде. Шундый нәфис һәм апак иде алар. Минем бик тә Харис абый урынында буласым килгән иде ул чагында. Юк, синең рәхмәтеңне ишетер өчен түгел, әнә шундый, үз кулларың белән ясалган мәңгелек чәчәк бүләк итеп, сине сөендерер өчен.

— Чәчәк кенә түгелдер бу, күктән төшкән йолдыз кисәгедер, — дидең син, бүләгеңне әле зәңгәр су өстендә, әле яшел куаклар каршында уйнаткалап, — кеше кулы ясаганга ышанасы да килми...

Мәрмәр чәчәк кояш нурларында күзләрең төсле балкыды. Аның янында безнең бизәкле открыткалар, авторучкалар, үзебез ясаган рәсемнәр бөтенләй төссезләнеп калды. Дөрес, бүләкләребез өчен безгә дә рәхмәт әйттең син. Мәгәр ияк очыңдагы миңеңә, озын керфекләреңә, басу исе аңкып торган чәчләреңә кадәр Харис абыйга, бары тик аңа гына мактау җырлады.

Карап торганым бар Харис абыйның мәрмәрне ничек эшкәрткәнен. Нинди кораллар кирәген дә беләм. Мәрмәр карьеры Лачын тавы башында гына — мәрмәрнең төрле зурлыктагыларын табарга мөмкин. Әмма кул гына тыңламый. Кулны гына ничек күнектерергә. Харис абыйга ансат аңа. Кискечне менә болай тотасың, имеш, менә болай сугасың, менә болай кисәсең... Булмый шул алай гына, булмый...

Әти столяр минем. Әби әйтмешли, ул ясаган өстәл-урындыклар җанланып, тыпыр-тыпыр биергә генә тора. Ә минем нигәдер агачка күңел тартмый... Таш яратам мин.

Ни өчен әти турында сөйлимме? Аның зур гына остаханәсе бар. Мәрмәр кисәкләре белән генә шунда әвәрә киләм инде мин. Куяннан алып филгә кадәр ясый алам. Кеше башлары да ясыйм хәтта. Борынгы заман тарихындагы шикелле ак күзле кеше башлары... Аларның берничәсен мәктәп музеена да куйдылар. Мәгәр миңа ке-

ше башы кирәкми шул хәзер. Чәчәк кирәк миңа, чәчәк. Әгәр Харис абый шикелле нәфис итеп мәрмәр чәчәк ясый алсам, чын пионер сүзе, Әминә апа, йә туган көнеңдә, йә Сигезенче мартта сиңа бүләк итәр идем...

Түгәрәклим, шомартам, сабын да килештерәм. Тик таҗ яфракларына җиткәч, көймәм комга терәлә. Нәрсә белән генә, ни белән генә шомартып карамыйм инде. Юк, тәмам юкарып җитте, нәфисләнде дигәндә, керт итеп китеlә дә төшә яфрагым. Әни әрләп тә бетерә үземне. «Күр инде өс-башыңны, күр инде кыяфәтеңне, күр инде кулларыңны?» — ди. Әле ярый әби бар өйдә. Ул сүз әйттерми. Аңа рәхмәт.

Шулай сәгатьләр буе маташам-маташам да ахыр чиктә, барысына да кул селтәп, Лачын тавына менеп китәм. Машиналарның карьерда тыз-быз килеп йөргәннәрен күзәтеп утырам. Карьерда эш тәмамлангач, аска төшәм, актарылып ташланган тау токымнарына, ташларга, мәрмәр катламнарына ниндидер үче бар кеше сыман төксәреп карап торам. Нигә җәфалыйлар болар мине, ә? Нигә буйсынасы килми боларның миңа? Киләчәктә барыбер җиңәрмен җиңүен. Мәгәр бүгенгесе кыйммәт...

Беркөнне шулай чираттагы уңышсызлыктан соң карьерда ямансулап йөри идем, чак кына абынып егылмый калдым. Бер ягы мүкләнгән гап-гади таш икән, хәерсез. Ташны ачу белән куптарып алдым да, баш очында талгын гына әйләнеп йөргән тилгәнгә җиткезергә теләгәндәй, бик каты кизәндем. Шул чагында күзләремне ниндидер сәер нур чагылдырып узды. Әле генә мине сөрлектергән таш урыныннан бөркелә иде бу нур. Иелеп карагач, алсу-кызыл тау токымы күренде. Тиз генә казып алдым — чып-чын мәрмәр кисәге иде бу. Тик ни өчен кызыл әле ул? Безнең тауларда гомер булганы юк мондый мәрмәрнең. Үзе зур түгел. Кушуч кадәр генә. Баеп барган кояш шулай кызарткан, нурландырган микән әллә аны? Кояшка аркам белән борылдым — барыбер кызыл, барыбер нур чәчә... Юкка кына ашкынып типмәгән икән йөрәгем, бәхет кошы тоткандай, юкка гына шатланмаганмын икән — алып кайтып күрсәткәч, Харис абый беркавым өнсез калып торды.

— Фәрит! — диде ул аннары, гаҗәпләнүен яшермичә.— Памир мәрмәре бит бу, кызыл мәрмәр!.. Безнең тауларда бөртеге дә калмаган, дип йөриләр иде... Ничек таптың?

Мин сөйләп бирдем.

Харис абый кызыл мәрмәрне мәктәп музеена куйыйк, дип әйтер микән инде? Әллә... Юк, Харис абый алай әйтмәде. Минем теләгемне сизенгәндәй:

— Менә бу мәрмәр ичмасам! Тырышсаң, моннан йөзек кашы да ясый аласың, молодец, Фәрит, тауларда юкка гына йөрмисең икән, — диде. — Ничек теләсәң, шулай кисеп була кызыл мәрмәрне. Борынгы заманда аннан ук очлары ясаганнар...

Берничә көн табылдыгыма орынырга куркып йөрдем. Хәер, юкка курыкканмын икән. Бу юлы эш шундый шома барды. Кайсы минутларда ашыгып ашка пешмим тагын, дип шүрләп тә куйгалый идем. Андый чакларда кискечләремне, шомарткычларымны ташлыйм да саф һавага чыгам. Бакчада чәчәкләр карап йөрим. Нindирәк итеп ясыйм икән, дим...

Тик күпме генә тырышсам да, күпме генә теләсәм дә, синең туган көнеңә өлгертә алмадым мин чәчәгемне, Әминә апа. Алай гына да түгел, кызыл мәрмәрне хәтта чәчәк рәвешенә дә китерә алмадым. Шомарткан килеш калды шулай...

Әй, әти белән әни инде!.. Һич көтмәгәндә, әбинең берьялгызын иске өйдә калдырып, яңа өйгә күчтек. Күптән сала башлаган идек инде без яңа өйне. Әби дә бик сөенеп йөргән иде. Менә сиңа мә! Бик ярата идем бит мин әбиемне. Бәләкәй чагымда камырдан чыпчык, тургай сыннары ясарга өйрәтүче дә шул әбием иде ич инде. Күченәсе көнне әби, аулакта ялгызымны гына туры китереп, кысып кочаклады. Әллә ничек кенә кызганыч итеп: «Ташлама, килеп йөр, бәбкәм», — диде. Әбинең ни өчен иске йортта калуын әтидән дә, әнидән дә, әбинең үзеннән дә сорап карадым — әйтмәделәр. «Олылар эшенә кысылма», — диде әти. «Атаң үзе beләдер», — диде әни. Әби исә: «Язмыштыр, бәбкәм... Кем белә, бабай сугыштан кайткан булса...» — дип, сүзен әйтеп бетермичә, читкә карады.

Әллә нишләдем мин, яңа өйгә күчкәч. Ялкауландым дип әйтимме. Китап укыйсым килми, кулым эшкә бармый башлады.

Әбине ташламадым анысы. Яңа өйдә бер кич кунсам, әби янында икене кундым. Көндезләрен су китерештем, түтәлләренә су сибештем. Мәгәр әти белән әнигә ачу килә иде. Ничек инде?.. Әби белән әти арасында нинди дошманлык булуы мөмкин? Сугыш чорында, әти әле бәләкәй малай чагында, сөлге-җәймәләрен сатып тамагын туйдырган ич аның әби. Әти үзе шулай ди. Башка сыймаслык хәл бит бу...

Җиңү бәйрәме алдыннан якыннары, туганнары Бөек Ватан сугышында һәлак булган кешеләрнең капкаларына затлы металлдан ясалган йолдызлар куярга сөйләш-

кән идек бит әле, Әминә апа. Хәтерендәдер, батырлар исемлегендә безнең бабай да бар иде...

Шул көнне мин сбордан кайткач, әти:

— Кайсы капкага куясыз соң йолдызны, янасынамы, искесенәме? — дип сорады.

— Әби капкасына, билгеле, — дидем мин, уйлап-нитеп тормыйча.

— Ә үзебезнең капкага? Бабаң минем әти була түгелме соң?..

— Белмим, — дип мыгырдандым мин, тәрәзәгә борылып, — андый сүз булмады сборда.

Әтинең йөзе караңгыланды. Ул, кулларын чалбар кесәләренә тыгып, идән буенча йөрде-йөрде дә, аны-моны дәшмичә, җилләнеп урамга чыгып китте.

Ә кире әйләнеп кайтканда, бөтенләй алмаштырып куйганнар иде әтине. Кәефе күтәрелгән. Авызын җыя да алмый. Бусаганы атлап керүгә:

— Булды, җайладык эшне, — дип, иңендә әләгер-әләкмәс селкенеп торган костюмын диванга җилпеп төшерде.

— Нәрсәне җайладың? — дидем мин хәвефләнеп.

— Йолдызны безнең капкага куячаклар.

— Ә әбигә?

— Әбигә, әбигә, — диде әти, мине үртәп, — беренчедән, син үскән егет инде, дөньяны аңларга вакыт... Икенчедән, белмәсәң белеп кал, синең үз әбиең түгел бит ул... Синең үз әбиең, ягъни минем әнием сугышка кадәр үк дөнья куйды. Шуннан соң инде әти яңа әни алып кайтты... Кайсыдыр ки, буладыр ул синең менә хәзерге әбиең...

Нигә башымны катыра бу әти? Нигә сөйли миңа боларны? Минем бер генә әбием бар. Башка әбине белмим мин һәм белергә дә теләмим.

Елап җибәрмәс өчен иренемне тешләп, урамга чыгып йөгердем.

Хәтерлисеңме, Әминә апа, синең янга елап кердем мин ул көнне. Ә син... ә син: «Юкка-барга борчылма, тапкансың кайгырыр нәрсә, бер кеше истәлегенә ике йолдыз куймыйлар инде... Аннары йолдызларыбыз да санаулы гына ич безнең, Фәрит», — дидең. Эх, Әминә апа, Әминә апа!

Кайтыр юлда Харис абый очрады. Мәсьәләне төшендереп биргәч, бик аз гына уйланып торды да:

— Ничек тә җайларга кирәк бит эшне, әле төнгә кадәр байтак вакыт бар, — дип, минем күзләремә карады. Аннары капылт кына сорап куйды: — Теге кызыл мәрмәрне нишләттең син, Фәрит?

— Нишләтим, ята шунда...

— Нәрсә ясарга иде исәп?

— Чәчәк лә...

— Чә-чәк?! — Берничә секунд күзләрен кысып көлемсерәп торганнан соң, Харис абый: — Ә йолдыз ясасаң, — дип, тагын минем күзләремә карады. — Йолдызы булса, калган ягын үзем рәтләр идем...

Исем-акылым китте — ничек мин уйлаганны гына уйлап йөри бу Харис абый...

Ә иртә белән капкасында йолдыз күргәч, әбинең шатлыгы эченә сыймады. «Карасана, нәкъ күктәге йолдыз кебек балкый... Бар икән рәхмәтле бәндәләр, онытмыйлар бит... Бабаң фронтка киткән кичне Зөһрә йолдыз нәкъ шулай яктырып янган иде», — дип, яулык читен күзләренә китерде.

Син үпкәләмә инде, Әминә апа. Мин сиңа барыбер мәрмәр чәчәк ясап бүләк итәчәкмен әле. Әйтте диярсең менә.

## ЭЛЬМИРА

Биеп кенә тора Эльмираның бармаклары клавишалар өстендә. Язу машинкасыннан ниндидер көй чыгарырга тырыша сыман алар. Ләкин көй чыкмый. Саргылт типография кәгазенә тигез кара хәрефләр, җансыз юллар гына тезелә.

Пенсионер Хөсәен абзый — ул редакциягә, икенче машинистка Алсу ялга киткәч, вакытлыча эшләп торырга килде — Эльмира бармакларына бераз сокланып та, бераз көнләшеп тә карый. Ул үзе дә бармакларын шулай биетергә тырыша. Әмма буыннары каткан бармаклар алай тиз генә биеп китәргә теләмиләр. Аннан соң редакция эшеннән киткәнгә дә күптән бит инде, һай, күптән. Тимерен дә, агачын да, көрәген дә, мылтыгын да кысты инде бу бармаклар вакытында. Шуңа күрә алар төннәрен сызлыйлар, кызышалар.

Кайчагында Эльмираның күз карашы картның ак бөртекләр белән чуарланган чигәләренә туктала, кәгазьгә бер хәреф төшергән саен диярлек сикереп-сикереп китүче маңгаендагы киң җыерчыгы, тамырлары күгәреп торган ябык куллары буйлап шуып үтә. Хөсәен абзый аның карашын тоя, ләкин күтәрелеп карамый: карашын алай төрле урынга күчереп йөрткәч, уң күзенең яшьләнә торган гадәте бар. Елаган шикелле томанланып, дымланып торган көне хәерсезнең.

Бары тик Эльмираның бармаклары, җәйге коеп яуган яңгыр тамчылары сыман, клавишаларга тупырдап төшә башлагач кына, Хөсәен абзый анда-санда калган чал керфекләрен тибрәндерә. «Чәчләрен нигә болай кыска итеп кистерде икән соң бу юләркәй? Мондый тигез маңгайга, каратутлы түгәрәк йөзгә озын толым килешер иде. Хәер, болай да өзелеп тора, ахры, үзе өчен теге шофер егет. Югыйсә һәр көнне тәрәзә каршыннан ниндидер шартлы авазлар белән сигнал биреп узмас иде».

Хөсәен абзый шулай уйлый, ә Эльмира үз уйлары белән мәшгуль. Ничек диде әле кичә Рәсим, син ул картны мактыйсың да мактыйсың, кияүгә чыгып куйма тагын үзенә, дидеме? Хәер, Эльмира да сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел: «Чыксам ни, синеңише егетләрнең бишесен бергә бөтереп сала ул Хөсәен абзый», — дип, Рәсимнең шаяртуына шаярту белән җавап кайтарды.

Эльмира, авыз чите белән генә елмаеп, тагын Хөсәен абзыйга карады: карт кулъяулыгы белән күзләрен сөртеп маташа иде.

Шул чагында ишектән, кулына бер папка кәгазь тотып, өлкән сотрудник Хәсәншин килеп керде.

— Менә, Хөсәен абзый, — диде ул, кара коелган йөзенә ягымлылык билгеләре чыгарырга тырышып, — телә — асыл, телә — кисел, әмма иртәгә сәгать унга өлгерт. Редактор бәйрәм санын җыеп куярга кушты.

Эльмира: «Сез нишлисез соң, Гайнан абый, ярты көндә шулкадәр әйбер басып бетерергә әллә теге?» — дип әйтергә авыз ачкан иде, ләкин Хәсәншин, дәшмә дигән мәгънәне аңлатып, аңа күз кысты. Эльмира төшенде, карт кешегә: «Булмый икән синнән», — дип әйтергә базмыйлар, дөресрәге, «булмый» сүзен аның үзеннән көтәләр.

Эльмира юкка гына Хөсәен абзый бернәрсә дә сизми дип уйлый. Сизә Хөсәен абзый, теге яктагы канәгатьсез тавышлардан да, Хәсәншинның кара коелган йөзеннән дә сизә ул моны. Хәер, аңа ике айны кайда эшләсә дә барыбер түгелмени? Әнә алдагы елларда китапханәдә эшләде ләбаса. Тик быел аның бик тә редакциядә эшлисе килгән иде шул...

Машинкалар җыры, типографиядә әле генә басылып чыккан газета исе, бигрәк тә менә бу акыллы коңгырт күзле Эльмира исемле кыз аны бик еракларга, яшьлек елларына алып китә... Әйе, әйе, теге ябык кыз да Эльмира исемле иде бит... Һич уйламаганда, һич көтмәгәндә сыгылмалы нечкә билләреннән узып торган юан кара чәч үремнәрен җилфердәтеп килеп керде дә ишек янагына сөялде, һәм машинка клавишаларында күз иярмәс тиз-

лек белән тупырдап торган Хөсәен бармакларына карап катып калды. Зур булып ачылган күзләреннән иксез-чиксез яктылык, соклану, гаҗәпләнү агыла иде аның. Урамда эссе җәй булуга карамастан, аягында йон оек, чабата. Күренеп тора: район үзәгенә кайдандыр ерак авылдан килгән.

Хөсәен — ул чакта сызылып киткән кара мыеклы, ак чырайлы чибәр егет — бер күтәрелеп карады кызга, ике күтәрелеп карады. Әмма кызның кузгалыр исәбе дә, Хөсәен бармакларыннан күзләрен алыр исәбе дә күренми иде.

Ахырда түзмәде Хөсәен, эшеннән туктап, кызга эндәште:

— Ни йомыш, сеңел?

Кыз сискәнеп китте, кызарды һәм, балаларча беркатлылык белән тотлыга-тотлыга:

— Гәҗит баса торган кеше син буласыңмы? — дип сорады.

— Мин дип, мин машинист, ни бит, без күбәү, — дип мыгырданды Хөсәен, үзенең шушы чабаталы авыл кызы алдында шулчаклы югалып калуына ачуы чыгып.

— Мин хәбәр китергән идем дә... — дип сузды кыз һәм озын керфекләре белән Хөсәеннең йөрәген әллә нишләтеп авырттырып алды. Тик ләззәтле, рәхәт авырту иде бу.

Хөсәен кызны редактор янына алып керде. Хәбәр дигәне, чыннан да, бик кирәкле, бик мөһим — кулакларның икмәк яшерүләре турында булып чыккач, редакторның йөзе дәррәү яктырып китте.

Сораша-сораша кызның Әсмабикә исемле булуы, этисе дә, әнисе дә ачлык елны вафат булганлыктан, хәзер бер кулакта яшәве, укырга-язарга герман сугышында хәбәрсез югалган абыйсыннан өйрәнүе мәгълүм булды.

— Безгә нәкъ менә синеңише грамотный кызлар җитешми бит, сеңел, ә, — диде редактор, бер Хөсәенгә, бер Әсмабикәгә карап. — Әллә, мин әйтәм, бездә генә каласыңмы? Укый-яза белгән кешегә эш әллә ни авыр түгел, теләсәң, үзебездә, теләсәң, тулай торакта торырсың.

Кыз, Хөсәеннең гаҗәпләнүенә каршы, берсүзсез риза булды.

— Аннары, — дип дәвам итте редактор, маңгаендагы бер тотам ак чәчен бармакларына чорный-чорный, — без сиңа Әсмабикә дип түгел, ә бәлки... ә бәлки Эльмира дип дәшәрбез, килештекме? Хәбәрләреңә дә шулай кул куярсың.

Кыз бусына да күнде.

Хәер, Эльмира редакциянең эшенә дә, кешеләренә дә тиз ияләште. Авылларга чыгып хәбәрләр язып кайтырга

да, хәбәрләрен яшен тизлегендә машинкада суктырып алырга да өлгерә иде ул.

Чабатасын нәфис аякларын кысып торган җыйнак туфлигә алыштырып җибәргәч, Эльмира танымаслык булып чибәрләнде. Хөсәен бервакытта да аның якты күзләренә туры карый алмый, кызны күрде исә, уңайсызлана, дулкынлана. Әмма аннан башка узган минутлар бик озын, буш иде егет өчен. Кыз аз гына күздән югалып торгач ук, Хөсәеннең эче поша башлый. Ә Эльмира Хөсәен күкрәгендә айкалган давылны сизми дә, күрми дә сыман. Ләкин үзе, авыллардан кайткан саен, Хөсәен янына кереп, бар яңалыкларын, кайгы-шатлыкларын сөйләп чыга. Сабыйларча матур итеп, энҗе тешләрен җемелдәтә-җемелдәтә көләргә дә онытмый:

— Әй Хөсәен абый, билләһидер менә, Суксы авылында бер түтәй әйтә, кулакларның котын алдың бит син, кызым, гәҗит басучы камсамул килгән, дип дер калтырап торалар, ди...

Тик беркөнне — сәнәкчеләр фетнәсе кузгалган яз иде бу — Эльмира авылларга чыгып киткән җиреннән әйләнеп кайтмады. Бер көн көттеләр кызны. Ахырда, авыл советларына, милициягә хәбәр итеп, эзләргә чыктылар... Өченче көнне Эльмираның гәүдәсе табылды. Көек урманында, олы юлдан шактый читкә алып кереп, газаплап үтергәннәр иде аны.

Шушы канлы вакыйгадан соң әллә ни генә булды Хөсәенгә: эшлим дисә, кулы эшкә бармады, кеше белән сөйләшим дисә, теле әйләнмәде.

Сәнәкчеләр фетнәсе вакытында кулга алынган бер кулакның башын кендек белән бәреп ярган өчен, аны эшеннән алдылар. Хөсәен читкә китте. Һәм шул китүдән бик озак йөреп, бик күп еллардан соң гына яңадан бу якларга кайтып урнашты.

Әмма Әсмабикә-Эльмира онытылмады.

Инде менә бик күп еллар үткәч, шул ук редакциядә, шул ук бүлмәдәге кыз янында үзенең мәңге онытылмаслык фаҗигале мәхәббәте турында уйлап утыру ничектер рәхәт иде аңа.

Әнә, бу бәхетле чор Эльмирасының Рәсиме машинасын тагын тәрәзә каршына китереп туктатты. Кыз, кофта якасын рәтли-рәтли, башын ачык тәрәзәгә тыкты. Алар башта йомшак кына сөйләштеләр, аннары, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, бәхәсләшә үк башладылар.

— Бүген бармыйбыз, — диде ахырда Эльмира, катгый итеп.

Егетнең дә кәефе кырылды бугай: кабина ишеген бар

хәлгә шапылдатып япты да тулы газ бирде — машина котырган үгездәй үкереп кузгалып китте.

— Эш сәгате бетте, Хөсәен абзый, — диде Эльмира, ярсуын картка сиздермәскә тырышып, — кузгала башласаң да ярый.

Хөсәен абзый, шуны гына көткәндәй, урыныннан торды һәм өстәл өстендә чәчелеп яткан кәгазьләрен җыештыра башлады: «Редакторга иртәгә килмим, дип әйтеп чыгарга кирәк, җитезрәк, яшьрәк кеше эзләсен». Әмма, ишектән чыгып барганда, аның күзләренә тагын клавишалар өстендә тупырдап, биеп йөргән җитез бармаклар чалынып үтте, борынына инде онытыла язган якын ис килеп бәрелде. Юк, иртәгә эшлим әле дип уйлады Хөсәен абзый, ныклы бер фикер белән канатланып.

Икенче көнне ул редакциягә килеп эш урынына утырганда, кичә Хәсәншин керткән кулъязмалар машинкада басылган һәм пөхтәләп өстәл читенә өеп куелган иде.

## ИСЕМЕҢ ЛӘЙСӘН БУЛЫР

*Кызым Раушаниягә*

Аның янында тезелешеп торган башка курчакларның да исемнәре юк иде. Шулай да аларны сатып алып бетерделәр.

Иртәнге якта кибеткә, әнисенә ияреп, коңгырт чәчләренә сары тасма кушып үргән кызчык керде. Прилавка янына килүгә, энҗе тешләрен җемелдәтеп:

— Әни, күр әле, нинди матур курчак! — диде.

Сатучы апа курчакны кызның әнисенә сузды.

— Фи, — диде кызчыкның әнисе, кызыл тырнаклары белән курчакның сандалларына чирткәләп караганнан соң. — Күбәләк канат җилпегәнгә дә сүтелергә тора. Сандаллары әйбәт булса, күптән алып китәрләр иде аны.

Курчакка каерылып-каерылып караган кызын әнисе ишеккә әйдәде.

Курчак тагын чыга алмады урамга. Кояшлы күк гөмбәзен тагын күрә алмады. Сатылмый яткан китаплар арасында янә берьялгызы басып калды.

Төш җитәрәк кулына портфель тоткан күзлекле абзый, курчакка ымлап, сатучы апага эндәште:

— Нишләп курчакларыгыз китаплар янында?

Сатучы апаның йөзенә кызыллык йөгерде.

— Курчаклар түгел, курчак кына, — диде ул уңай-

сызланып, — сандалларын матур текмәгәннәр, шуңа күрә алучы юк, уенчыклар янына куясым килмәгән иде...

Калын портфельле абзый артыннан ишек ябылгач, сатучы апа курчакны прилавка астына ташлады.

Нәрсә дә нәрсә, әмма монысын көтмәгән иде курчак. Уйныйсы бар ич әле аның. Берәр нәни кызның көлгәнен күрәсе бар. Курчак үзе көлә белми, кибеткә кергәч тә көлеп җибәргән кызларга кызыгып карый, ә елак кызларны бик кызгана иде. Инде көләч кызларны да, елакларын да күрмәс микәнни курчак? Исеме дә юк бит әле аның. Ә бит, уйлап карасаң, барысы да шул ямьсез сандаллар аркасында.

Җыештыручы апаның елтыр күзле йөнтәс маэмае бар иде. Менә шул шаян маэмай кичкырын иснәнә-иснәнә прилавка астына керде дә курчакны, күлмәк итәгеннән эләктереп, идән уртасына күтәреп чыкты.

Сатучы апа белән җыештыручы апа бер-берсенә карап көлештеләр. Аннары акрын-акрын йөнтәс маэмайга таба килә башладылар. Бик тә шаян иде шул йөнтәс маэмай. Тегеләрнең ниятләрен сизгәч үк, төймәдәй түгәрәк күзләрен хәйләле елтыратып, башын чайкады һәм курчакны күлмәк итәгеннән тешләп капкан көе ачык ишектән урамга атылды.

Курчак бөртек тә курыкмады йөнтәс маэмайдан. Киресенчә, сөенде генә. Сөенми ни, күз аллары бердән яктырып китте аның. Зәңгәр бишектә тирбәлә-тирбәлә, офыкка төшеп барган алтынсу кояшны күрде ул, яшел ябалдашлары белән кояш бишеген күтәреп торган мәһабәт агачларны күрде.

Йөнтәс маэмай, үз күләгәсен үзе узарга тырышкандай, тимер рәшәткәле бакча буенча алдына-артына карамыйча чапты-чапты да курчакны сирень куагы төбендә калдырып китте.

Әле көзгә ерак, көннәр генә түгел, төннәр дә җылы иде. Исемсез курчак көндез сирень яфракларының кояшны алкышлавын, ә төнлә карасу-зәңгәр биеклектә исәпсез-хисапсыз йолдызларның серле җиһанга моңсу нур сибүләрен күзәтеп ятты.

Җилле иртәләрнең берсендә курчак сирень ботаклары арасыннан биек ак стена, шунда якты тәрәзә күреп алды. Бераздан тәрәзә ачылды, бакчага тузган чәчле нәни кыз сузылып карады. Күзләре төнге йолдызлар кебек моңсу иде кызчыкның. Елак кыз икән дип уйлады курчак.

Ак стена буенда шәмәхә яулыклы мөлаем апа пәйда булды.

— Нигә урамга чыкмыйсың, үскәнем, көн җылы бит, — диде ул тәрәзә төбенә яңагын куйган моңсу кызчыкка.

— Аякларым авырта минем, — диде кызчык, күз яшьләренә төелеп.

— Ә син елама, төзәлә ул, врач әйткән киңәшләрне тотсаң, һичшиксез, терелерсең, елама, — дип юатып узды шәмәхә яулыклы апа моңсу кызны.

Ачык тәрәзә каршына чал сакаллы, хәтфә түбәтәйле бабай килеп туктады.

— Нихәл, Ландыш кызым!

Курчакның керфекләре дерелдәп куйды. Димәк, бәләкәй кызчыкның исеме бар икән, исеме Ландыш икән.

— Бабай, минем урамга чыгасым килә, — диде Ландыш еламсырап.

— Сабыр иткән — морадына җиткән, бәбкәм. Тиздән терелерсең дә менә... урамга да чыгарсың. Бакчаларда, су буйларында йөгереп йөрерсең. Ә мин аңарчы сиңа тәти сандаллар тегеп өлгертермен.

Сандал турында сүз чыккач, курчакның кәефе кырылды. Үзенең ямьсез сандаллы курчак булуын оныта язган иде инде ул. Нигә шушы ягымлы тавышлы бабайга тектермәделәр икән соң курчакның да сандалларын? Моңарчы өе булыр иде инде аның, исеме булыр иде. Ландышка охшаган йомшак күңелле кыз җылы кочагында тирбәтер иде аны.

Шул чагында чал сакаллы бабай, сирень куакларын аралап, курчак өстенә иелде, зәңгәре уңган күзләрен челтчелт йомгалап, курчакны кулына алды.

— Ландыш кызым, карале берегә...

— Бабай, курчак!— дип шатланып кычкырды Ландыш. — Бабай, китер тизрәк, җирдә ята-ята туңып беткәндер ул... Әл-лә-ли, бабай, нинди сөйкемле курчак!

— Ашыкма, бәбкәм, — диде чал сакаллы карт, дерелдекле тавыш белән. — Мин аны менә синең каршыңа, тәрәзә төбенә утыртып куям. Югалткан булсалар, шуннан күреп алырлар. Эзләп килүче булмаса, үзең уйнарсың.

Ландыш курчакка сузылды. Ләкин бабай курчакны аның кулы җитәрлек урынга куймаган иде.

— Исемең ничек синең? — диде Ландыш һәм, башын нәни куллары өстенә салып, курчакка текәлде, елмая биреп дәвам итте: — Исемең дә юкмыни әле? Синең исемең Ләйсән булыр, яме. Син минем янда кал, эзләп килсәләр дә, минем янда кал, яме, Ләйсән. Бабай сиңа тәти сандаллар тегеп бирер. Минем аякларым төзәлгәч, без икәү бергә бакчада уйнарбыз, су буйларында йөгереп йөрербез. Кал, яме, Ләйсән...

Курчак Ландышның куенына атылырга теләде. Тик шунда ук мондый теләгеннән оялып китте. Әгәр дә Ландыш яңа сандал өчен шулай шатлана икән бу дип уйласа, нишләрсең? Һәй, сандалларның нигә кирәге бар соң әле аңа? Шундый килешле исемең, шундый әйбәт дустың булганда, ялантәпи дә яшәргә мөмкин ич дөньяда.

## ӘТИ ТӘТИ

Күптән кызыгып йөри идем инде мин шушы ике яшьлек сөйкемле кызчыгыбызны үземчә тәрбияләргә. Олы кызны күбрәк әнисе тәрбияләде. Тик әнисенең тәрбия нәтиҗәләре ошап җитми миңа. Күңелгә ятмый торган сүзләр ычкындыргалый кайчагында олы кыз. Кемгә дисез әле? Миңа, әтисенә. «Нигә кычкырасың?» дип допрос ала. «Кычкырмыйча гына аңлатып булмыймы әллә?» дип акыл өйрәтә. Әйтеп тә торасы түгел — әнисе мәктәбе.

Кичәгенәк эштән кайтып керсәм, әнисе, әлеге дә баягы, шул ике яшьлек кызыбыз Резидәне орышып маташа.

— Тилесеңдер син, бу кадәрле иркә, назлы сүзләр әйткәч, изрәп кенә йоклап китәр идең, тибенеп ятмас идең, — ди.

— Соң, җүләр! «Тилесеңдер» назлы сүз буламыни? — дип элеп алдым мин әнисен. — Балага шундый сүзләр сөйләргә ярыймыни? Шундый сүзләр белән тәрбияләп буламыни баланы?

— Алай бик оста булгач, мә, алайса, үзең тәрбиялә, үзең йоклат! — дип, тиктомалдан гына кызып китте хатын.

— Тукмак чаклы баланы тәрбияләмәскә теге! Тәрбиялим! Рәхәтләнеп тәрбиялим! — дип гайрәт чәчтем мин, җиңнәремне сызгана-сызгана. — Сары май кебек эри ул назлы гөл минем куенымда.

Мин, шулай гөрли-гөрли, Резидәне кулыма алдым. Әнисе, ирен читләре белән мыскыллы елмаеп, икенче бүлмәгә юнәлде.

— Җүләр әниең, ие бит, — дип тирбәтә-тирбәтә, өстенә җылы юрган яптым мин Резидәнең.

— Әни җүлә, — дип кабатлады Резидә, ялагай тавыш белән.

— Әти тәти, — дидем мин күңелем булып, һаваланып.

— Әти тәти, — дип кабатлады Резидә.

— Тәти әтисе ә-ә-ә иттерә хәзер тәти Резидәне.

— Ризә тәти, Ризә тәти...

— Ризә ә-ә итә. Йоклый хәзер Резидә. Тәти әтисе ә-ә-ә иттерә тәти Резидәне...

Резидә шуклык һәм шаянлык яшерелгән керфекләрен җем-җем иттереп тирбәндереп алды да күзләрен шарландырып миңа карады.

— Йоклый инде Резидә. Ә-ә-ә итә. Бөтен кешеләр йоклый хәзер, бәбиләр дә йоклый, әбиләр дә ә-ә итә, абыйлар да ә-ә итә, әтиләр дә, әниләр дә ә-ә итә, маэмайлар да, мияулар да, — дип, матур сүзләремне борчак урынына сиптем мин.

— Әти дә ә-ә-ә, — диде Резидә, уяу тавыш белән аермачык итеп.

— Резидә дә ә-ә-ә итә, — дидем мин, сабырсызлана төшеп.

— Ау-ау да ә-ә итә, — диде Резидә һәм җәһәт кенә урыныннан сикереп торып утырды.

Мин аны көчләп диярлек мендәренә яткырдым.

Монысы бер дә ошамады Резидәгә. Иреннәрен кыстыбыйландырып шыңшырга тотынды. Шул гына кирәк иде, шул гына җитмәгән иде, туктатырга иде эш зурга киткәнче, ничек тә туктатырга иде.

— Резидә ә-ә итми, Резидә мәми ашый, — дип ычкындырып ташладым мин каушавым белән.

Шым булды Резидә. Тик шул минутта ук аваз салды:

— Мәми, мәми! Әпис мәми!..

Әфлисун сорый бит бу вәсвәсә, әфлисун сорый. Әфлисун бирмәсәң, йоклатып булмаячак хәзер моны. Менә бәла, менә авыртмас башка тимер тарак.

Әнисе кайдандыр бәйрәмгә дип юнәткән иде дә соң әфлисун. Аны эзләп табып кергәнче, йокысы тәмам ачылып бетәчәк бит әле бу коткының.

Караватында олы кызым астыртын гына пырхылдап куйды.

— Әле син дә йокламыйча ятасыңмыни? — дип, җен ачуларым кузгалып, урынымнан сикереп тордым мин.

— Нигә кычкырасың, әти, шулкадәр? — диде олы кызым, сару кайнаткыч сабырлык белән.

— Йокла! Ичмасам, син нервыма тиеп ятма. Шушы төнгә кадәр йокламыйча ятырга җүләр түгелсеңдер.

Минем әфлисун алып кергәнемне Резидә аяк өстенә басып, кечкенә тәпиләрен мендәргә батырып, йөзенә түземсезлек билгеләре чыгарып көтеп тора иде.

Мин аңа әфлисунны әрчеп бирергә теләгән идем дә, кая ул — секунд эчендә, «мәми, мәми» дип, йөз генә мәртәбә кычкырмагандыр. Җиде җил чатында үскән усак яфрагы да алай еш лепердәмәс.

Урынына яткыргач, ак чәчәк таҗлары сыман нәфис бармакларын җәеп кысып тотты да бу, кояш кебек түгә-

рәк әфлисунны иреннәренә якын китерде, һәм аның кабыгыннан, каз бәбкәсе чирәм өзгәндәй, тавышсыз гына бер чеметем элпә тешләп алды, табышын миңа сузды.

— Әти, таша.

— Ташлыйм, кызым, ташлыйм, — дидем мин, аның бармак очында күренер-күренмәс ябышып торган элпәне эләктерергә тырышып. — Ә син йокла инде, йокла, ә-ә ит.

Резидәнең көньяк җимешеннән алты-җиде чеметем элпә тешләп биргәнен аны-моны дәшми генә көтеп яттым, аннары, ничек кирәк алай алдаштыргалап, эт булып өреп, мәче булып мияулап дигәндәй, әфлисунны үз кулыма алу бәхетенә ирештем һәм, минуты-секунды белән кабыгын әрчеп, кычкырып елау өчен авызларын бөргәләп репетиция ясый башлаган нәни артистканың кулына тоттырдым.

Ах Алла! Болай да бик озакка сузылачак икән әле бу. Әфлисунның унике бүлкәсе бар. Бүлкә саен йөзләп күзәнәк. Ә кызым әле фәкать беренче бүлекнең беренче күзәнәген генә суырып маташа.

Ничек итсәм иттем, алдап-йолдап китереп, кызым күрмәгәндә, әфлисунның унбер бүлкәсен, чәйнәми-нитми генә, үзем кабып йоттым.

Резидә дә, ниһаять, беренче бүлкәне чүбекләндереп, калдык-постыкларын миңа сузды.

— Әти, таша!

— Ташлыйм, кызым, ташлыйм. Менә үскән кыз ул, менә мәми ашады ул, инде хәзер йоклый ул, тыныч кына ә-ә итә.

Резидә беркавым миңа тасраеп, шикләнеп карап ятты. Аннан соң, урыныннан күтәрелә төшеп, кечкенә кулларын мендәр өстендә йөртергә кереште.

— Тая?

— Нәрсә, кызым?

— Мәми тая? Әпис тая?

— Бетте, кызым. Үзең ашадың ич. Үзең ашап бетердең.

— Мәми! Әпис мәми!

Кызым аяк-кулларын чәбәләндереп еларга кереште.

— Ә-әпис, әпис мәми!..

— Ах, син алаймы әле?! — дип, сабырлыгымны җуйдым мин, ниһаять. — Әле син тәти әтиеңне тыңламыйсыңмы? Алайса, менә сиңа, мә сиңа!..

Йомшак җиренә берне чәпелдәтеп алгач ук, Ходайның рәхмәте, керфекләре йомылды кызның, сулышы тигезләнде. «Шулай менә, ата кулы шифалы була, — дип уйладым мин, эчемнән генә сөенеп. — Баланы гел-гел иркәләп-сөеп кенә торырга ярамый шул, бераз катырак торырга кирәк».

Аяк очларыма гына басып бүлмәдән чыктым. Әмма ишекне ябып та җиткермәдем, эчке якта башта олы кызымның тыелып кына пырхылдаганы, аннары Резидәнең ярсу катыш нәфрәт белән тәтелдәгәне ишетелде:

— Әти җүлә... Җүлә әти...

Әнисе ишетмәсә ярар иде, дигән идем, ишеткән икән. Килеп җиткән тизрәк. Үзе авызын ерып көлә, үзе кыз белән сөйләшкән була. Нишләп алай әйтәсең, кызым, әтиеңә алай әйтмә, янәсе. Әти тәти була ул...

# ФИРҮЗӘ

*Кыш хикәяте*

Кар дөньясында Фирүзә исемле кар бөртеге оча иде. Ни өчен Фирүзәме? Асылташтай җем-җем итеп җемелдәгәнгәдер, бәлки. Ә бәлки... Хәер, әти-әниләребезнең безгә ни өчен нинди исем кушуларын ничек белеп бетермәк кирәк тә һәм бу хакта бәхәсләшүнең нигә кирәге бар? Фирүзә икән Фирүзә. Хикмәт аның исемендә түгел.

Бар җиһанны тутырып очкан кар бөртекләре чиксез галәм океанында сәяхәт кылып йөргән йолдызлар санынча. Кем белә, бәлки, аннан да күбрәктер. Шул галәмәттә, шул ыгы-зыгыда, шул буталышта ничек танырсыз икән, кадерле дусларым, Фирүзәне?

Ә сез, тәңкә карлар талгын гына тирбәлеп очканда, һавага карагыз. Һай, шаян абый, кар бөртекләре барысы да бертөсле бит, диярсез инде башта. Ә сез игътибар беләнрәк карагыз. Күрдегезме? Бер кар бөртеге сезнең йөзгә орынам-орынам дип тирбәлде-тирбәлде дә читкә очып китте, җиргә кунам-кунам дип түбән төште-төште дә, җил канатларына утырып, янә югарыга омтылды. Асыл болытлар арасыннан күз сирпегән кояш яктысында йөзек кашыдай ялтырап алды да үзе шикелле үк шаян, җитез кар бөртекләре арасына кереп югалды.

Әллә күрми дә калдыгызмы? Фирүзә шул иде бит инде. Шул үзе иде Фирүзә. Әйе, көмеш керфекле, ефәк чәчле, ачык йөзле кар бөртеге Фирүзә шул иде.

Кая бара, кая оча соң ул Фирүзә, дисезме? Үзе дә белми кая очканын, кай тарафларда йөзгәнен. Күк океаны чиксез, күк юллары озын, җил канатлары җитез.

Әллә сез үзенең кая очканын белергә теләми дип уйлыйсызмы Фирүзәне? Һи, теләмәгән кайда ул! Тик аның тирә-ягындагы өлкән кар бөртекләре бик җитдиләр шул, һич кенә дә ипләп сөйләшергә теләмиләр Фирүзә белән.

Очты-очты да, йөзде-йөзде дә, озак кына тирә-ягына карангалап, Фирүзә янәшәдән генә очып барган өлкән кар бөртегенә эндәште:

— Абзыкаем, әйтче, зинһар, шулай ашкынып, дәртләнеп кая очабыз без?

— Урманнарга, тауларга, басуларга, — диде өлкән кар бөртеге, тизлеген киметмичә.

— Нигә очабыз?

— Урманнарны агартырга, тауларны яңартырга, басуларны җылытырга.

Фирүзә түбән карады.

— Ә нишләп төшмибез?

— Җирдә һәркайсыбызның үз урыны бар. Шул урынга барып җиткәч тә төшәрбез. Барыбыз бергә түгел, берәм-берәм төшәрбез. Берәм-берәм төшмәсәк, җиргә кар тигез ятмый. Кар тигез ятмагач, җир җылынмый. Җир җылынмагач, игеннәр уңмый. Игеннәр уңмагач, икмәк булмый. Икмәк булмагач, балалар куанмый. Балалар куанмагач, кар дөньясының кызыгы бетә. Безнең иң олы максатыбыз — балаларны куандыру.

Фирүзә берара, шат йөзле балалар һәм кызыгы беткән дөнья турында уйлый-уйлый, сүзсез генә очты. Аннары, йомшак иреннәрен турсайтып, болай диде:

— Ә минем бүген үк, хәзер үк шатландырасым килә балаларны.

Тәҗрибәле кар бөртекләре бер-берсенә карап елмаештылар.

— Алайса, — диде арадан бер өлкәнрәге, — син, сеңелкәем, ә-нә теге тау битенә төшеп кунарсың. Ә-нә, күрәсеңме, балалар чаңгы шуалар. Син төшеп кунгач, тау биегәебрәк китәр. Тау биегәйгәч, балалар шатланырлар.

— Анда бик күп бит кар бөртекләре, мине ничек танырлар соң балалар?

Кар бөртекләре Фирүзәнең беркатлы соравын җавапсыз калдырдылар. Чөнки балаларны бергәләп шатландырырга күнеккәннәр ич алар. Ә Фирүзә — кар дөньясында гомер булмаган хәл — башкалардан аерылып торырга уйлый.

— Моның өчен, моның өчен, — дип сүз катты, ниһаять, авыраеп җиргә төшәргә әзерләнгән кар бөртекләренең берсе, — моның өчен зур булып үсәргә кирәк, иңнәрең юллардан җилдереп узган чана табаннарын күтәреп торырлык нык булырга тиеш. Ә син әнә нинди нәни, әнә нинди бәләкәй.

— Бәләкәй кар бөртекләре шатландыра алмыймыни балаларны? — диде күңелсезләнеп калган Фирүзә.

Ул арада теге кар бөртеге юлга төшеп яткан иде инде.

— Бер генә баланы булса да шатландырасым килә минем, — дип, як-ягына карады Фирүзә.

Фирүзә белән сөйләшеп торырга вакытлары юк иде кар бөртекләренең. Алар берәм-берәм җиргә төшеп ята тордылар. Чана юлларын калынайттылар, күл, болын, басу өсләренә ак юрган булып сырыштылар.

— Минем сезнең кебек шатландырасым килми балаларны, минем үземчә шатландырасым килә, — дип, әле бер кар бөртеге, әле икенчесе янына очып килде Фирүзә.

— Безнең дә үзебезчә шатландырасыбыз килә дә бит аларны, тик кар дөньясының кагыйдәләре һәммәбез өчен дә бертөрле шул, — дип көрсенделәр кар бөртекләре.

— Бер генә баланы булса да үзебезчә шатландырыр идем, үземчә, — дип такмаклады Фирүзә һаман.

— Мондый холкың белән тиз эрерсең син, җирсемә алай, башкалар эшләгәнне генә эшләргә тырыш, — дип үгетләп карадылар Фирүзәне өлкән кар бөртекләре.

— Юк, юк, юк, — дип, һаман үз сүзен сөйләде Фирүзә, — эресәм эрермен, әмма теләгемә ирешермен. Мин бик телим бит, бик теләгәч, теләгем үтәлергә тиеш минем.

Фирүзә башка кар бөртекләре белән тал ботагына кунып тирбәлде дә янә югары күтәрелде. Телеграф чыбыгында да, хәтта песнәк каурыенда да урын табалмады ул үзенә. Башка кар бөртекләре кунып калган урыннар һич кенә канәгатьләндермәде аны.

Шулай оча торгач, авыл урамына килеп керде Фирүзә. Анда, зәңгәргә буялган капка төбендә, дөнья кубарып, нәни кызчык елап тора иде. Мамык шәлле апа юатып узды кызчыкны. Ләкин кызчык апага күтәрелеп тә карамады, кемгәдер үпкәләп, кемгәдер рәнҗеп елады да елады. Ак колаклы, кара тәпиле, кәкре койрыклы маэмай килеп, башын әле бер, әле икенче якка мәзәк кенә кыңгырайткалап, өреп торды кызчыкка — файдасы тимәде. Суыкта алсуланган бәләкәй йодрыклары белән күзләрен уа-уа, кычкырып елавын гына белде кызчык.

Фирүзә бер очып үтте нәни кызчыкның каршыннан, ике очып үтте. Әмма кыз аңа бөтенләй игътибар итмәде.

— Елама, елама, мин сине шатландырырга телим, кара миңа, күр мине, менә мин нинди матур җемелдим! — дип кычкырды Фирүзә бөтен көченә.

Тик аның тавышы бик нәзек, бик көчсез иде шул. Елау ләззәтенә бирелгән кызчык аның тавышын ишетмәде.

Бераздан кыз йодрыкларын язды. Ләкин, нәни учларында яшь тамчылары күргәч, тагын да кычкырыбрак еларга тотынды.

Менә шул мизгелдә тәвәккәлләде инде Фирүзә. Күкне тутырып очкан кардәшләренә соңгы мәртәбә карап алды да кызчыкның алсу учына очып төште. Нәни учтагы җылы яшь тамчысына кушылып эреп беткәнче, кызчыкның елаудан туктавын, аның чиста күк йөздәй зәңгәр күзләрен киң ачып, соклану катыш куану белән тулуын күреп өлгерде ефәк чәчле, көмеш керфекле, ачык йөзле Фирүзә.

Фирүзәнең:

— Хушыгыз, туганнарым, мин теләгемә ирешеп эрим, — дигән соңгы сүзләрен җил биеккә-биеккә алып менеп китте.

— Хуш, кыю Фирүзә! — дип, бердәм гөрләделәр кар бөртекләре.

Җил көчәйде. Кар дөньясында буран чыкты.

# ҖИР МАЛАЕ

Яңа көн туган саен, өйдә: «Кая йөри бу йөзе ак булгыры малай, — дип борчылды Рәшитнең әнисе Хәерниса апа. — Көнгә бер капчык печән чабып кайтса да файда булыр иде. Бөтен каникулын юкны бушка авыштырып үткәрде. Әле, җитмәсә тагын, муеныннан майга чумып кайта...»

Серне күршеләре Сәлимә апа ачты:

— Әллә, мин әйтәм, Хәерниса, малаең Әхнәф комбайнында ярдәмче булып эшләргә йөриме?

— Ник?

— Ник дип... көне буе Әхнәф комбайны астыннан чыкмый бит.

— Ни сөйлисең син, күрше? Кечкенә бит әле безнең Рәшит. Алтынчы класска гына күчте. Кая аңа комбайнда эшләү...

Күршесе чыгып киткәч, Хәерниса апа түзмәде, кырык эшен кырык якка ташлап, колхоз остаханәсенә юл тотты.

Рәшит, чыннан да, Әхнәф комбайны янында зур ачкыч белән нәрсәдер борып маташа иде. Әнисен күргәч, аның кулындагы ачкычы җиргә төшеп китте, тирләгән түгәрәк йөзенә гаҗәпләнү һәм курку билгеләре чыкты.

— Син нишләп буялып йөрисең монда, малай актыгы! — дип кычкырып салды Хәерниса апа, комбайн янына барып җитәр-җитмәс.

— Болай гына...— дип мыгырданды Рәшит, аяк очларына карап.

Майлы кулларын чүпрәк белән сөртә-сөртә, комбайнның әллә кай җиреннән Әхнәф килеп чыкты.

— Ачуланмагыз инде, Хәерниса апа, — диде ул, йомшак тавыш белән. — Менә әйтте диярсең, рәт чыгачак сезнең малайдан, укулар башланганчы йөрсен әйдә минем янда.

— Ә мин рөхсәт итмәсәм?.. — диде Хәерниса апа төксе генә.

— Әни... — дип шыңшып куйды Рәшит.

— Әни дә түгел, чурт та түгел... Әйдә, марш өйгә...

Рәшит, нәүмизләнеп, яшьле күзләре белән бер энисенә, бер Әхнәф абыйсына карады. Әмма Хәерниса апаның йомшар исәбе күренми иде. Әхнәф исә, бер читкә карап, иңнәрен генә җыерды һәм чак кына ишетелерлек итеп әйтеп куйды:

— Алай булса, бар, кайт инде, Рәшит. Мин синең эшләгән көннәреңә наряд яздырырмын.— Бераз уйланып торгач, катгый тавыш белән: — Әти-әни сүзен тыңларга кирәк, Рәшит, — дип тә өстәде.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Күңелсез иде Рәшиткә, бик тә күңелсез иде. Иртән уянды исә, кыр ягыннан ишетелгән мотор тавышына колак сала торган булды ул. Иптәшләре белән дә уйныйсы килмәде. Мәктәп бакчасына барып, үзенә тиешле практика сәгатьләрен эшләп кайту да сөенеч бирмәде. Улының шулай сагышланып йөрүе өчен тәмам хафага төшкән Хәерниса апа көннәрдән бер көнне:

— Шул комбайн дия-дия, тәмам тәкатең корыды бит. Бу кадәр дә булырсың икән. Җибәрәм инде, җибәрәм, бара гына күр, — диде.

— Ничек барыйм хәзер анда? — дип сузып куйды Рәшит еламсырап.— Иртәгә уракка төшәргә торалар. Инде Әхнәф абый комбайнын күптән ремонтлап бетергәндер.

— Теләсәң нишлә, алайса. Балтасы суга төшкән утынчы кебек беркемгә бер авыз сүз катмый йөрүеңә аптырап кына әйтүем иде.

Шулай да икенче көнне, Хәерниса апа көтү куарга чыгып киткәч, Рәшит иске киемнәрен киде дә, кесәсенә бер телем икмәк белән берничә кыяр тыгып, куе булып яшел чирәм үскән бакча сукмагыннан басу ягына элдерде.

Өйгә тәмам күз бәйләнгәч кенә, муеннан тузанга, майга батып, әмма бәхетле йөз белән әйләнеп кайтты ул. Энисе ачуланмасын дигәндәй, юынгычны артык шалтыратмыйча гына юынды, басма иңсәсендә эленеп торган ап-ак сөл-

генең бер читенә сөртенде һәм аяк очларына гына басып өйгә керде.

— Кайттыңмы, эшем кешесе? — дип каршы алды аны әнисе, әллә чынлап, әллә шаяртып.

Рәшит, әнисенең йөзенә карамыйча гына, өстәл янына килеп утырды. Кашыгын тәмле исләр килеп торган тәлинкә өстендә еш-еш уйнатып, әнисенең: «Икенче болай буялып йөрисе булсаң», — дигән ачулы сүзләрен көтте. Ләкин Хәерниса апа дәшмәде.

— Әни, иртәгә иртәрәк уятырсың, яме, — диде Рәшит, йокларга ятканда, ялварулы тавыш белән.

Хәерниса апа ризалык белдереп баш какты. Аннары күзләрен тутырып озак кына Рәшиткә карап торды да:

— Нишләдегез соң бүген, улым? — дип сорады.

— Бодай суктырдык...— дип, урыныннан сикереп торып, нәрсәдер сөйләргә керешкән иде дә Рәшит, әнисе аның юрганын башыннан ук бөркәп куйды.

— Йә, ярар, йокла, йокла... Җәйге төннәр кыска...

Хәерниса апа башта Рәшитнең иртә таңнан торып кырга чабуын малайларга хас бер мавыгу гынадыр дип уйлаган иде. Ләкин Рәшит көннән-көн дәртләнебрәк, көннән-көн канатланыбрак кырга омтылды, ә өйгә һәр көнне елмаеп кайтып керә торган булды.

«Ни генә кыра ала икән соң бу малай? Анда кешегә комачау булып кына йөрми микән? — дип уйлады Хәерниса апа борчылып. — Тукта, булмаса, барып карыйм әле».

Ул тәмле-тәмле ризыклар тутырылган хуҗалык сумкасын күтәреп басуга килгәндә, Әхнәф комбайны, өзек-өзек гүләп, бодай суктырып йөри иде. Әхнәф үзе рульдә, ә күзлек, эш костюмнары киеп алгач олы кешегә охшап киткән Рәшит, бер кулы белән ниндидер ялтыравыклы тимергә тотынып, аның янында басып тора.

Хәерниса апаны алар икесе дә берьюлы күреп алдылар. Әхнәф, комбайнны туктатып, җиргә сикереп төште һәм ерактан ук:

— Улыңның хәлен белергә килдеңме, Хәерниса апа? — дип кычкырды.

Рәшит, нишләргә белмәгәндәй, кызган салам исе аңкып торган бәләкәй тимер күперчектә таптанып тора бирде. Үзе эчтән генә: «Әллә мине алып кайтырга килде микән?» — дип уйлый-уйлый, кырын күз белән әнисенә карады.

— Кара әле, Әхнәф улым,— дип сузды Хәерниса апа, мотор гөрелтесе азрак басылган арада, — син чынлап та шул малай белән эшләргә уйлыйсыңмы?

— Уйламыйм, Хәерниса апа, эшлибез, — диде Әхнәф.

Хәерниса апа борчулы карашын Рәшиткә юнәлтте.

— Булыр микән соң аннан?.. Әле бигрәк яшь бит...

Шул чагында Әхнәф Рәшиткә кул изәде. Ә тегесе, шуны гына көткәндәй, руль артына кереп утырды да нәрсәгәдер басты, нәрсәнедер тартты, һәм комбайн тигез генә гөрләп урыныннан кузгалып китте.

— Күрдеңме? — диде Әхнәф, Хәерниса апаның аптырабрак калган күзләренә туры карап.

— Рәхмәт инде, Әхнәф улым... — дип кенә әйтә алды Хәерниса апа.

— Шундый акыллы, эшчән малай үстерүең өчен үзеңә рәхмәт, Хәерниса апа...

Рәшит, загонның аргы очына җитеп, комбайнны борганда, әнисен тагын күрде: ул һаман болайга таба карап тора иде. Рәшит, шатлыктан очкынланган күзләрен кыса төшеп, газны арттырды. Алтынсу-соргылт тасма булып еракка-еракка, зәңгәрләнеп күренгән урманнарга таба сузылып киткән бодай теземен комбайн дәртләнебрәк йотарга кереште.

## ӘНКӘ КҮРКӘ ҺӘМ АНЫҢ БАЛАЛАРЫ

Әнкә күркәнең үз баласы берәү генә иде. Берәү генә булгангадыр, ахры, — шаян, иркә иде. Төнлә әнкәсенең култык астына кереп йокларга ярата, култык астында яту туйдырса, әнисенең җилкәсенә менеп кунакларга да күп сорамый иде Пиәк. Кара, әйтергә онытканмын икән — күркә баласының әнисе кушкан исеме Пиәк иде. Кичләрен ояда, челтәрле тәрәзә аша моңсу ай караган мизгелдә, әнкә күркә, кинәт кенә уянып, җәһәт кенә башын борып, ягымлы тавыш белән:

— Пиәк! — дип эндәшә.

Пиәк, син мондамы, янәсе.

— И-ие, — дип җавап бирә аңа Пиәк йокы аралаш.

Әнкә күркә үзенең Пиәгеннән тыш әле тагын үрдәк бәбкәләре дә үстерә. Алары сап-сары иде. Алары икәү — берсе Фиәк, икенчесе Ниәк исемле.

Фиәк белән Ниәкне дә бик ярата әнкә күркә. Пиәк кебек иркә булмасалар да, төнлә җилкәсенә кадәр менмичә, канат астына кереп йокларга риза булсалар да, ярата ул аларны. Һе, яратмый теге: Фиәк белән Ниәкне дә йомыркадан үзе басып чыгарды ла ул. Көннәр буе ашамый-эчми ояда саргаеп утырды. Йомыркаларның сәеррәк булуына бик исе китмәгән иде әнкә күркәнең. Ә менә йомыркалар борынлап, чебиләр чыгып, ике чебие оядан

төшкәч үк сулы тәлинкәләргә кереп киткәч, бераз гаҗәпсенде, дөресрәге, курка калды ул. Батып үлмәсеннәр тагын дигән сыман, сыгылмалы муенын әле тегеләй, әле болай боргалады, үрдәк бәбкәләрен күзәтте. Әле инәлеп, әле үпкәләп, әле ачуланып, нәни сары йомгаклардай бәбкәчләрен үз янына чакырды, тамак төпләрен голдырдатып, су белән уйнауның куркыныч икәнлеген аңлатырга тырышты:

— Фиәк! Ык корр!.. Ниәк! Ык корр!..

Фиәк балакаем, чык корыга, янәсе! Ниәк балакаем, чык корыга!

Фиәк белән Ниәктән күрә Пиәк тә суга керергә уйлаган иде бугай, озын тәпиен тәлинкә читенә дә куйган иде инде ул, тик шул минутта карт әтәч койма артында шундый тавыш-гауга куптарды ки — нәни чебиләр, нәни бәбкәләр генә түгел, дөнья күргән тәҗрибәле тавыклар да, бер мизгелгә һуштан язарга җитеп, җиргә сеңеп тордылар. Аннары кинәт ишегалдында коточкыч шау-шу купты. Кош-кортларның һәркайсы үз телендә:

— Качыгыз, кач! Тилгән! Тилгән килгән! Качыйк, котылыйк-кытыйк, — дип кычкырдылар һәм күз ачып йомганчы лапас асларына, сәрви, карлыган төпләренә кереп постылар.

Баш өстеннән тавышсыз гына кара күләгә шуып үткәндә, әнкә күркә үзенең нарасыйларын чатырдай киң канатлары белән каплап алырга өлгергән иде инде.

Әллә күркәнең җәелгән канатларын күреп, сугышырга әзер икән бу, дип уйлады инде — шул китүеннән тилгән кабат әйләнеп килмәде. Тирә-як тынычлангач, әнкә күркә дә канатларын җыйды, тәлинкәгә карады, тик Фиәк белән Ниәкне күрмәгәч, сискәнеп муенын уракландырды, канат каурыйлары арасыннан сыңар күзе генә күренеп торган Пиәгенә endәште:

— Пиәк!

— И-ик!

— Кая Фиәк, кая Ниәк?

— Пи-ик, и-ик!..

Әнкә күркә уңга күз салды, сулга күз салды, аннары тагын муенын ураклaндырды, үзенең төз аякларын күрде, аяклары янында сары йомгаклар күрде. Сары йомгаклар аша ипләп кенә атлап үтте.

Артына әйләнеп караса, сары йомгаклар йомгак булмаганнар икән, Фиәк белән Ниәк булганнар икән. Менә үрдәк бәбкәләре, өсләрендә чиксез бушлык күреп, куркышып пи-пип-пип, дип елый-елый, әнкә күркә артыннан йөгерделәр, тагын аның аякларына килеп сыенды-

лар. Пиәк тә каурыйлар арасыннан шуып төште һәм күз ачып йомганчы Фиәк томшыгына кунарга маташкан черкине кабып йотты, черкигә Ниәк тә үрелгән иде, ләкин аның кызыл соскычлары буш һаваны гына шыкылдатып кисте.

Ул көнне Пиәк, Фиәк һәм Ниәк черки куып бик озак уйнадылар. Фиәк белән Ниәк тәлинкә янына килеп челтер-челтер су эчкәндә, әнисеннән күреп Пиәк тә койма буендагы кычыткан яфракларыннан авыз иткәләде.

Тагын берничә көннән әнкә күркә балаларын җим эзләргә, җим табарга өйрәтте. Әмма бу һөнәргә Пиәк кенә һәвәс булып чыкты. Әнисе күрсәткән җимне кабып йоткан саен, кечкенә канатларын җилпегәндәй итеп, сөенеп-һаваланып кычкыра торды:

— Йәк, йәк, йәк! Йәк-йәк! Йәәк!

«Шәп, шәп, шәп! Мин — шәп!» дип куануы иде инде Пиәкнең бу.

Фиәк белән Ниәкнең күзгә төртеп күрсәткән җимне дә күрмәүләре, әллә күреп тә күрергә теләмәүләре гаҗәпләндерде әнкә күркәне. Пиәген бер читкә этәреп тә карады ул. Мәгәр юкка гына, дөнья бәһасе ризыкны кызыл ярылы тәпиләре белән таптап кына киттеләр дә тегеләр янә тыпы-тыпы сулы тәлинкә янына йөгерделәр. Башларын суга тыгып чупырдашып алдылар да соскычтай томшыкларын югары күтәреп кылкынгалап тордылар. Аннары тагын әнкә күркә чакырган җиргә йөгереп килделәр һәм тагын җимне күрмичә дулап уздылар да, кырт кына борылып, сулы тәлинкә янына элдерттеләр. Хикмәт дисәң дә хикмәт инде! Ни бар икән соң ул тәлинкә төбендә?

Әнкә күркә эре адымнар белән тәлинкә янына килде, томшыгын суга тыгып алды. Ипи валчыклары! Тәлинкә төбе тулы ипи валчыклары икән! Фиәк белән Ниәк ачка тарыгып йөридер, дип, юкка борчылган икән лә әнкә күркә. Болай булгач, тамаклары тук инде аларның.

Әнкә күркә тынычланып калды. Олы канатларын җилпеп, киртә өстенә очып кунды, кечкенәләренә биектән торып акыл өйрәтергә кереште:

— Киәк, крак, ирәк, риәк, рәк, рәк...

Бер-берегез белән тату яшәгез. Бер-берегезне рәнҗетмәгез, үзара дус булыгыз ягъни.

— Ие-ие-ие, әни, дөрес әйтәсең, — дип, әнисе артыннан киртәгә сикереп менәргә тырышты Пиәк.

Фиәк белән Ниәк тә Пиәк сүзләрен расладылар:

— Пи-пип-пи, пип-пи-пи... Сүзең дөрес, әни. Без дус булырбыз, әни.

Балаларының шундый ягымлы, сүз тыңлаучан булу-

ларына сөенеп бетә алмады әнкә күркә. Шатлыгыннан нишләргә белмәгәч, канатларын шапыл-шопыл иттереп кагынып куйды, күкрәген киереп, бар дөньяга аваз салды:

— Яхшы сүзегез өчен рәхмәт сезгә, балакайларым! Игелек күрегез!

Пиәк, Фиәк һәм Ниәк көннән-көн исәйделәр, матурайдылар. Аларның бала йоннарын йомшак каурыйлар каплады. Фиәк белән Ниәкнең көннәр буе суга чумып ятуларына да исе китми инде хәзер әнкә күркәнең. Суда рәхәт икән үзләренә, әйдә чыпырдый бирсеннәр. Чыпырдыйлар-чыпырдыйлар да, чыпырдап туйгач, чыгалар ич әле, суда кунып калмыйлар. Кояш баеп, челтәр тәрәзәле өйләренә кергәч инде балалар өчесе дә әнкә күркәнең җылы канатлары астына кереп чумалар, иркәләнеп-назланып пипелдәшәләр һәм озак та үтми татлы йокыга талалар.

Оя почмагына кунача да куелган югыйсә. Ләкин балалары чыкканнан бирле әнкә күркәнең бер генә мәртәбә дә куначага менеп йоклаганы юк әле. Әллә теләми, әллә бәбкәләрен кызгана шунда, белмәссең...

Баш очыннан кызыл күзле тимер кош гүелдәп үтә. Ерак басулардан карт тупыл ботакларына кайтып кунаклаган каргалар, нидәндер куркып, ябалдашларны шаулатып, һавага күтәреләләр. Ишегалды буенча трас-трас басып сыер үтеп китә. Хуҗа хатын чиләкләр чылтырата. Кайдадыр эт өрә. Күркә баласы Пиәккә дә, үрдәк бәбкәләре Фиәк белән Ниәккә дә канат астында җылы, рәхәт, тыныч.

* * *

Кояшлы иртәләрнең берсендә, күркә гаиләсе шулай тыныч-тату гына яшәп ятканда, авыл читендәге камышлы күлдән әнкә үрдәк кайтты. Өйдәгеләр бөтенләй югалтканнар иде инде аны. Баксалар, югалмаган икән. Күлдә сый мул булган, күрәсең, — симергән әнкә үрдәк, чибәрләнгән. Тавышына кадәр җырлап тора. Башка үрдәкләр кебек «бак-бак» дип кенә кычкырмый, «брат-брат» дип, дөнья яңгырата.

— Брат-брат, арт!

Менә, янәсе, мин дә бар әле дөньяда.

Ярар, кайтты әнкә үрдәк. Хуҗаларны шатландырды. Өй нигъмәтләреннән — бодаеннан, бәрәңгесеннән авыз итте. Аннары ашыгыч адымнар белән бакчага чыкты, әнкә күркә тирәсендә сөенешеп йөргән шаян бәбкәләрне күреп алды, гаҗәпләнүен яшермичә кычкырып җибәрде:

— Ба-ак! Исемегез ничек сезнең?

— Фи-фи-фиәк минем исемем, — диде Фиәк, тотлыга-тотлыга.

— Туганыңның исеме ничек?

— Ни-ни-ниәк...

— Б-рат, — дип башын чайкады әнкә үрдәк. — Шундый исем буламы? Б-рат...

— Ие, — дип, Пиәк тә сүзгә катнаша башлаган иде дә, әнкә үрдәк аңа шундый итеп җикерде, тегe бичарага әнкәсе артына кереп шылудан гайре чара калмады.

— Ә син тик тор! Күркә баласы белән сөйләшмим мин, үрдәк бәбкәләре белән сөйләшәм. Бак син аны! Фиәк, әйдәгез камышлы күлгә. Анда бакалар күп.

— Пи-пи-пи, ни әйтер бит әни, — дип, әнкә күркәгә карады Фиәк.

Ниәк тә аның сүзен кабатлады:

— Ни-ни... ни әйтер бит әни?

— Бак! — диде әнкә үрдәк, мыскыллы тавыш белән. — Күркә нишләп сезнең әниегез булсын? Менә мин булам сезнең әниегез. Бак, ничек әйбәт мин!

Фиәк белән Ниәк еларга тотындылар.

— Син түгел безнең әни, менә бу безнең әни, пи-пи-пипи. Менә безнең әни, — дип, әнкә күркә тирәсендә бөтерелделәр алар.

Әнкә үрдәк, ниһаять, әңгәмәгә катнашмыйча, авыз эченнән генә нәрсәдер җырлый-җырлый, җим караштыргалап йөргән әнкә күркәгә эндәште:

— Бир миңа Фиәк белән Ниәкне! Мин аларны камышлы күлгә алып төшәм.

— Бирмә, әни, бирмә, — диде Пиәк, еларга җитешеп, — мин кем белән уйнармын аннары.

— Ниәк, Фиәк, тыңлагыз мине, — дип сүзгә катнашты шунда әнкә күркә, сабыр тавыш белән. — Сез инде зур үстегез, тиздән үз көнегезне үзегез күрә башларсыз. Камышлы күлгә барасыгыз килә икән — барыгыз, мин тотмыйм. Миңа «әни» дип эндәшмәсәгез дә үпкәләмәм. Чөнки сез, чынлап та, үрдәк йомыркаларыннан чыктыгыз. Туктале, Пиәк, еламый тор, әйтеп бетерим. Менә шулай, балакайлар. Үзегезнең язмышны үзегез хәл итәр вакыт җитте сезгә.

— Пи-пи-пи-п, синең яннан беркая да китмибез без, әни, — диештеләр, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Фиәк белән Ниәк.

— Пи-п, син безне үстердең, салкын төннәрдә, җилъяңгырларда канат астына алып юаттың, җылыттың, иркәләдең, әни, пи-пи-пи-пи, без сине дә, Пиәкне дә ташламыйбыз, әни. Безгә бергә-бергә күңелле, әни.

Әнкә үрдәк башын иеп кычытканнар арасына кереп киткәч, әнкә күркәнең күзләреннән сәйлән тамчыларыдай ике бөртек яшь атылып чыкты. Әллә әнкә үрдәкне кызганып елый инде әнкә күркә, әллә шатлык яшьләре томаландырган иде күзләрен — Пиәк тә, Фиәк тә, Ниәк тә бу хакта әниләренең үзләреннән сорарга базмадылар.

Ә нигә сорап торырга? Кояшлы яшел бакчада алар тагын бергә, алар тагын бәхетле иде.

## ЧИКЛӘВЕК

Кая карама яфрак та яфрак. Ник бер генә чикләвек калсын. Пәрәвезләр сырышкан куакларны карашың талганчы күзләсәң дә күренми чикләвек, яшеле уңа башлаган ябалдашларны тотып-тотып селкесәң дә коелмый.

Шуңа күрә Фазыл, куак очларына карап яки ябалдашларны селкетеп, вакыт әрәм итеп йөрмәде. Бормалы сукмак буенча әрәмәлекнең аргы ягына чыкты да, басу читендәге кыска куаклар арасына кереп, чалкан сузылып ятты.

Әйе, җыярга теләсәң, бары тик шулай гына җыярга мөмкин сентябрь азагында чикләвекне. Әнә бит берсе, үләннәргә орыныр-орынмас, сары күзен җемелдәтеп тора. Фазыл аксыл кишәнкәгә орыну белән, гәрәбәдәй сапсары чикләвек аның учына тәгәрәп төште. Тәмам өлгереп җиткән инде хәзер. Фазыл өзеп алмаса, тагын берничә көннән төше кабыгын ватып чыккан булыр иде, мөгаен. «Гали-баба һәм кырык карак» әкиятендәге май чүлмәгеннән ким түгел бер дә.

Озак та үтмәде, ике чикләвекле кишәнкә тапты Фазыл. Аннары янә икелене, аннары берьюлы дүрт чикләвекле кишәнкәгә юлыкты.

Куак асларыннан авыл ягындагы тау буена шуып барып җиткәндә, кесәсе сизелерлек кабарган иде инде аның. Тау буена чыгып утыргач, Фазыл чикләвекләрен кепкасына бушатып санарга кереште. Вагы-төяге белән утыз җиде чикләвек җыелган иде. Парсыз булса, берсен ашармын дигән иде Фазыл — сүзендә торды. Нәкъ бая үзе уйлаганча, симез һәм утырган балдай каты иде чикләвек төше. Тәмен хәтерендә калдырырга теләгәндәй, бик озаклап, әнкәсе әйтмешли, җанына яткызып чәйнәде аны Фазыл...

Әнисенә бирсә алтысын, каладыр утыз. Сеңлесе Гөләндәмгә бирсә дүртесен, каладыр... каладыр егерме алты. Күрше кызы Мәдинәгә дүртесе... Юк, бик күпкә китә ич әле бу болай. Мәдинәгә биргәч, Ибрайны да калдырып

булмый. Ибрайга биргәч, Шәриф нәрсә әйтер аннары? Әнисенә өлеш чыгарса, шул җиткән инде. Калганнары үзләре менеп җыйсыннар. Чур, яңабаштан... Әнисенә алтысын бирсә, каладыр утыз. Утызны икегә бүлгәч, унбишәр чыга. Менә шулай, унбишен үзе ашый Фазыл, ә унбишен Ясминә апасына бирә. Бик әйбәт бит Фазылларның Ясминә апалары. Фазылга дүртле белән бишледән гайре билге куйганы да юк. Хәер, билге куйганы өчен бирми аңа Фазыл чикләвекне. Болай, хөрмәт иткәнгә, яратканга, бирәсе килгәнгә бирә.

Фазыл, уйларыннан аерылып, карт өянкеләр арасыннан кызарып күренгән мәктәп түбәсенә, аннары шактый биек күтәрелергә өлгергән сентябрь кояшына күз ташлап алды да көндезге аш вакыты җитүен чамалады һәм, өермәдәй бөтерелеп, тау астына төшеп китте.

Әнисе чикләвекләрне, кирәкмәс иде, улым, үзең ашар идең, дигән булып, ялындырып кына алды. Бәхеткә каршы, Гөләндәм өйдә юк иде. Өйдә булып, кесәңдә чикләвек барын сизсә, тынгылык бирмәс иде абыйсына, берне генә, тагын берне генә, дип, теңкәсен корытып бетерер иде...

Әнисе өстәлгә китереп тезгән ризыкларны ашаганда да, ашап-эчкәч, аркасына сумкасын асканда да, мәктәп юлында да, шаулы класска барып кергәч тә бер уй, бер сорау борчыды Фазылны. Ничек итеп ялгызын гына туры китерер дә Ясминә апасын, ничек итеп тапшырыр чикләвекләрне?..

Беренче дәрес тә, икенчесе дә үтеп китте, әмма һич кенә дә чикләвек бирергә җай чыкмый иде.

Озын тәнәфестә Фазыл Ясминә апасын укытучылар бүлмәсенә кадәр озата килде. Тик ялгызы гына түгел иде шул Ясминә апасы. Гадәттәгечә, бер төркем чыркылдык кызлар уратып алган иде аны. Сөйләп сүзләре бетәсе юк һич тә шул тел бистәләренең. Тәнәфестә дә укытучыларга тынгылык бирмиләр.

Ул да түгел, Фазылның башына тагын бер борчулы уй килде. Кесәсез ак кофта гына кигән икән бүген Ясминә апасы. Кая куяр икән инде ул Фазыл биргән чикләвекләрне?..

Тагын бер генә дәрес калып бара бит инде. Ә чикләвекләрне бирергә җай чыкмый да чыкмый. Әгәр дә кайтканын саклап торсаң...

Басмадан төшкәч, Фазыл мәктәп ихатасы буенда торган мотоциклны күреп алды. Менә бәла. Җәяү кайтмый бит әле аларның Ясминә апалары өенә дә. Аны һәр көнне физкультура укытучысы Галимҗан мотоциклына утыртып кайта.

Бүген дә шулай булыр инде. Фазыл мотоцикл янына килеп бармагы белән тәгәрмәчләренә баскалап карады. Бәлки, ватыктыр ул бүген? Бәлки, тәгәрмәчләренең тыны чыккандыр? Юк, тәгәрмәчләре таш кебек. Ватылган урыны да күренми. Бөтен җире көзге кебек ялтырап тора.

Дәрескә чакырып кыңгырау чылтырады. Шау-шулы чуар төркемне мәктәп ишеге минуты-секунды белән эчкә суырып алды.

Соңгы дәрес бит инде, соңгы дәрес. Фазыл Ясминә апасы сөйләгән сүзләрне рәтләп тыңламый да. Кесә төбендә унбиш чикләвек яткангадыр, ахрысы, тактага язылган саннарның һәркайсы унбиш булып күренә аңа.

— Фазыл, ә син нигә язмыйсың?

Фазыл сискәнеп каләменә ябышты.

— Язам мин, апа.

— Йә, Фазыл, әйтеп кара әле, ике сигезең ничә була?

— Унбиш, апа.

Тирә-якта көлү тавышлары ишетелде.

— Дәрестә болай игътибарсыз утыра башласаң, икеле куярмын, кара аны, Закиров, — дип, шәмәхә-зәңгәр күзләрен җемелдәтеп алды укытучы.

«Икеле» сүзе башта хәтерен калдырган иде Фазылның. Аннары аның башында, азагы ни белән тәмамланасын әле үзе дә чамалап бетерми торган, үзенә калса кызыклы гына бер уй кыймылдап куйды.

Дөрес җавап бирмәгән укучыларны дәрестән соң алып кала торган гадәте бар лабаса Ясминә апасының. Ә бүген дөрес җавап бирмәгән укучы юк бугай әле. Димәк, Фазыл беренчесе була. Димәк, тагын бер тапкыр «ялгышса», Фазылның берүзен генә алып калачак Ясминә апасы.

Шул чагында укытучы, Фазылның уйларын сизгәндәй, аны такта янына чакырды.

— Нәрсә, Закиров, әллә сорауны ишетмәдеңме?

— Юк, — диде Фазыл, астыртын гына көлемсерәп.

— Илдус исемле малай өч дустына сигезәр чикләвек бүлеп биргән. Барысы ничә чикләвек биргән була инде Илдус дусларына?

— Егерме биш, — дип ялганлады Фазыл, күзен дә йоммыйча.

Арткы партадагы кызлар, прых-прых килеп, авызларын учлары белән томаладылар.

— Ничек егерме биш? Яле, йә, Фазыл, хисаплап күрсәт, — диде укытучы, тавышын күтәрмичә генә.

Фазыл, чынлап та берни белмәгән сыман, башын аска иебрәк, баскан урынында баганадай катып тора бирде.

— Нишләдең син, Закиров, — диде укытучы, шәмәхә-

зәңгәр күзләрен зур ачып. — Утыр, бар. Икеле. Иртәгә әзерләнеп кил дәрескә.

Фазыл урынына барып утырды һәм, башын аска игән килеш, түземсезлек белән дәрес беткәнен көтәргә керешге.

Ниһаять, зарыгып көтелгән кыңгырау чылтырады... Тик нәрсә була соң әле бу? Ясминә апасы ни өчендер дәрестән соң калырга кушмады Фазылга.

Ишектән чыгып киткәнче ничек тә туктатырга кирәк иде аны. Фазыл җәһәт кенә урыныннан сикереп торды да, әле класстан чыгып бетмәгән укучыларның игътибарын җәлеп итмәскә тырышып:

— Апа, — дип пышылдады.

Укытучы әйләнеп карады.

— Апа, мин икеле алдым ич.

— Алсаң соң, — диде Ясминә апасы, бер дә исе китмичә. — Икенче укып килергә яхшы булыр.

— Апа, чикләвек... — диде дә Фазыл тотлыгып калды.

— Йә, ничә? — диде укытучы, Фазылны уңайсыз хәлдән чыгарырга теләгәндәй, йомшак кына итеп.

Фазыл, кесәсенә кулын тыгып, чикләвекләрне йомарлап алды.

— Унбиш, апа.

— Әллә нишләдең әле син, Закиров, бүген, — диде Ясминә апасы, бөтенләй кәефе кырылган тавыш белән. — Ике җирдә сигезең уналты, ә өч җирдә сигезең егерме дүрт була, Закиров. Онытма. Колагыңа киртләп куй.

Укытучы, ишекне җилле генә ябып, класстан чыгып китте.

Коридорда биек үкчәле туфли тавышлары ераклашты. Бераздан урамда мотоцикл тавышы ишетелде. Ә Фазыл исә, кесәсендәге чикләвекләрен бармак араларында әвәли-әвәли, баскан урынында торды да торды.

## ТАУ БИТЕНДӘ КҮЛӘГӘ

Җем-җем килеп, сизелер-сизелмәс кенә агып яткан инешнең бер ягында авыл, икенче ягында битләре ермаклар белән телгәләнгән текә тау.

Тын. Рәхәт. Шәһәр шау-шуыннан соң бигрәк тә. Бер рәхәт төшкересе инеш буена гына утыргыч та ясап куйган. Тау башындагы төпсез зәңгәрлектә яисә инеш төбендә төрле төсләргә кереп ялтырашкан йомры ташларга карап уйланып утыр да утыр шулай бер көе.

Тик көзге табигать белән озак хозурланып утыра ал-

мадым — якында гына шатланышып сөйләшкән тавышлар ишетелде. Мин борылып карадым: бәрәңге бакчасы буендагы сукмактан инешкә таба өч малай төшеп килә иде. Алдагысы ни өчендер кулын югары күтәргән. Әһә, аның кулыннан җеп сузылып килә икән. Малай үзе аяк астына карамый да диярлек. Күзләре гел һавада. Арттагы малайларның баш очларында лапас түбәсе чаклы кәгазь очырткыч тирбәлә. Алары да җиргә карамыйлар, аларның күзләре очырткычта.

Әллә кайдан күренеп тора — бу сукмактан беренче генә тапкыр узулары түгел малайларның.

Алай, аңлашыла — көне буе эш белән мәшгуль булган икән болар. Хәтта күлмәк изүләрен каптырырга да вакытлары булмаган. Үз эшләреннән канәгать икәнлекләре бер-берсенә сөенеп сүз катуларыннан, көлешүләреннән үк күренеп тора.

Алдагы малайның кулындагы җеп, — кәтүккә чорналган булган, ахры, — һаман озыная бара.

Очырткычлары, чыннан да, сокланырлык икән малайларның — үзе зур, үзе төрле төсләргә буялган. Канатлары оча торган балыкны да, әкияттәге лачын-кошны да хәтерләтә. Аз гына җил иссә дә, күккә очып менеп китәм дип тора. Малайлар үзләре куаклар арасына кереп күздән югалгач та, кызыллы-сарылы яфраклар арасыннан әллә ничә тапкыр агарып күренде әле аларның очырткычлары.

Малайлар тау битенә барып менгәч кенә күземә чалынды: алар өчесе дә бертөсле зәңгәр күлмәктән икән. Кем белә, үскәч очучы яки космонавт булырга хыяллана торганнардыр, шәт, алар.

Алдагы малай биеккәрәк менгән саен, очырткыч та югарырак күтәрелде. Малайлар тауга каршы йөгерә башладылар. Очырткыч тагын да текәрәк юнәлеш алды, тик һава бушлыгына туры килде бугай — кинәт кенә янтаеп, кызгылт ермак буена кадалып төште. Малайлар, йөгерешеп килеп, очырткыч өстенә иелделәр. Миңа хәзер аларның тавышлары ишетелми, яшькелт-сары тау җирлегендә генә олы зәңгәр чәчәктәй балкып күренә иде.

Очырткычның канаты-фәләне имгәнгәндер, ахры, шактый озак бер урында әвәрә килделәр малайлар. Ниһаять, аларның берсе — озыны бугай — кулын өскә күтәреп, янә тау түбәсенә йөгереп менеп китте. Очырткыч башта ермак буенда калган малайлар биеклегендә бер яктан икенче якка чайкалып торды. Аннары капыл гына югарыга ыргылды, канатларын җәйгән серле кошка охшап, зәңгәр күк гөмбәзе буйлап йөзеп китте.

Көзге тынлыктан изрәп утырган авыл, ука киемле тал куаклары, алтынсу-яшькелт тау сырты һәм төпсез зәңгәрлек... Шул зәңгәрлектә, биектә-биектә, салмак кына тирбәлгән аксыл очырткыч... Аннары тау буенча сибелешеп йөгерешкән зәңгәр күлмәкле малайлар. Карап утыра-утыра, миңа алар үзләре дә алтынсу-яшькелт тау битенә төпсез зәңгәрлектән очып төшкәннәрдер сыман тоела башлады.

Серле очырткыч төпсез зәңгәрлектә әнә шулай әйләнеп-әйләнеп йөрер дә салмак кына тау түбәсенә төшәр һәм, малайларны утыртып, янә һавага күтәрелер.

Шул вакыт кинәт минем күңелдә дә очырткыч җебен тотып карау, кулларымда аның тарту көчен тою теләге уянды. Мондый очырткычлар ясый белми идек бит без бәләкәй чакта... Без бәләкәй чакта куәтле реактив самолетлар да, космик кораблар да юк иде бит әле... Бу малайлар егет булып җиткәндә, нинди очкычлар йөзәр икән галәм океаннарында, нинди ераклыкларны, нинди биеклекләрне буйсындырыр икән кеше акылы, кеше хыялы?..

Мин әнә шундый уйларга чумып утырганда, бакча киртәләре буеннан, кача-поса, янә бер малай йөгереп узды. Кепкасының алдын артка әйләндереп кигән, көн инде кичкә авышып баруга карамастан, майкачан гына, оекбаш балтырларын да, балак очларын да тигәнәк сырган. Аргы урамнан ук йөгереп төшкәнгә охшый бу малай — йөзе кызарган, борын очы дымланган. Тау башына текәлгән күзләреннән астыртын көлемсерәү сирпелмәсә, игътибар белән карамаган да булыр идем мин аңа. Әнә бит, зәңгәр күлмәкле малайларның күзләрен күрми дә калдым. Хәер, аларның бөтен барлыклары — көлешүләре, хәрәкәтләре, кыяфәтләре — һәммәсе-һәммәсе шатлыктан гына гыйбарәт иде...

Майкалы малай тал куаклары арасына кереп китте. Мин аның инеш аръягында күренүен көттем. Ләкин майкалы малай беркайда да күренмәде, суга төшкәндәй юкка чыкты.

Югалмагае, нигә кирәге бар соң аның миңа! Куаклар арасында бозауларына үлән җыя торгандыр әле.

Очырткыч һаман да тау башындагы төпсез зәңгәрлектә тирбәлә. Ләкин хәзер инде ул баягыдан түбәнрәк төшкән һәм зәңгәр күлмәкле малайлардан шактый еракка тартылган. Малайларның озыны тау сыртының иң биек урынына менеп баскан, кулларын әле тегеләй, әле болай әвеш-тәвеш китерә. Әйтерсең лә шаян көйгә бии.

Ләкин очырткычның күтәрелер исәбе юк иде бугай инде. Ул һаман да түбәнәя, һаман да ермак ягынарак авыша бара.

Хәер, озын малай барыбер ермакка төшәргә ирек бирмәде очырткычка. Үзе менеп баскан биеклек өстендә әрле-бирле йөгергәләп, кулларын жонглер сыман җитез хәрәкәтләндереп, очырткычны, канатларын кыегайттырмый-нитми, яр читенә төшеп кунарга мәҗбүр итте.

Шул чагында ермак эченнән тауның нәкъ очырткыч агарып яткан турысына майкалы малай килеп чыкты. Килеп тә чыкты, очырткычны сөйрәп, яр астына төшеп тә китте.

Зәңгәр күлмәкле малайлар күрми дә калдылар инде әллә? Юк, күрделәр бугай — өчесе өч яктан җай гына атлаган җирләреннән кинәт кубарылып йөгерә башладылар. Яр читенә җиткәч тә тукталып тормадылар, йөгергән уңайга яр астына сикереп югала бардылар.

Яр астындагы хәлләрдән мин, әлбәттә, хәбәрдар түгел идем. Шактый вакыттан соң гына яңадан күренделәр зәңгәр күлмәкле малайлар тау битендә. Тик бу юлы теге, зур, серле кошка охшаган очырткычның берничә кисәккә өзгәләнгән канатлары гына иде инде аларның кулларында.

Өч малай бер урынга җыелышып нәрсә турындадыр сөйләшеп тордылар да кайтыр юлга борылдылар. Мин аларның түбән иелгән башларын, салынган иңнәрен аермачык күрдем. Якты тау битенә дә, малайларның күк төсле күлмәкләренә дә шәрә бакчалардан кинәт кенә кара күләгә төшкәндәй тоелды. Урынымнан торып авыл эченә таба атладым. Көз кояшы шактый түбән тәгәрәгән икән — аркамны салкын дулкын чымырдатып узды.

Мин адымнарымны кызулаттым. Зәңгәр күлмәкле малайлар белән түгел, майкалы малай белән очрашудан курка идем мин бу минутта.

## МИН ДӘ ҮСӘРМЕН ӘЛЕ

Кем булган соң әле ул кадәр? Абыйны әйтәм. Йә, миннән өч яшькә олырак, ди. Бик харап икән! Мин дә үсәрмен әле. Шулай да абыйның миннән зур булуына ачу килә. Өстәвенә әни дә гелән-гелән гарьләндерә бит әле. Әнә, имеш, Хәмит улым, абыеңнан үрнәк алыр идең. Абыең акыллы, абыең үскән, абыең фәлән, абыең фәсмәтән. Боларына гына түзәр дә идең, шәт. Әмма быел җәй һич уйламаганда абый колхозда эшли башлады.

Әти шофер безнең. Чын октябрят сүзе, әти машинасына бөртек тә кызыкмыйм мин, ә абый җигеп йөри торган күк байтал төшләремә керә.

Абый саран түгел үзе болай. Һәр көнне авыл башына кадәр арбасына мине дә утыртып бара. Әмма — безнең авыл зур түгел — кадерле минутлар бик тиз үтә. Арбага менеп кунаклагач, күк байталның тузгыган ялларына карап сокланырга да өлгермисең, борылыштан өч тирәк калкып чыга. Өч тирәк турысына җиткәч, мин арбадан төшеп калам.

Ә син нишләп әле авыл башында төшеп каласың, нишләп абыең арбасына утырып кырга, күрше колхозга яисә станциягә бармыйсың, диярсез инде сез. Ничек әйтергә? Әллә бөтенләй әйтмәскә микән? Абый утыртып бара анысы. Әни дә каршы түгел аның мине утыртып йөрүенә. Әти дә әнә «йөргән таш шомара» дип әйтеп тора. Хикмәт нәрсәдәме? Хикмәт яшенле яңгырда. Әллә сез курыкмыйсызмы яшенле яңгырдан? Һе, алайса, эләккәнегез юк инде сезнең яшенле яңгырның шәбрәгенә. Бервакытны малайлар белән җиләккә баргач эләктек без. Ай-яй! Теге агач төбенә барып басабыз — ми тартмаларын зыңгылдатып чытырдый, бусына барып басабыз — тагын да катырак чытырдый. Яшен яшьнәгән саен, агач ботаклары арасыннан елтыр-елтыр очкыннар коела, һавадан яңгыр аралаш ут ява диярсең.

Яшенле яңгырдан куркуымны сер итеп кенә чиштем мин сезгә. Моны берәү дә белми авылда. Дус малайларны әйткән дә юк инде. Әти дә, әни дә белми. Хәтта үзем дә белмәмешкә салышам кайчагында. Ие, нәкъ әнә шул белмәмешкә салышуым харап итте дә инде мине.

Кояш кыздырып ук күтәрелде ул көнне офыктан... Абый күк байталын җигеп кайткан. Станциягә бара икән. Кибеткә көнбагыш мае алып кайтыргамы шунда. Мин ул кадәресе белән кызыксынып тормадым.

Алдымдагы ботканы ике кабып бер йоттым да тизрәк капка төбенә чыктым. Күк байталның муеннарын сыйпаштыргаладым, маңгаендагы йолдызына бармак очы белән басып карадым.

Озакламый капкадан абый да килеп чыкты. Өске ирене катыкка буялган, йөзе җитди, кулында олы бияләй. Сиздерми генә янына барып, буемны үлчәп карадым. Миннән әллә ни калку түгел. Булса, шул, бер карыш чамасы зуррактыр.

Әһе, аркалыгын җилтерәтеп күтәрде, тезгенен тәртә башына бәйләп куйды, кепкасын басыбрак киде һәм иске пинжәк җәелгән хуш исле люцерна өстенә менеп утырды. Мин дә җирдә түгел инде, мин дә арбада.

Кузгалып киттек. Әни, гадәтенчә, тәрәзәдән карап калды. Менә минем олы улым Харис нишләтә, дип, абыйны

мактый торгандыр инде эченнән генә. Мактасын соң! Мактамагае!

Арба артыннан җиңелчә генә тузан күтәрелә, тәгәрмәч кыршаулары елтырый, күк байтал авызлык тимерен чылтырата-чылтырата, башын чайкый-чайкый юырта.

Авыл башындагы борылыштан өч тирәк калкып чыккач, мин зәп-зәңгәр күк гөмбәзенә күтәрелеп карадым да, сүз юктан сүз булсын дигән шикеллерәк кенә, абыйга эндәштем.

— Син ничек уйлыйсың, яңгыр явар микән бүген?

Абый да һавага күтәрелеп карады. Маңгаен җыерды һәм, артык исе китмичә генә:

— Белмим, бик кыздыра, — диде.

— Кыздырса, ни булган?

— Кыздырса, яңгыр яварга, диләр.

— Яшенләпме?

— Мин каян белим. Болай кыздыргач, яшенләп явар, мөгаен.

— Явар инде шундый аяз көнне! — дидем мин үҗәтләнеп. — Кичә дә, өченче көн дә кыздырды, бер дә яумады әле.

Абый минем яккарак борылып утырды. Күзләремә мыскыллабрак карап:

— Нишләп әле тиктомалдан гына яңгыр белән кызыксына башладың? — диде. — Сиңа яуса ни дә, яумаса ни?! Барыбер кыр капкасыннан ары китмисең.

— Китмәс инде! — дип элеп алдым мин. — Теге вакыт, яшенле яңгыр яуганда, кем җиләк җыеп кайтты урманнан?

— Кайттың дөнья бетереп үкереп елый-елый...

— Бер дә еламадым, бер дә еламадым. Яңгыр тамчылары күз яше булып күренгән сиңа.

— Еласаң ни дә миңа, еламасаң ни! — диде дә абый һәм, капыл гына дилбегәсен тартып, атын туктатты. — Төш арбадан!

Мин тирә-ягыма карап алдым. Авылны чыгып, өч тирәк янына килеп җиткәнбез, имеш.

— Төш арбадан! — дип кабатлады абый тавышын күтәрми генә.

— Ә төшмәсәм?!

— Яңгыр явачак бүген, күрәсең, ничек кыздыра.

— Яуса!

— Яшенләп явачак.

— Яшенләсен! — дидем мин, абыйның күзләренә чекрәеп караган килеш.

Шуннан соң абый: «Төшмә, алайса, утыр», — дип әй-

тергә тиеш кебек иде миңа калса, һәм мин: «Юк инде, юләрне башка җирдән эзлә», — дип, арбадан сикереп төшеп калырга тиеш идем. Ләкин абый һич көтмәгәндә дилбегәсен каерып торып болгап җибәрде — күк байтал ярсып алга ыргылды, мин арба артына авып киттем.

Шул хут белән солы басуын да чыгып киттек, бодай кырына да барып кердек. Мин, еларга да, еламаска да белмичә, арба дыңгырдаган көйгә сикергәләп бара бирдем.

Нык ачуы килгән абыйның. Миңа күз дә салмый. Юлында тирән упкын пәйда булса да туктатмас, мөгаен, атын.

Китте баш, калды муен утырып! Сер бирмәскә кирәк инде хәзер абыйга. Ерак үрләр артында станция биналары да шәйләнә бугай. Көннең дә болытлар исәбе сизелми, бәхеткә каршы. Эшләр болай тәгәрәсә, исән-имин барып җитеп, исән-имин әйләнеп тә кайтырбыз әле, шәт.

Нур өстенә нур дигәндәй, бераздан абыйның да ачуы басылды. Күк байталны тыя төште, дилбегәсен тез өстенә салды, картуз астыннан гына сөзеп карап, миңа эндәште:

— Керебрәк утыр, чалбарыңны дегеткә буйыйсың.

Чалбар буялудан түгел, егылып калуымнан куркып әйтте бугай абый бу сүзләрне. Һәрхәлдә, мин шулай аңладым һәм, карышып-нитеп маташмыйча, арба түренәрәк шуыштым.

Станциядә эшне тиз тоттык. Май мичкәсен авыш бүрәнәләр буенча үлчәүгә тәгәрәтеп кертү дә, үлчәүдән арбага тәгәрәтеп менгерү дә бик җайлы икән баксаң.

Абый кәгазьләргә кул куйдырырга кереп китте, мин күк байталны люцерна белән сыйлый тордым.

Кайтыр юл әйбәт кенә булыр кебек иде башта. Килгәндәге кебек үк җилдермәсә дә, ярыйсы гына юыртырга керешкән иде күк байтал. Әмма бермәлне салкынча җил исеп куйды, бодай кыры өстеннән олы күләгә шуышып үтте. Әле боларына артык исем китмәгән иде, инде баш очында ялтырап торган кояш дөрен генә тоныкланып калгач, дерт итеп киттем һәм тирә-ягыма күз салдым.

Әнкәчем лә! Нәкъ без менәсе үр артыннан, итәкләре көлсуланып-күгелҗемләнеп, дегет кебек кара болыт күтәрелеп килә. Кара, ничек зурая, кара, чит-читләре ничек кайнашып бөтерелә.

Әллә абый бөтенләй күрмичә дә утыра инде. Мин, кипкән иреннәремне ялый-ялый, абыйның кабыргасына төрттем.

— Ни бар? — диде абый, ачу китергеч тынычлык белән.

— Яңгыр!..

— Булса соң, шикәр түгел, эремәбез, — диде абый, минем якка күз дә салмыйча.

Әрүен эремәбез дә дип уйлый башлаган гына идем, чытыр-р-р! Айкалып-ургылып килгән болытлар кинәт миңгә тетелеп киткәндәй булды. Күкнең әллә ничә урыннан җиргә таба утлы сөңгеләр кадалып төште.

Бөтен уйларым чәлпәрәмә килде. Зур ачылган күзләремне кая яшерергә белмичә калтыранып утырдым да ахыр чиктә башымны абый аркасына терәдем. Бәрәңге, катык, май исе килә иде абыйның иске пинжәгеннән. Бер мизгелгә хәтта күңелем тынычланып киткәндәй булды.

Әмма ул да түгел, тагын чытыр-р-р! Баягыдан да хәтәррәк булды монысы. Хәтта арбадагы мичкә яңгырап җавап бирде чытырдауга.

Җил, изүемнән кереп, күлмәгемнең аркасын ертып алырга теләгәндәй, ярсыды да ярсыды. Акрын гына күзләремне ачып һавага карадым. Теге куркыныч болыт нәкъ безнең баш очына килеп җиткән. Хәзер ул баягы шикелле чем-кара түгел, азрак сыекланган, солы басуы төсенә кергән. Ә үзе киңәйгәннән-киңәя бара. Озакламый ярты күк гөмбәзен каплап алачак.

Кара, җил нишли. Кара инде, бодай кыры ничек айкала. Кара инде, үр өстеннән болайга таба төшеп килүче пәри туеның котырынуын!..

Йөзгә, күзләргә башта тузан килеп сыланды, аннары тузан дымланды, юешләнде, һәм без күз ачкысыз су ташкыны эчендә калдык. Күлмәк, минут эчендә манма су булып, тәнгә ябышты. Безнең баш очында гына юан агач сынгандагы шикелле чытырдаулар секунд саен кабатланып тора иде инде.

Мин, абыйның пинжәк чабуына башымны тыгып, мышык-мышык еларга, шыңшырга тотынган гына идем — бөтенләй якында гына коточкыч шартлау ишетелде. Күк байтал пошкыра-пошкыра атлаган җиреннән лып туктап калды, басуга таба каерылыбрак шомлы итеп кешнәп куйды.

— Абый! — дип чәрелдәдем мин, юл буеннан һавага утлы багана сузылып менгәнен күргәч. Икенче мизгелдә генә абайлап алдым — басу читендәге ялгыз караманы яшен суккан, һәм ул, ялкынга, төтенгә уралып, көек исе чыгара, хәтәр тавышлар белән чыжлый иде.

— Абый! — дип чәрелдәдем мин тагын бер мәртәбә һәм, үз-үземне белештермичә, арбадан сикереп төштем дә, тирә-юньдәге куркыныч тавышларны, күренешләрне күрмәс-ишетмәс өчен, юл буендагы ызанга йөзтүбән капландым. Ызан төбеннән күбекләнеп гөрләвек ага иде. Тик мин аңа игътибар итмәдем.

Бермәлне кемдер иңемә кагылды. Абый икән. «Әйдә

арба астына», — диде ул йомшак кына. Күзләремне ачып карама ягына борылдым. Карама хәзер ялкынланып янмый, пыскып, төтенгәме, паргамы уралып, тоташ яңгыр пәрдәсе аша агарып кына күренә иде. Аннары юлга күзем төште: абый, кай арададыр күк байталны туарып, тезген очын арба үрәчәсенә бәйләп куйган, үзе һаман мине йолыккалый. «Тор әйдә! Яңгыр агызып китә ич үзеңне, нишләп ятасың», — ди.

Абый мине, өстерәп, төрткәләп дигәндәй, арба астына алып керде. Иңемә лычма су булган иске пинжәген япты һәм, майкадан гына калган килеш, арба астыннан тышка сузылып карады.

— Болыты сыекланды, уза, — диде ул һәм, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә теләгәндәй, бераз уйланып утырды. Кепкасын салды, аны әни кер сыккандагы шикелле бөтереп сыкты да минем башка чәпәде. Шул чагында гына мин аның күзләрендәге курку билгеләренә игътибар иттем, ул миңа абый булганга гына куркуын яшерергә тырышуын һәм яшерә алуын аңладым.

Әгәр дә абый урынында мин булып, минем урында кечкенә энекәшем булса?.. Әйе шул, мин дә нәкъ абый шикелле тыныч тотарга тырышыр идем үземне. Мин әнә шулай уйладым һәм нәүбәттәге яшен җиргә төшеп югалганчы керфек тә какмый карап озаттым.

## КЫР КАЗЫ

Кыш бабайның ак туны тәмам искерде, ала-кола булып калды. Иңкү аланнарга җәелгән кар суы яз кояшында көмеш көзгедәй булып ята. Ә кыр казлары ерак сәяхәттән кайтып та килә. Алар, өчпочмаклы тигез сафларга тезелеп, үзләре туып үскән тымызык күлләрне, кеше йөрми торган тын аланнарны эзләп очалар.

Кайтып төшү белән әнкә каз эшкә тотына: су уртасында калган берәр калкурак урынга, чытырмандай куаклар төбенә оя кора башлый. Ул аны төрле чыбык-чабыктан, корыган камышлардан әмәлли. Күкрәгеннән йолкып мамык-йоннарын да түши. Шунда дистәгә якын эре, яшькелт йомыркалар сала. Аннары, кайнар шәрә түше белән булачак бибиләрен җылытып, айга якын урыныннан купмый утыра. Ә әткә каз, төнне көнгә ялгап, оя тирәсендә сакта тора. Әгәр якын-тирәдә берәр хәтәр җәнлек яки ау эте күренсә, «гак» дип, бу хакта хәбәр сала. Сак бул, тынычны чыгарма, янәсе.

Менә беркөнне, бер үк сәгатьтә диярлек, әллә ничә йомырка борынлап, әллә ничә биби-бәбкә борын төртә. Әнкә каз, шатлыктан ни кыланганын белмичә, уңга-сулга боргалана, «га-га-га» дип, йомшак тавыш белән үзенең нәниләренә дәшә, аларны назлый, иркәли.

Әниләренең җылы канаты астында бераз кипшенгәч, йоп-йомшак хәтфә йомгаклар тәгәрәшеп суга төшәләр дә йөзеп китәләр. Ә эткә каз, аларны хәвеф-хәтәрдән саклап, иң арттан бара.

Шундый кайгыртучан эти-әниләре тәрбиясендә бәбкәләр күзгә күренеп үсәләр, бер айдан үсмер казлар булып җитәләр. Җылы күлләрдә, сай урыннарда сыйланыр сый — татлы тамыр, төрле бөҗәкләр, симез чукмарбашлар күп. Бераздан кырларда борчак, клевр кебек кыяклы азыклар да өлгерәчәк. Иртә-кич, шул басуларга очып, тәнгә көч җыярга, канат чыныктырырга була. Ямьле җәй узып бара, җилле-яңгырлы салкын көз якынлаша, җылы якларга очар вакытлар җитә.

— Кыйгак-кыйгак, юллар ерак!..

# СӨЗГӘК ТӘКӘ

Әхнәф карават астыннан башын чыгарды.

— Апа, яшен яшьнәмиме инде?

— Ят әле бераз, яшьни, — диде Әхнәфнең апасы, мыскыллы тавыш белән.

Әхнәф, күзләрен челт-челт йомгалап, тәрәзә янына килде.

Көн чалт аяз, тәрәзә артында чыпчыклар чыркылдаша иде.

— Апа, мин уйнарга чыгам...

— Ничек чыгасың, казлар ишегалдында бит, — диде дә Әхнәфнең апасы тагын көлемсерәде, — ата каз кемне тешләргә аптырап йөри анда.

Әхнәф апасының эчтән генә көлүен сизде, әмма сер бирмәскә тырышты. «Һәй, курыккан бар иде ата каздан», — дигән булды.

Ишегалдында, чыннан да, казлар каңгылдаша иде. Әхнәф, ишекне ачаргамы, юкмы дип, берничә минут чоланда икеләнеп торды. Ниһаять, тәвәккәлләде. Чолан ишеге ачылуга, ата каз, муенын сузып, яңгыр суларына чап-чоп баса-баса, бик яман ысылдап, Әхнәф өстенә килә башлады. Ишекне шартлатып ябып куясы килсә дә, түзде Әхнәф. Әнә Идрис агай да сугышта пулеметыннан дошман

якын килгәч кенә ата торган булган бит. «Кил әле, кил. Ысылда. Муеныңны ишеккә кыстырып куярмын менә!»

Хәер, ата каз акыллы икән. Муенын ишеккә кыстырасы килмәде. Әхнәф янына килеп җитәргә ярты адымнар калгач, башын югары күтәрде, ишек артында кем дә батыр дигәндәй, канатларын җилпеп каңгылдап алды һәм, кырын күз белән Әхнәфкә карый-карый, гаиләсенә таба китеп барды.

— Әһә, курыктыңмы! — диде Әхнәф, җирдә яткан тал чыбыгын кулына алып. Ата каз тагын бер мәртәбә каңгылдап куйды. Аннары тагарактан су эчәргә кереште. Ул арада Әхнәф җил капкадан исән-имин урамга чыгып ычкынды.

Ни галәмәттер инде — өйдә дә, урамда да Әхнәфне «куркак» дип хурлыйлар. Әйтерсең үзләре бер дә курыкмый инде. Идрис агай әйтмешли, һәркемнең җаны кадерле. Вәт Идрис агай кеше ичмасам!.. Мыскыл итеп ник бер сүз әйтсен Әхнәфкә! Күргән саен, «батыр егет» дип, аркасыннан сөеп уза. Ә малайлар «куркак» дигән булалар, үртиләр. Көтү кайтмаса да, көтү кайта, дип кычкыралар. Көтү кайтса, куркыныч инде анысы. Һәрвакыт көтү алдыннан коточкыч кыяфәтле сөзгәк тәкә кайта. Күзләрен һәрвакыт кан баскан булыр. Ул әкәм-төкәмгә охшап бөтерелгән мөгезләрен күрсәң! Юлында нинди җан күрә — тузан туздырып йөгереп бара да дөпелдәтеп сөзә. Бервакытны хәтта каршысына килгән тракторны сөзгән, диләр. Шул тәкә белән нигә бер Әхнәфне генә үртиләрдер малайлар! Үзләре бер дә курыкмыйлар диярсең! Сарык көтүе кайта башласа, урамда җил себергән кебек була анысы...

Әнә Идрис агай тагын бүрәнә өстенә чыгып утырган. Уңган гимнастеркасы мендәр кебек кабарып тора. Әллә күрми инде бу юлы Әхнәфне? Күрде. Күзләре яктырыбрак, нурланыбрак киткәндәй булды.

— Кил, утыр, Әхнәф улым. Ял итеп ал бераз.

Әхнәф сүзсез генә Идрис агай янына барып утырды. Карт белән малай бүгенге яңгыр турында, ата каз турында, печәннәре җиткән болын турында әңгәмә корып җибәрделәр. Шулай ипләп кенә сөйләшеп утырганда, рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, Әхнәфнең уена әлеге сөзгәк тәкә килеп керде. Керде дә бөтенләй җан тынычлыгын алды малайның.

Шунда ул үзе дә сизмәстән картка эндәште:

— Идрис агай!

— Нәрсә, Әхнәфетдин?

— Син дә куркасыңмы сөзгәк тәкәдән, Идрис агай?

— Юк, курыкмыйм, Әхнәфетдин. Әллә син куркасыңмы?

— Куркам шул.

— Ә син, Әхнәфетдин, курыкмаска өйрән. Курыккан саен куркыта ул куркаклык.

— Ә сугышта, Идрис агай?

Идрис агай аңламады, ахры, сораулы караш белән Әхнәфкә текәлде.

— Сугышта куркынычмы, дим.

— Ә-ә-ә, син аны әйтәсең икән. Сугышта да курыкмаска кирәк. Курыкмасаң — җиңәсең, курыксаң — җиңеләсең... Бервакытны шулай Рязань егете Сергеев белән безгә дошманны бер сәгать тоткарлап торырга куштылар. Сүзем ялган булмасын, әллә алты, әллә җиде тапкыр чигендердек инде без аларны. Менә шулай аркылы-торкылы кисәбез генә ике пулемет белән. Керер тишек тапмыйлар. Тәмам җеннәре котыргач, тегеләр безнең өскә танк җибәрде. Без Сергеев белән баш кагышып алдык. Соңгы чиккә кадәр көрәшәбез дигән сүзебез иде бу. Менә танк коры елганы да үтеп чыкты. Тавышыннан җир селкенә. Түбә чәчләре үрә тора. Пушкасыннан ут бөркеп, бездән ерак түгел бер нарат агачын да урталай кисеп төшерде бу. Пулеметтан атудан мәгънә юк. Тимергә борчак белән бәргән кебек кенә. Ул чагында яшь бит әле без. Әй торып йөгерәсе килә. Йөгерергә ярамый. Гранаталар бәйләмен кочаклап җирдән күтәрелә башладым. Сергеев йодрык күрсәтте. Ашыкма, янәсе. Ә танк инде бөтенләй якын. Котырган ерткыч кебек, ант әгәр. Әй шул вакытта җирдә түзеп ятулары! Ниһаять, Сергеев боерык бирде. Безнең гранаталар танкның кайсы җиренәдер бәрелеп гөрселдәде. Аннары тагын ыргыттык. Ут, ялкын, эрегән тимер исе, төтен... Ул арада безнең пулеметлар тагын телгә килде. Дошманның соңгы һөҗүме булган икән. Шуннан соң борыннарын күрсәтмәделәр... Ә мин сине, Әхнәфетдин, батыр егет дип йөридер идем. Ярый, мин керим әле, кояш та баеп килә. Иртәгә Бүре чокырына печән чабарга барасы бар...

Әхнәф учы белән тирләгән маңгаен сөртеп алды.

— Мине алып бармассың микән, Идрис агай?

— Барырсың, Әхнәфетдин улым, барырсың. Әниеңнән рөхсәт сорарбыз да... Барырсың...

Идрис агай кереп киткәч, Әхнәф төрле уй-хыялларга бирелеп, онытылып утырган иде. «Сарык көтүе кайта» дигән тавышка сискәнеп артына борылды. Инде тыкрыкта тәгәрәшеп уйнаган малайларның эзләре дә калмаган. Урам буп-буш. Тимер-томыр склады почмагыннан сөз-

гәк тәкәнең бөтерелгән мөгезләре күренгәч, бүрәнә өстеннән сикереп торып, ярым ачык калган капкага таба элдертәсе килде Әхнәфнең. Әмма, ниндидер бер көчкә буйсынып, ул бүрәнә өстендә утыра бирде.

Сөзгәк тәкә Әхнәф турысына килеп җиткәч тукталып торгандай итте. Башын чайкап, нәрсәдер ошатмагандай, кагынып алды. Артына борылып карады һәм, тузанда тәгәрәткән йон төргәген хәтерләтеп, тыкрыкка кереп күмелде.

Көтү узып, урамда тузан басылгач, Әхнәфне иптәш малайлары уратып алды.

— Ничек курыкмадың, малай?..

— Мөгезенә элеп селкеп ата дип торам...

— Әхнәфне курка, диген... менә!..

— Әйдә, Әхнәф, безнең белән җәплекәч уйнарга...

Әхнәф, кулларын чалбар кесәсенә тыгып, сүзсез генә аяк өстенә басты. Җыелган малайларга карамыйча гына:

— Өйгә керәм әле, — диде. — Ата казны акылга утыртырга исәп, югыйсә, котырган эт кебек, кергән бер кешенең өстенә ташлана... — Әхнәф кулларын кесәләреннән чыгарды, Идрис агай кебек аркасына кушырып куйды: — Аннары иртәгә таң тишегеннән торасы була. Бүре чокырына печән чабарга барабыз...

## ТӨГӘЛЛЕК

Ял көне.

Фәритнең әнисе бәйли башлаган оегын диванга ташлады да, аш пешерәм дип, кухняга кереп китте.

Фәрит, бармакларын бөкли-бөкли, мисал чишә калды. Бераздан әнисе Фәритне кухняга чакырып алды.

— Нәрсә, әни? — диде Фәрит, кухня ишегенә башын тыгып.

— Улым, карап кына менче, базда бәрәңге бетмәде микән? Бетсә, кибеткә чыгып керермен.

Өстәл астында утырган ак песи колакларын селкетеп алган арада, Фәрит базга төшеп чумды.

Көтә әнисе Фәритне, көтә әнисе, Фәрит чыкмый да чыкмый.

— Улым, нишлисең анда? Бәрәңге әллә бөтенләй беткәнме?

— Хәзер, әни!

— Улым, әллә йокладыңмы?

— Хәзер, әни!

— Улым...
— Әй әни, оныттырасың.
— Нәрсәне, улым?
— Хәзер, әни...
— Фәрит, дим, улым...
Менә берзаман баздан чәч-кашлары пәрәвез җепләренә уралып беткән Фәрит килеп чыкты.
— Әни, — дип шатланып кычкырып җибәрде ул. — Әни, безнең базда әле тагын 647 бәрәңге бар.

## ЛИКАНДР

Бу вакыйганы, Яңа ел кичәсенә җыелгач, аксыл чырайлы, юка иренле, кызларныкы кебек дугаланып торган кара кашлы егет — мастер Галәү сөйләде.
— Ул безнең авылга кайчан килеп чыккандыр, хәтерләмим. Хәзер кая яши торгандыр, анысын да белмим. Тик аның Ликандр атлы булуы бик ачык истә калган. Халыкына шулай бозып әйткәндер аның исемен. Кем ул? Нинди милләт кешесе? Бу сорауга да ачык җавап биралмам.
Аны кайберәүләр Белоруссиядән, кайберәүләр Украинадан килгән, дип сөйләделәр. Кайсы дөрес булгандыр, анысы әһәмиятле түгел. Әмма шунысы хак: Ликандр урман каравылчысы булып эшли иде.
Олылар арасында: «Ликандр фәлән абзыйның чанасын ваткан икән, фәлән апайның бауларын тураган икән, агач кискән өчен фәлән кешеләрне судка биргән икән», — дип сөйләсәләр, малайлар арасында: «Ликандр фәлән малайның бер капчык чикләвеген алып калган икән, яшь имәнлектә җиләк җыйган өчен, фәлән малайның колагын борып җибәргән икән», — дип сөйлиләр иде. Янәсе, ул аксак булса да, хәтсез тиз йөри икән, шүрәленекедәй озын кулларын куаклар аша гына сузып, җиләкме, чикләвекме җыеп йөргән малайларның икешәр-өчәрен берьюлы эләктереп ала икән.
Күрше малае җирән Әхнәф миннән олырак та, батыррак та булгач, мин аның белән чикләвеккә бер дә курыкмыйча йөри торган идем. Әмма ул Яңа ел алдыннан: «Чыршы кисеп кайтыйк», — дип, безгә кергәч, мин шүрли калдым.
— Ә Ликандр?..
— Булса соң, күргәнем юк, дисең ич, күреп кайтырсың.
Әхнәф беравык миңа сынап карап торды һәм минем шүрләгәнне сизде, ахры, юаткан сыман итеп өстәп куйды:

— Котың очмасын ла шуннан, аксак ич ул. Әллә аңа тоттырып торырбызмы?

Ниһаять, мин күндем, без тиз генә җыенып юлга чыктык.

Аяк асты бозлавык, күктә көлсу болытлар — кар болытлары. Әмма әйләнә-тирә ниндидер җайсызлык, бушлык белән өртелгән.

Чыршылыкка килеп кергәч, тирә-як тагын да шомлырак булып китте. Урман да тын. Әхнәф урманнан да тынрак. Берәр сүз дәшсен иде, ичмасам. Инде шактый җир киттек. Ә алда һаман да очсыз-кырыйсыз караңгылык, һәм, үзара тар гына коридор хасил итеп, оеп утырган рәт-рәт чыршылар.

— Яшь чыршылыкка килеп җитәбез, — дип хәбәр итте Әхнәф. Һәм, кулын артына җибәреп, бишмәт астыннан пистолет кебек кабарып торган пычкысын капшап куйды.

Инде мин, уңга да, сулга да, артка да карамыйча, күзләремне Әхнәф аркасына гына текәп бара башладым. Ләкин Әхнәф, кинәт иңнәрен җыерып, бер урында катып калды. Аннары тиз генә мине ботакларын җиргә үк тидереп үскән чыршы төбенә тартып кертте дә кипкән иреннәрен чак кына тирбәндереп пышылдады:

— Ликандр!

Мин коелдым да төштем. Түбә чәчләрем бүрекне күтәрерлек булып тырпайдылар, аркам буенча бозлы шарлар тәгәрәшеп үткәндәй булды. Тез буыннарым, тотрыксызланып, берөзлексез дерелди башлады. Үзем бер туңдым, бер кызыштым, шулай да, тотлыга-тотлыга:

— К-кая? — дидем.

Әхнәф ияге белән ымлап күрсәтте.

Бездән берничә адымда гына, башын иеп, озын буйлы бер кеше басып тора иде. Өстендә кыска тун. Аның аяк астында төбеннән үк кисеп аударылган яшь чыршы ята. Аны, ахрысы, әле күптән түгел генә аударганнар: кәүсәнең киселгән җире гөмбә эшләпәсе сыман агарып күренә.

Әхнәф, ишетелер-ишетелмәс кенә: «Чыршы кисүчеләрне эләктерә язган бит бу», — дигәч, мин тагын да яманрак дерелди башладым. Әхнәфкә җавап кайтарырга да көчем җитмәде, җайсыз басылган уң аягымны да урыныннан кузгата алмадым.

Шулай байтак катып торгач, әлеге кеше җиргә чүгәләде һәм киселгән чыршыны, саклык белән генә күтәреп, төбенә утыртып маташты. Әмма чыршы, ул торгызып куйган саен, әле бер, әле икенче якка кыйшайды. Әлеге кеше дә, чыршы кыйшайган саен үчегә барып, чыршыны

төбендә озаграк тотып тора башлады. Бермәлне (әллә ул тигезлек саклый алды, әллә башка берәр сәбәп аркасында) яшь чыршы кыйшаймый-нитми урынында утырып калмасынмы. Әйтерсең лә һич тә пычкы-мазар кагылмаган. Бу искиткеч күренешкә әлеге кеше үзе дә гаҗәпләнде булса кирәк: аптырап йөзен безгә табарак борды һәм киң итеп елмайды. Шулкадәр сәер балкыды урман ешлыгындагы бу елмаю. Әмма, елмаюыннан бигрәк, мине аның йөзе таңга калдырды. Бер генә тамчы усаллык галәмәте дә күрмәдем мин аның йөзендә. Чал йөгерә башлаган кара мыегында, кылыч борынында, салынкы кабаклы йомшак күзләрендә кешене үзенә тарта торган яшерен көч, серле матурлык бар иде аның. Миңа җиңел булып китте. Күкрәк читлеген бәреп чыгардай булып типкән йөрәгем урынына утырды, җайсыз басылган аягымны да кузгатып куйдым. Хәтта бияләй башын иреннәренә куеп тынып калган Әхнәфтән шыпырт кына:

— Чыннан да Ликандрмы бу? — дип сорарга да кыюлыгым җитте.

Әхнәф раслап баш какты.

Шул чагында теге, кем әйтмешли, Алланың кодрәте белән генә аягүрә басып торган чыршы, саңгырау гына сызгырып, яңадан алан уртасына авып төште. Шуның белән бергә Ликандр күзләрендәге әлеге серле матурлык та сүнде. Хәзер аның күзләре сагышлы, юк, алай гына да түгел, кайгылы, газаплы иде. Бу юлы ул җирдә яткан чыршыны күтәреп азапланмады, уң аягына аксаклыйаксаклый, өстенә калын боз каткан каен төбенә барып утырды. Нәрсәдер хәтерләргә тырыша идеме ул, нигәдер кайгыра идеме — йөзе бер җитдиләнде, бер уйчанланды.

— Кисеп булмас, ахры, — дип пышылдады Әхнәф.

— Сызыйк моннан яхшы чагында, — дидем мин, Әхнәфнең сүзен куәтләп, һәм йөгерергә әзерләндем.

Әмма алан ягыннан килгән тавыш безне яңадан Ликандрга карарга мәҗбүр итте.

Мин ни өчендер (ләкин бу юлы куркудан түгел) тагын эсселе-суыклы булып киттем. Ликандр тагын теге чыршы янына килеп баскан иде. Уң кулын салмак кына ылыслар өстендә йөртә. Әйтерсең лә мәче баласын иркәли. Каяндыр еракка, агач башларына төбәлгән күзләрендә тирән, әйтеп бетергесез тирән кайгы. Менә ул ни өчендер башын селкеп куйды, салынкы кабаклы күзләрен алан уртасында атылган бөркет шикелле канатларын җәеп яткан чыршыга төбәде, көрсенде һәм тагын башын селкеде, тагын көрсенде. Сәер һәм кызганыч иде бөтен районга «усал» дип аты таралган кара мыеклы бу озын кешенең

япа-ялгыз урман уртасында шулай әсәрләнеп торуы. Без Әхнәф белән бер-беребезгә карашып алдык та, кисәк кенә урыннарыбыздан кубып, тәмам сулышларыбыз капканчы йөгердек.

— Менә барысы шул, — дип бетерде Галәү үзенең хикәясен. — Шул вакыйгадан соң Ликандрдан курыкмый башладым. Хәзер берәр җирдә киселгән яшь чыршы күрдем исә, күз алдыма урман уртасында кайгырып торучы шул озын кеше килеп баса.

## ӘНФИСӘ КЕМГӘ ЕЛМАЯ?

Әлегә кадәр тыныч кына яшиләр иде безнең йорт малайлары. Тавыш юк, гауга юк, көнләшү юк. Гомумән, һәркем үз эшендә, һәрни үз урынында. Һәркемнең дусты яисә иптәш малае бар. Телисең икән, кызлар белән дуслаш. Бергә кинога, мәктәпкә бар. Бер партада утыр. Әнә, мисал өчен, озын Мидхәт өченче каттагы җирән Улина белән, ә управдом малае — кечкенә буйлы, ябык чырайлы, әмма ут ташы кебек чая Габделбәр — елак Нәҗибә белән бер партада утыра.

Тик көннәрдән бер көнне һич көтмәгәндә икенче каттагы моңарчы бер ялгыз карчык кына яшәгән зәңгәр балконлы квартирага сумаладай кара мыеклы, хәрбиләрчә мәһабәт сынлы запастагы полковник кайтып төште. Кайтып төште дип, үзе генә булса, бер хәер иде. Ялгызы гына түгел шул. Үзе кебек ак йөзле, почык борынлы, якты кара күзле Әнфисәсе белән. Анысы бик җентекләп үтүкләнгән кара итәктән, нәфис ак муенын кысып торган зәңгәр якалы матроскадан.

Менә шул кыз кайтканнан бирле безнең йортта малайлар белән кызлар арасындагы дуслык чәлпәрәмә килде. Мидхәт тә иң арттагы партада үзе генә утыра башлады. Малайлар кызлар белән генә түгел, хәтта үзара ачылып китеп сөйләшми башладылар. Бер дә юктан тавыш, бәхәс чыккалый торды. Полковник кызына әһәмият бирмәгән бер генә кеше — ул да булса кечкенә Габделбәр иде. Ул һаман да иң алдагы партада үзенең елак Нәҗибәсе белән утыра иде.

Әллә ялга гына, әллә бөтенләйгә кайтты инде полковник. Малайлар ул кадәресе белән кызыксынмадылар. Ә менә Әнфисә турында күбрәк беләселәре килде.

— Эх, малай, скрипка уйнаганын тыңлап тордым. Вәт уйный...

— Дөрес булса, менә дигән җырчы, ди ул.
— Балерина, ди.
— Ә мин шигырь яза икән, дип ишеттем.

Хәер, Әнфисәнең кем булуыннан бигрәк, малайларны аның елмаюы гаҗәпләндерде. Әллә ничек кенә, бит урталарын чокырайтып, зур кызлар төсле серле итеп, матур итеп елмая иде ул. Шуңа күрә малайлар һәрвакыт, нинди дә булса кызык ясап, аны елмайтырга тырышалар. Бу турыда бер-берсенә ләм-мим сүз әйтмәсәләр дә, әлеге теләк аларның күз карашларыннан, кыланышларыннан сизелеп тора.

Тик Әнфисәне елмайтырга тырышып егетлек күрсәтүләр әледән-әле кабатланып торса да, ул көзне полковник кызы бер малайга да елмаймады.

Кышын Әнфисә өйдән сирәк чыкты. Чыкса да, кулына скрипка тартмасын тотып, таркау, битараф бер кыяфәт белән каядыр китеп югала торган булды.

Ә ял көннәрендә алар әтисе белән чаңгы шуарга йөриләр иде. Өстенә калын йон свитер, башына ал башлык кигән Әнфисәне шәһәр читендәге Газинур тавында малайлар ул кышны ял саен диярлек очраттылар.

Аннары яз килде. Декабристлар урамындагы өч катлы йортта яшәүче малайлар аны үз мәшәкатьләре, үз ыгы-зыгылары белән каршы алдылар. Йорт каршындагы каен ботакларына өр-яңа сыерчык оялары тезелеп китте, урам яктагы өрәңге башлары тигез итеп кыркылды, телевизор антенналары беркетелгән торбалар аяз күк төсенә буялды.

Ә инде шушы йорт яныннан ук шәһәрчекне урталай бүлеп аккан исемсез инештә боз кузгалгач, малайлар да, кызлар да, бүтән язлардагы кебек, баш-башларына чылбырлы тимер баганалар утыртылган бәләкәй күпергә җыела торган булдылар...

Беркөнне күпергә, болай да ал йөзен тагын да алсуландырып торган ал башлыгын киеп, Әнфисә дә төште.

Кайбер малайлар, аны күргәч үк, зур, тоташ болыттан аерылып киткән нәни болыт кисәге шикелле, күпернең икенче башынарак авыштылар һәм, гадәттәгечә, бер-берсен уздыра-уздыра ярышырга керештеләр. Аларның, Әнфисәне елмайтыр өчен, берсеннән-берсе җитезрәк булып күренәсе килде. Әмма Мидхәт барысыннан да уздырды. Ул күпер иңсәсенә дә башкаларга караганда озаграк асылынып торды, агып килгән бозларны да колга белән башкаларга караганда җитезрәк эләктерде.

Тик чибәр Әнфисә, аңа карап елмаю түгел, хәтта иренен дә кыймылдатмады. Киресенчә, аның каядыр инеш

борылышына текәлгән якты күзләре моңсу иде. Мидхәт башына әллә кечкенә Габделбәрне күпердән инешкә төртеп төшерим микән дигән уй да килеп китте. Кем белә, бәлки, ул Әнфисәне елмайту бәрабәренә бу уен тормышка да ашырган булыр иде. Ләкин нәкъ шул чакта батачума, әйләнә-тулгана йөзгән калын бозлар арасыннан чемкара йонлы, ак маңгайлы бәләкәй көчек агып килгәне күренде. Кызларның кайсыдыр аһ итте, малайларның кайсыдыр уңайсыз гына, урынсыз гына көлеп куйды. Чибәр Әнфисәнең йөзе агарды. Аның куе керфекләрендә яшь бөртекләре ялтыравын күргәч, Мидхәт токлы чыбыкка орынгандай сискәнеп китте.

Ул да булмады, малайлар арасыннан берәү атылып чыкты да, җәһәт кенә күперне әйләнеп, яр буена йөгереп төште һәм, үзле кызыл балчыктан тая-тая, су читенә килде.

Көчек кызганыч тавыш белән чиный һәм ишелеп аккан бозларга менәргә тырыша. Тик менә алмый: инде алгы аякларын куйды, инде сикерде дигәндә генә, әлеге боз кисәгенә тагын да зуррак икенче бер боз килеп бәрелә, көчек янә суга егылып төшә, агымга каршы борылып йөзә башлый. Тик кая ул — ак сыртлы салкын соры дулкыннар аны баштанаяк күмеп китә, бер урында бөтереп тора, бозларга китереп ора.

Су читенә төшкән малай әлеге кечкенә Габделбәр икән. Менә ул инеш буенча тагын да түбәнрәк йөгерде. Агып барган көчек белән тигезләште. Бераз гына уйланып торды да, алдындагы боламыкланган карны сөреп чыгып, тагын алга йөгерде.

Көчек инде тәмам хәлдән тайган иде, ахры: тыпырчынмый да, чинамый да, бозларга да менәргә тырышмый. Дулкыннар ирегенә бирелгән килеш, бата-калка ага да ага гына.

Күпердәге малайлар икенче караганда, Габделбәр, кызарган куллары белән ярсып килгән боз кисәкләрен читкә этәрә-этәрә, бил тиңентен суда тора иде инде.

Менә ул, агым бәреп екмасын өчен сәер хәрәкәтләр ясап, инеш уртасыннан ук агып барган эт баласын эләктереп алды да ярга ташланды. Ләкин ярга чыгып җиттем дигәндә генә, әллә таеп китте, әллә яр буенда чәчелеп яткан боз кисәкләренә абынды, кинәт футбол кырында туп кочаклап ауган капка сакчысы сыман, эт баласын кочаклап, бөтен гәүдәсе белән су читенә капланды. Аның аякларына бозлар килеп бәрелде, гәүдәсе аша дулкыннар сикереп үтте.

Күпердәге малайлар, дәррәү кубып, инеш буена йөгерделәр. Габделбәр янына беренче булып барып җиткән

кеше — Әнфисәнең әтисе — кара мыеклы полковник иде. Ул Габделбәрне тиз генә яр читенә тартып алды да, күз ачып йомганчы юеш киемнәрен салдырып, аңа үзенең озын шинелен бөркәде.

Әнә инде алар дүртәү — кара мыеклы полковник, офицер шинеленнән ике күзе генә елтырап барган Габделбәр, тузгыган чәчле Әнфисә, аның кулында йомшак ал башлыктан дерелдәп торучы ак маңгае гына күренеп барган көчек — күпергә якынлашып киләләр. Чибәр Әнфисә бер үз кулындагы эт баласына, бер әтисе шинеленнән елтырап барган күзләргә карап бәхетле елмая.

Әй матур иде дә инде бу елмаюлы йөз. Белмим, малайларның кайсы гына шул зәңгәрсу офицер шинеле эченнән Әнфисәнең нурлы йөзенә карап барырга теләмәде икән!

## СУГЫШЧАН БУРЫЧ

Әгәр дә Нәбир математикадан икеле алып кайтмаса, бу хикәягә Мәгълүмә әби кирәргә тиеш түгел иде.

Икелегә килгәндә, монысы беренче чиректә Нәбирнең өченче икелесе инде. Нәбир рус теленнән икеле алгач, мәктәпкә аның әтисен чакырттылар, язма эштән икеле алгач — әнисен. Бүген аларның кайсын чакырганнардыр — әлегә билгесез.

Әнә Нәбир кызарып кайтып керде дә, борынын тартатарта, сүзсез генә чишенде. Әлмәттән кунакка килгән Мәгълүмә әбисенең ягымлы сүзләренә дә игътибар итмичә, кухняга узды.

Бераздан Нәбирнең әнисе дә кухняга керде. Улының өреп тутырылган шардай түгәрәк кызыл йөзенә, сизелерсизелмәс кенә пар чыгып торган йомшак чәчләренә сынап карап торды. «Тагын икеле алдыңмы?» — дип сорады.

Нәбир раслап баш какты. «Әни, класс җитәкчесе Сәкинә апа сине чакырды», — диде.

Әни кеше, беркавым ни әйтергә белмичә тынып, аптырап торгач:

— Нәрсә җитми сиңа, малай актыгы, нигә укымыйсың?.. Тамагың тук, өс-башың бөтен, китап-дәфтәрләрең җитәрлек, — дип, гадәттәге битәрләү сүзләрен тезеп китте. Шулай ук гадәтенчә: «Әтиең кайтсын әле менә!» — дип кисәтеп куярга да онытмады.

Әнисенең сүзләрен әллә ишетте Нәбир, әллә юк —

аннан-моннан әштер-өштер кайнар токмач капкалады да, өс-башын киенеп, агач мылтыгын асып, бәрелә-сугыла ишеккә ташланды. Чыгып барышлый аның: «Әни, мин уйнап керәм әле, дәресләрне аннары әзерләрмен», — дигән ваемсыз сүзләре генә ишетелеп калды.

Тышта саргаеп, кызарып килгән өрәңге яфраклары, тәрәзә рамнарына ышыкланып, пышын-пышын үзара нәрсә турындадыр сөйләштеләр, нигәдер тыелып кына көлделәр.

Әни кеше Нәбир чыгып киткәч тә әле озак кына улын битәрләп, сукранып йөрде. Ә Мәгълүмә әби сүзсез-нисез баш чайкап утырды.

Кичкырын Нәбирнең әнисе мәктәпкә барып кайтты. Ул ачулы иде. Нәбир уеннан кергәч, алар арасында мондый сөйләшү булып алды:

— Нәрсә диде, әни, Сәкинә апа?

— Улың ялкау, укыса укый ала, укымый гына, диде.

— Син ни дидең?

— Нәрсә әйтим, колагын борырмын, дидем.

— Ә нигә бормыйсың?

— Атаң кайтсын әле менә... Гомере озын булыр, әнә үзе дә.

— Тагын нәрсә булды, нигә шаулыйсыз?

Нәбир әтисенең пошмас-ягымлы тавышыннан сизде: давыл аны урап узачак.

— Ни булсын, әнә малаең тагын икеле алып кайткан... Тагын бер икеле алса, ике аягымның берсен атламыйм мәктәбенә.

— Туктале, әнисе, син генә бармыйсың лабаса, узган атнада мин барган идем. Аннары һаман-һаман балага кычкырырга да ярамый, иплəп кенә аңлатырга кирәк.

— Аңлат, нигә аңлатмыйсың. Син яклый-яклый шундый тыңлаусызга әйләнеп бара инде ул. Әле без өйдә чакта шулай...

Нәбир мондый сөйләшүләргә күнегеп бара иде инде. Шуңа күрә ул әтисе белән әнисе янында озак тукталып торасы итмәде, залга кереп телевизор кабызды.

Бу кичне әтисе белән әнисе Нәбиргә бик озаклап акыл өйрәттеләр. Мәгълүмә әби колагына әледән-әле: «Укы, улым... Дәрес хәзерләмичә барма... Иртәгә без Владивостокка Камилә апаң туена очабыз... Син монда рәтле генә йөр, кара аны...» — дигән сүзләр ишетелгәләп торды.

Иртәгесен Нәбир мәктәптән кайтканда, Мәгълүмә әби өйдә ялгызы гына иде инде.

— Киттеләрме, әби?

— Киттеләр, улым, киттеләр.

— Әби, аш!

— Әй Алла, онытып та җибәргәнмен синең мәктәптән кайтасыңны. Әйдәле, улым, бергә-бергә пешереп алыйк әле ашны. Син әнә бәрәңге әрчи тор, ә мин, газны кабызып, ашка ит юып салыйм.

Нәбир, бу нәрсә була соң әле дигәндәй гаҗәпләнеп, әбисенә текәлде, башын иеп уйланып торды. Аннары, әбисе сузган пычакны алып, бәрәңгеле табак янына килде, теләр-теләмәс кенә әрчи башлады...

— Тизрәк кыймылда, улым, аш кайный.

— Ярар сана! — дип кычкырып салды Нәбир, ниһаять, түземлеге бетеп, әбисенә тәмам ачуы чыгып.

— Ашыйсың килмәсә пешермим, сүндерәм газны.

Нәбир Мәгълүмә әбинең дистәләрчә җыерчыклар катып калган тыныч йөзенә күтәрелеп карады, ашыгыбрак әрчергә тотынды.

Ашап-эчкәч, Нәбир, гадәтенчә, кием элгече янына килде, агач мылтыгын кулына алды. Бер әбисенә, бер киемнәренә карый-карый:

— Әби, мин уйнап керәм әле, дәресләрне аннары хәзерләрмен, — диде.

— Миңа димәгәең, ник бер дә хәзерләмисең инде. Минем дәресләрмени алар?!

Гаҗәпләнүдән Нәбирнең авызы ачылып калды. Нәрсә кылана соң бу Мәгълүмә әби. Әтисе белән әнисе бер дә алай итмиләр иде ич.

— Әби, курткамның бер төймәсе төшкән, тагып бир әле, — диде Нәбир, нишләргә белмичә озак кына ишек төбендә таптанып торгач.

Мәгълүмә әби башта, бәләкәй кулы белән авызын каплап, тавышсыз гына көлде. Аннары кинәт кырысланды.

— Солдатка баргач, кем тагып бирер соң төймәләреңне?! — диде, тәрәзә яңагында эленеп торган бәләкәй мендәрчеккә төртеп күрсәтте, — әнә энә, кәтүк комод тартмасында, бик матурлап кына үзең тагып куй әле, улым, төймәңне, күрсәт әле егетлегеңне.

Нәбир, мышный-мышный, бармак очларын каната-каната, чирек сәгать чамасы төймә тагу белән шөгыльләнде. Төймә ныгыгач, җепне теше белән шартлатып өзде дә энәне өстәлгә ташлады.

— Нәбир, улым, энәне урынына кадап куй! — диде Мәгълүмә әби йомшак кына. — Солдатка баргач, мылтыгыңны төрле җиргә ташлап йөрсәң, рәхмәт әйтмәсләр.

Нәбир ачудан энәне мендәргә батырып ук җибәрде. Кызарып-бүртенеп янә кием элгече янына килде. Нәрсә турындадыр уйланып торды. Курткасын киясе итте дә,

ни өчендер кимәде. Чөйгә элеп куйды. Китап-дәфтәрләрен алып түр якка чыкты, дәрес хәзерләргә утырды.

Иртәгесен Мәгълүмә әби Нәбирне ярты сәгать чамасы алданрак уятты. Чалбары үтүкләнмәгән иде, аны үтүкләтте. Ул көнне китапларын да сумкасына үзе тутырды Нәбир, ботинкаларын да үзе чистартты. Хәер, бу хәлләр икенче, өченче, дүртенче көннәрне дә, аннары да шул көйгә дәвам итте. Нәбир өчен эш-мәшәкать белән тулы тынгысыз көннәр башланды.

Математикадан тагын бер икеле алып кайткач та орышмады әбисе Нәбирне. Шулай да: «Нигә аны миңа әйтәсең, гадәттә кешеләр бер-берсен яхшы хәбәр белән сөендерәләр, ә син, үзеңнең начарлыгыңны сөйләп, мактанып торасың», — дип, үзәгенә үтәрлек итеп әйтте.

Класста да болай оялмаган иде Нәбир, әбисе янында колакларына кадәр кызарды. Тавышы да бик мескен, бик зәгыйфь чыкты аның:

— Әби, Сәкинә апа сине мәктәпкә чакыргание.

— Нигә чакыргание, улым?

— Мин икеле алганга.

— Син икеле алганга нигә мине чакыра икән соң ул?

Нәбир дәшмәде, башын тагын да аскарак иде...

Караңгы төшәр алдыннан яшь укытучы Сәкинә Нәбирләргә үзе килде. Нәбир, кеше-кара күргәнче, урамга чыгып шылырга маташкан иде дә, Мәгълүмә әби кычкырып өлгерде:

— Улым, кая барасың, әнә синең янга укытучың килгән.

— Мин синең янга да килдем, әбекәй, — диде укытучы кыз, маңгай чәчендәге яңгыр тамчыларын кага-кага. — Нәбирнең әтисе белән әнисе, улларының кайбер дәресләргә битараф икәнен белә торып, еракка китеп барганнар... Инде бөтен җаваплылык сезгә төшә.

— Нишләп миңа төшсен, кызым! Җаваплылык Нәбирнең үзенә төшә. Зур ич инде ул безнең Нәбир. Аның яшендә бабасы, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, партизаннарга ияреп сугышчан бурычлар үтәп йөрде.

— Нишләтергә дә белгән юк инде аны, әбекәй, бүген тагын икеле алды.

— Алмасын, нигә ала? Без кушабызмыни аңа икеле алырга, әллә сез кушасызмы? Ала икән, үзе җавап бирсен. Мисал өчен әйтик, сугыш вакыты, ди. Нәбир сугышчан бурыч үтәргә тиеш. Ә ул ялкаулана, мылтыгын чистартмый яисә патроннарын онытып калдыра... Нәбир аркасында сугышчан бурыч үтәлми. Инде аның өчен кем җавап бирә? Командирмы? Иптәшләреме? Әти-әнисеме?!

Моңарчы борынын еш-еш тартып, ут кебек кызарып тәрәзә артындагы өрәңге яфракларына карап торган Нәбир, кинәт стенага борылып, мышык-мышык еларга кереште.

Укытучы Нәбирне юатырга ымсынган иде дә, Мәгълүмә әби аны бүлдерде:

— Тимә, еласын. Ояла, гарьләнә, елый белгән кешедән рәт чыга аннан...

Шушы әңгәмәдән соң ун көн вакыт узды. Әлегә Нәбирнең икеле алганы ишетелми. Тиздән аның әтисе белән әнисе кайтып җитәр. Алар кайткач, нәрсә булыр тагын?!

## НИШЛӘРГӘ ТИЕШ ИДЕМ?

Тимерчелектән чаң-чаң тимер кыйнаган тавыш ишетелә. Аягүрә басып карасаң, алачык авызын да күреп була торгандыр инде. Светлана да шундадыр, бәлки. Әтисенә салкын квас алып килгәндер. Текә сукмактан нәкъ беркөнге шикелле...

Беркөннәрдә Габделгазиз белән якын дуслар, сердәшләр идек әле без. Нәкъ менә шушы аулак урында, үзебезнең яраткан аланыбызда, хыялларга чумып утырдык. Габделгазиз, кинәт кенә аяк өстенә басып: «Үскәч мин боксер булам, сугасың... раз — егыла, икенчесенә сугасың... раз», — дип, йодрыкларын минем борын төбендә уйнатып та күрсәтте.

— Ә мин тимерче булам, — дидем мин, аннан калышмаска тырышып, — чәчәкләр, сабаннар төзәтәм, атлар дагалыйм, чиләкләр төплим, көянтә тимерләре ясыйм...

Су чупылдавын беренче булып мин ишетсәм дә, Светлана турында Габделгазиз сүз башлады ул көнне:

— Панкрат дәдәнең җирән кызы су коенырга төшкән...

— Кая? — дидем мин, як-ягыма каранып.

— Муенына тагын теге әкәмәтен таккан, — диде Габделгазиз, миннән бигрәк үз-үзенә әйткән сыман.

Мин тал арасыннан сузылып караганда, Светлана билдән суга кереп (үз шәүләсенәме, нәни дулкыннар өстендә биешкән кояш нурларынамы) сокланып карап тора иде. Көзге шәрә басуда янган учак ялкыны төслерәк кызгылтсары чәчләрен җил тузгыта. Ара шактый ерак булса да, ни өчендер аның озын ак муены, нәзек гәүдәсе калтыранып, дерелдәп торадыр сыман тоелды миңа.

Шул чагында алачык ягыннан калын, көр тавыш ишетелде:

— Светлана!

Бу, әлбәттә, Панкрат дәдә иде.

Ай күрде, кояш алды Светлананы. Буа өстендә якты бөҗралар гына ялтырашып, бер-берсен куышып калды. Бераздан Светлананың кызгылт башы таш өемнәре арасында җемелдәп күренде, аннары сукмакта... Кыр кәҗәсеннән бер дә ким түгел бу Светлана дигәннәре. Чабышларда, сикерешләрдә безнең авыл малайларының берсенә дә бирешми.

Сугыша башласак, Габделгазиз мине, әлбәттә, җиңәчәк. Ә Светлана Габделгазиздән дә курыкмый. Аннары шунысы кызык: егылып тезен сыдырса да, бармагын пыяла киссә дә еламый ул. Кайчагында хәтта мин аның турында: «Әллә бөтенләй елый белми микән бу?» — дип уйлап куям.

Бервакытны Габделгазиз тирәк очында карга йомыркалары җыю белән мәшгуль иде. Светлана моны күреп алды да: «Төшәсеңме, юкмы?!» — дип кычкырды. Габделгазиз тыңламагач, уч-табаннарын төкрекләми-нитми генә агач башына менеп китте Светланабыз. Кыр мәчесе диярсең. Югарыда ботаклар селкенде, дөнья кубарып каргалар шаулашты. Аннары яфраклар арасыннан Габделгазизнең чебиле аяклары күренде... Җиргә алар икесе дә берьюлы мәтәлеп төштеләр. Габделгазиз «әни!» дип чырылдап җибәрде. Светлана исә, иренен тешләп, чирәм өстендә тавышсыз гына бөтерелгәләнде дә, кеше-кара күргәләгәнче, аяк өстенә сикереп торды. Күз каралары йөзек кашы сыман ялтырый иде аның. Кай арада кулына нәзек чыбык сындырып алды һәм:

— Рәнҗетмисеңме кошларны, рәнҗетмисеңме икенче?! — дия-дия, Габделгазизне үрле-кырлы сикертергә кереште.

— Фәһим, — дип, минем уйларымны бүлдерде Габделгазиз, — Светлананың киемнәре су буенда калды бит.

Мин аны-моны әйтергә өлгергәнче, Габделгазиз:

— Мин хәзер... Күренмичәрәк, качыбрак тор, — диде дә куаклар арасына кереп чумды. Кыршылган чалбар төбе белән кояшта янган үкчәләре генә ялтырап калды аның.

Күп тә үтмәде, куаклар арасында Габделгазиз яңадан күренде. Кысылган учыннан нindидер ялтыравыклы әйбер чыгып тора иде аның.

— Менә, — диде, ниһаять, шабыр тиргә төшкән, сулышы капкан Габделгазиз һәм бармакларын җәеп җибәрде.

Яссы гына ике башлы бөркет, кабарынкы ягына хәрби кораб сурәте төшерелгән тәңкәне күрү белән, мин апам-

ның тарих китабын, шул китаптагы Кутузов рәсемен, аның күкрәгендәге орденнарын искә төшердем. Бавы ефәк, ахры, — кояш нурында күгәрчен каурые сыман елык-елык итеп тора. Бөтерелгән төшенә кызыл чәч бөртеге дә ияреп килгән... Светлана чәче...

Мин әле ефәк баулы тәңкәгә, әле тынычсызланып кыймылдашкан аяк бармакларыма карап торган арада, Габделгазиз бая «менә» дип башлаган сүзен ялгап китте:

— Ә хәзер бетерәбез моны. Җиргә күмәбез...

Габделгазиз сүз көрәштергәнне яратмый. Әнә әле дә колак яфраклары алсулана башлады. Яхшыга түгел бу...

Комлы җирне бик тиз казып, эшне бик тиз төгәлләп куйдык.

Тал арасындагы сукмактан авыл ягына сыпыртканда, Габделгазиз:

— Кара аны, бу хакта кешегә лыгырдасаң, үпкәләштән булмасын! — дип янап куярга да онытмады.

— Әйтмим, нишләп әйтим, бик хаҗәте бар, — дидем мин, Габделгазизнең сөякчел йодрыкларына күз төшереп алгач...

Өйгә кайттым. Салкын катыктан әйрән ясап эчтем. Ишегалдына чыгып, төш вакыт әти турап киткән утынны әрдәнәгә өя башладым.

Әйтергә онытканмын икән әле. Светланалар өе белән безнең өйне Мәйдан тыкрыгы гына аерып тора. Бермәлне шул якка күз салган идем — гомердә булмаганны Светланалар эте Полкан капка астына башын тыккан да миңа тешен ыржайткан. Йөрәгем жу итеп китте.

Утынны өеп бетергәч, ишегалдын себерергә керештем. Әти эштән кайтты. Чәй өлгерде. Ә минем өйгә керәсем килми. Нигәдер үтереп эч поша.

Табын янында чак кына чынаягымны кулдан төшереп җибәрми калдым. Кайнар чәй, түгелеп, ботымны пешерде. Әти белән әни әңгәмәсенә колак салгач, шулай булды ул. Ә алар болайрак сөйләшәләр иде.

Әни. Кибеттән тимерче Панкрат хатыны белән бергә кайттык әле. Кызыннан зарлана, сүз тыңламый, усал, ди...

Әти. Нишләгән тагын?

Әни. Бабасының орденынмы, медаленме муенына асып йөргән иде, бүген шуны югалтып кайткан, ди. Әтисе күз карасы кебек саклап тоткан иде, ни әйтер инде белсә, ди.

Әти. Ә-ә! Япон сугышында бирелгән орденны әйтәсең инде син, алайса. Бик гаярь матрос булган шул Светлананың бабасы. Рәсеме әле дә бар. Панкрат күрсәткән иде беркөннәрдә. Мыеклары менә болай...

Ашаганым аш, эчкәнем чәй булмады. Әти белән әни аны-моны сизенгәләгәнче чыгып сыздым тизрәк ишегалдына... Ишегалдыннан — бакчага, бакчадан — тыкрыкка... Габделгазизгә барып әйтсәң инде?.. Юк, әйтергә ярамый. Габделгазизне тыңлатып булмаячак. Уңай сүз сөйләгән саен үҗәтләнә генә бара ул.

Светланалар бакчасы ягынарак елышып, рәшәткә буендагы акация арасына кердем. Күңелем мине дөрес алып килгән икән. Светлана бакчада иде. Шәфәкъ нурларында чәчләре тагын да кызарыбрак, ут капкан шикелле булып күренә. Ак маңгаен миләш кәүсәсенә терәгән. Ябык иңбашлары дерелди — Светлана елый иде.

Аны кызганудан әллә нишләп тетрәнеп киттем. Йөрәгем тукталып калгандай булды хәтта.

Акация арасыннан тавышсыз гына чыгып, түбән урамга йөгереп төшеп киттем.

Ун-унбиш минуттан инде мин, бер кулымны чалбар кесәсенә тыгып, икенче кулымны җан-фәрманга селки-селки, кире йөгереп кайта идем.

Мин киткәндә ничек калган булса, һаман шулай басып тора Светлана. Тик шәфәкъ нурлары гына аның чәчләреннән миләш ябалдашларына менеп киткән. Аннары иңбашлары да калтыранмый икән инде Светлананың.

Алып кайтуын алып кайттым. Ничек тапшырырга менә хәзер? Рәшәткә аша гына ыргытсам, күрми калуы бар. Чакырып, үз кулына бирсәм... Юк, булмый, йөрәк җитми... Бәлки, Габделгазизне күреп тә калгандыр әле ул буа буенда.

Соң, рәшәткә арасына кулны тыгасың да сукмакка ташлыйсың. Өйләренә кергәндә, шул сукмактан узачак бит Светлана...

Суламыйм да. Посып утырам куаклар арасында. Башта бәрәңге сабаклары кыштырдады. Килә Светлана. Килә. Туктады. Иелде. Алды... Кичке һаваны сөенечле аваз ярып узды:

— Әни! Таптым! Таптым, әни!

Ул төнне барыбер рәтләп йоклый алмадым мин. Әллә нинди төшләр күреп, саташып беттем...

Иртәгесен хәлнең ничек булганын Габделгазизгә үзем сөйләп бирдем. Моны ишеткәч, колак яфраклары алсуланып кына калмады, борыч кузагы кебек кызарды Габделгазизнең.

Тегермән буасына җиткәнче сөйләшмичә бардык. Ә тал арасына кереп буш чокырны күргәч, Габделгазиз, озын бармаклы кулларын йодрыклап, минем өскә ташланды...

Эләкте анысы, Габделгазизгә дә нык эләкте. Икенче

бәйләнерлек итмәдем мин аны. Дуслашасы килсә — мин каршы түгел, дуслашасы килмәсә — башка малайлар эзләсен. Тапкан югыйсә йомшак икмәк...

Ә, сезнеңчә, нишләргә тиеш идем мин?

## АКБАЙ БЕЛӘН КАРАБАЙ

Язгы төннәрнең берсендә, аһ-уһ килеп урынымда әйләнгәләгәндә, караңгы почмактан әни тавышы ишетелде:

— Нишләп көрсенәсең әле, улым, авырмыйсыңдыр ич?

— Юк, авырмыйм, әни. Түбәтәй тавы башында ятим көчекләр туңып ята, әниләре кайтмый да кайтмый, шуларны жәллим.

— Күңелем сизә, син аларны барыбер алып төшәсең инде, — дип көлде әни. — Җан биргәнгә җүн бирер әле... Сөтебез дә мул, алып кайт син аларны.

— И әни, — дидем мин, шатлыгымнан айлы тәрәзәгә сикерердәй булып, — рәхмәт, әни.

Иртән, көтү куганчы, безнең ишегалдында иде инде көчекләр. Ничек шулай яраткандыр табигать: берсе — бүздәй ап-ак, икенчесе — җир кебек кап-кара; агының күзләре күксел төстә, карасының күзләре дә чем-кара, ерактанрак карасаң, аның күзләре күренми дә хәтта, нәни төймәчекләр генә елтырап тора сыман.

Көчекләр, дерелди-дерелди, сөт эчтеләр дә кояшта җылынган басма тактасы өстендә икесе бер йомгакка әвереләп йоклап киттеләр.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Мин үзем дә, күрше малайлары да уйнап туйды сөйкемле көчекләр белән. Басма алдында аклы-каралы сәер йомгак тәгәрәп ятуын күргәч, тавыклар да гаҗәпләнү катыш шомлы кытакламыйлар, яшел күзле бохар песие дә, сырт йоннарын кабартып, мыекларын тырпайтмый инде хәзер. Хәер, басма алдына җылынырга гына чыга көчекләр. Лапас астында үз куышлары, үз оялары бар аларның — шунда кочаклашып йоклыйлар, шунда төн куналар, оя авызыннан башларын чыгарып кына чәпел-чәпел сөт эчәләр.

Исемнәре дә бар инде хәзер аларның. Бик гади, бик ятышлы исемнәр — Акбай белән Карабай. Чәңгелдәп өрә-өрә, ишегалды буенча күбәләкләр, шөпшәләр куарга да өйрәнделәр.

Ә җәйге каникуллар бетәрәк мондый хәл булды. Өйгә яңа көзге алып кайткач, иске көзгене әни басма алдына чыгарган иде. Шул көзгене кичтән йөзе белән яктыга

әйләндереп куйган идем. Иртән ни күрим — көчекләр икесе дә көзге каршына килеп туктаганнар, әниләреннән качып кичке уенга барырга җыенган кызлар кебек, мыштым гына көзгегә карыйлар. Карабай, үзенең кара булуына гарьләнгәндәй, ничектер боегыбрак тора. Ә Акбай, киресенчә, күзләрен куанычлы елтыратып, үз шәүләсенә текәлгән, бертуктаусыз койрыгын болгый. Әтәч койрыгыдай кәкрәеп төшкән колакларына кадәр шатланганын сиздерә Акбайның.

Карабай озак маташмады, якынрак килеп үз шәүләсен иснәштергәләде дә борылып китте. Акбай, башын әле бер, әле икенче якка кыйшайткалап, үз кыяфәтенә сокланып туя алмыйча, шактый озак торды. Ул да түгел, бәләкәй тәпиләреннән нәни тырнакларын чыгарып, көр тавыш белән өреп тә җибәрде. Аннары, кисәк кенә мәтәлчек атынып, бер читкә тәгәрәде һәм, сикерә-сикерә, лапаска таба йөгерде. Җайлап кына сөт эчәргә керешкән Карабайны әле болай, әле тегеләй төрткәләде, тегесе тыңламагач, тешләрен ыржайтып ырылдап та алды. Карабай, бу хәлгә гаҗәпләнми-сәерсенми генә, язмышына буйсынды, койрыгын кысып, лапас почмагына кереп шылды.

Акбай ашап туйгач кына чыкты ул сөт эчәргә. Бу хәл көндез дә, кич тә, алдагы көннәрдә дә шулай кабатланды. Ояларында да бер йомгакка әверелеп йокламыйлар хәзер алар. Акбай түрдәрәк, корырак урында кәпрәеп ята, Карабай оя авызындагы каты җиргә кадерсез генә тәгәрәгән...

Көз җитте. Бәрәңге бакчалары Карабай йонындай каралгач — атна-ун көн микән, юк микән — бервакыт иртүк сәер тавыш сискәндереп уятты мине. Кайдадыр кемдер, кемгәдер рәнҗеп, җәберләнеп елый иде сыман. Торып тәрәзә янына килдем. Бөтен җиһан ап-ак. Кар яуган, беренче кар яуган. Җиңел генә киенеп ишегалдына чыктым. Йомшак карга беренче эз салуым булды — теге тавыш янә, бу юлы якында гына ишетелде. Күз камашуы кими төшкәч, ишегалдындагы тамашаны күреп тетрәнеп киттем: кар җәймәсе уртасында соргылтланып, төсе уңыбрак калган Акбай, ак дөньяның бердәнбер чәчәгедәй балкып утырган туганының ияге астына башын яшереп, кызгандырып, нәзек кенә шыңшып, үзенчә чын күңелдән елый иде. Карабай әледән-әле аның колак артына кара борынын тидергәләп ала. Әйтерсең лә Акбай, үзенең ак төстә булуы белән масаеп йөрүе өчен, туганыннан гафу үтенә, тегесе исә: «Елама, елама, гафу итәм мин сине... Дөнья шулай ул, гел актан яисә гел карадан гына тормый, аклы-каралы була», — дип, Акбайны юата иде.

# КОМАНДИР

Урманда агач ботагы шартлап сынса да, сарайлар артында тавыклар кытакласа да, бака күленә таш яисә балчык кисәге чупылдап төшсә дә, әниләрнең авызында бер генә сүз:

— Командир!

Шуннан китә инде сүзгә сүз ялганып, шуннан китә, тыңласаң — тыңла, тыңламасаң — колакларыңны томала.

— Малайларыбызны аздырып бетерә инде тәмам. Таң тишегеннән урманга ияртеп керә дә китә. Ашауларын да оныталар аннары бәбкәчләребез.

— Әти-әнисе дә инде... Авыз ачып бер кәлимә сүз әйтмиләр, ахры, шуңа. Үскәч, бер зимагур булыр әле менә, әйтте диярсез.

— Укытучылар да зарлана икән, начар укый, ди. Әле менә шушы, рәхмәт төшкере, исемең ничек әле, үскәнем? Нәгыймә кызы шефка алган икән дә үзен... Мәгънәсе юк ди шул әле бер дә. Ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән керми шул менәтерә. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга таба карый, ди.

Нәгыймә кызы дигәннәре мин, Фирүзә булам инде ягъни. Күрше хатыннары ялганламыйлар. Командирны шефка алуым хак. Безнең бишенче «А» классында отличниклар дүртәү. Әмма аларның берсе дә шефка алырга теләмәде Командирны.

Мәктәптә командир түгел инде ул. Мәктәптә Нигъмәтҗан гына. Кинолардагы, китаплардагы командирларга да охшамаган ул үзе. Аксыл чырайлы, көмеш чәчле, төссез күзле. Соңгы дәрестә бигрәк тә төссезләнә аның күзләре. Әллә арый шунда, әллә авырый, белмәссең.

Авыруын авырмый torгандыр ла. Каланча буе булып үсәмени авырган кеше?

Авырсын иде ул, ичмасам. Авырса, тыңлар иде ул мине. Тыныч кына мәсьәлә чишеп утырганда, капыл гына сикереп торып, ишеккә ташланмас иде. «Мин хәзер керәм», — дип кычкырган була бит әле, җитмәсә. Ә үзе туп-туры урманга сыптыра. Урманда нишлиләр дип уйлыйсыз инде сез аларны? Нишләсеннәр, дүрт-биш малай бергә җыелалар да киселгән имән төбенә агач наганнарын тезеп куялар. Командир фанер планшетыннан карта чыгара. Юкә портупеяле «партизаннар», карта өстенә иелеп, бармаклары белән әле теге, әле бу ноктага төртәтөртә, үзара киңәш-табыш итәләр дә төрлесе төрле якка таралышалар. Карта янында, катыргы погоннарын тырпайтып, Командир гына торып кала.

Аннары куаклар артында «ура» кычкырган тавышлар ишетелә. «Разведка»дан кайткан «партизаннар», әлсерәп, ах-вах килеп, аланлыкка чыгып егылалар; кайсы «яраланган» шунда — аксый-аксый атлый; кайсылары «дошман солдатларын» әсир төшергән — Бака күле буенда ята-ята мүкләнеп беткән юкә кайрысын бәйләп күтәргән...

Урман кардонында яшәгәч, малайларга да ачуланып булмый шул. Каланчага менеп кайсы якка гына карасаң да, урман да урман бездә. Наратлы үренә кадәр яшеллесарылы урман аннары — кара, ә тагын даерактарак, офык читендә үк, диңгез кебек зәңгәр, серле урман...

Бүген бигрәк тә ачуым килде Командирга. Әти белән әни эштән кайтканчы, өйгә биргән эшләрен ялтыратып куйыйк әле дип, бакча артыннан гына килеп керсәм боларга — китап-дәфтәрләре кайсы кайда таралып ята, тәрәзәләре шыр ачык. Әһә, «көмеш баш» тәрәзәдән чыгып шылган.

Урман авызында дөнья җимереп сызгырган, кычкырган тавышлар ишетелә. Тукта әле, бик шәпләп кыздырып кайтыйм булмаса моны. Җил куып йөрер чакмыни хәзер?

Ишекләрне ачып-ябып әрәм итәсе килмәде, күлмәк чабуларымны җыебрак тоттым да ачык тәрәзәдән кызыллы-сарылы яфраклар белән чуарланган йомшак сукмакка сикердем. Җил чәчләремне туздырды, маңгаема, битләремә пәрәвез җепләре килеп сырышты. Йөземне кура җиләге исе сеңгән учларым белән сыпыргалап алдым да урманга таба йөгердем.

Кардон кибетен урап, иркен яланга барып чыгуга, каршыма шундый күренеш ачылды: урман буендагы иңкүлектә эреле-ваклы малайлар ыгы-зыгы килә. Кулларында таяклар, ташлар. Үзләре берсен-берсе уздырып кычкыралар, сызгыралар. Иң алдан, озын сыйракларын ялтыратып, Командир чаба.

Тукта инде, ниндидер җан иясен эзәрлеклиләр түгелме соң болар? Аһ, хулиганнар! Ах, мәгънәсезләр!

Тирән итеп сулыш алдым да, кулларымны йодрыклап, иңкүлек уртасына атылдым. Ә үзем, йөгергән уңайга:

— Тимәгез, тимәгез! — дип кычкырам.

Башта күзләремә кош кебек күренгән иде ул. Шактый йөгергәч кенә мин аның мәче баласы кадәр ап-ак җәнлек булуын абайладым. Түм-түгәрәк күзләре елтыр кара, аяклары кыска, колаклары тал бөресенә охшаган. Ә җитезлеге... Малайлар селтәгән таяклар арасыннан елан кебек кенә бөтерелеп чыга да югарыга сикерә, ата каз кебек ысылдый.

Иң арттан, симергән тартай сыман, Чулпыр Хәлиме тарсылдый иде. Йөгергән уңайга терсәгем белән генә орынып уздым анысына — чирәм өстенә тәгәрәп кенә калды.

Бишенче «Б» малайлары Шамил белән Фәритне куып узу да читен булмады.

Ибрайны чалбар каешыннан тартып мәтәлдердем һәм бөтен урман авызын яңгыратып аваз салдым:

— Тимәгез! Үтермәгез!

Ни Командир, ни өлкән лесничий малае Мөсәл игътибар итмәде минем тавышка. Таякларын бутап, теге бичара җәнлекнең өстенә баса язып, борыла-сырыла сикергәләүләре сикергәләү иде аларның.

— Тимәгез!

Тавышымның зәгыйфьлегеннән, ачудан гарьләнеп, җиргә капланып елыйсыларым килде, үземнең көчсезлегемнән сулышым кысылды.

Үтерәләр бит инде, күрәләтә харап итәләр. Таягын югары күтәргән Командир алгарак йөгереп чыкты. Хәлдән тайган, хәлсезләнгән җәнлек белән бер тигезлектә иде ул хәзер.

— Сук инде, сук! — дип кычкыра-кычкыра чапты бераз арткарак калган Мөсәл.

Мин күзләремне йомдым.

Күзләремне ачканда, Командир, таягын култыгына кыстырган килеш, саргылт үләннәр өстендә тирбәлә иде.

Ә җәнлек кайда соң? Әллә... Юк икән. Ак йомгак һаман да урманга таба тәгәри. Ләкин инде аның сикергәне дә күренми, ысылдаганы да ишетелми.

— Үтермәгез! — дип кычкырдым мин, соңгы көчемне җыеп, һәм чирәмгә тезләндем.

Инде Мөсәл алдан йөгерә иде. Тагын бер генә адым, тагын бер адым җир үтсә, харап итәчәк сөйкемле җәнлекне.

«Хулиганның да хулиганы икән, рәхимсезнең дә рәхимсезе икән, — дип, эчемнән генә Командирны тиргәдем. — Яздырырмын мин сиңа диктантлар, чишешермен мәсьәләләр! Күтәрсәң менә икенче, булырмын менә мин сиңа шеф!..»

— Малай-лар, ди-м!

Ләкин соң иде инде. Мөсәлнең ике япьле таягы ак йомгак өстенә күтәрелгән иде. Тик шул мизгелдә әллә ни генә булды. Командир, ян беләнрәк борылып, Мөсәлгә килеп бәрелде. Өскә күтәрелгән таяк зырылдап читкә очты, Мөсәл үзе юл читенә барып төште, ул арада ак йомгак кыска куаклыкка кереп югалды.

Мин кызулык белән тешләп өзелгән толым очымны

төкереп аттым да аяк өстенә тордым, табигать корткычларын утлы табага бастырырга ниятләп, малайлар янына ашыктым. Ләкин Мөсәл өстенә иелеп нәрсәдер аңлатып маташкан Командирның соңгы сүзләре адымнарымны акрынайтырга, аларны бөтенләй туктатырга мәҗбүр итте. Алай гына да түгел, аның соңгы сүзләре минем зиһенемне таркатып җибәрде.

— Азык алып кайтадыр... Оясында балалары көтәдер аны, шәт. Әшкә барган җирендә синең әниеңне үтерсәләр, яхшы булыр идеме соң менә?..

Уй-фикерләрем чуалды, тамак төпләрем кымырҗый, күз төпләрем ачыта башлады. Калтыранган иреннәремне малайларга күрсәтәсем килмәде. Балчыкка буялган тезләремә бармак очларымны тиергәләп алдым да, сары яфракларны кыштырдата-кыштырдата, күл буена төшеп киттем.

Үз колагым белән ишеткән сүзләрне өйгә кайтып сөйләгәч, әни ышанмады.

— Юктыр, юктыр, кызым, ялгыш ишеткәнсеңдер, Хәбирә атаманы әйтмәс андый сүзләрне, — диде ул, бик белдекле булып. — Биш яшьлек энесенә авыз ачып бер җылы сүз әйтә белмәгән баладан нинди рәхим-шәфкать көтмәк кирәк.

— Җәмилгәме?

— Кемгә булсын тагын? Шагом марш та айт-два, стуй да смирны... Шул да булдымы сүз? Солдат түгел ич ул, нарасый бала. Нигә күзләреңне тасрайттың? Әллә ялган сөйли дип уйлыйсыңмы? Хак дөресен әйтәм. Ышанмасаң, энисе кибет җыештырырга киткәч, бакчага чыгып тыңла әнә. Иптәш малайлары белән ничек дорфа кыланса, энесенә дә шулай җикеренә. Син генә ул, тиле күке, шуны әллә кем урынына күреп, өйләренә кереп, сабак өйрәткән буласың.

Мин аны-моны дәшмәдем. Дәресләремне әзерләп бетергәч, кечке ашка бәрәңге юып, әрчеп, салкын суга салып куйгач, бакчага чыктым. Яфраклар арасында миләш тәлгәшләре ялкынлана. Җил тагын бераз гына көчлерәк иссә, бөтен агачларга ут кабар сыман. Миләш ябалдашларына чыпчыклар табын корган. Табыннарының муллыгына соклангандай, чыр-чу килешеп, бәрәңге буразналарына атылып төшәләр дә кабат югарыга томырылалар, йоннарын кабартып, кызыл очкыннар арасына кереп күмеләләр.

Командир да, кичләрен бакчага чыгып, чыпчыкларны күзәтергә ярата. Әллә аяз күк шәүләсе төшә инде — төссез күзләре матурланып, зәңгәрләнеп китә аның, югарыга карап торганда.

Бүген соңрак чыкканмын, ахры. Күләгәдә калган акация куаклары артында кеше-фәлән күренмәде.

Иске рәшәткәгә якынрак килдем. Акация куакларын аралап, Командирлар бакчасына карадым — бернинди хәрәкәт, бернинди тавыш-тын юк. Колак яфрагыма орына язып, ялгыз бал корты гына безелдәп үтте.

Ә-ә, әнә кайда икән алар — бакчаның теге ягындагы чирәмлектә, нарат төбендә. Ибрай белән Фәрит үрә катып торалар. Янә Командир кечкенә Җәмилне дә бәрәңге сабаклары арасыннан җилтерәтеп чыгарды һәм тегеләр янәшәсенә бастырып куйды.

Мин акация куакларының сирәгрәк урынын эзләгән арада, «Шагом марш!» командасы яңгырады. Шуның артыннан ук «Бегом!» дигән нәзек тавыш ишетелде.

Менә, ниһаять, күзәтер өчен җайлы урын таптым. Ибрай белән Фәрит, агач штыкларын алга сузып, кечкенә Җәмилне шактый артта калдырып, бакча ишегенә таба элдерделәр.

Бераздан Командир үзе дә энесенең үкчәсенә бастырып йөгерә иде инде. Үзе йөгерә, үзе энесен тирги:

— Алга, алга! Күтәребрәк аякларыңны, күтәребрәк.

Җәмил сөртенеп егылгач та тукталып тормады бу. Өстеннән генә сикереп үтте энесенең. Жираф!

Җәмил җиргә ничек тиз егылган булса, шулай җәһәт кенә сикереп тә торды, абына-сөртенә чабарга да тотынды.

Йөгереп арыгач, озынлыкка сикерештеләр болар.

— Нәрсә, гәүдәңне күтәрә алмыйсыңмы? — дип, Командир тагын Җәмилне тиргәп ташлады.

Биеклеккә сикергәндә дә эләкте Җәмилгә.

— Пешмәгән бәрәңге, — дип җилләнде Командир. — Алай сикерәләрме соң аны, менә болай сикерәләр.

«Һе, син дә сикермәгәч, синең сыйракларың...»

Җәмил мескеннең йөзе миләш кебек кызарды. Ибрай белән Фәриткә нәрсә, алар, Командир сүз әйтмәгәч, биеп кенә йөриләр. Берсеннән-берсе уздырып, берсеннән-берсе биегрәк сикерергә тырышалар.

Сикерегез, сикер! Командирыгыз хәзер сезне сикертә, сез киткәч, мин Командирыгызны сикертәм әле, бик шәпләп сикертәм, бәләкәйләрне рәнҗеткән өчен эләгә әле аңа, бик яхшы эләгә.

Йөгерү-сикерү буенча беренчелекне Ибрай алды, ахры, — Командир аның күкрәгенә фанермы, катыргымы кисәге такты. Тегесе берничә минут үрә катып торган булды да, күкрәген киереп, бакчаның арт ишегеннән тыкрыкка чыгып китте. Фәритенә мактау күп эләкмәде, ахры, — анысы җире-күге белән шатланмады, күкрәгенә

тагылган нәмәрсәне сүзсез генә капшаштыргалый-капшаштыргалый, гадәти адымнар белән генә ераклашты.

Җәмилгә берни дә тәтемәде. Нарат кәүсәсенә сөялгән хәлдә, башын иеп, боегып тора бирде ул.

Инде мин: «Әй, Командир!» — дип кычкырырга әзерләнгән идем, әмма авызымны ачып өлгерә алмадым, Командир, нарат төбенә килеп, кулын Җәмилнең җилкәсенә салды һәм, гаҗәп йомшак тавыш белән:

— Син миңа ачуланма инде, Җәмил туганым, — диде.

— Асуланмыйм, ник асуланыйм, — дип мыгырданды тегесе, — командил ис син, командил булмасаң, асуланылием.

— Минем сине чыныктырып үстерәсем килә, Җәмил туганым. Йөгерүен дә каты йөгерәсең син, сикерүен дә әйбәт сикерәсең. Ибрайлар алдында мактасам, әһә, үзе командир, ә үзе энекәшен яклый, диярләр. Син миңа ачуланма, яме.

— Асуланмыйм мин. Икенсе юлы Иблай белән Фәлитне узам әле мин.

— Дөрес әйтәсең, Җәмил туганым. Намуслы партизан син. Шуңа күрә яратам да мин сине. Әйдә, хәзер качышлы уйныйбыз. Син кач, мин эзлим.

— Юк, баста саныйбыз. Санагас, кем көтүсе кала, сул эзли.

— Саныйк әтү.

Җәмил кулларын бутый-бутый санарга кереште:

— Әке-бәке, кыек сәке, сыел-сык...

Әллә шундый сөйкемле энекәшем булмаганга, әллә аниләрнең Командир турында әйткән сүзләре исемнән чыкмаганга, күңелемне кинәт сәер моңсулык биләп алды.

Миләш ябалдашларыннан чыпчыклар да, кояш нурлары да киткән икән инде. Шуңа күрә ямансулыймдыр мин, бәлки. Моңаям, имеш, ямансулыйм... Кемне ышандырырга тырышам соң әле? Үземнеме? Теләк ич бу, әйе шул, теләк. Командирның шефы гына түгел, дусты да буласым килә минем.

## БУРАНГА — ШАХ!

Малайлар ашханәдән чыкканга күрә генә сизми торганнар икән — кай арада җиле дә салкын якка авышкан, борыннарны, иякләрне туңдыра, йон перчатка аша сөзелеп керә дә бармак очларын чеметтерә.

Ул да түгел отыры көчәя барган буранның турылыклы юлдашы — соры шәлле төн карчыгы да килеп җитте.

Ашханә каршындагы багана башында гөлт итеп ут кабынгач, минуты-секунды белән ак бураннар арасына кереп качты качуын төн карчыгы. Әмма барыбер бөтен тарафтан аның салкын сулышы сизелә, шул чакларның шомлы кыштырдавы ишетелә иде.

Күпер борылышыннан, өзек-өзек гөрелдәп, чанасына берничә рәт ашлама капчыклары төялгән трактор килеп чыкты, ашханә янына җитеп туктады. Кабина ишеге ачылып, өстенә солдат бушлаты кигән Галләм абыйлары күренүгә, малайлар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә:

— Галләм абый, безне дә утыртып кайт әле, — дип кычкыра-кычкыра, трактор янына йөгереп килделәр.

— Белмим шул, малайлар. — Галләм каш-керфекләрен бияләй аркасы белән сыпырды. — Юл хәлен белеп булмый, күрәсез, һава да бозылды. Кунак йортында гына кунасызмы әллә?..

— Иртәгә безнең дружина советы була шул. Галләм абый, утырт инде, — дип ялынырга тотынды чын-чынлап хафага төшкән Нәгыйм.

Тракторчы моторның кай җирендер капшап карады.

— Шулай дисезме? Ярар алайса, тәвәккәлләдек... Йә, шахмат ярышлары ничек узды? Йөзгә кызыллык китермәгәнсездер бит?

— Район буенча беренче урынны алдык, Галләм абый! — диде Фәрит, әңгәмәнең мондый юнәлеш алуына куанып.

— Тел бистәсе Фәйзи сөйләп торды әле бүген станциядә. Хәзерге пионерларга нәрсә аларга, җылы урын булсын да тәмле ризык булсын, ди. Ә мин әйтәм, безнең колхоз пионерлары андый түгел, баскан җирдән ут чыгара безнең колхоз пионерлары, мин әйтәм. Молодцы, малайлар, дөрес яклаганмын икән сезне... Әйдәгез, кабинага кереп утырыгыз.

Кабинада җылы иде.

Берничә минуттан йөзе-бите дымланган, баштанаяк карга буялган Галләм дә кабинага керде, җитез хәрәкәтләр белән тракторны урыныннан кузгатты.

Район үзәген чыккач, юл читендә үк җәелеп яткан салам эскерте яныннан тау төшә башладылар.

Үрне төшеп җиттеләр, яртылаш кар күмгән бәләкәй күперне хәвеф-хәтәрсез кичтеләр. Әмма ләкин акбүз ат ялларыдай сибелеп торган өермәләр аша үргә күтәрелгәндә, юл кинәт кенә җебегәндәй, йомшаргандай тоелды. Трактор кыйшайды. Малайлар карлы тәрәзәдән тәгәрмәч чылбырларының тонык кына ялтырап карга иңә баруын шәйләп калдылар.

Трактор тагын берничә мәртәбә ярсып-ярсып алга ыргылып карады да туктады.

— Утырдык, — диде Галләм, өметсез тавыш белән һәм, кабина ишеген җәһәт кенә ачып, кар диңгезенә чумды. Ябылып җитмәгән ишектән кар өерелеп керде, җил сызгырганы ишетелде. Аннары трактор артында тимерләр шалтырады. Галләм абыйлары озаклагач, малайлар да өермә эченә сикерделәр, карга бата-чума трактор артына килделәр.

Галләм абыйлары, таккыч өстенә иелеп, чананы ычкындырырга маташа иде.

— Үзебез булышабыз, Галләм абый, нишләргә кирәген син әйт кенә, — диде Фәрит, буранга йөзе белән борылып.

— Ие шул, Галләм абый, бер дә борчылма. — Нәгыйм дә иптәшенең сүзен шулай куәтләде.

Галләм абыйлары малайларга сынаулы караш ташлады. Нәгыйме буйга тәбәнәк булса да, гаҗәеп хәрәкәтчән, күзләре ут кебек яна, бүрек колакларын күтәреп бәйләгән, суыкка да, буранга да исе китми сыман. Фәритне инде Галләм электән үк белә. Узган ел малай әтисе белән комбайнда эшләгән иде. Ышанычлы, чыдам. Җилгә каршы күкрәк киереп басып торуларын күр син аның!

Бераздан малайлар күңелендәге ышаныч Галләмгә дә күчте.

— Алайса, — диде ул, чана алдына өелгән карны көрәк тыгып айкый-айкый, — мин тракторны азрак артка чигерәм, сез шул арада чананы ычкындырырсыз. Трос белән тарттырып карарбыз.

Галләм кабинага кереп югалды. Мотор бар хәлгә улап куйды. Трактор чылбырлары, көрт казый-казый, артка тәгәрәде...

Чанасы ычкындырылгач җиңеләеп калган трактор, дөбер-шатыр килеп, каты юлга менеп китте. Аннары тагын акрын-акрын гына артка чигә башлады. Малайлар чана башына уралган тросны сүтеп, трактор янына сөйрәп китерделәр. Арткы тәрәзәдән Галләм абыйларының җылы карашын тоеп, трос элмәген таккыч йозагына эләктерделәр.

Мотор тавышы көчәйде, фара нурлары тоташ кар пәрдәсе белән капланган соры киңлекне аркылы-торкылы тураклады, трос скрипка кылыдай тартылды, мәгәр чана урыныннан кузгалмады.

Малайлар, бил тиңентен кар ерып, чананың әле бу ягына, әле теге ягына чыктылар, әйдә-әйдә, тагын бераз, тагын, тагын, дип, тракторга көч биреп тордылар. Әмма

кая ул — карлы эскертне хәтерләткән чана әйтерсең лә җиргә берегеп каткан иде.

Трактор, хәл җыйгандай, азрак артка чигенеп торды да тагын алга ыргылды. Аның чылбырлары күз иярмәс тизлек белән ялтырадылар, трос тагын тартылды. Малайлар аның әледән-әле зыңлап куюын ишеттеләр.

— Әллә көн сындырды, әллә мин җылындым, — диде Фәрит. Ул, үз хәлен Нәгыймгә белдерүдән бигрәк, Нәгыйм хәлен белергә тели иде шикелле.

— Көне җылы ла аның, бураны гына теңкәгә тия, — дигән булды Нәгыйм. Үзе, Фәриткә арты белән борылып, яңакларын иңбашларына ышкып алды.

Ниһаять, Галләм абыйлары трактор эзенә сикереп төште.

— Казып карасак, ничек булыр икән, Галләм абый? — диде Фәрит, аяклары тирәсендәге карны таптый-таптый.

Галләм чана астына иелеп карады, башын чайкады.

— Юк, оланнар, көрәк белән генә ярдәм итәрлек түгел монда эшләр. Үрне менеп җитсәк, юл әйбәтләнә дә бит...

Нәгыйм: «Чананы калдырып кайтсак, ничек булыр, Галләм абый?» — дип әйтә башлаган иде. Әмма Фәрит аны бүлдерде, пулеметтан тырылдаткандай кызу-кызу сөйләп алды:

— Беләсеңме, нишлибез, Галләм абый? Йөкнең яртысын бушатабыз. Тросны ялгыйбыз. Йөк артта гына калгач, чананың алды күтәрелә.

— Көч җитмәс шул, оланнар... Станциядә кран белән төягән идек тә кана...

— Кронсыз да бушатабыз, Галләм абый, — диде Фәрит, әле генә үзе әйткән сүзләрнең тәҗрибәле тракторчы күңеленә хуш килүен сизеп. — Авыр түгел ич ашлама капчыклары. Син өстән тәгәрәтерсең, ә Нәгыйм белән без юл читенә ташып өярбез. Ие бит, Нәгыйм?

— Капчыклар бик авыр булмаса, бушатырбыз, нигә бушатмаска, — диде Нәгыйм, карлы капчыклар тавына бераз шүрләбрәк карап торганнан соң.

Галләм абыйлары чынлап та тәвәккәлләде бугай. Чана башыннан юл катысына кадәр киң генә сукмак ачып ташлады, көрәген көрткә кадап, капчыклар өстенә үрмәләде.

Кар пәрдәсе белән челтәрләнгән караңгы күк гөмбәзе астында газаплы юлдан, туктаусыз искән җилдән, карбураннан алҗыгандай сүрән генә янган фаралар яктысында кызу эш башланды. Нәгыйм белән Фәрит Галләм абыйлары сөйрәп китергән капчыкларны, икесе ике башыннан тотып, юл читенә ташый бардылар. Менә ун кап-

чык булды... Егерме... Илле. Малайларның күзләре томаланды, битләре кызышты. Озакламый алар юешләнгән бияләйләрен салып кесәләренә тыктылар... Җил улавын да ишетмиләр, кәгазь капчыкларга челтер-челтер коелган ярма карга да әһәмият бирмиләр иде инде алар хәзер.

Галләм абыйлары эш арасында берничә мәртәбә: «Армадыгызмы әле?» — дип сорады.

Арсалар да, арганлыкларын сиздермәскә тырыштылар малайлар. Фәрит хәтта: «Бер кызган көе барсын да бушатып ташлыйбызмы әллә, Галләм абый», — дип шаяртып та алды.

— Бушатуын бушатырбыз, төйисе дә була бит әле бу капчыкларны, — дип авыр сулады Нәгыйм һәм, күзләрен йомып, чана кырыена сөялде.

— Син нәрсә, Нәгыйм, арыдыңмы әллә? — диде Фәрит, иптәше янына килеп. — Ярышта сынатмадык, монда да сер бирмик. Нәгыйм, Нәгыйм, дим, ач күзләреңне...

Нәгыйм күзләрен ачты, сизелер-сизелмәс кенә чайкала-чайкала, Фәриткә таба атлады...

Менә йөз капчык булды. Йөз дә бер. Йөз дә ике... Керфекләр авырайды, тырнак төпләре сулкылдады, тез буыннары, кул тамырлары тартышты... Йөз дә өч, йөз дә дүрт... Карга сузылып ятып хәл аласылары килде малайларның, кайнар учлары белән умырып-умырып кар ашыйсылары килде.

Йөз дә унынчы капчыкны күтәреп килгәндә, әллә җил катырак исте, әллә үзләре сөртенделәр инде шунда, малайлар икесе дә капчыклары-ниләре белән карга капландылар.

Беренче булып Фәрит көләргә тотынды, аңа хәлсез тавыш белән Нәгыйм кушылды. Аларның йомшак кар эчендә озаграк яту өчен генә бер-берсен уздырырга тырышып көлүләрен аңлады бугай Галләм абыйлары. Үзе ишеп төшергән капчыкны бер читкәрәк алып ташлады да япан кырны яңгыратты:

— Отбой!!!

Малайлар аяк өстенә торганда, Галләм трактор артында тросны ялгап маташа иде инде.

— Бирешмәгез, оланнар, — дип каршы алды ул малайларны, — чыгарга тиеш без бу шайтан чокырыннан. Тотыгыз әле менә шушы тросның очларын. Мин акрын гына тарттырам. Төен кысылгач кына җибәрерсез. Карагыз аны, берүк саклык белән генә.

Утлар биешеп алды. Ак өермә бөтерелеп торган һава әле тәбәнәкләнде, әле биегәйде. Трос карны сыдырып бар-

ды-барды да өскә күтәрелде. Алар чананың выжылдап көрт сыртына килеп менүен дә күрми калдылар. Җиңел, бик җиңел елдыра иде яртылаш бушаган чана. Менә ул, биниһая олы танк сыман, малайлар яныннан үтеп китте, калын көрт буенча кыеклап шуды да трактор эзеннән каты юлга калыкты.

Фәрит, сөенеченнән нишләргә белмичә, әле генә үзләре ташыган капчыклар өстенә йөгереп менде, бөтен әйләнә-тирәне кочакларга теләгәндәй, кулларын җәеп:

— Буранга — шах! — дип кычкырды.

...Менә соңгы капчык та чанага менеп ятты. Малайлар көрт өстенә шуып төштеләр. Галләм абыйлары да ярыйсы ук алҗыган икән. Яңакларында, маңгаенда бөрчек-бөрчек тир тамчылары ялтырый.

— Сиздегезме, егетләр, буран басылды бит, — диде ул.

Малайлар буран басылганын сизмәгәннәр иде. Алар беркавым тирә-яктагы сәер тынлыкка хәйран калып тордылар. Бу, әлбәттә, буран басылганны сизми калудан гына түгел иде: Галләм абыйлары Фәрит белән Нәгыймгә менә хәзер генә, үз итеп, тиң итеп, «егетләр» дип эндәште. Баягынак «оланнар» дигән иде. Ә юлга чыкканда малайлар гына иде әле алар. Инде менә егетләр булдылар. Егетләр булгач, әллә нинди җил-бураннарың да, давылзилзиләләр дә куркыныч түгел инде аларга хәзер.

## ЯЗАРГА КӘГАЗЬ БЕТКӘНМЕ?

Назим Әминәгә гашыйк булды. Тик торганнан, уйламаганда, ис китмәгәндә. Әминә такта янына «Урман кызы» шигырен сөйләргә чыккан иде. Әминәнең күзләрен очкынландырып: «Әй, Әминәм, синнән качам мин», — дип әйтүе булды, арттагы партада ялгызы гына утырган Назимның күкрәгендә — йөрәк турысында — җылы, назлы дулкын кузгалды. Рәхәт, бик рәхәт булып китте Назимга. Әнисе йомшак канат белән майлаганда, бәйрәм кабартмаларына да шулай рәхәт була торгандыр, мөгаен. Эрегән май кайнар да була бит әле аннары. Кабартмалар, рәхәтлек кичерү белән бергә, кызыша. Әйтерсең лә Әминәнең түгәрәк, мөлаем йөзе кояшка әверелгән иде. Пешерепме пешерә Назимны.

Назим, кисәк кенә кузгалган хисләрен тыя алмыйча, кесәсеннән пәке алып, башын парта астына яшереп, эшкә кереште. Тик парта капкачының аскы ягына «Әй, Әми-

нәм» дигән сүзләрне генә уеп өлгерде Назим, укытучы өстәле яныннан тавыш килде:

— Син ни белән шөгыльләнәсең анда, Мифтахов?

Назимның пәкесе шалтырап идәнгә төште. Класс, дөбер-р иттереп, артка борылды.

Назим:

— Мин, мин, абый, — дип мыгырданган арада, әдәбият укытучысы Нуретдин Хәмзин яңа ботинкаларын шыгыр-шыгыр иттереп килеп тә җитте, парта капкачын ачып та салды, кычкырып та җибәрде:

— Син нәрсә, Мифтахов, күчерәм дисәң, Такташ шигырен күчерергә кәгазь беткәнме әллә сиңа?

Тирә-якта көлү тавышлары ишетелде, Назим, чаган яфрагыдай кызарып, башын түбән иде.

Тәнәфестә малайлар парта капкачына уеп язылган сүзләрне укырга тырышырлар инде дип курыккан иде Назим. Ләкин юкка курыккан икән. Кыңгырау шылтырагач ук класска француз теле укытучысы Гөлчирә апалары килеп керде һәм, түргә узып, Хәмзиннең колагына тиз-тиз нәрсәдер пышылдап алды. Хәмзиннең күзләре ялтырап китте, авызы ерылды.

Ул да түгел Гөлчирә апалары, класс белән саубуллашырга да онытып, Хәмзинне җилтерәтеп коридорга әйдәде.

Тәнәфескә чыгу белән, башта кызлар чышын-пышын килделәр. Тәнәфес азагында инде бөтен мәктәп шаулый иде. Хәмзиннең хатыны — агроном Нәфисә — ир бала тапкан, имеш. Коридор буенча берничә кыз чәчәк бәйләмнәре тотып йөгерде. Ишегалдында машина гөрелдәде, котлыйбыз, котлыйбыз, дигән шатлыклы авазлар яңгырады.

Назимны артык гаҗәпләндермәде, хәер, бу хәбәр. Харап икән, ир малай туган! Моның ниенә шаккатасың? Авыл зур, ай саен өч-дүрт бала туып тора. Гашыйк булуны әйтсәң дә ярый ичмасам менә. Әминә үзе сизмәсен тагын. Узган ел: «Кызлар, шар күз Җамалиевның миңа күзе төшкән», — дип, Нәҗиптән дә көлеп йөргән иде әнә. Әминәгә ышансаң! Шигырь сөйләгәндә дә теле телгә йокмый. Бөтен класс алдында хур итәргә дә күп алмас.

Дәресләр беткәч тә өйгә кайтасы килмәде Назимның. Калын толымнарын дулкынландырып кәс-кәс атлаган Әминәне тыкрыкка кадәр карап озатты да инеш буена төшеп китте. Инеш суы көмештәй якты, мүкләнгән субайлар мәрмәрдәй ак булып күренделәр бүген Назимга. Малай портфелен таш өстенә куйды, пәкесен чыгарып, субайларның берсенә уеп язарга тотынды. Ләкин ул «Әй,

Әминәм» дип кенә язып өлгерде — баш өстендә Хәмзин шәүләсе пәйда булды.

— Син ни белән шөгыльләнәсең анда, Мифтахов?

Назим пәкесен артына яшерүгә, Хәмзин күпер астына сузылып карады.

— Сиңа язарга кәгазь беткәнме әллә, Мифтахов? Аннан соң нәрсә дип бәйләндең әле Такташның ул шигыренә? Нигә авызыңны ерасың?

— Ачуланмагыз инде, абый, — диде Назим, пәкесен учларына кысып.

— Мин ачуланмасам, башкалар ачуланыр. Ташла ул койма-капкаларга яза торган гадәтеңне, ташла. Тәртипсез малайлар һөнәре ул.

Назим күпер астыннан чыгып яр өстенә күтәрелгәндә, Хәмзиннән җилләр искән иде инде.

Һе, кызык кына! Тегендә язарга ярамый, монда ярамый. Эчеңдәге хисләреңне җиһанга ничек сөйләп бирергә соң алай булгач? Кәгазь беткәнме, имеш. Кәгазьгә мәңгеләштереп буламыни мәхәббәтеңне? Агачка, тимергә, ташка язсаң да җирендә. Ташка? Ташка шул! Назим, башын артка чөеп, тау түбәсенә карады. Булды гына! Портфелендә төсле акбурлар да бар. Ә Лачын тавы түбәсендәге ташлар өстәл кебек. Үзләре киң, үзләре шома. Яз да яз! Хәмзин дә күрми, чорт та.

Назим, портфелен селки-селки, шаян кәҗә бәтие кебек сикергәли-сикергәли, бормалы сукмак буенча тауга каршы йөгерде. Түбәннән караганда гына якын тоела тау түбәсе. Менә башласаң, сулышларың каба, тез буыннарың сыеклана. Хәер, бүген арганлыгын сизмәде дә диярлек Назим. Шатлыклы хисләре, якты теләге югарыга әйдәде аны бүген.

Юан карамалар да артта калды. Яфрагы коелып бетә язган әрәмәлекне ярып чыккач, ниһаять, олымсак ташлар Назимның каршысына ук килеп басты. Әмма шул чагында Назим куак төбенә чүгәләргә мәҗбүр булды: ташларның иң биеге янында Хәмзин басып тора иде. Юк, тик кенә тормый, күмер беләнме, графит беләнме ак ташка ниндидер сүзләр сырлый иде ул. Менә Хәмзин язып бетерде, читкәрәк китеп, озын чәчләрен сыпыргалый-сыпыргалый, әле генә үзе язган сүзләргә сокланып карап тора башлады. Назим эре-эре кәкре-бөкре хәрефләр белән язылган сүзләрне куак артыннан да бик җиңел укыды. Имән яркасыдай киң ташның буеннан-буена «Ура, баһадир туды!» дип язган, ә ахырдан бастырык юанлыгы өндәү билгесе куйган иде Хәмзин.

# УРМАН АША ЮЛЛАРЫМ

Быел мин Кара диңгезгә абый янына кунакка бардым. Ул «Уссурийск» дигән зур теплоходта эшли. Инде тугыз-ун ел бугай. Сирәк-мирәк туган якларга да кайтып киткәли. Күпне күргән инде, күпне белә. Океаннарның барысын да кичкән, материкларның барысында да булган.

Кара диңгез буендагы Туапсе портында алар быел атна-ун көн чамасы тордылар. Озын муенлы, мамонтныкыдай юан аяклы порт краннары теплоход трюмыннан көне-төне руда бушатты, куәтле чыгырлар беләк юанлыгы тимер арканнарны әле сүтеп, әле чорнап торды, трюм төбендә ара-тирә кырмыска зурлыгы гына булып бульдозер күренгәләп китте...

Абыйның вахтадан бушаган чагы. Икәү генә каютада утырабыз. Бала чакларны искә төшерәбез. Ачык иллюминатордан сизелер-сизелмәс кенә тибрәнеп зәңгәр диңгез күренә. Ерак офыкта суга тия язып кояш тәгәрәп бара. Җил каютага диңгез исен, көньяк үләннәре исен алып керә.

Бермәлне, хатирәләргә бирелеп, сүзсез калганбыз икән. Абый кинәт басынкы тавыш белән җыр башлады:

Урман аша юлларым...

Мин сискәнеп киттем. Арыш кырын, ефәк ябалдашлы юкәләрне, кәүсәләре яргаланып беткән карт имәннәрне, котырып үскән сусыл печән арасында качып утырган алсу битле җир җиләкләрен, салпы колаклы тугры Акбайны, әни кулларын, бала чагымдагы якын дусларым — Мидхәт белән Кәбирне искә төшерде бу җыр.

Ә абый диңгез җилләреннән уңа башлаган күзләрен күксел томан эчендә эреп югала барган тау тезмәләренә текәп җырлый бирде:

Урман аша, сулар аша
Сузсам җитми кулларым.

Ул төнне мин бик озак йокыга китә алмыйча яттым. Палубада кемнәрдер дөбердәп йөрде, яр кырыенда краннар шыгырдады, кайдадыр еракта әллә чит илләргә китеп баручы, әллә кайтып килүче пароходларның сузып-сузып кычкыртулары ишетелде.

Абыйны төнге вахтага чакырып алдылар. Ул өстәл лампасын яндырып киенде. Мине йоклый дип уйлады, ахры, одеалымны рәтләп япты һәм акрын гына каютадан чыгып китте.

Бераздан теге җыр яңадан ишетелде. Олы диңгез бу-

ендагы олы корабта бер көчәеп, төнге тавышлар арасында бер югала язып тибрәнгән таныш җырны тыңлавы рәхәт тә, ямансу да иде миңа. Океан уртасында да шулай җырлыйдыр инде абый, Африка ярлары буйлап йөзгәндә дә һавада татар җыры тибрәнә торгандыр, Яңа Зеландия утраулары янында да, Урта диңгезгә кергәндә дә...

Бәләкәй чакта ук җырларга маһир иде абый. Искә төште. Безнең урам малайларын станциягә поезд күрсәтергә алып баргач та нәкъ шул җырны җырлаган иде ич ул.

Абый бездән өч-дүрт яшькә олырак. Аягына кызыл эчле галош киеп йөри. Аның инде берничә мәртәбә район үзәгендә булганы да, әнигә ияреп калага барганы да бар. Без исә — яшьтәшләрем Мидхәт, Кәбир һәм мин — яланаяклы малайлар — Алпамша урманының теге ягында нәрсә барын да белмибез. Әллә кыр анда, әллә диңгез, әллә дөньяның чиге. Җил урман ягыннан искәндә гаҗәеп авазлар ишетелә ул яктан. Өлкәннәр поезд кычкырта, диләр. Бик зур машина ди ул поезд, әллә ничә трактор зурлыгы, ди. Көпчәкләре тимер юлдан тәгәрәп йөри икән.

Балачак календареның бизәкле битләре сизелми генә коела торды. Авыл тирәсендәге болыннар, әрәмәлекләр әллә ничә мәртәбә яшәрде, әллә ничә мәртәбә саргайды. Без генә белгән кош ояларында безгә генә таныш кошлар әллә ничә тапкыр бала чыгарды, әниләр әллә ничә тапкыр уракка төште. Алпамша урманы артыннан ишетелгән поезд тавышлары безнең күңелләрне көннән-көн ныграк тарта, ныграк кытыклый башлады.

Көннәрдән бер көнне үз мәшәкатьләре, үз дус-ишләре белән мәшгуль абыйны, Мидхәт белән икәү ялына-ялына, тәки поезд күрсәтергә алып барырга күндердек. Абый безне алдан ук кисәтеп куйды:

— Арыдым, дип елаштан булмаса гына.

— Еламыйбыз, — дидек барыбыз да бертавыштан.

Мидхәт белән без берсүзсез абыйга иярдек. Әнисе юып элгән керләргә берничә минут карап торгач, Кәбир дә урыныннан кузгалды.

Кизләү башындагы карама агачларын узгач, урылып беткән кыр, чүмәләләр күренде. Алпамша урманы ерактан гына караңгы, шомлы булып куркытып торган икән. Без якынайган саен, урман буйлары ачыла барды. Урман борынында юл өч тармакка аерылып китә икән. Нәкъ әкияттәге кебек. Абый юлларның уңдагысына да, сулдагысына да борылмады, ышанычлы адымнар белән урман эченә кереп китте. Без, өч яланаяклы, тирә-яктагы серлелеккә, матурлыкка хәйран калып сөйләшә-сөйләшә, абый артыннан теркелдәдек.

Кайсыдыр имән ботагыннан, юлга кара күләгә төшереп, козгын күтәрелде. Ерактан яшел стена булып күренгән усаклык арасыннан урман күгәрчене тавыш биреп куйды.

Ай-һай калын икән бу Алпамша урманы! Юл әле борыла-сырыла дымсу ешлыкларга кереп югала, әле озын яшел тасма булып еракка-еракка сузылып күренә. Агачларның исәбе дә, хисабы да юк. Эчәсе килә. Ял итеп алганда бик шәп булыр иде дә бит...

Ләкин абый галош табаннарын ялтыратып атлавын белә. Кулларын артка куйган. Зурлар шикелле нәрсә турындадыр уйланып бара.

Бөркү урман арасыннан бик озак барганнан соң, ниһаять, битләргә җиләс һава килеп бәрелде. Юкәләр арасыннан елтыр-елтыр ниндидер яктылык кисәкләре күренде.

— Менә Алпамша урманын да чыгып җиттек, — диде абый, артына борылып карамыйча гына.

Без, ниндидер могҗиза күрергә җыенгандай, бер күчкәрәк тупландык.

Баксаң, урманның бу ягында да нәкъ безнең авыл янындагы кебек болыннар, басулар сузылып, чүмәләләр, кибәннәр тезелеп киткән икән. Күк чите монда да җиргә килеп тоташкан. Офык буенда күкселләнеп тагын бер урман күренеп тора.

— Карагыз әле, кара, — дип кычкырды кинәт Мидхәт, кулын сыек томан йөзеп йөргән иңкүлеккә сузып. Иңкүлек төбендә, тонык кына ялтырап, ике озын сызык шәйләнә иде.

— Тимер юл шул инде, — диде абый, шатлыклы тавыш белән.

Станция дигәннәре бик гаҗәп икән, бер дә безнең авылга охшамаган. Калай яки чүлмәк түбәле ак йортлар, тимер баганалар, челтәрле күперләр... Дегет исе, сумала, мазут, корым исе...

Тимер юлга менеп, бармак очлары белән генә рельсларга, шпалларга төрткәләп караганнан соң, Кәбир курыкынган күзләре белән тирә-якны айкап алды да:

— Ә поезд кайда? — дип сорады.

— Поезд килмәгән әле, — диде абый. — Әнә, күрәсезме, кечкенә өй янындагы кисәүгә охшаган тимер баганаңы? Семафор ул. Шуның башы югары күтәрелгәч килә поезд.

Поезд килгәнче, абый безгә вокзалны да, башына кызыл фуражка киеп йөри торган сары чәчле хатынны — станция начальнигын да күрсәтергә өлгерде.

Башта офык артыннан кара төтен ургылып чыкты. Басынкы гына гудок тавышы ишетелде. Аннары ерак

борылыштан, әкияттәге аждаһа сыман сызгырып, поезд үзе килеп чыкты.

Ай-һай тиз килә икән ул, ай-һай ажгырып килә икән! Тәгәрмәчләрен күрсәң — берсе-берсе кеше буе. Ул пошкыра, ул дөберди. Безнең янга килеп җиткәч, паровоз дигәне, колак яргыч тавыш белән кычкыртып, чыжылдатып кайнар пар җибәрде. Без артка чигенеп куйдык. Ә инде ни үле, ни тере булып дер-дер калтырап торган Кәбир куллары белән колакларын томалады да, «Әни!» дип кычкырып, тимер юлдан читкә йөгерде.

Күз ачып йомганчы, тимер юл тирәсендә җил, өермә, ком бураны уйнатып, поезд узып та китте. Шул арада күзләр әлҗе-мөлҗе килде, башлар, битләр бер салкынайды, бер кайнарланды. Товарный поезд булган икән. Бәләкәй станцияләрдә туктап тормый, ди. «Кызык, моннан да зуррак станцияләр бар микәнни дөньяда?» дип уйладым мин, бу хәбәргә таң калып. Икенче поездны көтеп тормадык. Анысы караңгы төшкәч кенә килә икән. Болай да без бик канәгать, бик шат идек.

— Вагоннары йөз генә булмагандыр...

— Паровозында гына да унике тәгәрмәч...

— Күрдегезме, бер вагонга сыерлар төягәннәр.

— Ай-яй, җир уба дип торам. Бөтен дөньяны дер селкетте.

Шулай, поезд турындагы тәэсирләрдән айный алмыйча кайта торгач, кояш баеп, кич булганын сизми дә калганбыз. Моны беренче булып Кәбир абайлап алды.

— Караңгы төшә бит, урманны урап кайтабызмы әллә? — диде ул, адымнарын акрынайтып.

Җавап бирүче булмагач, Кәбир як-ягына каранып алды да безгә иярде.

Ә урман торган саен караңгылана бара, юл читендә куаклар кыштырдый, аяклар ниндидер чокырларга туры килеп, чак кына йөзтүбән капланмый каласың.

Бик озак бардык инде. Урманны әллә кайчан чыгып җитәргә тиеш кебек идек. Әллә адаштык микән?

Кәбирнең генә түгел, Мидхәт белән минем дә хәлләр әйбәт түгел. Бер-беребезгә карашабыз, кайнар учларыбыз белән тирләгән йөзләребезне, күзләребезне ышкыйбыз.

Абый гына тыныч кебек, як-ягына да каранмый, безгә дә игътибар итми. Гәүдәсен төз тотып, кәпәч картузы белән караңгылыкны сөзеп, бер көйгә атлый да атлый.

Әле ачыклыкта яктырак булган икән. Ешкынлыкка килеп җиткәч, тирә-як бөтенләй баз төбенә охшап калды. Шул гына җитмәгән иде — берзаманны кайдадыр нәрсәдер суга таш аткандагы кебек шапылдады, шуның

артыннан ук җан өшеткеч шомлы тавыш ишетелде. Нәкъ яшь бала елаган шикелле.

Барыбыз да абый янынарак елыштык. Кәбир ике кулы белән абыйның кәчтүн чабуына ябышкан килеш үксе үк башлады.

— Мәче башлы ябалак ич ул, нәрсәсеннән курыктыгыз шуның, — диде абый һәм бөтен урманны яңгыратып җырлап җибәрде.

Безнең эчкә җылы кереп китте. Озакламый Кәбир дә үксүдән туктады.

Абыйның тавышы басынкы, иркен, җыры олыларныкыча моңлы иде.

Урман аша юлларым,
Урман аша, сулар аша
Сузсам җитми кулларым.

Абый җырлый башлагач, караңгы юл кинәт яктырып, киңәеп киткәндәй булды. Шомлы кара пәрдә күтәрелде. Баш очында бихисап күп якты йолдызлар белән чигелгән күк җәймәсе балкып күренде.

Ул көнне урманны чыгып, камыллы кыр аша авыл утларына таба атлаганда, мин үземне ниндидер бер бик зур батырлык эшләгән малайдай хис иттем. Кәбир белән Мидхәт тә шундый ук хис кичерәләр иде, ахрысы, әледән-әле тамакларын кыргалап, аякларын абый сыманрак басып атлыйлар иде...

Зур теплоходның кайсыдыр почмагыннан һаман да әлеге моңлы җыр ишетелә. Юк, бу өн түгел, бу инде төш бугай. Мин йоклыйм, мин төш күрәм. Кайдадыр якында гына урман шавы да, дулкыннар тавышы да ишетелә. Хәтфәдәй йомшак болын юлы буйлап яланаяклы малайлар тезелешеп бара.

## ЕРЫК АВЫЗЛЫ ЭНЕКӘШЕМ

Энекәшем Нәсимне әйтәм. Энәгә җеп тагылгандай, минем арттан йөри. Җитмәсә, мин нәрсә эшләсәм, ул да шуны кыланган була. Мин койма башына менсәм, ул да шунда үрмәли, текә ярдан инешкә сикерсәм, ул да минем арттан сикерә. Табын янына утыргач кына... Мин вакытында туеп, вакытында торып китәм. Ә Нәсим өстәлгә куелган савытларның төбе ялтыраганчы тырыша. Үзе кызарып чыга, үзе мыш-мыш килә, әмма барыбер кулыннан кашыгын төшерми. Әни дә ачуланмый тагын үзенә.

«Ярты кашык аш калганчы, яман корсак ярылсын, шулай бит, улым», — дип үсендереп кенә җибәрә. «Сулай», — ди Нәсим моңа каршы, авызын ерып.

Әй, аптырамас идең лә аның күп ашавына да... Тимерче Зиннәт малае Фәргать ачуны китермәсә... Нәсимне ияртеп урамга чыгуымны саклап кына тора, пожар баш. Тәтел-тәтел үртәргә үк ябыша. «Капкорсаклар чыкты, ырый, ырый, капкорсаклар чыкты...»

Быел Фәргатьләргә фатирга Минзәлә шоферын керттеләр. Фәргатьнең үзенә охшаган. Пожар башлы, сипкелле бер абый. Машинасы биек, тәгәрмәчләре Нәсим буе гына түгелдер. Машина тирәсендә буталып йөргән өчен безгә яхшы сүз дә, яманын да әйтми үзе. Мәгәр машинага утырып йөрү теләге эчләребездән йөзләребезгә чыгып, дөрләп-ялкынланып торса да, безне күрмәмешкә салыша. Капка төбендәге чирәм өстендә таралып яткан вактөяк тимер-томырларын җыеп бирүебезне көтеп тора да, машинасын кабызып, безне җылымса төтен болыты эчендә калдырып, амбар ягына элдерә.

Билгеле инде, Фәргать ачуын бездән ала. Имеш, минем капкорсаклы энекәшем генә гаепле, имеш, шул гына боза бөтен эшне. Ул тагылып йөрмәсә, без икебез дә машина түрендә киерелеп йөрисе малайлар икәнбез... Ә нигә?! Дөрес сукалый бит чынлап та Фәргать. Машинадан тәгәрәп төшеп калмас дип кем ышандыра ала Нәсимне? Туп та — туп, ул да — туп... ерык авыз. Ишегалдында ялгызы гына калып уйнаса, тилгән күтәреп китәр дип курка үзен әллә тагын! Гомер буе шулай өлкән абыйсына тагылып йөрергә уйлый торгандырмы...

Басу ягыннан берсен-берсе уздырырга тырышып моторлар гөрләшкән көннәр иде. Мине кемдер тәрәзә кагып уятты: «Әнәс, Әнәс, чык әле, уян әле», — дип кычкыра үзе. Мендәрдән күтәрелеп карасам, рамнар арасында (кояш дип торам) Фәргать башы кызарып тора. «Чык әле, Әнәс!» — дип кычкыра Фәргать, кулын изи. Урынымнан сикереп торып, күлмәк белән чалбарымны йөгереп барышлый гына кидем дә ишегалдына атылып чыктым. Фәргать күз ачып йомган арада хәлне төшендереп бирде.

Теге өметсез дигән шоферлары бик үк өметсез түгел икән әле. Бүген станциягә бодай илтеп карарга уйлаганнар икән дә, шофер Фәргать белән мине дә утыртып барырга ризалык биргән.

Булды гына инде, булды гына. Күктән көткәнне җирдән бирде. Тегеләйгә алты чакрым, болайга алты — буладыр унике чакрым. И-их, бар икән рәхәт күрәселәр! Без чыклы чирәм өстендә гөрләшеп торган арада, өйдән Нә-

сим уянып чыкты. Кулларын җилкәсенә кушырып куйганлыктан, күлмәге күтәрелгән, күлмәк астыннан кендеге күренеп тора.

Нәсим ерык авызга карагач, Фәргатьнең чырае кар болыты төсенә керде, мин дә коелып төштем. Үземне җылы су өстеннән йөзеп барганда искәрмәстән генә салкын агымга килеп чыккандай хис иттем.

— Нәсим, акыллым, — дип сүз башладым мин, тавышымны мөмкин кадәр ягымлырак итәргә тырышып, — әни, эшкә киткәндә, мине уятып әйтеп калдырды, Нәсим бүген беркая да бармасын, чебешләрне сакласын, тилгән апкитәр юкса, диде.

— Ә кая безнең себесләр? — дип, авызын ерып җибәрде Нәсим.

— Чебешләр... ни... чебешләрне тавык бүген басып чыгара, диде әни.

Ул арада Фәргать, җитди-борчулы карашын өй кыегына юнәлтеп, мине җиңемнән сөйрәде:

— Әйдә, әйдә, вакыт юк минем сезнең сатулашканны тыңлап торырга, машина кетә.

Мин Фәргать артыннан атладым. Нәсим сүзсез генә безгә иярде.

— Кая барасың?! — дип җикеренде Фәргать, кинәт артына борылып.

Мин Нәсимне кычкырып кына җиңеп булмаячагын белә идем. Шуңа күрә эшне һаман да яхшылык белән көйләүдә иде өметем.

— Нәсим, акыллым, — дидем мин, ниһаять, соңгы чарага керешергә мәҗбүр булып, — баздан каймак алып чыгып бирсәм, иярмәссеңме безгә?!

Нәсим, телен чыгарып, иреннәрен ялап куйды. Иярмәм дигән мәгънәне аңлатып, башын селкеде.

Фәргатьнең йөзе яктырып китте.

Мин баздан әнинең май язарга дигән каймагын сосып чыктым.

Нәсим коштабак өстенә иелеп каймак белән мавыккан арада, без, җил кебек ыжылдап, бәләкәй капкадан кибет тыкрыгына чыгып сыздык.

Әмма Нәсим безне кибет янына җиткәнче үк куып тотты. Үзе мыш-мыш килә. Авыз-борыны, иякләре каймакка баткан. Яшелле-зәңгәрле күзләрендә яшерен шатлык балкый.

— Ә-ә! Әле син шулаймы?! — дип, ата каз кебек ысылдады Фәргать, Нәсимне, ачык күлмәк изүеннән тотып, койма буена тарта-тарта. — Туктале, әби-бабаң күрсәтмәгәнне күрсәтим әле менә мин сиңа хәзер.

Фәргать, бер кулы белән Нәсимнең күлмәген тоткан килеш, икенче кулы белән кычыткан сындырып алды һәм Нәсимнең ялангач аякларына күпме кирәк... Үрле-кырлы сикерде Нәсим, әмма тавышын-тынын чыгармады. Шул кирәк аңа, абыйсы әйткәнне тыңласын икенче. Шулай да эчтән генә Нәсимне кызганып куйдым. Бигрәк кансыз инде бу Фәргать...

Нәсим тыкрыкта аякларын уып калды. Без ары йөгердек. Машина, бодай төяп, Фәргатьләр капка төбенә кайтып туктаган иде. Кабинага утыруыбыз булды — шофер газга басты. Фәргатьнең әбисе «ашарга» дип кычкырып калды. Ашау кайгысы идеме соң бу минутта бездә! Тибрәнү ләззәтеннән, ян тәрәзәләрдән ургылып кергән җилдән, капка төпләрендә кызыгу катыш көнләшү белән карап калган таныш малайлар карашыннан тәмам исергән идек без.

Юл рәхәте сизелми дә калды — бик тиз уза икән машина алты чакрым араны. Әмма иртәрәк сөенгәнбез икән. Станциягә килеп кердек дигәндә, баллонның тыны чыкты. Алгысы бит, ичмасам, арткысы булса — куш тәгәрмәчнең берсе ничек тә түзәр иде әле.

— Юләргә акыл кирәкми шул, якын булгач, запас көпчәк алып тормаган идем, — дип, шофер абый үз-үзен сүкте.

Өчәүләп, кара тиргә төшеп, арткы тәгәрмәчләрнең берсен алга күчереп куйганчы, кояш төшлек турысына җитә язган иде инде.

Эшне төгәлләп, домкратны бушатып, ачкычларны җыеп, майлы кулларны әрекмән яфрагы белән сөртеп кабинага кереп утырырга әзерләнгәч кенә, шофер абый сыңарын алгач, ничектер канатсыз кош кебек шыксызланып калган арткы тәгәрмәч янына килде, итек табаны белән сырлы резинага типкәләп карады, сипкелләрен җемелдәтеп башын чайкады һәм, бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп, болай диде:

— Булмады бу, малайлар... Монысының да исәбе безне илтеп җиткерүдә түгел икән. Авылга кайтып килергә туры килә. Бушатабыз бодайны. Бик коры да түгел бугай әле ул. Таратып киптерә торырсыз...

Ярар, бушатырга тек бушатырга. Юл читендәге чирәмлеккә брезент җәеп, бодайны бушаттык. Тараттык.

Шофер абый безгә агач көрәк, явым-төшем булса дип, тагын бер брезент, карыныгыз ачса, кибет әнә генә дип, бер тәңкә акча калдырды.

Йөге бушатылгач җиңеләеп калган машина доңгыр-доңгыр кузгалып китте дә озакламый үр астына төшеп күздән югалды.

Кичәге яңгырдан соң көн кыздыра. Бодай кибә. Фәргать станция кибетенә барып ике кесә печенье алып килгәч, дөнья бөтенләй түгәрәкләнде. Телләр әйләнми башлаганчы коры печенье чәйнибез дә колонкага барып су эчәбез. Эч күперә, тик нишләптер тамак туймый.

Көн тизрәк үтсен дип, чиратлашып станция биналары яныннан әйләнгәләп киләбез. Бодай болгатабыз. Брезент читенә кырын ятып, тегене-моны сөйләшәбез. Әмма ни турында гына әңгәмә куертсак та, ахыр чиктә сүзебез ашау мәсьәләсенә әйләнеп кайта:

— Их, бер-ике телем ипи булса хәзер!

— Бер табак бәрәңге, диген...

Хәвефне беренче булып Фәргать күрде.

— Яңгыр килә, — диде ул, авызына капкан бодай бөртекләрен ашыга-ашыга чәйнәп йотып, урыныннан сикереп торды да күзләрен чекрәйтеп офыкка текәлде.

Мин дә аягүрә бастым. Чынлап та, күкнең Фәргать карап торган ягыннан, берсен-берсе кысрыклап, күгелҗем-кара болытлар күтәрелеп килә иде.

— Җилгә каршы килә, хәтәр коячак бу...

Монысын гына Фәргать әйтмичә дә яхшы беләидем. Хәзер күк күкри дип уйлап бетерүемә — дөбер-р-р! — тимер юлда тезелешеп торган вагоннар калтыранып куйды хәтта.

Ашыга-ашыга бодайны бер күчкә җыеп өйдек. Аскы брезент почмакларын күтәреп, өстән икенче брезентны капладык, аның читләрен ташкүмер, таш кисәкләре белән бастырдык.

Бөтен дөньяны томалап, күк гөмбәзенең буеннан-буена дөбер-дөбер килеп яшен ташлары тәгәрәп йөргәндә дә, җилләп-давыллап яңгыр коя башлагач та, тимер күпер астына кереп тирә-юньдәге мәхшәргә карап торганда да, мин: «Ярый әле Нәсимне ияртмәдек, — дип сөенеп бетә алмадым. — Нишләр иде ул монда ач килеш. Аннары менә бу яңгыры...»

Хәер, озакка бармады табигатьнең болай котырынуы. Сыекланып көлсу төскә кергән болытлар, юеш итәкләрен сөйрәп, Ослан таулары ягына авышырга да өлгермәде, ялтырап кояш чыкты.

Без, балакларыбызны сызганып, бодай күче янына йөгереп бардык. Юеш брезентны ачып карагач, бодайны чирәм кипкәч кенә таратырга булдык.

Хәвефнең икенчесен дә иң элек Фәргать күреп алды.

— Карале, машиналарның тәгәрмәчләре дә күренми, — диде ул, олы юлга төртеп күрсәтеп.

Станциядән ерак та түгел ике машина әле артка, әле

алга ыргыла, тик урыннарыннан кузгала алмыйлар, киресенчә, моторларын ныграк елаткан саен, тирәнгәрәк чума баралар иде.

— Безнең машина да килә алмый инде болай булгач, — дидем мин, кипкән иреннәремне ялаштыргалап.

Йөзенә курку катыш аптырау галәмәтләре чыккан Фәргать нәүмизләнеп кибет ягына карады.

— Бер генә тәңкә калдырып китте бит акчасын да, ичмасам...

Үзара сөйләшми-нитми генә бодай чәйнибез, олы юл буена барып, озаклап авыл ягына карап торабыз. Җиңелчә генә парланып яткан басуларда ник бер җан иясе кыймылдасын. Үр башында ялгыз комбайн сураеп калган. Инде теге машиналар да моторларын елатмыйлар, юлның икесе ике ягына кыйшаеп ярдәм көтәләр.

Станциядәге кешеләр дә, машиналар да, поездлар да күзебезгә күренми инде безнең хәзер — үтереп ашыйсы килә.

Машина кузгалып киткәндә, әбисе Фәргатькә әйтә башлаган, ләкин әйтеп бетерергә өлгерә алмаган сүз искә төшеп җанны бимазалый, эчне тырный, башны әйләндерә. «Ашарга» дигән иде бит ул, «ашарга» дип кычкырып калган иде... Их... Иртә белән Нәсим иреннәренә буялган каймак күз алдына килә дә авыздагы бодай чәйнәлмичә-нитмичә йотыла башлый.

Чалбар каешларын, бер сырга тарттырып, кысыбрак бәйләп куйдык. Фәргать әйтә, шулай бәйләгәч, ашказаны үзен тамак тук вакыттагы кебек тыныч хис итә, ди. Ай-һай, белмим... Тынычланса, сазга баткан машина моторы кебек еламас иде әле ашказаны...

Олы юлга ничә мәртәбә чыгып, ничә уч бодай чәйнәгәнбездер, берзаманны үр өстенә нindидер карамчык күтәрелеп килгәнен шәйләп алдык: теләр-теләмәс кенә бәхәсләшергә тотындык.

— Машина...

— Трактор бугай...

— Ат!

— Ат сиңа! Кеше!

— Кеше?

— Кеше шул!..

— Безнең авылныкы микән?

— Безнең авылныкы булмыйча...

— Вокзал ягына борылды.

— Юк, бу якка төшә...

Юлчыны тагын берничә минут күзәтеп торгач, мин хәлсез тавыш белән пырхылдап көлеп җибәрдем. Фәргать сәерсенеп миңа карады.

— Нәсим ич ул, — дидем мин, эчем авыртса да көлүдән тыела алмыйча.

— Вәт капкорсак, — дип сузды Фәргать, аптыраудан ни әйтергә белмичә байтак кына сүзсез-өнсез торганнан соң.

Ни өчен икәнен әле үзебез дә тәгаен генә төшенеп җитмичә, юл читендәге чирәм өстеннән Нәсим каршына йөгердек.

Кара-каршы килеп туктадык. Без дә елмаябыз, ул да авызын җыя алмый. Йөзе кып-кызыл. Түбәтәен чалбар кесәсенә тыккан. Бер кулында төбе ләпеккә буялган тырыс, икенчесендә төенчек. Маңгаена биш тиен акча зурлыгы балчык кисәге ябышкан, аяклары тубыктан итек кигән кебек — бер генә ак җире дә юк.

Мин Нәсимнең өс-башын күздән кичергән арада, Фәргать төенчек белән тырыска үрелде.

— Ас анда, асны түкмәгез, — диде Нәсим, тырыска ымлап, — әни җибәлде, масина кискә кылын гына килә...

Кулындагы әйберләрне безгә биргәндә, Нәсимнең зәңгәр сатин күлмәге күтәрелеп, ләпек чәчрәгән кендегे күземә чалынды. Шул вакыт минем башыма бер-берсенә бәйләнмәгән ике уй килде: «Нишләп капкорсак булсын әле ул, һәммәбезнеке кебек матур ич аның эче... Кешегә ияреп кенә йөри ала дип торам мин аны тагын... Ә ул әнә — яңгыр димәгән, ерак димәгән — ялгызы чыккан да киткән... Яшен ташы белән бер...»

## АКМӨГЕЗ

Кинәт бөтен урман-кырларны ату тавышы яңгыратты.

Тәлгать сискәнеп китте. Чаңгылары берсе өстенә берсе менеп, чак кына егылмыйча калды. Еракта, авыл ягында, ялкау гына бер эт өреп куйды да, тирә-як тагын тынып калды.

«Пошилар... пошиларны, Акмөгезне аттылар» дигән хәвефле уй тырнап узды Тәлгатьнең күңелен. Ул ашыга-ашыга борылды һәм, кулларын еш-еш бутап, кире урманга таба шуып китте. Сырлы-сырлы тоташ стена булып күренгән урман бер ерагайды, бер, бөтен күз алларын каплап, каршыга ук килеп басты. Тәлгатьнең сулышы капты. Керфекләре, ирен читләре салкын бәс белән капланды. Ә башында һаман да «пошилар» дигән уй бөтерелде. Урман авызындагы агачлар карлы кулларын сузып каршы алдылар Тәлгатьне. Кайдадыр урман ешлыгында нигәдер шомланып ялгыз саескан тыкырдады.

Әнә уртасында пар каен үскән аланлык. Каеннар арасында тал чыбыкларыннан үреп ясалган утлык. Утлыкта әле печән күп калган, тик аланлыкта пошилар юк иде инде. Кар өсте эреле-ваклы эзләр белән чуарланган. Якынрак килеп карагач һәм яшь усаклыкка таба сузылып киткән кан тапларын күргәч, Тәлгатьнең йөрәге жу итеп китте. Эх, тәки атканнар... Пошилар әле бу яктагы урманнарда берничә ай элек кенә күренә башлаганнар иде. Бу турыда Чыршылы авылында Тәлгатьтән башка белүче дә юктыр. Пошиларны башта кулга ияләштерергә, аннары гына иптәшләренә күрсәтергә теләгән иде Тәлгать. Бүген дә аның пошиларга печән илтеп кайтып килеше иде. Тәлгать Акмөгез дип исем биргән, тармакланып торган зур аксыл мөгезле, киң күкрәкле ата поши аннан бүген бөтенләй диярлек ятсынмады. Авызына утлык рәшәткәләре аша сузылган ипи телемен бөтереп капты да зур кара күзләрен тутырып, нигәдер гаҗәпләнгәндәй, Тәлгатькә карап тора башлады. Тәлгать агачлар арасына кереп барганда, сылу гәүдәле ана поши да утлык янына килеп калды... Инде менә канлы эзләр... Кем булыр бу, кем булыр? Тәлгатьләр авылында андый явыз кешеләр дә юк бугай ич. Бәлки инде, пошиларның берсе үлгәндер. Теге явыз кеше аның тиресен тунап ятадыр. Тәлгать, авыр уйларга бирелеп байтак кына бер урында басып торганнан соң, канлы эзләр буенча ап-ак үр өстенә — яшәреп утырган усаклыкка таба юнәлде... Кан таплары инде анда-санда гына күренгәли. Әллә яраланган пошиның каны агып бетте микән?.. Бәлки, җәрәхәте куркынычлы булмагандыр, бәлки, ядрә аның тиресен генә сыдырып узгандыр.

Ниһаять, усаклык та артка калды. Алда ачык кыр күренде. Урман авызындагы куаклар белән челтәрләнгән кояш күксел офыкка төшеп бара. Җил көчәйгән. Тәлгать, урман ешлыгыннан яктыга килеп чыккач, башта берни дә күрә алмыйча торды. Аннары кинәт аның күзләренә кара шәүләләр чалынды. Урман култыгындагы киң аланны иңләп чыккан пошиларны таныгач, Тәлгатьнең йөрәге кысылып куйды. Ана поши аксабрак чаба. Ләкин Акмөгез аны ташлап китми. Әледән-әле туктап көтеп ала. Башын югары чөеп артка карап тора, аннары тагын йөгереп китә. Алан уртасында тагын бер карамчык кыймылдый. Башта Тәлгать аны нәрсәгә дә охшата алмады. Бераздан, күзләре яктылыкка ияләшә төшкәч, әлеге карамчыкның өстенә кыска ак кием кигән кеше икәнлеген абайлады. Ак киемле кеше пошиларның юлын кисәргә чамалый. Үзе бик ашыга бугай — ара-тирә, як-

якка чайкалып, егыла язып кала. Әнә ул егылып та китте. Әмма шул минутта ук яңадан аяк өстенә басып, мылтыгын күтәрде. Бер якка кыйшая төшеп, пошиларга төзи башлады.

— Тукта-а-а!.. Тукта-а!

Тәлгатьнең үз тавышы үзенә сәер булып тоелды. Ул, коты очып, мылтык шартлавын көтте — мылтык тавышы ишетелмәгәч, янә кычкырды. Ак киемле чайкалып китте, йөзен Тәлгатькә таба борды. Аннары, мылтыгын иңенә асып, ашыга-ашыга урман ягына китеп барды.

— Юк, миннән алай ансат кына котыла алмассың, барыбер эзеңә төшәм мин синең, — диде Тәлгать һәм, таякларын еш-еш уйната-уйната, ак киемле артыннан ташланды.

Пошилар алан уртасында ярымтүгәрәк ясап борылдылар да, яңадан урманга кереп, күздән югалдылар. Кояш офык артына китеп, шәфәкъ кансу-кызыл төскә керде. Җил һаман саен көчәя барды. Урман артыннан авыр болытлар ишелеп чыкты. Кар ява башлады.

Ак халатлы берничә мәртәбә артына борылып карады. Бер караганда, нәрсәдер кычкырды да бугай. Тик Тәлгать моңа әһәмият биреп тормады. Иреннәрен тешләп, күзләре белән ак киемлене ашардай булып йөгерде дә йөгерде. Урман буендагы олы юлга чыкканда, ак халатлы Тәлгатьне байтак кына артта калдырып өлгергән иде инде. Тәлгать тә олы юлга чыкты. Ара күзгә күренеп кыскарды. Бераздан ак киемле, кырт кына борылып, урманга кереп китте. «Чаңгылары киң — карның тирән урынын сайлый, — дип уйлады Тәлгать ачу белән, — барыбер тотам». Әмма урман ешлыгына кереп югалган эзләр буенча никадәр генә тиз барырга тырышса да, ак киемлене Тәлгать бүтән күрә алмады. Эзләр чәбәләнделәр-чуалдылар, бормаланып-сырмаланып, чытырманлыктан чытырманлыкка сузылдылар. Инде эңгер дә төшә башлады. Урман ниндидер шомлы тавышлар чыгарып шаулады, ыңгырашты. Бәләкәй генә аланчык аша чыкканда, Тәлгать чаңгысы белән ниндидер карамчыкка басты. Бу — яшел брезент белән тышланган ике бармакчалы бияләй — аучы бияләе иде. Тәлгать аны тиз генә иелеп алды да кесәсенә бөтереп тыкты. Тәлгатьнең аяк табаннары кызыша, беләкләре сызлый, күз аллары әлҗемөлҗе килә иде. Сибәләп торган кар инде ишеп-ишеп яварга кереште. Тәлгатьнең башына кинәт: «Әгәр дә теге кеше берәр агач артына качып саклап торса, — дигән шомлы уй килде. — Нигә мине эзәрлеклисең, — дип атты китте, ятарсың язга чаклы кар астында...» Тәлгать

туктап тирә-яктагы тавышларга колак салып торды. Кар күмгән сукмак читендәге сынган башлы бер агач бигрәк тә шомлы ыңгыраша. Еракта, зәңгәрсу эңгергә төрелгән куаклар арасында, кемдер әкрен генә сызгыра сыман. Җил әле ерагая, әле, бөтенләй якын ук килеп, агач ботакларын тотып селки, битләргә, җилкәләргә учлап-учлап кар сибә. Ак киемлене тоту турында уйларга да ярамый инде хәзер — эзләр чак-чак кына шәйләнә, эңгер дә куерганнан-куера бара. Тәлгать туктап өс-башын какты. Кесәсеннән теге бияләйне тартып чыгарды. Бияләйнең эчен-тышын әйләндергәләп карады... Түбән очта яшәүче балта остасы Галимулла агай бияләйләренә охшаган лабаса бу... Әйе, әйе, шуныкы булырга тиеш. Көзен Галимулла агай мәктәп мастерскоена такта китергән иде. Шунда Тәлгать киеп тә караган иде әле бу бияләйне. Ике бармакчалы, эче ак мех, яшел брезент белән тышланган... Теге елны да, ау сезоны ачылмас борын төлке атып кайтканы өчен, штраф салганнар иде ич Галимулла агайга. Ә быел, күрәсең, поши итеннән авыз итмәкче булган. Димәк, ул Тәлгатьне эздән яздыру өчен генә кергән урманга. Тәлгать бияләйне кесәсенә салып куйды да кайтыр якка борылды...

Битләргә, муеннарга салкын чыбык очлары кадала, авыз кибә, эч яна, тирләп юешләнгән чәч учмалары маңгайга ябыша. Утырасы яисә карга сузылып ятасы килә. Юк, ярамый. Тәлгатьнең ишеткәне бар: адашкан кешеләр, хәл җыеп алам дип, карга утыралар икән дә... катып китәләр икән... Инде чыгып җитәргә дә күп калмаска тиеш. Әнә анда күкселләнеп усаклык күренә бугай. Ләкин нигә якынаймый соң ул, нигә һаман бер урында гына тора. Чаңгылар чуен кебек авырайдылар. Сөйрәп барыр хәл юк. Күз алдында инде ак һәм кара төсләрдән гайре бернәрсә дә калмады. Урман һаман да шомлы тавыш белән шаулый, сыкрана, ыңгыраша. Тәлгать, иңе белән юан агач кәүсәсенә терәлеп, күзләрен йомды. Рәхәт, җылы... Аз гына, бик аз гына утырып торырга кирәк... Тәлгать чаңгыларын салмыйча гына агач төбенә чүгәләде. Тагын да рәхәтрәк булып китте. Хәзер, хәзер... Тагын ике генә минут утыра да тора Тәлгать, кузгала... Урман шавы ничектер басынкыланды, ераклашты... Тагын бераз гына. Тагын бер-ике генә минут... Мичтә чырт-чырт килеп утыннар яна, имеш. Тәлгатьнең әнисе ашарга пешереп йөри. Ул да түгел тупсасына кадәр каерылып ишек ачыла да өйгә салкын җил ажгырып керә. Аннары ут сүнә. Өй тулы кар, өстәл өсләрендә, мич буйларында буран уйный, имеш. Буран арасыннан кар шыгырдаган тавыш ишетелә. Шыгырдау якынлаша. Кемдер, Тәлгать-

нең йөзенә якын ук килеп, тирән итеп сулый. Тәлгать «Әни!» дип кычкырырга тели — кычкыра алмый, ә теге үзенең җылы сулышын Тәлгать битенә өрә дә өрә. Аю, ахры, дип уйлый Тәлгать, коты очып, һәм башын юрган астына яшерергә тели, әмма ни өчендер куллары селкенми. Теге нәрсә Тәлгатьнең йөзенә юеш иреннәрен дә тидереп алды.

Тәлгать дерт итеп уянып китте, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде. Ниндидер зур кара җан иясе пошкырып, кар туздырып артка тайпылды. Тәмам ката башлаган буыннарын көч-хәл белән хәрәкәтләндереп, Тәлгать аяк өстенә басты, әлеге җан иясенә текәлде. Тәлгать башта үз күзләренә үзе ышанмыйча торды, аннары шатланып: «Акмөгез!» — дип кычкырды. Каты бураннан соң тынып калган урман акрын гына гөрләп җавап кайтарды: «Мө-гез-гез...»

Әлеге җан иясе чыннан да Акмөгез иде. Әнә ерактарак тагын бер карамчык шәйләнә. Анысы ана поши булса кирәк. Акмөгез, икеләнгәндәй, бер урында иснәнеп торды. Бөтен гәүдәсен дерелдәтеп кагынды, башын алга сузып, Тәлгать янына килде, кайнар танавын Тәлгатьнең салкын учына тидереп алды. «Адаштым, Акмөгез, адаштым, юлны күрсәт миңа», — дип пышылдады Тәлгать, кулларын Акмөгезгә сузып. Поши аны аңлагандай башын чайкады, сынын катырып, озын аяклары белән кар ера-ера, аланлыкның ана поши басып торган читенә китеп барды.

Ниһаять, поши эзләрен югалтмаска тырышып бара торгач, Тәлгать урман кырыена килеп чыкты. Үр өстендә җем-җем килеп авыл утлары күренә иде.

## ВЕРОЧКА

Безнең өй алты почмаклы булып, бер ягында — үзебез, ә икенче ягында әнисе Татьяна түти белән биш яшьлек чуваш кызы Верочка яши.

Без, мин һәм тирә-күршедәге татар малайлары, чувашча бер авыз сүз белмибез. Ә Верочканы, бәләкәй булса да, безнең авылга килгәненә әле өч-дүрт кенә ай булса да, аңлыйбыз. «Чөясе килә» дип кычкырса, бу аның ашыйсы килә, диюе була. «Яшка» дигәне — аш, «поты» дигәне — ботка, «чөмер» дигәне — яңгыр, «юратам» дигәне шул, безнеңчә дә яратам була инде...

Әниләр, кырга эшкә киткәндә: «Карагыз аны, Вероч-

кага күз-колак булыгыз, базга егылып төшмәсен, шырпы белән уйнамасын», — дип, безне һәрвакыт кисәтеп китәләр. Югыйсә бер дә күз-колак буласы юк ул Верочка дигәннәренә. Әллә төнлә дә йокламый инде. Иртән торып ишегалдына чыккан саен исебез китә: тешле тәгәрмәчләрнең асты өскә килгән, чыра канатлы уенчык самолет гөрләвек эзендә аунап ята. Ә Верочка үзе исә бакча артында ярып пешергән бәрәңге белән акы ашап йөри. Акы белән бәрәңге дигәннән, шундый кызык гадәтләре бар инде Верочканың: кыярга — шикәр комы, коймакка тоз сибеп ашарга «юрата».

Верочканы бакчадан тотып керәбез. Ә ул тартыша, елый, тыпырчына, кайчагында кулны тешләргә дә күп алмый. Балчыкка буялган иреннәрен, чыклы үләндә кызарган ялангач тәпиләрен җылы су белән юып, тузгыган чәчләрен (чыбыркы үргәндәге кебек дүртләп яисә алтылап) үреп җибәргәч, менә дигән кыз була тагын. Үзе дә шатланып бетә алмый. Болай да ләйсән тамчысы кадәр генә күзләрен бөтенләй кысып бетерә язып, чәй янында безнең әни китереп куйган шикәр кисәкләреннән дә ваграк тешләрен җемел-җемел китереп елмая.

Якты кояш, карлыгачлар белән чигелгән зәңгәр һава, бәбкә үләне күпереп үскән иркен ишегалды һәм нәни Верочка көлүе...

Туктагыз әле, сүз белән мавыгып, төп вакыйгадан читкәрәк киттем бугай... Ә бит шундый якты көннәрнең берсендә Верочка чынлап та югалды. Башта сизмичәрәк тордым мин бу хәлне. Сөян агачыннан кылыч юнып маташа идем. Аннары исемә килеп тирә-ягыма карасам — юк Верочка... Бакча сукмагында сынык тарагы аунап ята — үзе юк, чирәм арасында ватык көзгесе ята — үзе юк. Бакча артында юк, базда, тыкрыкта юк... Ике бармагымны иреннәремә куеп сызгыруга, күрше малайлары Хәлим белән Тәлгать кереп җитте. Алар да күрмәдек, диделәр. Инде хәзер өчәүләп эзлибез...

Эзли-эзли кич булдырдык. Көтү кайтты. Әниләр кайтты. Ах-ух килделәр. Миңа әләгә инде хәзер таякның юан башы. «Йөзең ак булгыры малай, — ди әни, — күзең маңгаеңа менмәгәндер, курчак түгел ләбаса ул сиңа, тере кеше...» Татьяна түти аны-моны дәшми. Куштанлы күлмәкләрен җилфердәтеп, киндерә белән бәйләнгән галошларын ләштердәтеп, ишегалды буенча чабулап йөрүен белә.

Берзаманны ул ашыгып бакчага чыгып китте. Һәм озакламый анда ниндидер тавыш-гауга купты. Читән өстеннән сузылып карасак — Татьяна түти мунча ишеген каерып ачып куйган. Үзе эчтә кемнедер орыша.

Бераздан мунча авызында Верочка күренде. Өсте-башы чат көл, чат корым, күкрәгенә ак кашлы соры көчек кысып тоткан. Татьяна түтинең кулларын бутый-бутый елый-көлә сөйләвеннән шуны аңладык — Верочка әлеге көчекне тыкрыктан тотып кергән икән. Малайлар тартып алмасын дип, аны мунча чоланына, алай гына да тынычланмагач, мунча эченә үк алып кереп киткән һәм мунча мичендә оя ясарга керешкән.

Ярар, буласы булган, буявы сеңгән инде. Эш болай хәвеф-хәтәрсез генә тәмамлангач, барыбыз да шөкер иттек.

Менә шуннан соң башланды хәлләр. Верочка инде безгә әйләнеп тә карамый. Иртәдән кичкә чаклы елтыр күзле, ак кашлы (шул кашлары өчен без аңа Дүрткүз дип исем бирдек) көчеге тирәсендә. Буш әрҗәне лапас почмагына терәтеп өй дә ясап куйды аңа, әнисенең иске бишмәтеннән урын-җир дә әзерләде. Көчеге дә үзенә ошады тагын. Тоз сибелгән коймакны койрыгын болгый-болгый бик яратып ашый. Ике-өч көннән чәңгел-чәңгел өрергә дә өйрәнде. Ишегалдындагы бәбкә үләне арасыннан колаклары гына күренә үзенең, ә үзе, зур этләр кебек гайрәтләнеп, күбәләкләр, коңгызлар куып йөри.

Монысы әле аның баласы гына, анасы соңрак, яшенләп яңгыр яуган төндә булган икән. Без берни дә сизмәгәнбез, йоклаганбыз. Иртән Татьяна түти сөйләде.

Төнлә белән уянып киттем — янымда кыз юк, ди. Алай карыйм, болай карыйм, юк Верочка, юк инде, ди. Ә тышта дөбер-шатыр күк күкри, ялт-йолт яшен яшьни, ди... Шуннан нишләгән Татьяна түти? Башына капчык бөркәнгән дә ишегалдына чыккан. Яшен яктысында Верочканы күреп алган. Эт оясы янында чүгәләп утыра, ди. Ул арада Верочка, төнге сәяхәте өчен үзенә яхшы ук эләгәчәген сизеп, ахры, өйгә атылып кереп киткән дә юрганга төренеп тә яткан.

— Кызым, нәрсә булды? — дип сораган Татьяна түти, өйгә кергәч.

Верочка, юрган астыннан башын чыгармый гына:

— Дүрткүзне карадым. Оясына «чөмер» яумый микән, — дип җавап биргән.

Утны сүндереп, күпмедер вакыт узгач, Татьяна түтинең кулы юеш, салкын нәрсәгә орынган. Тагын сикереп торган. Тагын ут кабызган. Караса, юрган астында Дүрткүз койрыгын болгап ята икән.

«Бу кыз әллә ниләр кылана башлады, инде кешегә ышанып өйдә калдырып булмый», — дип, ул иртән Верочканы үзе белән эшкә ияртеп китте. Верочка Дүрткүзне дә алъяпкычка төреп күтәрергә ниятләгән иде дә, кая

ул, Татьяна түти бер сүз белән генә өзде: «Нәрсә, көчегеңне басуда бүре кабып йотуын телисеңмени?» — диде. Шым булды Верочка...

Әй, әллә нинди көн булды ла ул. Шатлыклары, кайгылары барысы бергә буталып бетте ул көнне. Рәте белән сөйлим, алайса.

Верочка югында Дүрткүз белән уйнап кинәнергә исәплəгән идек башта. Тик безне бер дә яратмады Дүрткүз. Ятсынды, дип әйтеп булмый, тик шулай да Верочка белән уйнаган шикелле шатланып сикергәләмәде, күбәләкләр артыннан йөгермәде. Оясыннан башын чыгарып, без куйган ризыкны иснәштергәләп алды да янә урынына кереп сеңде. Башын ал аяклары өстенә салган, мин сиңа әйтим. Күзләре әллә кая, еракка, тау башындагы болытларга төбәлгән.

Кояш кызарып тегермән басуына таба авышты. Капка шыгырдагач, без башта әниләр кайтты дип уйлаган идек. Аннары кинәт сискәнеп киттек. Хәлим елый ук башлады. Мәктәптә укырга да, колхозда эшләргә дә теләми торган колга Гарифулла иде капкадан керүче. Китте баш, калды муен утырып — барыбызны да елатмыйча күңеле булмаячак моның. Чалбар балакларын юри сызганып куйгандырмы — сыйраклары тырмавыч сабы кадәр.

Лапастан кинәт кенә Дүрткүз чәңгелдәп өреп чыккач, Гарифулла артка тайпылып куйды. Авызын зур ачып, бер урында селкенгәләп тора башлады. Дүрткүз исә һаман гайрәтләнде. Гарифулланың әле алдына, әле артына төшеп чәңгелдәде.

Тагын бераздан Гарифулла Дүрткүзне бөтен ишегалды буенча пыр туздырып куып йөри иде инде. Тавыклар кыткылдый, Хәлим белән без елыйбыз. Шыңшый-шыңшый Дүрткүз йөгерә. Аның койрыгына басардай булып Гарифулла чаба.

Икенче мәлдә Гарифулла иелеп Дүрткүзне эләктереп алуы булды, лапас түбәсенә атып бәрүе булды, канаган бармагын кысып, урамга чыгып йөгерүе булды...

Дүрткүз исә, бүрек кебек тәгәрәп, чуерташтай шома, каты сукмакка килеп төште дә тынсыз калды. Бетте Дүрткүз. Үлде. Чакырып та карадык без аны, әйләндергәләп тә карадык, төрткәләп карадык... Кыймылдамый Дүрткүз.

Әни эштән кайтты. Татьяна түти, Верочка... Еласын иде, ичмасам, ул. Юк. Еламый. Кулындагы кыр чәчәкләре чирәм өстенә төшеп сибелде. Йөзе агарып китте. Күзләренә курку билгеләре чыкты.

Менә ул Дүрткүз янына килеп чүгәләде. Үз телендә нидер әйтеп, әрем исе аңкып торган нәни куллары белән

Дүрткүзнең колак артларын, муеннарын сыйпады. Шул чагында кыймылдамый яткан көчегебез кинәт күзләрен ачты, башын күтәрде. Берни дә булмагандай сикереп торды. Койрыгын болгый-болгый, Верочканың күзләренә карады.

Без дәррәү шатланып көлеп җибәрдек.

— Верочканы көтеп, мутланып кына яткан ул, — диде Татьяна түти.

— Сабыйлар кулы шифалы була шул, — дип өстәде әни.

Без көләбез, ә Верочка ни өчендер елый иде...

* * *

Син инде хәзер үскән кыздыр, Верочка. Кем белә, бәлки, институтта укыйсыңдыр.

Сусыл чирәмнәрен елтыр канатлы җитез карлыгачлар сыйпап-сыйпап узган якты ишегалдын, чирәм өстендә йон йомгагыдай тәгәрәп йөргән Дүрткүзне, чувашча белми торган татар малайларын хәтерлисең микән син, Верочка?

## КАЕН ЯКТЫСЫ

Урманның иге дә, чиге дә, очы да, кырые да юк. Барабыз да барабыз, барабыз да барабыз. Югарыда, агач башларын шаулатып, җил йөри. Ә монда, билгесез чакрымнарга сузылган урман ешлыгында, тын, хәтта бераз бөркү.

Юлсыз-нисез бару Мөслимәне генә түгел, инде мине дә тәмам ялыктырды. «Әйләнгеч булса да, юл яхшы», — дип, тикмәгә генә әйтмәгәннәр, күрәсең, бабайлар. Ә мин, имеш, турыдан гына чыгам. Әледән-әле күңелгә: «Инде адашмадык микән», — дигән шөбһәле уй килә. Күптән чыгып җитәргә тиеш идек инде югыйсә. Башымны аз гына бора төшеп, күз чите белән генә Мөслимәгә карыйм. Ул тәмам йончыган, бичара. Өстендәге мәктәп формасының бер җиңе каядыр эләгеп ертылган. Тузгыган чәчләренә ылыслар, пәрәвез җепләре сырышкан. Үзе менә-менә елап җибәрер төсле.

Әллә утырып ял итеп алырга микән? Юк, ярамый. Караңгыга кадәр ничек тә чыгып калырга кирәк. Авыл урманы түгел бит бу — тайга, йөзләрчә чакрымнарга сузылган тайга. Ичмасам, шырпы да алынмаган.

Мөслимә эти ягыннан безгә туган тия. Былтыр искәр-

мәстән генә әнисе үлеп киткәч, мин аны үз яныма, Себергә чакырып алган идем. Быел ул Ангарадагы елга техникумына укырга керергә йөри.

Безнең поселоктан Ангарага күп булса өч чакрым. Бу — турыдан, урман аша шулай. Ә олы юлдан барсаң, алтмыш чакрымга җыела. Берничә көн рәттән яңгырлар койганлыктан, машиналар сирәк йөри, йөрсәләр дә, аларга ышаныч аз: сазламыкка кереп баталар да көне буе буксовать итеп яталар. Саргаеп утыр син алар янында. Менә шуңа күрә дә инде без җәяүләп киткән идек.

Мин әледән-әле Мөслимәнең хәлен сораштырам. «Армыйсыңмы, арсаң, утырып ял итәрбез», — дим. Ул: «Юк, армыйм», — дигән була. Сизеп торам: үзе еларга җитешкән, сер бирми, янәсе. Әле ярый кесәгә берничә кекс төреп тыккан идем. Аларны ашап алдык. Мөслимәнең ашыйсы да килми: иреннәрен теләр-теләмәс кенә кыймылдата, үзе куркынып як-ягына карана.

Адаштык, чынлап торып адаштык. Югыйсә өч чакрымны биш сәгать бармас кеше. Ләкин моны Мөслимәгә сиздермәскә кирәк.

— Чыгып җитәбез бугай, шәһәр гөрелтесе ишетелә...

Мөслимәнең күңелен күтәрер өчен, мин әледән-әле шулай сөйләнәм. Бераз баргач: «Инде краннар, вышкалар күренә башларга тиеш», — дип, агач башына менеп китәм. Күз күреме җирдә киртләч-киртләч диңгез кебек кара-яшел урман. Ичмасам, болытлар да таралмый. Кояшның кайсы якта икәнен күрер идең. Мөслимә, агачка сөялеп, тилмереп яхшы хәбәр көтә.

— Кит, Мөслимә, күзеңә чүп керер.

— ?

— Нәрсәдер күренә сыман...

Тагын иксез-чиксез урман, тагы газаплы юл. Битләргә чыбык очлары бәрелә, күзләргә пәрәвез җепләре сырыша, аякларга әллә нинди кыргый үләннәр чорнала. Инде караңгы да төшә башлады, күләгәләр куерды. Бөтен тирә-як зәңгәрсу-соры томан белән өртелде.

Җитмәсә, Мөслимә артка кала.

— Ардым, — диде ул, ниһаять.

Бу сүздән мин әллә кайчан курка башлаган идем инде.

— Ял итик соң...

Мөслимә, аптырап, як-ягына каранды.

— Утырыйк менә шунда, — дидем мин, бер юан чыршы төбен күрсәтеп.

Мөслимә кинәт: «Инде нишлибез, Равил абый, инде нишлибез, адаштык бит, инде нишлибез?» — дип такмаклый-такмаклый еларга кереште.

— Юләрләнмә, Мөслимә, тукта хәзер үк, соң өч чакрымлы юлда кеше адашамы? Син зур кыз бит инде, үзең капитан булырга йөрисең...

Мөслимә тынычланган сыман булды.

Мин өстемдәге курткамны салып, чыршы төбенә җәйдем.

— Ят менә шунда, азрак йоклап ал, мин сине уятырмын.

Мөслимә, кулларын тезләре арасына тыгып, бөгәрләнеп ятты. Әмма, бер-ике минут яткач ук, башын күтәрде.

— Мин барыбер йоклый алмыйм монда, шундый куркыныч.

— Ә нәрсәдән куркырга? Бу урман аша безнең монтажчылар көне-төне йөреп тора... Йокла, Мөслимә, йокла.

Чыннан да куркыныч иде бу төнге урманда. Озакламый караңгылык шундый куерды, әйтерсең безне ниндидер зур кара гөмбәз белән каплап куйдылар. Әле анда, әле монда чыбык сынган тавышлар ишетелеп китә, агач башларында һаман да, шомлы авазлар чыгарып, тынгысыз җил йөри. Мин шабыр тиргә батып утырам. Менә-менә хәзер өскә аю килеп чыгар төсле.

Мөслимә дә, әледән-әле сискәнеп, башын күтәрә. Бермәлне ул бөтенләй сикереп торып утырды. Үзе дердер килә, үзе миңа елыша.

— Куркам, Равил абый, әнә, әллә нинди утлар йөри.

Мин, күзләремне зур ачып, караңгылыкка текәлдем: бездән илле-алтмыш адымнарда гына очкыннар сибелеп киткәндәй булды.

— Ә-ә... каен яктысы, — дидем мин Мөслимәгә һәм тел очыма шундый матур сүз килүенә үзем дә гаҗәпләнеп куйдым. «Нигә борчылам соң? — дип юаттым мин үз-үземне. — Бу төн барыбер үтәчәк бит».

Аннары Мөслимәнең чәчләреннән сыйпадым.

Әллә баягы «каен яктысы» дигән сүзләрем, әллә Мөслимәнең чәчләренә орыну минем уйларымны бөтенләй яктыртып җибәрде. Күз алдыма бөтен матурлыгы, күркәмлеге белән туган авылым килеп басты.

— Синең каен яктысын күргәнең бармы, Мөслимә?

— Юк...

— Хәтерлисеңме Шәриф бабайлар каенын...

Мин Мөслимәгә акрын гына тугын авылның елгалары, таулары, урманнары, болыннары турында сөйләргә керештем.

Бераздан ул тигез сулыш алып йоклый иде инде...

Мөслимә яктыра башлагач кына уянды.

Төнлә утлар ялтыраган якта, чыннан да, ялгыз каен үсеп утыра иде. Ә барыбрак карагач, хәйран калдык: без яңадан кичә үзебез чыгып киткән җиргә әйләнеп кайтканбыз. Әлеге каен яныннан без яши торган поселокның бакчалары башлана иде.

## АВЫЛЫМ САНДУГАЧЫ

### 1

Әллә кайчан инде, бала чактан ук, мин Гөбенә буендагы әрәмәлектә сандугач сайравын ишетеп хәйран калган идем. Әмма ул сандугачны үзем белән су коенырга килгән малайларның кайсысыдыр таш атып куркытты. Әллә артык нечкә күңелле булганга, әллә сандугач сайравын гомеремдә беренче тапкыр гына шулай игътибар биреп тыңлаганга, гүзәл җыры ярты юлда өзелеп калган шул кош миңа бик тә, бик тә жәл булып тоелган иде.

Аннан бирле байтак сулар акты, байтак көннәр үтте. Ул чактагы егетләр — ир, малайлар егет булып җиттеләр. Минем дә менә үзебезнең колхоз кырларында тракторчы булып эшли башлавыма быел икенче ел.

Һәр көнне шулай без Сәгыйть белән тракторларыбызны җиргә караңгылык иңеп, тәмам күз бәйләнгәч кенә сүндерәбез. Болын юлыннан шабыр тиргә батып, ашыга-ашыга кайтабыз да, Гөбенә ярына җитәрәк, сүз берләшкәндәй, кинәт адымнарыбызны акрынайтабыз...

Ул инде, ул. Авыл хуҗалыгы техникумыннан практикага кайткан ачык йөзле, ягымлы кыз Раушания җырлый. Сихерледер лә бу кызый. Якын барырга да куркыта, үзеннән ерак та җибәрми. Ниндидер күзгә күренмәс тылсымлы көч белән баскан урынында катыра да калдыра кешене. Бөтен дөньяңны онытасың. Тәмам тулып җиткән ай Гөбенә суына төшеп ага; су читенә үк килеп тезәлгән җәйләү киртәләре, көмеш яфраклы тал куаклары, гаҗәеп авазлар дулкынында тирбәлә-тирбәлә, каядыр еракка, зәңгәр томан эченә шуыша. Зур булып ачылган күзләрне дымлы пәрдә каплый. Әлләниләр эшлисе, әллә кайларга китәсе килә. Җырлаучының һәрвакыт көлемсерәп йөри торган, кызыл чәчле, борын очларына кадәр сипкел баскан ак йөзле сылу гына бер кыз, үз авылыбыз кызы икәнен белеп торсаң да, ирексездән мондый искиткеч тавышка ия булган кыз гади түгелдер, ә бәлки әкиятләрдә генә сөйләнә торган җен яисә патша

кызыдыр дип уйлый башлыйсың. Юк инде, юк, тел белән сөйләп нәрсә аңлатасың соң? Җан, йөрәк белән тойганның тел чиреген дә әйтеп бирә алмый торгандыр...

Җыр тынып калгач, Сәгыйть һаман бер сүзне кабатлый:

— Да, малай, юкка гына «сандугач» димиләр шул! — Аннары үз фикерен дә өстәп куя: — Артистлыкка укыса, каерыр иде бу акчаны...

...Гөбенә буендагы җәйләүләр, тал куаклары һәм, ниһаять, ай нуры белән мөлдерәп тулган Гөбенә үзе дә артта кала.

— Ишеткәнең бармы, имеш, ул теге тәбәнәк Рәсим өчен өзгәләнә икән, — ди Сәгыйть.

— Белмим, кеше нәрсә сөйләмәс...

— Былтыр сабан туенда мин дә сүз катып караган идем. У-у, кая ул, чыгымчы ат кебек, тибеп кенә очырды.

Мин ни өчендер Сәгыйтьнең ботинка башларындагы атлаган саен җем-җем итеп киткән кадаклардан күзләремне ала алмыйм. Күңелем әле һаман Гөбенә буенда. Үзем атлыйм, үзем уйлыйм: «Нинди генә талантлар юк халыкта», — дим. Уйларымны һич тә Сәгыйть белән уртаклашасым килми. Сәгыйть ул ничектер үзенә бертөрле халык: бөтен нәрсәдән үзенчә мөгез чыгарырга ярата. Суда йөзеп йөргән каз төркемен күрсә: «Эх, берсен суеп ашарга», берәр җирдә ярыйсырак алмагач бакчасы күрсә: «Эх, моны безнең өй янына күчереп утыртырга», — ди. Ә инде урамнан берәр ят кыз узып китсә, аның артыннан тел шартлатып яисә сызгырып кала. Хәер, белмим, күнегелгәндерме, Сәгыйтьнең андый кыланышларына, андый сүзләренә авылда беркем дә шаккатмый. Гомумән, аның буе-сыны, килеш-килбәте, чәрелдәвек тавышы, туп кебек йомры башы, авыл кызлары ипи бит, дип көлеп йөри торган кабарынкы шома йөзе, ябалак күзедәй зур карасу-соргылт күзләре, бер чите һәрвакыт ярым ачык йөри торган авызы — барысы, барысы да дөньяны нәкъ менә шулай танып, күрә белергә һәм күргәннәрен нәкъ шулай үзенчә, бер яклы, тупас итеп әйтеп бирергә яратылган шикелле.

Аның мине җәлеп иткән бердәнбер сыйфаты — эшчәнлек. И эшли дә инде бер тотынса. Ал белми, ял белми.

Башка тракторчылар килгәнче, аның тракторының тузаны сөртелгән, майлана торган җирләре майланган, радиаторга су, бакка ягулык тутырылган була. Мин, аның артыннан өлгерергә тырышып, тәмам тирләп пешәм...

Авылга кайтып җитәрәк, Сәгыйть тагын Рәсимнәнме, Раушаниядәнме үч алачагы турында белгертеп куя.

Кайсыннан икәнен мин ишетми калам: юл буендагы яшь каеннар сызгырыша, шаулаша башлый.

— Яңгыр булыр, — дим мин, күккә карап.

— Хәйдәр, Хәйдәр, карале... — дип, Сәгыйть тагын сүзгә керешә.

Әмма мин, Сәгыйть авызыннан чыккан сүзләргә битараф булуымны аның үзенә сиздерергә теләп, баягыга караганда да кычкырыбрак өстәп куям:

— Уҗымнар саргая башлаган, яңгыр кирәк...

## 2

Без ул көнне күрше авыл кырында кукуруз араларын йомшарткан идек. Башлаган участокны бетерик-бетерик дип тырышканлыктан, өйгә кайтырга үткән көннәргә караганда шактый соңга калып чыктык.

Савымчы кызлар җәйләүдән кайтып киткәнгә инде байтак, ахры: сыерлар да мөгрәми, чиләкләр дә чылтырамый, болын печәненең хуш исенә кушылып җылы сөт исе дә аңкымый.

«Әллә бүген аның җырын ишетми калдык микән» дигән уй мине генә түгел, Сәгыйтьне дә борчый бугай: ул әледәнәле миңа карап куя, йомры башын җәйләүгә таба мәзәк кенә кыйшайтып, төнге тавышларга колак салып бара.

Бермәлне шулай, инде үкенүгә әверелә башлаган борчулы уйлар белән әвәрә булып атлаганда, Сәгыйть минем бөергә төртеп куймасынмы:

— Хәйдәр!

Мин сискәнеп Сәгыйтьнең сәерсенгән күзләренә, аннары Гөбенә ярының Сәгыйть төртеп күрсәткән урынына карадым... Күзләремне чытырдатып йомдым. Ачтым: әйтерсең лә Гөбенә ярына мин кайчандыр кайсыдыр картинада күргән гүзәл Венера сыны төшеп баскан.

Сәгыйть, миңа шауламаска ишарә итеп, бармакларын иреннәренә куйды һәм акрын гына пышылдады:

— Су анасыдыр ул, Хәйдәр!

— Рау-ша-ния, — дип суздым мин, ни өчендер эсселесуыклы булып.

— Шыр ялангач ич ул, Хәйдәр!

— Нишләп шыр ялангач булсын инде, тиле, плавки кигән.

Минем исемә кылт итеп иртән көтү куган чак күршебез Галимә апаның әнигә сөйләп торган сүзләре килеп төште: «Бар икән бер куш йөрәкле кыз, Сабира җиңги генәм... Бөтен савымчы кызлар кайтып бетә, ә ул берүзе Гөбенә буенда калып су коена, ди. «Мин туңмыйм да,

курыкмыйм да», — дип әйтә, ди. «Тегендә, калада, без кыш көне дә боз ватып су коенабыз», — дип әйтеп әйтә, ди...»

Еш-еш сулыш алуыннан, зур күзләре белән Раушанияне генә түгел, бөтен Гөбенә буен йотардай булып карап торуыннан сизәм: Сәгыйть дулкынлана.

Ул арада Раушания кулларын бер югары күтәреп, бер як-якка сузгалап алды да, су көзгесен һәм төнге тынлыкны челпәрәмә китереп, төнбоеклар арасына төшеп чумды. Мин ирексездән ахылдап куйдым. Гүя су салкыны минем тәнемне өтеп алды.

Аннары колак төбендә генә Сәгыйтьнең ярсыган ата каз кебек ачулы ысылдавы ишетелде:

— Э-э, әйткән идем лә аны, төн уртасында асыл кош берьялгызы гына йөрмидер, дип...

Карасана, мин ничек күрми торганмын. Бөдрә башын су өстенә үк тидереп үскән тал күләгәсендә, куллары белән тезләрен кочаклап, Рәсим утыра икән ләбаса. Юк, ул, бөтен тирә-якка көмеш тамчылар чәчрәтеп, пошкыра-пошкыра йөзгән кызга да, Гөбенәнең иң киң урынында сизелер-сизелмәс кенә калтыранып торган ай сукмагына да карамый, ә бәлки ни өчендер бер көчәеп, бер бөтенләй өзелә язып ишетелгән сандугачлар тавышын гына тыңлап утырадыр сыман иде. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

Кыз судан чыкканда да, тәненә караганда күп мәртәбә аграк булып күренгән сөлге белән муеннарын, аркаларын сөрткәндә дә, Рәсим кымшанмады. Кыз киенеп бетергәч, толымнарын бер уңга, бер сулга җибәреп, чәчләрен тарады; су читенә килеп, байтак кына тынып торды. Менә-менә җырлап җибәрер шикелле тоелды ул миңа. Ләкин җырламады; сынын төз тотып, йомшак адымнар белән Рәсим янына килде. Төнге һаваны чыңлап торган саф хатын-кыз тавышы телгәләп үтте:

— Менә рәхәтләндереп җибәрде.

Рәсим дә теләр-теләмәс кенә аяк өстенә басты. Аннан алар акрын гына нәрсә турындадыр сөйләшеп киттеләр.

Сәгыйть бер кулы белән тал куагына тотынган килеш, икенче кулы белән минем иңбашыма ябышып, йомры башын алгарак сузды, ләкин яр астындагылар күрер дип шикләнде бугай, тиз генә яңадан артка тартылды:

— Үбешәләр, ахры!..

Үкенү дә, өзгәләнү дә, көнләшү дә бар иде Сәгыйтьнең тавышында.

— Әллә күзеңә күренәме? — дидем мин Сәгыйтькә һәм, куртка чабуыннан эләктереп, аны читкә сөйрәдем: — Әйдә, әйдә, кешегә чыккан кояшка кызынып тормыйк... барыбер җырламас инде ул бүген.

Әмма кая ул! Сәгыйть тал куакларына берегеп үскән диярсең. Бернинди көч белән дә куптарып алырлык түгел.

Җил чыкты. Төнге караңгылыкта тонык кына ялтырап яткан су өсте эре-эре кара тимгелләр белән чуарланды. Төнбоеклар дәррәү тирбәлешеп куйдылар. Җил томан куып китердеме, ай көнбатышка авышканлыктан, күләгәләр куердымы, берничә минуттан яр астындагылар безгә бөтенләй күренмәс булдылар. Әмма аның каравы тавышлары баягыга караганда ачыграк ишетелә башлады...

— ...Минем беркайчан да беркемне дә яратканым юк, Рәсим...

— Минем...

Рәсимнең соңгы сүзләрен җил алып китте.

— Кемне, кемне, Рәсим?! — диде Раушания өзгәләнеп.

— Ул бик акыллы... Фирая... белмисең.

Сүз элек Рәсим белән йөргән, ләкин аның чирәм җирләрдән кайтканын көтмичә кияүгә чыккан укытучы Фирая турында бара иде булса кирәк.

— Мин гел синең турыда уйлыйм, Рәсим... Исеңдәме, син, теге сары кәләпүшеңә карга балалары тутырып, Мөгаллимә тавыннан төшеп килә идең. Йоннары кара, аңкаулары комач төсендә иде ул карга балаларының... Исеңдәме, мин бер карга баласын урлап качкан идем... син елаган идең...

Раушания ярым пышылдап, ярым кычкырып сөйли һәм, кемнең дә булса үзен бүлдерүеннән курыккандай, ашыга иде.

— Сандыктан сугышта үлеп калган абыемның сөяк саплы пәкесен урлап бирдем... Кечкенә чагыңда син бик юаш, бик йомшак күңелле идең, Рәсим... ихластыр әгәр...

Тавышлар ничек искәрмәстән ишетелә башлаган булсалар, шулай искәрмәстән тынып та калдылар. Инде көмеш төсләрен җуеп өлгергән тал яфраклары гына, яр астындагыларның серләрен дәвам иткәндәй, һаман да талпыналар, пышылдашалар иде.

Бу юлы Сәгыйть минем чабудан тартты:

— Әйдә, бездән башка да пешә боларның боткалары, — диде ул, бизгәк тоткандагы кебек калтырана-калтырана. — Шул бот буе егет муенына салынырга торгач инде!..

Олы юлга чыккач, мин Сәгыйтьнең әледән-әле хәтәр очкыннар сибеп янган күзләренә соңгы мәртәбә карап алдым да, башымны түбән иеп, үз уйларыма чумдым.

Сәгыйть әйткән сүзләргәме икән, һәр көнне ишетергә гадәтләнгән гүзәл җыр авазларын ишетмичә калуыма микән (бәлки, Рәсим бәхетеннән көнләшкәнмендер), кәефем кырылган иде.

«Миннән дә юләр кем бар икән дөньяда, — дип, үз-үземне тиргәдем. — Сәгыйть сантыйга ияреп, кеше серен тыңлап йөрмәсәм ни була инде миңа, ә?!»

## 3

Кояшлы иртә. Тау итәкләреннән, урман буендагы үзәннәрдән пар күтәрелә. Бу безнең трактор бригадасында смена алышына торган вакыт. Вагон яны, кырмыска оясыдай кайнашып, мәш килеп тора. Ягулык ташучы малайлар даңгыр-доңгыр мичкә тәгәрәтәләр, тракторчылар, ачкычлар, чүкечләр белән шалдыр-шолдыр килеп, мотор тирәсендә казыналар, плугарьлар, кулларына май чиләге яисә солидол ящигы тотып, сабан белән тракторлар арасында киләп сарып йөриләр. Әледән-әле төрле мәзәк сүзләр, көлүләр яңгырап китә. Арада Сәгыйтьнең чәрелдәвек тавышы бигрәк тә еш ишетелә. Ул үз эшен әллә кайчан төгәлләгән. Ә хәзер әле яңа гына төнге сменадан кайтып төшкән «Беларусь», дөресрәге, шул «Беларусь»та тракторчы булып эшләүче Рәсим тирәсендә бөтерелә. Ул тирә-юньдәге кешеләр ишетсен өчен юри кычкырып сөйли:

— Кая калдык әле, җәмәгать, ә, әйе, теге безнең «кызыл сандугач» белән танышыр өчен кала урамында егетләр чират тора, ди. Әмма «кызыл сандугач» әйтә, ди: «Зинһар өчен, саруымны кайнатып йөрмәгез, авылда минем борын җелеге кебек егетем бар, буе кечерәк булса да, аяк очларына күтәрелгәч, минем йөземә карый ала», — дип әйтә, ди. Кем икән ул, җәмәгать, ә?

Рәсим уңайсызланып тирә-ягына карана. Аннан-моннан гына сөрткәнгә ала-чула булып калган малайларча яшь, мөлаем йөзенә куртка җиңен тидереп ала. Аннары, башка тракторчыларның да үзенә игътибар итүләрен күргәч, башын капот астына яшерә.

Әмма Сәгыйтьнең кигәвен шикелле кадалып торган көне:

— Әллә, мәйтәм, җәмәгать, ул егет Рәсим микән, ә? Юкка гына колак яфракларына чаклы кызармас кеше...

— Җитәр, Сәгыйть, җитәр, — дип бүлә аны Рәсим, капотын шартлатып ябып, — һаман-һаман шаяру була димени инде...

Тракторчылар болар ягына карап көләләр. Ә Сәгыйть тиле дигән саен тигәнә буе сикерә:

— Йә инде, йә, Рәсим дус, яшереп маташма... Борыныңдагы сипкелләрнең «кызыл сандугач»тан йокканлыгын барыбер бөтен авыл белә. Хәер, андый сипкелләр сиңа гына түгел, кала егетләренә дә йоккалый, ди...

Мондый шаярулар гадәттә Рәсим (төнге сменада булса) өйгә кайтып киткәнче яисә (беренче сменада булса) тракторын кабызып басуга чыгып киткәнче дәвам итә.

Беркөнне Сәгыйтьнең бу тозсыз мәзәкләренә хәтта ни түзем Рәсим дә түзмәде, кулындагы ачкычларын бар хәлгә җиргә күтәреп бәрде дә, кызарып-бүртенеп, Сәгыйть алдына килеп басты:

— Син, син, үрдәк арты ашаган нәрсә, тел бистәсе... Моннан соң тагын бер мәртәбә Раушания белән авыз чайкасаң, кара аны, мактаулы тракторчы дип тормам...

Рәсимнең болай кызып китүе безнең өчен яңалык иде. Шуңа күрә барыбыз да эшләребезне ташлап, боларга карап тора башладык. Моның азагы нәрсә белән беткән булыр иде, әмма нәкъ шул мизгел вагон янына кузовына егермеләп савымчы кыз утырган «ГАЗ-51» машинасы килеп туктады. Кызлар арасында, әлбәттә, кызыл чәч толымнарын бик килешле рәвештә баш түбәсенә урап куйган, ак йөзле, ачык зәңгәр күзле Раушания дә бар иде. Аны күргәч, Рәсим югалып калды һәм, Сәгыйтькә әйтәсе сүзен дә әйтеп бетермичә, кырт кына борылып, тракторы янына китеп барды.

Ләкин Сәгыйтьнең (машинадагылар ишетмәсен дип, ахры) акрын әйтелсә дә, ярыйсы ук чәрелдәп чыккан тавышы аны яңадан борылырга мәҗбүр итте:

— Карале, кара, кәрлә тәре, нигә дип син шул кала егетләре калдыгын яклап маташасың?!

Рәсимнең кискен сүзләре серкәсе су күтәрми торган Сәгыйтькә ярыйсы ук тәэсир иткән иде, ахрысы: ул, зәңгәрләнеп, бер сүз әйткән саен тотлыга башлады. Аның тамырлары күгелҗем төскә кергән, муены да, йомры башы да сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде.

— Әллә үзеңә дә файдасы тигәне бармы? Хәер, кайберәүләр әйткәннәр иде шул. Имеш, Гөбенә буенда...

Сәгыйть бу сүзләрне әйткәндә миңа карап алды һәм ясалма елмаю билгеләре җәелгән йөзен, төрле юнәлештән искән җил ирегендәге флюгер сыман, әле бер, әле икенче якка бора-бора, бөтен вагон янындагы халыкка ишетелерлек күтәренке тавыш белән тезәргә кереште:

Гөбенә буе камышлык,
Камышлыкта таныштык...

Бусы инде чамадан ашып китте. Күз алдымнан кайберләре уңайсызланып, кайберләре каш җыерып торган тракторчылар, вагоннан чыгып килүче карт шофер Исмәгыйль, кыяфәтләреннән сүзнең нәрсә, кем турында барганын аңларга тырышу сизелеп торган савымчы кызлар,

алар арасында сөйкемле иягенә кадәр уттай кызарган Раушания чагылып үтте.

Мин, үз-үземне белештермичә кулларымны йодрыклап, Сәгыйтькә таба талпындым. Ләкин колак яныннан гына бик яман выжылдап үткән ялтыравыклы әйбер мине аек акылыма кайтаргандай булды. Чүкеч икән. Мин аны, Сәгыйть тракторының капотына бәрелеп, җиргә төшкәч кенә күреп алдым. Сәгыйть тә күрде. Ул, картерга май сала торган җиреннән тураеп, кулындагы чиләген бер читкә ыргытты. Күзләренең хәтәр ялтыравына карaганда, менә-менә Рәсимгә ташланыр сыман иде ул.

— Ә-ә, син монда кеше үтерергә килдеңме? — дип җикеренде Сәгыйть, сызганылган җиңнәрен тагын да югарырак күтәрә-күтәрә. — Күрсәтим әле менә мин сиңа чүкеч белән ничек эш итәргә икәнлеген...

Рәсим, үзенең кызып китүе өчен уңайсызланган шикелле, тирә-юньдәге кешеләргә, аннары үз өстенә томырылып килгән Сәгыйтькә карады. Әмма Сәгыйть кинәт тукталып калды һәм кулын гына селкеп куйды да кире борылды. Зәһәре йөзенә чыккан иде аның, иреннәре калтыранып-калтыранып китә иде:

— Нәрсә барыгыз да миңа күзләрегезне тозландырдыгыз. Көпә-көндез кеше үтерергә җыеналар... Ә сез кулларыгызны кушырып тик торасыз... Әллә... әллә мине ялганлый дип уйлыйсызмы?.. Ышанмасагыз, әнә Рәсимнең үзеннән сорагыз. Сөйләп бирер ул сезгә төнге Гөбенә тарихын...

Белмим, инде һәркайсы үз эшләренә керешкән тракторчылар тыңлыйлар иде микән Сәгыйтьне. Мин аларга карамадым: бөтен игътибарым Раушаниядә иде. Менә ул акрын гына башын күтәрде һәм яшьле күзләрен нишләргә белмичә бер урында таптанып торган Рәсимгә төбәде. Нәфрәтле дә, рәнҗүле дә, үпкәле дә һәм шул ук вакытта әйтеп бетергесез матур да иде бу караш. Хәер, турсайган ал иреннәр һәм керфек очларында ялтыраган яшь бөртекләре генә рәнҗүле итеп күрсәткәннәр икән Раушаниянең карашын. Менә яшь бөртекләре кипте, иреннәр кысылды, шуның белән бергә Раушаниянең йөз сызыклары да, карашы да үзгәрде. Ачулы, юк, дөресрәге, горур иде хәзер аның карашы. Мин гәүдәм белән калтыранып куйдым. Күкрәгемне эчтән нәрсәдер авырттырып тырнап алды. Гүя бу минутта Раушания Рәсим өчен генә түгел, минем өчен дә мәңгелеккә кайтмаска югалды.

Менә шушы истәлекле көннән соң Гөбенә буендагы тар сукмактан күпме генә үтсәм дә, — хәзер мин ялгыз гына йөри идем инде, — айны көмеш дулкыннарга төшереп тибрәтүче, камышларны җанландырып биетүче, су

буендагы яшь талларны йокыларыннан уятып серләштерүче сихерле җыр тавышы ишетелмәде.

Көз җитте. Туган илләреннән аерылып читкә киткән сандугачлар, тургайлар белән авылдан Раушания дә китте. Ул киткәч, мин ирексездән теге, бәләкәй чакта сандугач сайравын ишетеп хәйран калуымны һәм шул искиткеч гүзәл җырның иясен таш атып куркыткан малайны искә төшердем.

## БАЛ

Урманда кура җиләге беткән. Бөтенләй беткән. Кура төпләрендә генә яртылаш кырмыска кимергән җиләкләр күренгәләп китә. Әбисенә чәйгә салырлык кына булса да җиләк җыеп кайтырмын дип килгән иде Хәбир урманга. Булмады инде болайга киткәч.

Юл аермасына җитәрәк озын төз юкәгә күзе төште Хәбирнең. Бөтен кәүсәсе тирән-тирән җыерчыклар белән капланган, ә куе ябалдашлары астында бал кортлары тызбыз килә иде ул юкәнең. Хәбир башта аларны шөпшәгә дә охшатып торды. Күзләре талганчы карагач кына тәмам ышанды — куе ябалдаш астындагы төймә кадәр тишек авызында чынлап та бал кортлары кайнаша иде. Әллә кайдан гына агачлар арасыннан ыргылып киләләр дә кытыршы кәүсәгә килеп бәреләләр. Әйе, әйе, кунмыйлар, нәкъ менә бәреләләр иде бал кортлары. Әйтерсең лә кемдер, кәүсәгә төзәп, бер-бер артлы борчак ыргытып тора — килеп бәреләләр дә, канатларын җемелдәтеп, тишек авызына кереп югалалар. Беренчеләре әйләнеп чыгарга өлгерми, икенчеләре, өченчеләре кайтып җитә.

Хәбир бал кортларының өзлексез әйләнеш ясап очуларын сокланып күзәткәндә, бал турында бөтенләй уйламады да диярлек. Бары тик карашын җиргә күчергәч кенә күңелен: «Бушка очып йөрмиләр инде болар, бал җыялар, бал! — дигән татлы уй кытыклап узды. — Эчтә куыш тулы балдыр инде анда. Менә бәхет!..»

Хәбир алан-йолан күз атып алды да олы юлга йөгереп чыкты. Озын юкәгә тагын бер мәртәбә борылып карады һәм авылга таба элдертте.

Ракетадан да тизрәк очып кайтты бугай Хәбир авылга. Сулышы кабып, үзләренең ишегалларына килеп кергәндә, аның әбисе, кулына җилпуч тотып, тавык-чебешләргә җим сибеп йөри иде.

— Әби, — дип шәрран ярды Хәбир, җим чүпләргә

җыелган тавыкларның котын очырып, — урманда корт оясы таптым. Юкә башындагы куышта. Шундый күп. Выжлыйлар гына.

Хәбир каушаса да, аның әбисе нишләптер каушамады. Алай икән, кара син аларны, дип кенә куйды.

— Әби, куыш тулы балдыр инде анда, иеме? — дип, һаман да әбисе тирәсендә бөтерелде Хәбир.

— Иске оя булса, күптер. Быел гына аерылып чыккан күч икән инде, үзләренә кыш ашарга җитәрлек кенәдер.

— Ничек белеп була соң аны, әби?

— Нәрсәне?

— Искеме, яңамы икәнен?

— Иске оя булса, кортларның керү юллары балавызланып, саргаеп торыр. Ерактан ук бал исе килер. Шөпшәләр, нечкәбилләр, төклетуралар бал исеннән исереп кая очканнарын, кая барып бәрелгәннәрен дә белмичә безелдәшеп йөрерләр.

— Шөпшәләр дә, балавыз-фәлән дә юк иде бугай анда, әби. Ә менә бал кортлары үзләре выжлап киләләр дә юкә кайрысына бәреләләр.

— Ашыгалар инде, алайса, — дип нәтиҗә чыгарды Хәбирнең әбисе, беравык уйланып торгач. — Кышлык азык җыеп калырга тырышалар. Димәк, яңа оя инде ул, яшь кортлар оясы...

Шулайдыр шул. Әбисе белми сөйләмәс Хәбирнең. Юкка гына шатланып йөгергән икән болай булгач Хәбир.

Хәбир, күңелсезләнеп, капка төбенә чыкты, телеграф баганасына сөялде. Керфек тә какмыйча, Ослан тауларына таба агып барган җиңел, юка болытларга карап тора башлады.

Шул вакыт якында гына ирләр тавышы ишетелде.

— Әллә елыйсың инде, Хәбир?

Хәбир җиңе белән күзләрен сөртеп алды да тавыш килгән якка борылды. Кибет каравылчысы Әнвәр икән. Кайчан карама, капка төпләрендә тәмәке пыскытып утырыр. Күр әле син аның колхоз эшеннән качып ятуын. Басса, бакыр изәрлек егет бит югыйсә.

— Кил әле монда, Хәбир.

Хәбир теләр-теләмәс кенә Әнвәрләр капка төбенә килде.

— Берәрсе рәнҗетмәгәндер ич, Хәбир?

— Юк.

— Ә миңа елап торасың кебек күренгән иде... Нигә бик каты йөгереп төштең бая таудан? Урманга ут капмагандыр ич?

— Корт оясы тапкан идем лә, — диде Хәбир, карашын Әнвәрләр янындагы койма ярыгына юнәлтеп.

— Соң?

— Әби әйтә, яшь оя, ди, яшь ояның балы аз була, ди.

Әнвәрнең йокылы күзләре капылт кына очкынланып китте. Чыпчык ауларга чыккан мәче диярсең! Тавышы да йомшара төште кебек.

— Кайда соң ул корт оясы, Хәбир?

— Кайда булсын, урманда... Юкә башында.

Әнвәр теш арасыннан гына сызгырып куйды.

— Юл буенда нарат, нарат саен оя, оя саен йомырка икән, алайса...

— Бер дә нарат саен түгел. Бик билгеле юкәдә ул. Мин ул юкәне төнлә күземне бәйләп алып барсалар да табам.

— Таптың ди!

— Табам шул!

— Озак тотарга ярамый хәзер балны урманда... Үзең генә барырга җыенмыйсыңдыр ич?

— Балы аз бит аның.

— Кем әйтә?

— Әби әйтә.

— Һи, юри әйткән сиңа әбиең. Урманга барып, юкә башыннан егылып төшмәсен дип куркып кына әйткән. Бал тулып тора инде хәзер куышта. Тагын берәр көннән ташып ага башлый.

Хәбир, сихерләнгәндәй, Әнвәр авызына текәлеп катты.

Әнвәр тимерне кызуында сугарга ашыга иде бугай — кулларын угалый-угалый аяк өстенә басты, Хәбирне җитәкләп алды:

— Әйдә әле!..

Тагын берничә минуттан Хәбир Әнвәрләр ишегалдында капчык авызы тотып тора иде инде. Күз ачып йомган арада капчыкка битлек, пычкы, балта, чиләк, ә чиләккә шырпы, өтерге, капрон бау, кипкән сәнәк гөмбәсе кебек кирәк-яраклар кереп ятты.

— Баскычны урманда гына әмәлләрбез, — диде, ниһаять, Әнвәр, эшне тәмамланганга санап капчыкны иңенә аскач. — Бакча артыннан гына сыпырттык. Кеше-кара күрми дә калсын...

Сихерчедер, мөгаен, бу Әнвәр! Әйдә, алып бар, димәде, еракмы ул юкә, димәде, вакытың бармы, дип сорамады — ияртте дә китте Хәбирне.

Бәрәңге бакчаларына ук килеп терәлгән сусыз инешне чыгып тауга күтәрелгәч, ике арада янә сүз кузгалды.

— Кәрәзле бал ашатыйм әле менә үзеңә туйганчы,— диде Әнвәр, сукмак читеннән тыраклаган Хәбирне алга үткәреп.

Хәбир сер бирмәскә тырышты. Иреннәрен ялап куйса

да: «Балны күп ашап булмый ла аны, бер-ике кашык капкач ук тамак төбен әчеттерә башлый», — дигән булды.

— Әбиең нигә куышта бал аз дип әйтә соң?

— Күп булса, кортлар кереп-чыгып йөри торган тишек авызы балавызланган була, ди.

Хәбир тагын арткарак калды, тагын сукмак читенә чыкты.

— Үзләренә кыш чыгарлык кынадыр, шәт, анда кортларның җыйган баллары, — диде Хәбир, адымнарын тизләтеп, Әнвәр белән тигезләшкәч.

— Булса соң!..

— Әгәр кортларын да җыеп кайтсак?..

Әнвәр хихылдап көлде.

— Җыйдың, ди, җыеп кара, чагып үтерерләр.

— Кискәч яңадан кадаклап куябызмы соң без куыш авызын?

— Җүләр мәллә син?

— Кортларны ачык һавада калдырабызмыни?

— Беткән ди урманда куышлар! Табарлар әле...

— Көз җиткәчме?!

— Җүләр мәллә син? Без төтен белән ыслаганда, пычкы белән кискәндә, кәрәз куптарганда яртысы тәпи сузар әле кортларыңның...

Хәбир тигез җирдә сөртенеп егыла язды.

— Буш кул белән барганга җүләр уйлар керә синең башыңа, — дип көлде Әнвәр һәм капчыгындагы чиләкне Хәбиргә алып бирде. — Абагалы юлдан керәбезме?

— Абагалы юлдан, — дип, иреннәрен теләр-теләмәс кенә кыймылдатты Хәбир.

Урманда эңгер куерган, кояш биек агач башларын гына яктырта иде инде.

Әнвәрнең, юкә башларына бик дикъкать белән карап баруын күргәч, Хәбирнең күңеленә шом керде.

«Табачак, тапмый калмаячак, күзләре ут кебек», — дип уйлады ул һәм кулындагы чиләген юри чылтыр-чылтыр китерде.

Юл аермасына җиттеләр. Борыны бал исен сизгән диярсең — Әнвәр, тәвәккәлләп, уңга борылды.

— Турыга, турыга, — дип каушый-каушый туры юлга узып китте Хәбир. Әнвәр, ихтыярсыз, аңа иярде, авыз эченнән генә нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана, капчыгын рәтләде.

— Еракмы әле? — дип сорады ул, ниһаять, шактый гына сүзсез баргач.

— Ера-ак, — дип сузды Хәбир, артына әйләнеп карамыйча гына.

— Еракмы әле? — диде тагын бераздан Әнвәр, мыш-мыш килеп.

— Ерак, — диде Хәбир, чиләген чылтыратып атлаган көйгә.

— Караңгы төшә ич инде.

— Төшә шул.

— Кая соң синең юкәң?

«Каен башында» дип җавап бирәсе килде Хәбирнең, әмма тыелып калды. Агач башларына караштыргалап атлый-атлый:

— Үзем дә шуны эзлим, — диде.

— Җүләр мәллә син? — дип, капчыгын абагалар арасына атып бәрде Әнвәр. — Син җүләргә ышанып йөргән мин тиле!..

Хәбир дә Әнвәр янына килде. Чиләген капчык янына куйды.

— Каядыр шушы тирәдә генә кебек иде...

— Билгең бардыр ич?

— Юк шул.

Әнвәр, йодрыкларын йомарлап, Хәбир каршына томырылды, күзләренә текәлеп карады. Хәбир аның дерелдәп торган тамак сөяген күрде, ысылдап чыккан ачулы сүзләрен ишетте.

— Кая юкәң?

— Каен башына каймак ашарга киткән, — дип ярып салды Хәбир, керфекләрен дә кыймылдатмыйча.

Әнвәр Хәбирне аяк чалып, терсәге белән генә төртеп екмакчы иде дә, тик Хәбир тиен җитезлеге белән читкә сикерде, аяк астында тырпаеп яткан ботакны алып өлгерде.

— Тиеп кенә кара!

— Җүләр, — диде Әнвәр, ачуыннан нишләргә белмичә. Аннары абагалар арасында ялтырап утырган чиләкне юл уртасына тибеп чыгарды. Чиләк эчендәге сәнәк гөмбәләре тирә-якка чәчелде.

Чиләген капчыгына салганда да, капчыгын иңенә асканда да тәгәрмәч эзләрендә аунап яткан сәнәк гөмбәләренә охшаган котсыз сүзләр коелып торды Әнвәрнең авызыннан:

— Шул җүләргә ышанып соң!.. Олы башымны кече итеп...

Ниһаять, олы юлда аяк тавышлары тынды. Куе эңгер җәелә барган урманда бераз куркынычрак булса да, кинәт кенә җаны тынычланып, күңеле күтәрелеп киткәндәй тоелды Хәбиргә.

Хәер, юл аермасында караңгы түгел икән, монда кояш баешы ягыннан алсу яктылык саркып керә икән әле.

Таныш юкәне юл аермасына җиткәч үк тапты Хәбир. Агач төбенә килеп, югарыга күтәрелеп карады. Әмма анда куе ябалдашлар арасыннан чекерәеп торган ялгыз йолдыздан гайре бернәрсә дә күрмәде ул. Хәбир кайнар учларын һәм бәләкәй колагын кытыршы кәүсәгә куйды. Кәүсә эченнән бер көчәеп, бер әкренәеп тонык кына гүләү ишетелә иде.

## ЗӘҢГӘР ШУГАЛАК

### 1

Хәмит йокысыннан Зәңгәр шугалак турында уйлап уянды.

Шугалак дип, алай олылар уйный торган чын шугалак түгел инде ул. Хәмитләр көздән үк чирәмен үзләре кырып, суын үзләре сибеп ясадылар аны. Ә «зәңгәр» сүзенә килгәндә, анысын Марат уйлап тапты. Оста да, көчле дә инде шул Марат. Хәмитнең ишеткәне бар, дөрестерме, ялгандырмы, малайлар аның турында: «Иделне эһ тә итми йөзеп чыга»,— дип сөйлиләр...

Кәҗәләнә торган гадәте булмаса, бик шәп малай Марат. Ләкин бар шул, аның әнә шундый гадәте бар. Хәмит әллә ничә сынады. Тимераякларын аркасына асып, урам буенча килер-килер дә ул, пыяла кибете янына җитәрәк, болай да каз муены кебек муенын тагын да суза төшеп, шугалак өстенә күз ташлар: чистамы, янәсе, боз өсте, юкмы? Шугалак өстендә аз гына кар тузаны булса — бетте. Марат кырт кына борылыр һәм, теш арасыннан ниндидер гамьсез көй сызгыра-сызгыра, Кече поселокка, Ибрайлар шугалагына юл тотар. Аннары атна-ун көнсез көтмә инде Маратны Зәңгәр шугалакта. Ә Маратсыз — уен уен да түгел: Түбән очлар теләр-теләмәс, уйнасам хуш, уйнамасам хуш, дигән шикелле генә селкенәләр һәм, әлбәттә, күбесенчә җиңеләләр. Хәмиткә бик күңелсез була мондый көннәрдә. Һәм ул Маратсыз уенны азагына кадәр карап та тормый...

Хәер, мондый хәл бик сирәк, гадәттә, күз ачкысыз каты бураннардан соң, яисә авыздан төкерек төшмәслек зыкы суыкларда гына була. Югыйсә Хәмит шугалакны һәрвакыт чип-чиста тота. Әтисе әйтмешли, бер йокысын җиңмиме соң ул. Хәмит йорттагы бөтен кешедән элек уяна. Әнисе әрләп калса кала инде: «Таң тишегеннән йөрмә-

сәң... Сезгә өс-баш ничек җиткерергә кирәк», — ди. Тик чынлап түгел ич ул, юри генә әрли. Өс-баш, имеш. Бер күзгә күренерлек ертылган нәрсә — бияләйләр инде. Әнә, бик җәлләсә, сандыгына салып куйсын бияләйләрен. Яланкул да чыгала ул Хәмит...

— Бияләй эзлисеңме? Әнә мич куышында.

Хәмитнең авызы колакларына җитә: әнисе бияләйләрен ямап куйган, имеш.

— Тиз кер, ашарга өлгерә.

Тиз инде, бик тиз. Кайда соң әле агач көрәк, себерке? Ай-яй салкыны битләрне өтеп ала. Менә хәзер, хәзер... Шугалакның яртысын көрәгәч, җылына башлыйсың. Куллар җылынды инде... «Эшләгәч, эш карулашмый», — ди ич әтисе... Тагын бер көрәк, тагын ике... ун... Уф, тирләтеп тә җибәрде әле. Бияләйләрен салып кесәгә тыгарга туры килер, ахры. Аз инде, бик аз калды. Ун көрәк... ике... бер. Менә шулай. Хәзер себерке белән уңга-сулга селтәнеп җибәрсен дә... Ниһаять, зәп-зәңгәр боз көзгесе. Кара, ак башлы, ак кәүсәле каеннар ничек матур булып, түбән карап үскәннәр. Һе, шугалак өстендә икенче бер дөнья диярсең... Матур.

...Кит әле, Акбай, буталма аяк астында!.. Менә шулай, көрәк белән себеркене сарайга кертеп куясың... Кая куйды икән соң абыйсы тимераякларын? Әһә, чолан алдында икән. Менә берсе, менә икенчесе. Вәт шулай, Акбай. Кар өстенә утырасың да... Менә шулай киеп җибәрәсең тимераякларны. Китәсең чыгып шугалакка. Менә, менә шулай китәсең шуып... Абыйсы Самат уянып чыгып: «Бир минем тимераякларны», — дип сөрән салмаса гына ярар иде инде.

...Ай, ай-яй... Кара, кара, әллә нишләтә. Кайрамаган, ахры, абыйсы тимераякларын, ай-яй, басып торып та булмый. Тайдырта. Дүртаякланып торганыңны күрше малайлары күрмәсен тагын, бот чабып көләрләр... Егылдырамыни, Акбай, егылдыра шул менә, шугалак диләр аны! Ә мин егылмыйм, менә кара... Нигә колакларыңны шәлперәйттең? Егылды дип уйладыңмы әллә? Мин үзем утырдым ич, юри генә. Ышанмыйсыңмы? Алайса кара. Күрдеңме?

— Абыең белән бергә-бергә өйрәнерсең, улым, берьялгызыңа гына читен бит ул тимераякта йөрергә өйрәнү...

Әтисе көлеп тора, имеш.

Абыең да абыең, әләкләсәң, әләкче буласың, белми әле әтисе Саматның нindилеген...

## 2

Менә инде икенче ай Хәмит һәр көнне таң тишегеннән торып шугалак чистарта. Аннары күңеле булганчы тимераякта шуа.

Хәзер бик җитез шуа инде Хәмит. Акбай күпме тырышса да, куып җитә алмый хәзер аны...

Менә инде икенче ай Зәңгәр шугалакта кискен көрәш бара. Бер якта — Түбән очлар, ягъни Марат, икенче якта — Самат командасы. Ә боз читендәге кар өемендә тынгысыз аяклар тыпырдый, кызыксынучан күзләр ялтырый. Алары — тамашачылар. Алары — тимераякта шуа белмәүчеләр. Әнә араларында Хәмит тә бар. Аның азрак чөенке борыны, йомры ияге, түгәрәк бит алмалары әллә салкыннан, әллә артык кызыксынудан ут кебек кызарып, ялкынланып тора. Ә зәңгәр боз төсле зәңгәр күзләре бертуктаусыз Марат аякларын бораулый. Ничек өлгер, ничек җитез шуа! Алка Марат таягына эләктеме — бетте! Аны капкага кергән дип уйла. Әнә, әнә, чыннан да... Эх, юкка гына Самат таягын бутап маташа. Марат ифрат та шома, ифрат та җор хәрәкәт белән бер читкә омтыла һәм Самат ягындагылар аңга килеп өлгергәнче — гол! Исәп: ике дә ноль. Хәмит, үз-үзен белештермичә, бозга сикереп төшә... Тик тагын шул абыйсы. «Син генә калган идең, бар, башыңны карга тыгып куйганчы, сыпырт моннан». Нишлисең, олылар белән әрепләшеп торудан ни мәгънә? Хәмит яңадан тамашачылар рәтенә чыгып баса. Менә хәзер абыйсы егылып аягын авырттырыр да тимераякларын Хәмиткә салып бирер, яисә Марат: «Нишләп торасың, Хәмит, син шуа беләсең ич, әнә минем капка сакчысының тимераякларын ал да уйна безнең белән», — дип әйтер. Әнә шундый татлы хыяллар белән генә юанып торырга туры килә Хәмиткә. Юк, берәү дә егылып аягын авырттырмый, берәү дә чакырып алмый Хәмитне.

Кышын көннәр кыска. Караңгы төшә. Малайлар, шаугөр килеп, өйләренә таралышалар.

## 3

Урта урам буйлап, теш арасыннан ниндидер гамьсез көй сызгыра-сызгыра, Марат атлый. Пыяла кибете янына җитәрәк, адымнарын акрынайта һәм, уң кулын каш өстенә куеп, күзләрен Зәңгәр шугалакка юнәлтә. Кичә төн буе буран котыруга карамастан, боз өсте ялт иткән. «Тырышканнар Урта урамнар». Маратның киң борынлы озынчарак йөзенә канәгатьләнү билгеләре җәелә.

Берәм-берәм башка малайлар да җыела. Самат та чыга. Тамашачылар инде күптән үз урыннарында. Алар Маратны, папуаслар Миклухо-Маклайны каршы алган кебек: «О, Марат, о, Марат», — дип, ерактан ук «ура» кычкырып каршы алалар. «Шугалак өстен кем көрәгән, кем себергән — бу турыда сорашу да, эзләшү дә юк, тизрәк, күз тондырып, уйнарга да тотынганнар». Хәмит шулай уйлый. Ләкин Маратны күрү белән Хәмит күңеленең кайсыдыр почмагында баш калкыта башлаган күңелсез уйлар, иртәнге томан кебек эри, тарала. Аның күз алдында зәңгәр боз, алка һәм сихерле тимераяклар гына торып кала. Ә йөрәге, бәләкәй йөрәге каядыр ашкына, каядыр чиксез биеклеккә очып китәргә омтыла, дөп-дөп итеп тибә. Кем капкасына ничә алка кергән, кем таеп егылган — Хәмитне инде боларның берсе дә кызыксындырмый. Аның бөтен барлыгы, бөтен игътибары Маратта. Аның өчен Марат голлары гына гол, Марат хәрәкәтләре генә хәрәкәт... Әнә алка тагын Марат таягында. Әнә аның каршына Самат командасындагы кара малай Илдус очынып килә, ә Самат үзе арттан таяк тыгып маташа. Хәзер Марат уңга сикерергә тиеш. Хәзер бер аягын күтәреп, күз иярмәс тизлек белән артка талпынырга һәм бер урында зырылдап әйләнергә тиеш. Барысы да дөрес, барысы да Хәмит уйлаганча. Хәзер... хәзер... Гол!.. Бөтен каток тирәсе гүли, Марат, бүреген артка чөеп, шашынып көлә.

Бөтенләй шабыр суга баткан Самат бияләй аркасы белән маңгаен сөртеп ала һәм таягын бозга күтәреп бәрә.

— Хәрәмләшеп уйныйсың, хәрәмче, хәрәмче...

Марат, тамашачыларга күз кысып, иңбашларын сикертә. Хәмит бер мәлгә генә югалып кала. Нишләргә кирәк соң әле аңа? Ә, әйе, абыйсының тимераякларын сорап тормакчы иде бит ул. Бирмәс, үлсә дә бирмәс... Аһ, хур булды Хәмит, абыйсының: «Башыңны карга тыгып куярмын», — дигән сүзләренә Маратның: «Нәрсә ди, нәрсә ди, чәүкә баласы, иң элек такыр юлдан тәпи-тәпи йөрергә өйрән», — дигән мәсхәрәле көлүе кушыла. Мараттан күрә башка малайлар да шаркылдашып көләләр. Хәмитнең бөтен тәне, бөтен бите яна. Кулындагы кәкре башлы таяк белән Маратның башына кундырасы килә аның. Елар идең — оят. Бөтен тирә-яктан малайлар карап тора...

— Кыерсыталармы, улым?

Тагын әтисе. «Аңа ни калган инде монда?! Еламаска, еламаска!»

— Монда кара әле, улым!

Хәмит уптым гына әтисенә күтәрелеп карый да телсез кала — әтисе кулында өр-яңа ботинкалы тимераяклар.

— Яле, улым, күрсәт әле абыйларыңа һөнәреңне.

Каушый Хәмит, кабалана: аның куллары калтырый, сулышы эченә сыймый... Ниһаять, Хәмит тимераякта. Аның бозга егылып борын канатуын түземсезлек белән көтеп торган малайлар барысы да авыз ачып катып калалар. Китә Хәмит салмак кына шуып. Юк, шумый, йөзә Хәмит, оча Хәмит. Аның күз алдында инде гаҗәпләнүләре чиктән ашкан малайлар да, соклану катыш горурлык белән башын артка чөеп җибәргән этисе дә, кар өстендә бөрешеп утыручы Самат абыйсы да, хәтта күзләренең акаюы табигыйлектән ашып киткән Марат та юк. Бары тик зәңгәр боз һәм кышның беренче көннәреннән үк таныш борылышлар. Менә ул, искәрмәстән генә серле түгәрәк ясап, Маратның каршысына килеп туктый да: «Әйдәгез, абый урынына үзем уйныйм», — ди.

— Уйна, — ди әле исенә килергә өлгермәгән Марат, башка малайларга сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп.

Уен башлана. Ләкин ни өчендер Марат бик сүлпән уйный. Ул фәкать үзләре капкасына рәттән ике мәртәбә алка кергәч кенә бераз аңына килә башлый. Аның күзләре янып китә, йөзенә тир бәреп чыга. Һәм ул яңадан теге хәйләкәр хәрәкәтләрен кабатлый башлый. Хәзер уңга сикерергә... Менә чәүкә баласы!.. Ул сикерәсе урында таягын селкеп Хәмит басып тора. Юк, алай гына алдый алмассың Маратны. Хәзер алканы якынрак алырга да, бер аякка басып, зырылдап әйләнергә! Гол!.. Гол, ләкин Маратлар капкасына. Марат бөтенләй чыгырыннан чыга. Кызара, бүртенә, читлектәге юлбарыс кебек шугалакның әле бер, әле икенче башына ыргыла. Ләкин кая гына барса да, аның юлына, өермәдәй бөтерелеп, Хәмит килеп чыга һәм — алкадан җилләр исә.

Ачуың килмәслек түгел: кар өемендәге тамашачылар арасында инде берәм-берәм олылар да күренгәли башлады. Алар, Маратлар капкасына алка кергән саен, дөнья җимереп кычкыралар, көлешәләр:

— Җиде дә бер, җиде дә бер, Гайфулланың төпчек малае Түбән очларга күрсәтә күрмәгәннәрен!..

Кышын көннәр кыска. Акрынлап караңгы төшә. Тәрәзәләрдәге, багана башларындагы, урам чатларындагы электр утларының шәүләләрен үзенә җыйган боз өсте, зәңгәр очкыннар чәчеп, җем-җем итеп яна башлый...

Хәмит аңламый — әллә Зәңгәр шугалактан агыла бу якты йомшак нурлар, әллә үзенең нәни йөрәгеннән ташып чыга...

# ДЕЗЕРТИР

Диңгездә давыл. Меңәр потлы яшькелт-кара дулкыннар, безнең бәләкәй траулерны изеп китәргә теләгәндәй, ажгыралар, шаулыйлар, тузып, уйнаклап торган ак ялларын болытларга тидерә язып сикерәләр дә палубага ухылдап төшәләр.

SOS хәбәре алынганга инде ике сәгать. Бу ике сәгать безгә ике ел кебек озын тоела. Хәтта ни түземле капитан Барзунов та борчыла, ахры.

— Миңа калса, һаман бер урында торабыз кебек. Румбада?

— 240, — дим мин, хәрбиләрчә ачык итеп.

— Шулай тотарга!

— Горизонт ерагая башлады, әллә тынаргамы исәбе, — ди өлкән ярдәмче, илле мәртәбә зурайтып күрсәтә торган биноклен күзеннән алып.

Аннары колак төбендә генә тагын капитанның көчле, кырыс тавышы яңгырый:

— Боцман, боцман! Кранецларны хәзерләргә!

Рубка тәрәзәсеннән палуба уч төбендәге кебек кенә күренә. Әнә траулерның борынындагы өскорманың тимер ишеге акрын гына ачылып, аннан боцман килеп чыкты. Аның артыннан аякларына озын кунычлы итекләр, өсләренә балыкчы костюмнары кигән ике матрос күренде. Алар өчесе дә, палубаның бөтен буеннан-буена сузылган тросларга тотына-тотына, форштевеньгә таба йөгерделәр.

Ниһаять, батучы шхунаны мин дә шәйләп алдым. Аның койрыгы күренми, ә какао төсендәге борыны, очып китәргә хәзерләнгән сыман, югары карап тора. Тагын бер көчлерәк дулкын бәрсә, бу мескен тартма бөтенләй су астында калыр төсле.

Без якынайгач, әлеге судноның югарыга тырпайган өлешендә ыгы-зыгы көчәйде.

Барзунов, машина бүлегенә тизлекне киметергә сигнал бирә-бирә, үзалдына сөйләнеп куйды: «Япон балыкчылары...» Аның күзләре кырыс, әмма хәрәкәтләрендә каушау, борчылу сизелә. Әйе, шлюпкалар белән мәшәкатьләнеп торсаң, соңга калуың бар, ә болай, мондый дулкында икенче суднога якын килү өчен искиткеч осталык, тәвәккәллек кирәк. Шулай да Барзунов тәвәккәлләде, ахры: безнең траулер, бер күккә атылып, бер упкын төбенә шуып, һаман алга үрмәләде.

Инде һәлакәткә очраучыларның йөзләре, кыланышлары аермачык күренә. Барысы да кара-кучкыл йөзле, кысык күзле, тәбәнәк буйлы кешеләр. Билләрендә пробка

кирпечләр чылбыры — коткару пояслары. Барысының да өсләрендә бертөсле соры күн кием, һәммәсе дә, берьюлы суга сикерергә теләгәндәй, борт кырыена җыелганнар.

Ниһаять, безнең траулер белән тегеләр шхунасы арасындагы ара күзгә күренеп кечерәйде. Моннан артык якын килү турында уйларга да ярамый. Әле безнең траулер югарыга чөелә, әле тегеләр шхунасы. Гүя ике кораб кара-каршы басканнар да даган атыналар. Тегеләр куркуның соңгы чигенә җиткәннәр, ахры, шхуна югары чөелгән мизгелдә икесе берьюлы безнең палубага сикерде. Аннары тагын икесе. Тагын...

Әмма, кызганычка каршы, борт кырыена килмичә, шторм-трап янында басып торган җиденче кеше сикерергә ашыкмады. Аңа иптәшләре үзләре телендә нәрсәдер кычкырдылар, кул изәп чакырдылар. Барзунов калтыраган бармакларын реверс рычагына тидереп алды да миңа эндәште:

— Вахтенный Тимершин, бар әле... Нәрсә булган икән?.. Югыйсә ычкынырга вакыт.

Мин, штурман рубкасына илтә торган тимер басмадан өч-дүрт кенә сикереп, юеш, җилле палубага атылып чыктым.

— Сикер, сикер! Нәрсә, юләрме әллә ул? Әй, егет, сикер, югыйсә китәбез! — дип кычкыралар иде мин барып җиткәндә бөтен яктан.

Боцман коткару кругы ыргытырга маташа, ләкин җил ирек бирми. Ә теге сәер кеше кымшанмый да. Әйтерсең лә аның өчен батып барган шхуна — экрандагы күренеш, шәрран ярып кычкыручы япон кешеләре, безнең матрослар — экрандагы кешеләр. Сакал-мыек баскан йөзен югары күтәргән дә әллә безнең траулерның морҗасына, әллә морҗадан өстәрәк тырпылдаган кызыл флагка карап тик тора. Үз язмышы өчен бөртек тә кайгырмаучы мондый битараф кешегә минем дә ачуым кабара башлады. Башкаларга кушылып, мин дә:

— Сикер, сикер! — дип кычкырдым. — Хода бәндәсе, ишәк, сикер, сикер тизрәк!

Теге кеше бары тик шул чакта гына аңына килеп, тирә-ягына карады һәм, үзенең аяныч хәлен әле генә төшенгәндәй, ашыга-ашыга борт кырыена килде.

Аның калын иренле, җыерчыклы биек маңгайлы, җансыз күзле йөзе еллар үтү белән мүкләнеп, сизелер-сизелмәс кенә чатный башлаган таш сынны хәтерләтә иде.

— Карагыз әле, кара, нишли ул? — дип кычкырды кемдер.

Әлеге битараф адәм, берничә секунд борт кырыена ябышып торганнан соң, түшеннән ниндидер ак төргәк чыга-

рып, безнең якка ыргытып җибәрде. Төргәк, һавага менгәч, давылга каршы очкан акчарлактай сузылып, җәелеп китте һәм шапылдап юеш палубага килеп төште. Бу ак клеенка белән тышланган ярыйсы гына калын дәфтәр иде. Дәфтәр хуҗасы исә, үзенең уңышлы ыргытуына кәефе килгәндәй, аякларен тибрәтә-тибрәтә, беркавым безнең палубага карап торды. Бу юлы аның йөзенә кызганыч көлемсерәү җәелгән иде. Аннары ул, кинәт кенә борылып, Джек Лондон романнарындагы диңгез бүреләренә генә хас ышанычлы нык адымнар белән шхунаның безгә күренми торган ягына китеп барды...

Дизельләр дөпелдәве ешайды. Траулер, бөтен корпусы белән калтыранып, артка чигенә башлады. Без ике-өч йөз метр китәргә дә өлгермәдек, япон шхунасына бер-бер артлы берничә дулкын килеп сикерде. Ә тагын бераздан диңгезнең әле генә шхуна борыны тырпаеп торган урынында коточкыч тизлек белән күбек бураны гына уйный иде инде.

Шхуна баткан урындагы воронка югалырлык вакыт узгач, траулер тагын алга шуышты.

Әллә ничә күз диңгез өстен күзәтте. Өч диңгез бинокле дулкыннарга төбәлде. Әмма эзләнүләр тәмам караңгы төшкәнче дәвам итсәләр дә, теге сәер кешенең гәүдәсе табылмады. Шхунадан, ичмасам, бер кисәк такта, бер генә буш мичкә калкып чыкса икән. Аяусыз диңгез, шәфкатьсез дулкыннар!..

Кич, кают-компаниядә булган сөйләшүдән соң, без әлеге үзебез коткарган япон балыкчыларының Алеут атаулары янында мәрҗән рифына бәрелүләрен, инде икенче тәүлек ярсулы диңгез белән көрәшүләрен, аларның бер өлешен — шул исәптән капитаннарын да — Америка танкеры алып китүен, һәм ул танкерның капитаны озакламый әйләнеп килергә вәгъдә бирсә дә, ни өчендер вәгъдәсендә тормавын, боларның көтә-көтә тәмам гаҗиз булуларын белдек.

Кичке аштан соң радист Находка белән, аннан соң Мәскәү белән бәйләнешкә керде. Мәскәүдән безгә рәхмәт әйттеләр һәм батучыларны япон теплоходына тапшырырга куштылар.

Төн җитте. Траулерның бер ягында яшел, икенче ягында кызыл ут кабынды. Безнең матрослар да, японнар да инде күптән йоклыйлар. Түбәндә, машина бүлегендә, дизельләр дөпелди, койрыкта су шаулый. Рубкада әкрен генә сөйләшкән тавышлар ишетелә, тәмәке утлары ялтырап-ялтырап китә.

О, бу диңгез төннәре! Алар чегән күзләредәй чем-кара, алар төпсез, алар серле. Әнә берәм-берәм йолдызлар да күренгәли башладылар. Димәк, иртәгә көн әйбәт булачак һәм

безнең палубага көмеш елга булып балык агылачак. Йолдызлар! Никадәр алар! Юк, җир күгендә болай күп түгел йолдызлар... Кара инде бүгенге сәер кешене! Нигә үләсе килде икән соң аның? Һәм, гомумән, нинди кеше соң ул? Японнар: «Эмигрант», — диделәр. Ә теге дәфтәр? Туктале, булмаса рубкага меним, бәлки, капитан укыгандыр...

— Шайтан белсен, хәрефләре безнеңчә, ә сүзләре аңлашылмый, — диде капитан, минем соравыма каршы, штурман өстәлендәге Тын океан картасының бер читендә яткан дәфтәргә күрсәтеп.

Дәфтәрнең алгы битләре чыланган. Шулай да язуы танырлык. Дәфтәр: «...кайчандыр Идел егете идем, — дип, җөмләнең урта бер җиреннән башлана. — Ләкин мин рәнҗеттем ул илне, ул елганы, ул халыкны. Кичерү сорамыйм, мин — үлемгә хөкем ителгән кеше. Мин фәкать башкаларның минем язмышка дучар булмауларын гына телим...»

Үземне биләп алган кызыксыну тойгыларын тышка чыгармаска тырышып, мин капитанга:

— Роман Эдуардович, берничә минутка гына алып торыйм әле? — дидем.

Барзунов, җилкәсен җыерып, кулын гына селкеде: янәсе, нигә сорап торасың?

Мин, рубкадан чыгып, бизан-мачта янындагы ящик өстенә утырам да укый башлыйм.

«...Без Тәнзил белән бер авылныкы идек. Бергә уйнап үстек, бергә укыдык. Икебез дә бер көнне армиягә, юк, дөресрәге, сугышка киттек. Авыл халкы икебезне дә елап озатты. Хисамилар тавында яулык читләре белән бертөзлексез күзләрен сөртеп торган хатын — минем әнием иде ул. Киткән чагымда мин үзем дә тилерә-тилерә, башымны арба төбенә бәрә-бәрә еладым. Ә бит шуннан берничә көн генә элек, фермада тирес түккәндә, кызларга: «Иртәгә үк районга барып, фронтка җибәрүләрен сорыйм», — дип мактанып йөргән идем. Тәнзил миңа карап кыюсыз гына елмайган иде. Инде менә чынлап китә башлагач, киресенчә килеп чыкты. Мин, күз яшенә төелә-төелә:

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар, —

дип җырлаганда, Тәнзил арбадан төшә дә озатучыларның берәм-берәм кулларын кысып, аларның һәркайсына ниндидер җылы сүз әйтеп чыга.

Безне станциягә илтә баручы Тәкый абзый: «Җитәр, Сәет, җитәр, үзеңне кулга ал, әниеңнең чәчләрен агартма, нишлисең, ил өстенә килгән каза бит», — дип, мине тынычландырырга маташа. Әмма кая ул тынычлану! Үр ба-

шында басып калган хатыннарның гәүдәләре кечерәйгән саен, йөрәгемнең сыкрануы арта. Башыма: «Әллә шундагы кешеләрнең аякларына егылып, мине бер генә көнгә булса да авылда калдыруларын сорыйм микән?» — дигән уй килә. Инде авылның соңгы агачы югалды, инде барысы да бетте дигәндә, арышлар арасыннан кулына зәңгәр чәчәкләр бәйләме тоткан бер кыз чыкканы күренә. Ходаем, Хәлимә ич! Олы юлга чыккач, Хәлимә тиз генә авыл ягына карап ала. Аннары, кулындагы чәчәк бәйләмен болгый-болгый, безнең арттан йөгерә. Нигә йөгерә инде, нигә кайгымны арттыра? Нигә йөрәгемне парә-парә телә? Яшь пәрдәсе аркылы миңа Хәлимәнең ешеш хәрәкәтләнгән ялангач тезләре генә күренә. Тәкый абзый, атын туктатып, аны көтеп ала. Мин, яшьле күзләремне күрсәтмәскә тырышып, кулларымны Хәлимәгә сузам. Ах, Хәлимә чәчәк бәйләмен башын аска иеп, кызарып утырган Тәнзилгә ыргытты. Мин аптырап Тәнзилгә карыйм. Тәнзилнең күзләре әле генә Хәлимә өзеп алган зәңгәр чәчәкләр кебек яктырып, зәңгәрләнеп китә.

— Җиңеп кайтыгыз, Тәнзил, — ди Хәлимә тагын, мине гарьләндерергә телдәгәндәй, үзе кырын гына миңа карый. «Неужели Тәнзилне ярата?» — дигән вәсвәсәле, көнчел уй йөгереп үтә минем башымнан. Ә бит Тәнзил безнең арада почтальон булып кына йөргән иде. Кара, кара, Хәлимәгә карап елмайган була тагын! Аһ, мут суфый! Мин, елаудан туктап, кипшенгән иреннәремне ялап куям. Эчемне нәрсәдер тырный, яндыра. Хәлимә минем күзләремә карарга тели бугай. Юк инде, бик исе китте ди Сәетҗанның!..

Ләкин Хәлимә басып торган борылыш урман артына кереп күздән югалгач ук үпкәм языла. Арбадан сикереп төшеп, кире йөгерәсем, Хәлимәнең кулларыннан алып, күзләренә карыйсым килә. Мин тагын елыйм, тагын өзгәләнәм...

Вагонда безнең кебек яшь-җилкенчәкләрнең бихисап булуын күргәч, бераз тынычланам. Сүзем ялган булмасын, анда бертуктаусыз сөйләшеп, көлешеп баручы егетләр белән беррәттән минем кебек уйчаннар, боеклар да байтак иде. Шуларның берсе Тәнзил. Тәрәзә буена баскан да күзләрен берөзлексез артка шуып торган офыкка төбәгән. Калын иреннәре ярым ачык. Алга чыгыбрак торган маңгае ара-тирә тәрәзә пыяласына тиеп-тиеп китә.

Тәнзил, ахры, сөйләшергә кеше юклыктан гына моңаеп торган. Мин килгәч үк, елмаеп җибәрде һәм: «Беләсеңме, малай, мине яраксызга чыгара яздылар бит», — дип, ашыга-ашыга сөйләргә кереште. Буен үлчәгән чак ничек итеп аяк очына басып торуын, тәртип бозган өчен

өлкән врачның аны куып чыгаруын, аннан тагын военкомга, тагын өлкән врачка керүен сөйләгәндә, ни өчендер миңа Тәнзил ялганлыйдыр, үзенең кайгысын кешегә белдермәс өчен генә шулай икейөзләнеп маташадыр кебек тоелды. Һәм мин аннан капылт кына:

— Үзеңнең кая барганыңны беләсеңме соң? — дип сорап куйдым.

Тәнзил эндәшмәде.

— Ә син үлемнән куркасыңмы? — дидем мин, тагын да үҗәтләнә төшеп.

Тәнзилнең яңагы сизелер-сизелмәс кенә тартышты, калтыранды:

— Куркам...

— Киткән чагында елыйсың килдеме соң?

— Кызык кына сорап куясың син, Сәет, алайга китсә, әйе, әйе, минем дә елыйсым килде. Ләкин бит авылдашлар, әниләр... Әллә син аларга җиңел дип уйлыйсыңмы? Дөресен әйтим, синең кичәге кыланышың, җырларың, күз яшьләрең ошамады миңа, Сәет. Әллә нишләдең син. Үзеңнең егет булуыңны оныттың. Аннары, ничек әйтәләр әле... шәхси хәсрәтеңне бөтен ил хәсрәтеннән өстен куярга маташтың, димме...

«Сайра әле, сайра, — дип уйладым мин, Тәнзилнең әллә нинди эчке рухлану белән яктырып киткән йөзенә гаҗәпсенеп карап. — Тегендә баргач ничек сайрарсың икән».

...Башыңны күтәрсәң — үлем. Эх, бер генә секунд булса да шул баш очындагы үлемне онытып тору нинди рәхәт! Тып-тын. Артта каядыр зәңгәр урманнар эчендә урман күгәрчене гөлдери. Юл буендагы арыш арасында чикерткә кычкыра. Тирә-юньнәрен кырмыскалар сырып алган түмгәк төбендә җиләк чәчәге балкып утыра. Ходаем, кем әйтер сугыш дип?

Минем уң ягымда әрмән егете, ә сул ягымда Тәнзил ята. Аның да аксыл зәңгәр күзләре җиләк чәчәгенә төбәлгән. Менә аның керләнгән гимнастерка якасы кыймылдап куйды һәм яшел каскалы дәү башы миңа таба борыла башлады:

— Беләсеңме, Сәет, дөньяның ни эше юк, — дип пышылдады Тәнзил кызу-кызу. — Үзем сезнең арада почтальон булып йөрдем, ә үземнең йөрәгем эчтән генә сыза иде. Ихтимал, Хәлимә моны сизмәгәндер дә... Син миңа ачуланма, яме... Һәм әгәр дә илгә исән-сау кайтсаң...

Башка вакыт, башка җирдә булса, җир йотсын әгәр, Тәнзилнең яңагыннан ут чыгарасы идем. Ләкин монда... һәм Тәнзил авызыннан «исән-сау кайтсаң» дигән сүзләр дә ычкынгач, мин фәкать тешем сызлагандай, авызымны

гына кыйшайтып куйдым. Аһ, болар: бу чәчәкләр, бу сөйләшүләр — барысы да вакытлыча гына бит. Әнә, әнә ул дәһшәтле һәм горур авазлар ишетелә дә инде:

— Алга! Ватан өчен!..

Уң ягымда нәрсәдер көмеш кебек ялтырап ала. Бу инде аяк өстенә сикереп торырга өлгергән әрмән егетенең штык йөзе икән. Башымны тиз генә Тәнзил ягына борам. Аның бөтен гәүдәсе пружина кебек җыерылган. Менә-менә атылып китәр шикелле. Минем гаҗәпләнүемә каршы, аның күзләрендә куркуның әсәре дә юк. Курку юк, ләкин нәрсәдер бар. Нәрсәдер әйтергә телиме ул? Нигә болай ялварып карый? Аһ, мөгаен, Хәлимә турындадыр. Бу минем башымда ярты секунд чамасы дәвам иткән уйлар тартышының соңгы мизгелендә Тәнзил инде җирдән күтәрелә башлаган иде. Мин:

— Тәнзил! Тәнзил! Әйтермен Хәлимәгә, әйтермен! — дип кычкыруымны үзем дә сизми калдым.

Тәнзил ишетте, ахры: бер генә мәл тукталып торгандай булды. Аның болай да винтовка прикладын бик иплəп тоткан куллары, тимердәй каты агачны өзеп чыгарырга теләгәндәй, тагын да ныграк кысылдылар...

Торырга, торырга, йөгерергә кирәк. Әнә, азрак алга бөкрәя төшеп, Тәнзил йөгерә. Миңа аның тар аркасы, билендәге көрәге, приклад тимере һәм алмаш-тилмәш ялтыраучы итек табаннары күренә.

Бөтен җир шаулый, үкерә, сыкрана. Бөтен тирә-якта өзлексез «ура» тавышлары яңгырап тора. Әледән-әле колак тондыргыч шартлаулар, шуның артыннан ук үзәк өзгеч ыңгырашулар ишетелеп куя.

Торырга, торырга, йөгерергә кирәк ләбаса. Нишләп ятам? Башым әйләнә, колакларым шаулый. Ниндидер эчке явыз көч: «Җиргә ныграк сыен, ныграк!» — дип тәкрарлый. Тагын бер секунд, тагын ярты... Хәзер, хәзер торам, йөгерәм. Җитте, бетте... Тамырларымнан шаулап кан ага, йөрәгем дөпелди, бөтен тәнем, бөтен гәүдәм калтырана, дерелди. Винтовка тимере боз кебек, әллә җир дә салкына башлады инде. Юк, тирләгәнгә, кызышканга күрә миңа шулай тоеладыр...

Бөтен көч-куәтемне җыеп, күзләремне ачканда, Тәнзил миннән ун-унбиш адымнар алда, миңа таба борылып, хәрәкәтсез тора иде. Винтовкасы юк. Күкрәгенә кушырып куйган кулларының бармаклары арасыннан сиптереп кан ага, авызы ярым ачык, йөзе кыйшайган, ә күзләре? Ходаем, ул күзләрне минем гомеремдә дә онытасым юк. Ул коточкыч күзләр, минем әшәке йөземне, куян йөрәгемне тишеп чыгарга теләгәндәй, туп-туры миңа төбәлгәннәр иде.

— Тэнзил!

Мин кычкырып дэштемме аңа, эллэ йөрэгем генэ кычкырдымы? Хэзер хэтерлэмим. Мин барып җиткэндэ, ул чалкан ята иде. Инде баягы коточкыч ялтырауның эсэре дэ калмаган күзлэренэ күк, болыт шэүлэлэре төшкэн, куллары канлы.

Күкрэк төбеннэн үксүгэ охшаган сэер тавыш атылып чыкты. Күзлэрем яшь белэн мөлдерэп тулганнар. Нигэ битлэрем буенча агып китми ул яшь, нигэ берни күрсэтмичэ, күзлэремне сукырайтып тора?..

Аннары Тэнзил янына ике сестра шуышып килде:

— Беткэн, — диде берсе, аның кулын капшап карагач.

«Беткэн... Кем беткэн?..» Кинэт мин башым эйлэнеп, күз алларым караңгыланганын тойдым.

Э тагы бераздан мин, кая баруым турында үз-үземэ хисап биреп тормастан, артка, тынлыкка, тапталып, изелеп беткэн арыш басуына таба шуыша идем инде. Беренче исемэ китергэн нэрсэ арыш арасындагы зэңгэр чэчэклэр булды. Аh, Хэлимэ биргэн чэчэклэр бит болар! Юк ла, юк, кояш нурына манчылган якты чэчэклэр түгел болар. Болар — Тэнзил күзлэре. Мин кулларым белэн башыма тотындым. Нишлэдем мин? Йөгерергэ кирэк лэбаса, кире йөгерергэ кирэк. Кулларым винтовкага сузылды. Лэкин ул юк, ул тегендэ, Тэнзил янында калган иде. Барыбер торырга, йөгерергэ кирэк...

Бик озак, тирэ-ягымда гаҗэеп тынлык урнашып, сугыш авазлары бөтенлэй ишетелми башлаганчы йөгердем мин. Мең төрле нурга чумып, балкып, яшэреп, бөтен тирэ-юньгэ мең төрле хуш ис сибеп утыручы урманга барып кергэч, башымнан: «Яшим, яшим!» — дигэн сөенечле уй узды. Иреннэрем үлэннэрнең юешлеген, бармакларым туфракның йомшаклыгын, җылылыгын тойды.

Шул мизгел яфракларын минем битемэ үк тидереп утырган юкэ ботаклары арасында сэер кыштырдау ишетелде. Гүя кемдер юкэ башына төзэп таш җибэргэн дэ, хэзер шул таш, яфракларны кистереп, түбэн төшэ. Мин сискэнеп читкэ тайпылдым. Томырылып җиргэ төшкэн нэрсэ кош булып чыкты. Бэлэкэй генэ, яшел түшле, очлы сары томшыклы кош. Яраланган кош. Аның каерылган канатыннан энэ очы кадэр генэ кан тамчылары саркып чыга да җилэк чэчэклэрен буйый, алсуландыра. Кошның кечкенэ зэңгэрсу күзлэре ярым йомык. Ул да түгел, коштан бер-ике адымдагы юкэ түмгэге өстендэ чэч үремедэй ялтыравыклы кара тасма күренеп китте. Елан! Елан hэм кош. Туктале, кайда ишеткэн идем соң... Ул арада елан түмгэк өстендэ балдак кебек бөтерелеп алды. Аннары, авызыннан ике япьле кармавычын чыгарып, кошка

таба килә башлады. Шул чагында кош капылт кына хәрәкәтләнеп куйды. Аның ярым йомык күзләре бераз ачылдылар, аларда ниндидер сәер яктылык хасил булды. Ә елан һаман якынлашты. Кош тагын бәргәләнде. Аның күзләре зурайганнан-зурая, зәңгәрләнгәннән-зәңгәрләнә бардылар. Ниһаять, ул күзләр күк төсенә, фирүзә төсенә керделәр һәм миңа әллә кайчан, әллә кем кулында күргән йөзек кашын хәтерләтеп, җемелди башладылар. Елан кинәт авызы утлы тимергә тигәндәй сискәнеп, башын артка тартып алды һәм, юаш кына ысылдап, караңгы юеш куакларга таба качып китте.

Мин тагын кошка карадым. Аһ, коточкыч күзләр! Кинәт бөтен тәнем чымырдап куйды. Акылдан шашкан сыман, дәррәү аяк өстенә сикереп тордым һәм бар авазга кычкырып җибәрдем:

— Тәнзил!

Аннары үз тавышымнан үзем курыккандай, әле генә елан кереп киткән караңгы куакларга ташландым...

Өч көн, өч төн товар поездында, бүрәнәләр арасындагы куышта кысылып кайттым. Өч тәүлеккә өч кисәк ипи ашап, эчләрем тартышып бетсә дә, ни өчендер ашыйсым килмәде. Киресенчә, көне-төне башым әйләнде, күңелем болганды. Шулай бер төнне поезд ниндидер тукталышта озаграк торгач, бүрәнәләр арасыннан шуышып чыктым да тышка күз салдым. Ходаем, таныш җирләр! Ничек итеп вагоннан сикереп төшүемне, ничек итеп ике ягына да тигез итеп акация утыртылган станция юлы буйлап йөгереп киткәнемне дә сизми калдым. Юл да, кыр да буп-буш. Ник бер генә җан иясе, ник бер генә ут-мазар күренсен, ичмасам.

Еракта, инде аксыллана башлаган көнчыгыш як җирлегендә авылымның — минем туган авылымның — миңа бала чактан ук таныш тал, сәрви агачлары калкып чыккач, җиңел сулап җибәрдем. Аякларыма бераз хәл кергәндәй булды. Карасана, урынында икән ич авыл! Ә миңа калса, мин киткәнгә бик күптән дә, авыл инде урынында юктыр, кешеләре дә мин качып киткән яктагы дәһшәтле шартлаулардан, үлем авазларыннан кырылып, үлеп беткәннәрдер сыман иде.

Сәрви, тал очлары зураеп, авылның кырый йортлары күренә башлагач, тирә-юньнәрен алабута, әрем баскан зират сукмагына борылдым. Зираттан Хәлимәләр бакчасы якын гына. Әнә инде, әнә бер казыгы сукмакка егыла язган читән үзе дә күренә...

Бакча тын, салкынча. Бәрәңге буразналарыннан Хәлимә йоклый торган келәткә кадәр булган араны үткәнче, итекләрем чеп-чи булды. Бер атлыйм да туктап тыңлап торам. Әнә авылның фермалары, конюшнялары ур-

нашкан ягында шомлы тавыш белән бер эт уларга кереште (үз башыңа булгыры!). Аннары Хәлимәләр кетәгендә тавыклар сөйләшеп куйдылар. Менә келәт. Ап-ак бүз пәрдә корылган бәләкәй тәрәзә... Мин тәрәзәгә чиерттем. Тук-тук... Тынлык. Таң алды шул, йокының иң тәмле вакыты. Тук-тук... Менә келәт эчендә такталар шыгырдады, һәм бүз пәрдәнең бер чите аз гына тибрәнеп куйды.

— Хәлимә, бу мин — Сәет... Хәлимә!..

Эх, иңнәренә кара шәл салган, тәрәзә пәрдәседәй ак йөзле Хәлимә чыкмаган булса иде ул келәт эченнән!

— Хәлимә!

Җавапка минем битемә тач итеп төкерек килеп ябышты:

— Шакшы!.. Кабахәт!.. Димәк, дөрес... — Хәлимә, ике кулы белән битен каплап, үксеп җибәрде. — Ни бит белән, ни йөз белән... Аһ!..

— Хәлимә, Хәлимә! Акрын, кешеләрне уятасың.

— Әтиең нахак бәла белән китте, диделәр, ә син, ә син?.. — дип дәвам итте Хәлимә өзгәләнеп.

— Хәлимә, тынычлан, мин вакытлыча гына, мин китәм. Хәлимә, Тәнзил сине...

— Тәнзил белән авызыңны чайкама, куян йөрәк! Әниеңне кичә җирләдек. Синең әшәкелегең турындагы хәбәрне күтәрә алмады. Әнә кабере Тимери бабай нараты төбендә...

Минем борын төбендә генә шапылдап ишек ябылды. Аяк астымдагы җир каядыр бер читкә шуышты. Егылып китмәс өчен, келәт почмагына тотындым...

Әниемнең салкын кабер туфрагын кочып, күпме ятканмындыр, хәтерләмим. Җирдән торырга мине ачлык мәҗбүр итте. Таң атып килә иде. Зират өстендәге агачлар да, кабер ташлары да инде аермачык күренәләр. Мин, исерек кеше кебек чайкала-чайкала, кыр түрендә берьялгызы караеп утырган карамага таба атладым. Анда колхозның бәрәңге җирләре булырга тиеш иде...

Мин урман ешлыгына кереп учак якканда, көн тәмам яктырган иде инде. Агач башлары кояшның беренче кызгылт нурларына манчылганнар. Күк чалт аяз. Учактагы бәрәңгеләр бармак хәтле генә булсалар да, бөтен тирә-юньгә тәмле көйгән ис аңкыталар. Мин аларны, арчыпнитеп тормыйча, учлап-учлап авызыма тутырам. Үзем бернәрсә дә уйламаска, бернәрсә белән дә газапланмаска тырыштым. Әнә шул җете зәңгәр күк тә учактагы көйгән бәрәңгеләр генә булсын...

Шулай утыра торгач, изрәп киткәнмен. Төшемдә Хәлимәне күрдем. Ул минем мәхәббәт хатларын нииндидер чокырга җыеп тутырган да кулындагы таяк белән шак-

шы суга батыра. Үзе җирәнеп йөзен читкә бора, борынын җыера. Ул бу шөгыле белән шулкадәр мавыккан, хәтта янына мин килгәнне дә бөтенләй күрми, имеш. Аннары әлеге таякны чокырдан тартып чыгарды һәм җанфәрманга башы тирәли әйләндерә башлады. Ә мин, бөтен тирә-юньгә сибелгән әшәке тынчу тамчылардан котылыр өчен, башымны яка эченә яшерәм, күзләремне җиңем белән каплыйм. Ләкин ул зәһәр тамчылар мин яшеренгән саен ешрак сибеләләр, битләремә сыланалар, күзләремә керәләр, яка эченә тулып, күкрәкләрем, аркаларым буйлап агалар. Шул мизгел инде бөтен киемнәрем пычранып беткәндер дип иелеп карасам, коточкыч хәл: мин елан сурәтендә! Аякларым урынында ялтыравыклы озын койрык, киемнәрем — елан тәңкәсе, ышанмыйча башымны тотып карыйм... баш та еланныкы! Аптырап, Хәлимә ягына борылсам, кыздан җилләр искән. Әле генә Хәлимә торган җирдә кешенеке кебек зәп-зәңгәр күзле бәләкәй генә зәгыйфь кош бәргәләнеп ята. Аның күзләре яктырган саен яктыра, зәңгәрләнгән саен зәңгәрләнә бара. Аннары ул күзләрдән ике көмеш нур атылып чыга да минем бөтен тәнемне, яңакларымны, кулларымны пешерә башлый... Мин йөгерергә телим, йөгерә алмыйм: кулларым да, аякларым да тораташ булып каткан. «Елан кебек, елан кебек шуыш!» — ди каяндыр Хәлимә тавышы, һәм мин черек юкә шикелле тавышсыз гына җиргә авам. Аннары, елан кебек боргалана-боргалана, куакларга таба шуыша башлыйм. Минем яннан ук җилкәләремә кан тамчылары чәчрәтә-чәчрәтә Тәнзил йөгерә. Аның тавышы ямьсез, буш мичкәгә кычкыргандай, дөбердәп чыга: «Тукта, тукта, качма!»

Шабыр тиргә батып уянып китсәм, күкне болыт баскан. Урман эче ниндидер шомлы караңгылык белән өртелгән. Битләремә тимер кебек авыр, үткен яңгыр тамчылары сибелә. Уң кулым әле сүнәргә өлгермәгән кисәү башына тиеп яткан, ахры: әрнеп-әрнеп сызлый, әчетә.

Бары тик шул чакта гына булган хәлләр бөтен тулылыгы белән күз алдыма килеп басты. Мин тетрәнеп аяк өстенә сикереп тордым. «Нишләдем мин, нишләдем?!» Бу аяусыз сорау бөтен барлыгымны биләп, күкрәгемне без белән чәнечкәндәй, бертуктаусыз авырттырып, әрнетеп тора башлады. «Нишләдем мин, нишләдем?!» Асылынырга, менә шушы агач ботагына тотарга да асылынырга!.. Көләчәкләр. «Ул куян йөрәкнең үзенә-үзе кул салырга көче җитмәс, фронттан качканга ачуы килеп, кем дә булса асып куйгандыр», — диячәкләр. Шул чагында күңелнең кайсыдыр почмагында: «Бәлки, кичерерләр», — дигән өмет чаткысы кыймылдап куйды. Су-

гышыр идем, Тәнзил кебек үләр идем. Нигә, чынлап та... Мин бит акыл белән әллә нинди планнар корып басмадым бу юлга. Әллә ничек кенә булды шунда, үзем дә сизми калдым. Кичермәсләр... Бәлки, кичерерләр...

Әнә шундый икеләнүле, вәсвәчел уйлар белән әвәрә булып, район үзәгенә илтә торган олы юлга килеп чыкканны сизми дә калганмын.

Район үзәгенә караңгы төшәр алдыннан килеп җиттем. Урамда көпчәкләре кыеш-мыеш су арбасына җигелгән чыгымчы үгезне бура таяк белән кыйнап маташучы йолкыш малайдан гайре беркем дә очрамады.

Менә милиция бүлеге. Тәрәзәләреннән сүрән генә яктылык сирпелә. Үземнең нинди кеше кулына тапшырылачагымны белер өчен челтәрле тәрәзәгә якынрак килдем. Ахры, минем бәхетсезлегемә каршы, эчтән ачулы, тупас ирләр тавышы ишетелде: «Молчать, син, фәләнфәсмәтән, эттән туган нәрсә!.. Хәзер военное время... менә моның белән...»

Бөтен башым түнеп, өметсез уйларга бирелгән килеш, акрын гына караңгы урамнар буенча атладым. «Әти — халык дошманы, мин — дезертир. Сөйләшеп тә тормас. Тукта, монда нигә килдем соң әле мин? Кайткан юл белән тотарга да кире фронтка китәргә. Һе, җиңел генә! Анда миңа кем ышана, кем миңа корал бирә? Үләргә, миңа хурлыклы үлем белән үләргә язган икән. Ә икенче юл? Теге бәхетсез әнием әкиятләрендәге кебек икенче юл да бар бит: мосафир ике юл чатына килеп җитте. Беренче юл — үлемгә, икенчесе ачлыкка илтә».

Мин ачлык юлын сайладым. Дөньядагы бөтен нәрсәмне: халык ышанычын, намусымны, әниемне, сөйгән ярымны җуйсам да, акылсыз йөрәгем «яшәргә!» дип тибә иде әле.

Аннан соң миңа бу минем өстемә кинәт ябырылып килгән кайгы-хәсрәтләр, сагыш-газаплар вакытлыча гынадыр, көннәр үтү белән барысы да онытылыр, мондый зур, иксез-чиксез илнең күңелемдәге әнә шул ямьсез хатирәләрне оныттырырлык тын почмагы, әнә шул Каф тавы кадәр гаебемне юкка чыгарырлык, йолып алырлык кешеләре дә бардыр сыман тоела иде. Өстемдәге хәрби киемемне җиң төпләре сүтелгән иске костюм белән бер бөтен ипигә алыштырып, Себер ягына сәфәр чыгуым да әнә шундый уйлар тәэсиреннән булган, күрәсең. Әмма мин ялгышканмын: әлеге өмет-юанычларның балалар өреп тутырган сабын куыгы гына икәненә тормыш мине көннән-көн ныграк ышандырды. Берөзлексез көнбатышка агылып торган эшелоннар. Икешәр-өчәр смена эшләп арыган, йончыган хатыннар, яшүсмерләр, хәтта бала-чага-

лар, бер урамнан икенче урамга чаклы сузылып киткән ипи чиратлары. Ләкин һәр җирдә ниндидер гаҗәеп күтәренкелек, горурлык, һәр җирдә минем йөрәгемә утлы хәнҗәр булып кадала торган нәфрәтле карашлар...

Көннәрдән бер көнне поезд Тын океан буендагы кечкенә генә шәһәрчеккә килеп туктады. Шуннан ары тимер юл юк. Шуннан ары океан. Мин, чалбар ертыкларын кулым белән томалаштыргалый-томалаштыргалый, юлда беренче очраган төзелеш конторына килеп кердем. Аннан, әлбәттә, кагыйдә буларак, паспорт, хәрби билет сорадылар.

— Юк, югалттым, — дидем мин еламсырап.

Бәләкәй тәрәзәнең тимер капкачы, минем соңгы өметемне сүндерергә теләгәндәй, шапылдап ябылды.

Шул мизгел артымда кемнеңдер хихылдап куйганын ишетеп, борылып карадым: күн тужуркалы, күн кепкалы берәү сөзеп карый торган күзләрен миңа текәгән иде. Куллары чалбар кесәсендә. Мин әйләнеп карагач, ул:

— Да, синең эшләр хана, братец, — дип, баягыдан да ямьсезрәк итеп айгылдарга кереште. — Чалбарың да төшеп бара, кесә якларың да чамалы, ахры...

Мин, бу бәйләнчек адәмгә ачулы караш ташлап, ишеккә таба атладым. Теге дә күләгә кебек миңа тагылды.

— Син артың белән киртә җимермә әле, братец, — диде ул, уң кулы белән минем иңбашыма кагылып. Бу юлы аның тавышы ягымлы гына яңгырады. — Бәлагә юлыксаң, син һәрвакыт кешеләргә таян.

Кара син, әйбәт кешегә охшаган ич бу! Көлүе дә баягы кебек җирәнгеч түгел. Күз карашыннан да кызгану, хәлеңә керү, ярдәм вәгъдә итү сизелеп тора...

Әйе, мин аңа барысын да, барысын да түкми-чәчми, бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

Ул мине бүлдермәде. Бары тик «Шуннан, шуннан, билгеле, әлбәттә, әйе, һем...» шикелле шаккату ымлыклары, җупләү сүзләре генә кыстыргалап барды. Мин сөйләп бетергәч кенә: «Да, синең эшләр мин уйлаганга караганда күп мәртәбә катлаулырак икән, братец!» — дип көрсенеп куйды.

Алтын кебек ялтыравыклы портсигарыннан папирос алып кабызганда, мин, аның йөзендә сәер көлемсерәү күреп, тагын тәшвишкә төштем. Ләкин берничә көн рәттән бәләкәй булса да ярыйсы гына җиһазландырылган бүлмәдә кунгач, рестораннарда йөреп, мин гомеремдә дә авыз итеп карамаган төрле тәмле-тәмле ризыклар белән сыйлангач, әлеге Кимо исемле мәрхәмәтле танышымның миңа күктән Алла тарафыннан җибәрелгән фәрештә икәненә тагын бер кат инандым. Берничә көннән өр-яңа до-

кументлар да табып бирергә вәгъдә иткәч, аңа булган ышанычым тагын да үсә төште. Балыкчы һөнәрен мактый-мактый, мине ятьмәләр үрергә өйрәткәндә дә, үзе белән бәләкәй, ике ишкәкле көймәгә утыртып, диңгезгә алып чыкканда да, инде кояш баеп, диңгез өстенә зәңгәр эңгер җәелүгә карамастан, «Монда рәтле балык буламы соң!» — дип, һаман эчкәрәк ишкәндә дә, бу төймәдәй түгәрәк күзле кешегә карата эчкерсез тирән хөрмәт сакладым мин. Ләкин...

Аннары барысы да яшен тизлеге белән эшләнде. Безнең көймәдән аз гына уңдарак диңгез төбеннән зур мичкәгә охшаган карамчык калкып чыкты. Соңыннан белдем: су асты көймәсе булган икән, ул, һаман зурая барып, безнең көймәгә якынлашты. Аннан карамчык өстендә кеше башы пәйда булды. Шул мизгел башымның чигә турысында һәм билемнән аз гына өстәрәк, буш җиремдә коточкыч тупас авырту мине «Аһ!» дип кычкырып җибәрергә мәҗбүр итте. Мин сикереп торырга теләдем. Ләкин минем беләкләремне көчле тимер куллар эләктереп алдылар да күз ачып йомган арада юан бау белән селкенмәслек итеп чорнап та куйдылар. Бу юлы минем мәрхәмәтле танышымның тавышы теге, беренче очрагандагы шикелле коры, мыскыллы яңгырады: «Бар, бар! Анда синнән яхшы кеше ясарлар...»

Элмәк беләкләремне, күкрәгемне кысты. Мин башта суга егылып төштем, аннары шакшы, лайлалы тимергә килеп бәрелдем һәм акрын-акрын судан аерыла башладым. Аннары күз алдымда яшелле-кызыллы бөҗралар хасил булды. Каядыр еракта нәрсәдер шаулады, нәрсәдер дөбердәде. Миңа аңлаешсыз ят телдә кемнәрдер акрын гына сөйләштеләр. Бераздан теге бөҗралар барысы берьюлы хәрәкәткә килеп, берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, әйләнергә, бөтерелергә, биешергә тотындылар...

Аңыма килгәндә, мин чит илдә идем инде.

И, мин шакшы җаныңны күтәреп торырга җирәнмәгән газиз җирем, и, кабердәге бәхетсез анам, и, Хәлимә! Ни булды соң миңа! Шулчаклы да куркак идеммени мин?

...Тәбәнәк буйлы, кызларныкы кебек итләч кечкенә куллы, купшы мундирлы япон полковнигы сорау алганда миңа болай диде: «Илеңә кайтсаң, сине баштүбән асып куячакларын беләсеңдер инде. Синең яшисең килә, зиннәтле, матур сарайларда матур кызлар кочып торасың килә. Димәк, шулай булгач...»

— Бармыйм мин сезнең ул мәктәбегезгә, хет чукынып китегез! Һәм тагын бер кат үтенеп сорыйм: мине үзебезнең ил карамагына тапшырыгыз.

— Дезертир да, хыянәтче дә була алмыйм бит инде мин, дисеңмени? Ах-ха-ха!.. Юк, тәти егет, безнең развед-

ка мәктәбен бетерми торып, илеңне телгә дә алма. Укып кеше булып чыккач, пожалуйста...

Ничәнче көн инде мин караңгы, тынчу камерада аңыма киләм. Бөтен тәнем әрни. Аз гына кузгалсам да, арка тиреләрен пычак белән уеп-уеп җибәргән кебек. Барысыннан да бигрәк, нигә кеше төсле туган ил кырында үлә белмәдем икән соң мин? дигән уй җәфалый. Мин инде үземне әллә ничә кат сынадым: юк, юк, мин куркак түгел, мин үлемнән курыкмыйм. Ә теге чакта? Әллә гомеремдә беренче мәртәбә мәет күрү һәм, җитмәсә, шул мәетнең балачак дустым Тәнзил булуы акылдан шашар дәрәҗәгә җиткерде микән мине? Алай дисәң, фронтка киткәндә нигә өзгәләндем? Нигә ил турында уйламадым? Димәк, мин балачактан ук куркак, мескен җан, үзем турында гына уйлаучы бәндә булганмын. Ни өчен? Тумыштан укмы? Җавап табуы читен булган меңнәрчә сораулар, очсыз фикерләр, чуалчык уйлар... Ходаем, әллә юләрләнәм инде!.. Әнә чатлыкта Тәнзил күзләре бугай ич. Юк, кош, теге вакытта еланны куркытып качырган кошның зөбәрҗәт күзләре...

Тәбәнәк буйлы, чепи күзле полковник, калын иреннәрен чәйни-чәйни, мине шпион булырга өндәгән саен, аркама төшкән резина таякларның саны арткан саен, миндә яшисе килү теләге көчәя барды. Әйтерсең лә әнә шул резина таяклар Ватан каршындагы гаебемнең дә бер өлешен юкка чыгаралар, каныма кушып агызалар иде...

«Бу гарип-горабадан рәт чыкмастыр», — дип, ахры, озакламый мине Япония хәрби әсирләр лагерена озаттылар.

Аннан качтым. Тоттылар. Тагын тынчу, сасы камера, тагын салкын идән, тагын резина таяклар...

Беркөнне мин аяк очымда гына ишетелгән дулкыннар шавыннан, акчарлаклар тавышыннан уянып киттем. Күзләремне ачсам, мине сәләмә киемле кешеләр урап алган. Берсен-берсе бүлә-бүлә, нәрсә турындадыр сөйләшәләр, бәхәсләшәләр, телләре аңлашылмый. Бер очлы яңаклы, акыллы кара күзлесе, ахры, минем уянганны күреп, балчык кувшин белән каяндыр су алып килде. Аннары бер кисәк ипи һәм ярты табак чамасы балык шулпасы китереп куйдылар...

Соңыннан белдем: бу ирекле балыкчылар мине ерак диңгез ярының гадәттә тормыш белән бәхилләшкән әсирләрне чыгарып ташлый торган урыныннан табып кайтканнар икән.

Шул көннән мине Сәетҗан түгел, ә бәлки балыкчы Ян-факу дип йөртә башладылар. Шәһәргә барсам, бай малайлары минем арттан: «Аксак Ян-факу, телсез Ян-фа-

ку, саңгырау Ян-факу!» — дип, ташлар атып калалар, ә йөрәгем исә, шул тирә-ягымда тәгәрәшкән ташлар кеенә: «Ватансыз Ян-факу, куркак Ян-факу, дезертир Янфаку!» — дип кабатлый иде. Кыскасы, теге тәбәнәк буйлы япон полковнигы белән сөйләшкән чактагы кебек горур түгел идем инде мин. Патриот, имеш, лагерьлардан качып йөрдем. Бәдрәфкә батып кына үләсе калган да бит... Эх, кая барам соң мин качып? Кем көтә мине? Кем сөенә минем кайтуыма?

Сугыштан соң Хиросима, Нагасаки вакыйгалары тына төшкәч, үземне көне-төне газаплаган уйлардан берьюлы арынырга теләп, Токиога Совет илчелеге урнашкан йорт янына барып чыктым...

Гомердә дә онытасым юк ул көнне. Акрын гына җылы җил исә, ә югарыда кызыл флаг җилферди. Кызыл флаг! Элек мин дә шул кызыл флагны тотып карарга, үбәргә, хәтта урам буйлап күтәреп йөртергә хокуклы идем бит... Эх!..

...Әнә йорт алдына өр-яңа җиңел машина килеп туктады. Машинадан озын буйлы, кара эшләпәле кеше төште. Ходаем, минем якка борылды! Чү, нигә болай текәлеп карый? Яндыра, кисә, акылдан яздыра бу күзләр! Тукта, Тәнзил күзләре түгелме соң бу? Теге вакыт, бармаклары арасыннан чаптырып кан акканда, Тәнзил нәкъ шулай караган иде... Йөгерергә, йөгерергә, качарга!.. Урамда очраган кешеләр миңа сәерсенеп карыйлар, шоферлар йодрык селки. Мин, беркемгә, бернәрсәгә игътибар бирмичә, кара, кысан урам буенча йөгерәм дә йөгерәм...»

Дезертир Сәетҗанның көндәлеге шул урында тәмамлана. Аннары буш битләр һәм аерым-аерым җөмләләр, эпизодлар китә. Алары әле күптән түгел генә язылганнар булса кирәк: язуы яңа, сүзләре бозылмаган.

«Бүген Владивостокны тыңлаганда татар музыкасын, татар җырын ишеттем. Тәнзил шикелле батыр солдатлар турында ул җыр:

Аналар хәтере шикелле,
Җил йөри курганнар артында...
Аналар йөрәге шикелле,
Мәңгелек ут яна мәйданда...

Ә мин әле һаман сөйрәләм... Төшемдә Хәлимәне күрдем... Ике дистә ел бит, ике дистә ел! Нигә үлмим, нигә газапланам?..

Һәммә нәрсә үги монда: шушы җир дә, яр да, су да...
Ул адашкан малай сыман һаман илен уйлап сула,
Эх, күңеле омтыла шул һаман шунда!..

Бәлки, минем әти дә халык дошманы булмагандыр...
Әгәр хайван булырга теләсәң, кешеләр хәсрәтенә артың белән борыл...»

Ә иң соңгы биттәге язулар, әлбәттә, әле кичә генә язылганнар.

«...Шхунаның яртысы су астында. Батабыз. Япон матрослары, мин нәкъ фронтка киткәндәге кебек, башларын бортка бәрә-бәрә елыйлар, хәтта кайберләренең чәчләре агарды. Америка танкеры барыбызны да ала алмыйча китеп баргач, шау-шу, ыгы-зыгы, үксү бермә-бер артты. Радист совет траулеры белән сөйләшә. Шхунада мине акылдан язганга саныйлар, хәтта миннән бераз шүрлиләр дә, ахры: берсе дә якын килергә базмый... Совет траулеры, совет кешеләре! Һе, күрәсе иде берсен генә! Аннары, аннары үкенмәс идем...»

«Ә бу дәфтәрне кая куярга? Әй, батсын ла үзем белән!..»

Мин дәфтәрне укып бетергәндә, офыктан зур бакыр табак кебек кызгылт ай күтәрелеп килә иде. Аннан безнең траулерга таба берөзлексез хәрәкәтләнеп, җемелдәп тирбәлеп торучы ука юл сузылган.

Рубкада әле һаман тәмәке утлары ялтырый. Бәлки, капитан да шундадыр. Керергә, аңа сөйләргә кирәк.

Мин, фонарь астыннан чыгып, чайкала-чайкала палуба буенча атлыйм. Башым тубал кебек. Дәфтәр тоткан кулым калтыранып-калтыранып китә.

## ИКЕ ТИЕН АКЧА

Марат дәрескә кичегеп килде. Бәхетсезлеккә каршы, бу аның икенче кичегүе иде. Шуңа күрә Маратны класс җыелышында тикшерделәр.

— Йә, Марат, соңга кала белдең, инде иптәшләрең алдында җавап бирә дә бел, — диде класс җитәкчесе Мөршидә апа.

Марат башта кып-кызыл булып сүзсез торды. Аннары күз чите белән генә классташларына карап алды: Мөршидә апа гына түгел, бөтен класс аннан җавап көтә иде.

— Юлда ике тиен акчамны төшереп югалттым,— дип сузды, ул, ниһаять, ишетелер-ишетелмәс кенә һәм, көлмиләр микән дигәндәй, тагын классташларына карады.

Чыннан да, арткы партада кемдер пырхылдап җибәрде.

— Соң... шуннан? — диде Мөршидә апа, арткы партага ачулы караш ташлап.

— Билетка акчам җитмәде дә җәяү килдем...

Класс бер мизгел генә тынып торды. Аннары малайлар да, кызлар да, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, шауларга, гөжләргә керештеләр.

— Кондуктордан сораган булсаң, акчасыз да утыртыр иде...

— Мин булсам, автобус артына ябышып та килер идем.

— Бәлки, әле билет та тикшереп тормаганнардыр.

— Эх, Марат...

Торып сөйләүчеләр дә, урыннан кычкыручылар да байтак булды җыелышта. Укучыларның һәммәсе дә диярлек Маратны йомшаклыкта гаепләделәр. Иң ахырда Мөршидә апа сүз алды.

— Дәрескә кичеккән өчен, һичшиксез, Марат гаепле, — диде ул, инде элеккеге ягымлы, мөлаем күзләре белән әле Маратка, әле башка укучыларга карый-карый,— ләкин акчасын югалтканнан соң аның җәяү килүе гаеп эш микән?.. Уйлагыз әле, балалар?..

## ИСЛЕМАЙ

Бәләкәй генә станция.

Тагын ярты сәгатьтән аның поезды — Көнбатышка, ә минеке Көнчыгышка китәргә тиеш. Без әле һаман да ниндидер чит нәрсәләр хакында сөйләшәбез. Бер-беребезгә ерактагы зәңгәр сопкаларны төртеп күрсәтәбез. Байкал күленең сафлыгына карап сокланабыз. Әкълимә кесәсеннән тимер акча алып күлгә ыргыта. Нинди тонык су: акча тәмам күл төбенә төшеп җиткәнче җемелдие. Ниһаять, көмеш нокта кадәр генә калып, күздән югала. Минутлар уза. Без тагын бер-беребезгә карыйбыз. Бер-беребезнең күзләреннән серләр эзлибез. Әйтерсең лә, бер-беребезгә карап, узган гомер тарихын укырга тырышабыз. Кемдер безнең янда гына: «Омуль сатам, омуль балыгы... башка станциядә табалмассыз», — дип кычкыра. Минутлар уза...

— Бәхетлеме син?

— Ә син?

Юк, без үзебез түгел, күзләребез сөйләшә.

— Син нигә ташладың мине?..

Әкълимәнең әзрәк эчкә баткан зур соры күзләреннән мин шул сорауны укыйм.

— Син нигә ташладың мине?

Мизгел уза... Юк, мизгел генә түгел... Айлар, еллар уза... Гомер уза... Кояш нәкъ төшлек турысында.

— Соң, без бер генә мәртәбә дә икәүдән-икәү генә калып мәхәббәт турында сөйләшмәдек ләбаса...

Минем күзләрем шулай диләр.

Байкал өстендә шаян җил йөри. Дулкыннар өстендә кояш юлы.

— Ләкин без бер-беребезне ярата идек...

«Ярата идек, ярата идек», — дип, безнең уйларны раслыйлар зөбәрҗәт дулкыннар.

Әкълимәнең толымнары һаман да шулай — озын. Элек гелән-гелән көлеп торган күзләре генә моңсу. Бәлки, күз кабакларындагы зәңгәрсу кайма шундый моңсу күләгә төшерә торгандыр аның күзләренә...

Минем поезд китә. Станциядә ыгы-зыгы. «Сау бул, Әкълимә, авылдашларны, дус-ишләрне күрсәң, сәлам әйт... хуш... хуш!..»

Вагон тәрәзәсеннән берничә минут бик-бик таныш, бик-бик сөйкемле, бик-бик якын йөз күренеп тора. Китә. Кала, кала. Гомеремдә беренче тапкыр Әкълимә мине кул болгап озата.

Кемне назлый икән хәзер ул сөйкемле кулларың, Әкълимә?

Вагон тәгәрмәчләре җырлый, иксез-чиксез тайгалар җырлый. Елый-елый йөрәгем җырлый:

Карама,
уйлама,
эндәшмә, Әкълимә —
Син генә тик минем уемда...

Ничә ел узган соң инде аннан бирле? Ун ел, унбиш? Миңа хәзер егерме сигез яшь. Ә мин сигез яшемнән хәтерлим Әкълимәне. Димәк, егерме ел. Бик кыланчык иде Әкълимә ул чагында. Әнисе бөтен авылда даны чыккан тегүче булганга, чук кебек киендереп йөртә иде кызын. Аннары биш таш уенын бик оста уйный торган иде Әкълимә. Без, малайлар, ниндидер яшерен соклану һәм көнләшү белән карап тора идек аның уйнаганын.

Бервакытны Әкълимәнең этисе Гарифулла абзый (ул борчак каравылчысы булып эшли иде), борчак урларга баргач, безнең кәпәчләребезне җыеп калды. Әле, җитмәсә, кәнсәләргә чакыртам, дип котыбызны очырды.

Мин кайтканда әни өйдә юк иде. Шылт иткән тавышка да сискәнеп, дежур мине кәнсәләргә чакырырга килгәндер дип, мич арасында утырам... Менә капка ачылды, чолан ишеге шыгырдады. Ләкин өйгә керүче юк та юк. Курка-курка гына почмак тәрәзәсеннән тышка карадым. Ишегалды буйлап, кызыл тасмаларын җилфердәтә-җилфердәтә, Әкълимә йөгереп чыгып бара иде. Менә ул капка янына җитте. Ачты. Тәрәзәгә күтәрелеп карады. Ми-

не күргәч, нишләргә белмичә, аптырабрак торды, нәрсәдер кычкырды, телен күрсәтте һәм, капканы шыр ачык калдырып, урамга атылды.

Бу нәрсә булыр икән дип, өй ишеген ачсам — чолан идәнендә минем кәпәчем ямьшәеп ята иде.

Дүртенче класста укыганда кияү белән кәләш дип үрти башлаганнар иде инде безне. Шуңа җен ачуларым чыгып, мәктәптән кайтканда Әкълимәне берничә мәртәбә карга да батырдым. Әмма үзе ни өчендер ачуланмый иде Әкълимә. Матур күзләрен елтыратып, азрак үпкәләгән сыман карап тора-тора иде дә миңа, ак киндер белән тышланган йон бияләен бик хәтәр шапылдатып, өс-башын кагарга керешә иде.

Томанлы хәтер тәрәзәсе аша туган авылыма карыйм. Түбәндәге аклы-яшелле чуерташларга нәрсәдер сөйли-сөйли бормаланып аккан йөгерек инеш. Кем тарафыннан, кайчан утыртылганын авылда беркем дә хәтерләми торган карт өянке. Өянке башындагы кара каргалар шәһәре. Чыклы чирәм. Ярым җимерек агач күпер. Шомырт чәчәге исе... Бертабан тавы артыннан һич ис китмәгәндә генә калкып чыга торган, кочакласаң кочакка сыймаслык түгәрәк ай. Һәм, ниһаять, күпер иңсәсенә пәке белән чокып язылган исем: Әкълимә...

Шул язуны күргәч башланды бугай барысы да. Әле минем беркайчан да мондый хис кичергәнем юк иде. Кем язды икән моны? Кем? Авылда тагын кем кызыксына икән Әкълимә белән? Нигә кызыксына икән? Мин җәлпәк борынлы, киң маңгайлы малай. Күзләрнең агы каен тузы кебек ап-ак, карасы корым кебек кап-кара. Мине бөтен кеше әтигә охшаган, ди. Әтигә охшаган әтисез малай... Хәер, авылда күп инде ул минем ише әтисезләр. Без үзебез дә зур егетләр булып җиттек хәзер. Сигезне бетердек. Авыл советы председателе Гайни абый мине тиздән ФЗУга җибәрәм, ди. Әни дә, тугани апам Сәлимә дә каршы каршысын. Колхозда гына эшлә, диләр. Әмма минем ФЗУга китәсем килә. Минһаҗ Сәмите кебек елтыр төймәле кара бушлат, соры бүрек, хром перчаткалар киеп, авылга кунакка кайтырбыз әле... И-их!

Шулай да кем язды икән бу язуны? Болай, эч пошканнан гына яздылар микән, әллә... Мин битемнең кайнарланганын тоям, күкрәк читлегендә нindидер дөпелдәү ишетәм. Йөрәктер, мөгаен — сул якта бит...

Әлеге алтын ай Бертабан тавы артыннан ипи кыерчыгы кадәр генә күренеп торган бер кичтә тәки үзен генә очраттым мин Әкълимәне. Чишмәгә суга төшкән иде. Бер чиләген тутырып улак читендәге таш өстенә утырткан. Икенчесен тутырырга әзерләнә.

— Кәҗәгез кайтмады мәллә, Илгиз? — дип кычкырды ул миңа еракстан ук.
Мин, тавышымны аныкычарак үзгәртергә тырышып:
— Кайтмады шул, Әкълимә, — дидем.
— Һе-һе, алай икән, кая китте икән төнгә каршы? — дип, аптырап баш чайкап торды.
— Ә? Нәрсә дисең? — дидем мин якынрак килеп һәм су тавышы аша бернәрсә дә ишетмәгәнгә салышып.
Ә ай инде түм-түгәрәк. Тау түбәсенә орынып ук тора. Аз гына кагылдың исә, түбән тәгәрәп төшәр сыман.
— Китәр юлларыңны карыйсыңмы, Илгиз?
Әкълимә бер кулы белән улак читенә тотынган, икенче кулы белән чиләк чайкаган булып маташа. Үзе күз кырые белән генә миңа карый.
— Паспортлар алып кайттым инде, шушы көннәрдә китәм.
— Ишеттем.
— Ә син нишләргә уйлыйсың быел, Әкълимә?
— Белмим әле.
— Әкълимә! Бернәрсә сорасам, әйтерсеңме?
— Сорап кара.
— Теге күпер иңсәсенә синең исемне язып куйганнар.
Әкълимә эндәшмәде. Миңа аркасы белән борылып, су агызырга керешә. Чиләге тулып ташый башлады. Әмма Әкълимә аны улактан алмады. Кисәк кенә борылып миңа карады.
— Һәмбәл абый язган аны.
— Укытучы Һәмбәлме?
— Киномеханик.
— Соң ни бит, соң... синнән олы бит ул, — дидем мин, күңел төбеннән актарылып чыга башлаган ачуымны басарга тырышып.
— И Илгиз,— дип, көянтәсенә таянып сөйләп китте Әкълимә,— аптыратып бетерде инде ул мине. Теге ни, син район үзәгендә паспорт алып йөргәндә, һич кенә дә кич урамга чыга алмадым. Самокатына атлана да күзләрен тозландырып килеп җитә. Әйдә, Әкълимә, утыртып урам әйләндерәм, дигән була. Әллә нинди сүзләр сөйли...
— Ә син соң, син, Әкълимә?
Әкълимә йөзен улак эченә яшерде.
— Әйттем инде.
— Ни дип әйттең?
— Егетем бар, дидем.
— Ә ул?
— Һәй, аның ише бала-чага, дигән була.
— Иманын укытам мин аның!..
— Бәйләнә күрмә, Илгиз. Җен кебек таза бит ул. Ан-

нан соң тамчы да ошамый Һәмбәл абый миңа... Ичмасам, син дә китәсең, Илгиз.

— Болай булгач, китүне кичектереп торырга туры килә инде, — дидем мин, гайрәтле тавыш белән.

— Илгиз!

Ничек матур, ничек ягымлы әйтә Әкълимә минем исемне. Эх, хәзер аның кулларыннан тотасы иде дә әйтәсе иде... Юк шул, әйтеп булмый. Әллә ничек үзеннән-үзе дер-дер китерә, куркыта, оялдыра.

— Әкълимә!..

— Син ничек матур әйтәсең, Илгиз, минем исемне...

— Әкълимә!..

— Ярый, мин кайтыйм инде,— диде Әкълимә, көянтә тимерен югары улактан шаулап ага торган суга тотып, — иртәгә кино була икән.

— Син барасыңмы, Әкълимә?

— Барыр идем дә, Һәмбәл абыйдан куркам. Күзенә күрендем исә, озатып куям, дип аптырата башлый.

— Әкълимә, телисеңме, мин сине үзем озатып куям?..

Әкълимәнең көянтәсе инде иңендә. Чиләкләрендә ай шәүләләре уйный. Менә ул минем яннан ук узып китте. Хәтта мин аның кайнар сулышын тойгандай булдым. Чәчләре иңнәренә сибелеп елкылдый. Күз карашы — сукмакта. Бераз баргач, Әкълимә туктады. Миңа таба борылды. Мин Әкълимәнең ике күзендә ике ай күрдем. Менә аның матур иреннәре сизелер-сизелмәс кенә кыймылдады:

— Кинодан соң карт өянке янында, яме...

Әкълимә ераклашты. Чиләкләрендә һаман да ай нурлары уйнады. Баш очымда гына карт өянке нидер пышылдап куйды. Улакларда, көмеш тамчылар чәчрәтә-чәчрәтә, бертуктаусыз су чылтырады.

* * *

Китәсе дә килә сыман авылдан. Китәсе дә килми. Күңелдә ниндидер рәхәт борчылу, рәхәт дулкынлану. Түбән очта, дәртле күңелне тагын да дәртләндереп, кино моторы дөпелди. Әле кино башланырга иртә. Механиклар сынап кына карый торганнардыр моторларын. Гадәттәгечә, кинога тагын акча юк инде. Һаман-һаман әнидән дә сорап торып булмый. Әле узган атнада гына бөтен акчаларын кырып-себереп миңа чалбар алган иде — акчасы да юктыр. «Три мушкетер»га качып-посып кына кергән идем дә бит. Белмим шул, бу юлы ишек төбендә Һәмбәл үзе билет сатачак, ди. Ул инде үлсә дә акчасыз кертми. Кино башланганчы өч-дүрт мәртәбә билет тикшермәсә, күңеле булмый аның. Әллә кинога бармыйча,

Әкълимәнең клубтан чыкканын гына саклап торырга микән? Алай да егетләрчә булмый...

— Нигә бик уйга батып торасың әле, улым?

Мин сискәнеп киттем.

Өстенә һәрвакыт эт өрсә дә ертылырга торган зәңгәр сатин күлмәк киеп, башына ак яулык бәйләп йөри торган акыллы, юмарт әнием бу юлы да мине аңлады.

Ишегалдында кер элә торган җиреннән тукталып, йомшак тавыш белән генә:

— Баядан бирле минем тирәдә кыршынып йөрисең, кинога акча кирәктер инде сиңа? — диде.

Мин дәшмәдем. Иреннәремне тешләштергәләп, йөземә нәүмиз кыяфәт чыгарырга тырышып, Нәкыя абыстайлар каенына гына карап тордым.

— Акча юк шул, — диде әни, соңгы керен шапылдатып селки-селки.

Әнинең тел төбеннән: «Акча югын юк та, тик син кайгырма, берәр әмәлен табарбыз», — дигән мәгънә яңгырады.

Һәм шулай булып чыкты да.

Менә ул керен элеп бетереп, эмальләнгән кара табагын култыгына кыстырды һәм «ристан» галошларын лыштырдатып, болдырга таба китте. Бер уңайдан «әйдә, керик әле» дип, мине дә чакырып узды.

Өйгә кердек. Әни табагын почмак сәкесенә куеп килде дә өстендә ястык-юрганнар өелеп торган зур иске сандык янына тукталды. Ястыкларны сәкегә алып ташлады. Сандыкны ачты һәм тынып калды.

Бу сандык ачылгач, эш пешә инде дип уйладым мин. Шатлыгымнан авызым ерылып ук китте.

Элегрәк сөлге-җәймәләр белән шыгрым тулы иде бу сандык. Хәзер саеккан. Саегыр да шул. Кайчандыр шул сөлге-җәймәләр өс-башыбызны бөтәйттеләр, «ни ашыйм, ни эчим» заманнарында безне ризыклы иттеләр.

Әни ачык сандык өстенә иелгән килеш шулай беркавым уйланып торды да кулын чигүле салфеткалар арасына тыгып җибәрде. Салфеткалар арасыннан бәләкәй генә тартма килеп чыкты. Әни аны кулына алды. Саклык белән генә ачты. Тагын уйланып торды. Мин сузылыбрак карадым. Тартмада читләренә бизәкле кәгазьләр ябыштырылган нәни генә шешә ята иде.

Ни өчендер керфекләре дымланган әни шешәне кисәк кенә учларына кысты да миңа сузды.

— Мә, — диде ул, дымланган күзләрен алъяпкыч итәге белән сөртеп,— укытучы Фагыйлә апаңа илтеп бир, әни сатам, дип әйтте, диген. Шул сөйләшенгән бәягә дип әйтте, диген, үзе белә ул. Кинога да керерсең, китсәң-нитсәң, калганы юлыңа да җитәр...

Мине ай күрде, кояш алды. Очтым гына ике ягына ямь-яшел бәбкә үләне үскән сукмак буйлап. Фагыйлә апалар янына барып җиткәнче түзмәдем — учымдагы шешәнең капкачын борып ачып, иснәп карадым. Әттәгенәсе! Мондый тәмле исне гомеремдә дә иснәгәнем юк иде минем. Ай-яй! Ландыш, миләүшә чәчәкләренең, җир, каен җиләкләренең исен җыеп шушы шешәгә тутырганнар диярсең. Эх! Шул чагында кылт итеп Әкълимә исемә төште. Аңа да иснәтеп карасаң моны? Яисә елкылдап торган чәчләренә сөртсәң! Шул чагында минем башыма вәсвәсәле һәм шул ук вакытта мавыктыргыч уй килде... Очлары ниндидер серле зәңгәрсу эңгергә төренгән талларга күтәрелеп карадым. Ара-тирә нәрсә турындадыр сөйләшкәләп куйган карга тавышларына колак салып тордым. Һәм, тирә-ягымнан үтеп-сүтеп йөргән кешеләр күрмәсен тагын дигәндәй, шешәнең капкачын ябып, кесә төбенә салып куйдым да, бөтен эчем-тышым белән шатланып, клуб ягына йөгердем.

Чаба-чаба уйлыйм. Уйлый-уйлый чабам.

Фагыйлә ападан гына килмәсен әле тәмле ис. Әкълимәдән дә килсен, дим. Кинога без бушлай да керәбез, ә китә-нитә калсам, ни пычагыма акча? Станция бер чакрым. Әллә вагон подножкаларына басып йөрмәгән малайлармы без! Күз алдыма, ак күлмәкләрен җилфердәтеп, тагын Әкълимә килеп баса. Чәчләренә кадап куйган кәкре тарагына кадәр күрәм мин аның. Нәрсә дияр икән шушы хушбуйны бүләк итеп биргәч! Сөенер микән? Ә алмаса?

Клуб янында кеше аз әле. Минем ише егет-малайлар һәм ыбыр-чыбыр бала-чагалар гына судагы маймычлар кебек тыз да быз йөргәләп тора. Киносы сугыш турында икән.

Кич болытлы. Өянке ябалдашлары, ниндидер яңа көй чыгарырга тырышкандай, бер ду килеп, бер бөтенләй тына язып тирбәләләр. Яхшы, бик яхшы төн кыяр каракларына дип уйлыйм мин эчемнән генә. Үзем, клуб артына чыгып, ярым ачык калган тәрәзәгә карыйм. Эчтә ут янмый януын. Ләкин тәрәзә биек. Баскыч-фәлән сөйрәп килеп булмас инде. Почмакка чыгып, бүрәнә башларына ябыша-ябыша, өскә үрмәлим. Бөтен көчемә ыргылып, бер кулым белән тәрәзә яңагын эләктерәм. Менә инде икенче кулым да тәрәзә яңагында. Аяклар әлегә һавада асылынып тора. Зарар юк, без инде мондыйны гына күргән малайлар. Бөтен көчеңне беләкләреңә туплап, менә шулай күтәрелергә дә гәүдәңне менә шулай эчкә ыргытырга. Караңгы клубка кереп, идәненә баскач, тизрәк кесәне капшап карыйм — төшеп калмады микән?! Юк, исән-сау...

Сәхнә астында тагын да караңгырак. Өстәвенә бөркү.

Башка пәрәвезләр тиеп тора. Идәндә бер карыш тузан — өс-баш буялмасын өчен чүгәләбрәк утырырга тырышам.

Тышта кино моторы дөпелди. Өянкеләр шаулый. Кесәдә — ислемай. Бераздан уйларым тагын Әкълимә чәчләренә кереп адаша.

Ишек тавышы ишетелгәч һәм сәхнә астын каплаган такталар арасыннан гөлт итеп ут шәүләсе күренгәч кенә уйларымнан айнып киттем. Ишетәм — Һәмбәл билет сата башлады. Алгы рәткә, чыр-чу килеп, бер төркем юеш борыннар кереп тулды. Бертуктаусыз сөйләшәләр, көлешәләр, чарт-чорт симәнке яралар. Дөбердәшеп сәхнәгә сикереп менәләр дә кәҗә бәтиләре кебек тагын шыбырдашып төшәләр. Ара-тирә Һәмбәлнең кырыс тавышы ишетелгәләп китә: «Артыгыз кычыта, ахры, сезнең, артыгыз...»

Инде урта рәтләрдә басынкырак тавышлар да ишетелгәли башлады. Болары — олылар. Кемдер гармун кычкыртып куйды. Тышта моторны беркавым сүндереп тордылар да тагын кабызып җибәрделәр. Чыгарга вакыт түгел микән инде миңа? Ләкин ни өчендер залда ут сүнми дә сүнми. Мондый тузан арасында утырганыңны Әкълимә күрсә, җуләр! Әнә баш очында гына нәрсәдер шыңгырдап куйды. Музыка уйнап җибәрде... Ә ут сүнми дә сүнми. Болай утырып булмый ич инде. Кино башланды бугай. Ниһаять, кызыксыну җиңде. Сәхнә астыннан, башның яртысын гына чыгарып, залга карадым. Әмма, көчле яктылыктан күзләрем әлҗе-мөлҗе килеп, бернәрсә дә күрми тордым. Аннары... аннары кемнәрдер шаркылдап көлеп җибәрделәр. Баш очында радио гына шыңгырдаган икән дә бит, әмма ләкин соң иде инде. Кире тартып алганда башым сәхнә аратасына бәрелде. Һәм шул чагында кемнеңдер тимердәй каты бармаклары җилкә тамырыннан кысып алды. Хром итекләреннән таныдым — Һәмбәл үзе. Күз алларым караңгыланып китте. Тирә-юньдә чыр-чу, көлеш. Ә мин Һәмбәл кулыннан ычкынырга тырышмыйм да. Яңакларымның уттай януын тоеп, зал буенча сөйрәлеп барам. Һәмбәл тавышы кайдандыр еректан, стена артыннан ишетелә сыман:

— Куян тоттым, җәмәгать, менә карагыз, ата куян.

Инде бала-чагалар гына түгел, олылар да көлә. Әкълимә! Эх, Әкълимә дә монда бит инде. Клуб идәне ярылмый, ичмасам... Бетте, барысы да бетте...

Ишек төбенә җитәрәк, идәнгә нәрсәнеңдер шылтырап төшкәнен ишетәм, Һәмбәл кинәт идәнгә иелә. Ислемай! Бөтен клуб, бөтен халык яшелле-кызыллы томан эчендә. Беркемгә дә карамыйм, беркемне дә күрмим. Күзләрем фәкать Һәмбәл кулындагы шешәдә. Тешләремне кысып, Һәмбәл өстенә сикерәм. Һәмбәл артка тайпылып

өлгерә, тиз генә шешәне ачып иснәп карый. Сипкелле борынын җыерып, зәһәр итеп көлә. Аның тавышы тагын каядыр еракта, стена артында:

— Бик көяз куян булып чыкты әле бу, кесәсенә хушбуйлар гына тыгып йөри икән, әй...

Көлү тавышы ярым ачык ишектән ургылып кергән мотор тавышын күмеп китә. Түшәм чайкала. Юк, түшәм түгел, мин үзем чайкалам...

Менә инде мин караңгы урамда.

Клуб почмагына китеп, кызган битләремне төн җиленә куеп тордым да тагын ишек янына килдем. Эчтә кино бара. Басма алдында, җен ачуларымны чыгарып, ялгыз мотор дөпелди. Аны-моны уйлап тормыйча, җирдән бер уч комлы туфрак умырып алдым да, капкачын ачып, бензин багына салдым. Тагын салдым, тагын... һәм караңгы урам буенча йөгердем... Бераз йөгергәч, туктап тыңлап тордым. Мотор ничектер тончыгып-тончыгып эшли башлады. Аннары тагын бер-ике мәртәбә төчкереп алды да бөтенләй тынып калды...

Капканы бикләп, чолан ишеген дөбердәтүгә әнинең: «Бетте дәмени кино?» — дигән йокылы тавышы ишетелде.

— Бетте, — дидем мин, аны-моны сиздермәскә тырышып.

Өйгә кереп ут кабызгач, мич алдындагы бәрәңгеле табакны алып өстәл янына килеп утырдым. Әнигә карамыйча гына тиз-тиз ашадым. Урынымнан торып, юлга җыена башладым.

— Әни, мин китәм.

— Ничек?

— Иртәнге поезд белән китәләр икән безнең район малайлары.

Әни бераз сүзсез ятты.

— Ничек инде шулай уптым илаһи гына, — диде аннары, калтыравыклы тавыш белән. Үзе, тиз генә идәнгә төшеп, әрле-бирле йөренә башлады.

— Укырга кереп урнашкач ук кайтырмын,— дидем мин, мышык-мышык елаган әнине юатырга теләп.

Әни башка туганнарымның китеп-кайтып йөрүләренә күнегеп беткән иде инде — озак еламады. Яулык чите белән күзләрен сөртеп алды да миңа үгет-нәсихәт бирде, хәерле юл теләде һәм, шау чәчәккә күмелгән ялгыз шомырт сыман агарып, капка төбендә торып калды.

Мин авылны чыкканда, яктыра башлаган иде инде. Бытбылдыклар моңсу гына кычкырып озатып бардылар. Еладым бугай мин ул чагында. Имәнәй болынындагы чыклы үләнгә ятып, тәгәри-тәгәри еладым бугай.

Аннан соң авылга әллә ничә тапкыр кайтсам да, ни өчендер Әкълимәне очрата алмадым. Ул кайтса, мин авылда булмый торган идем, мин кайтсам — ул...

Карама,
уйлама,
эндәшмә, Әкълимә...
Син генә тик минем уемда...

## МИҢА УЙЛАРГА КИРӘК

Лагерьга берничә көнгә соңгарак калып килде ул. Килде дип, үзе килмәде, өч тәгәрмәчле мотоцикл бишегендә тирбәтеп әтисе китерде.

Йөзгә бик ябык, гәүдәгә безнең малайларның һәркайсыннан кайтышрак булса да, тегермәне әйбәт тарта булса кирәк — рюкзагы шактый симез күренә. Аннан соң киемнәреннән төрле тәм-том, яңа пешкән прәннек исләре дә аңкып тора моның. Күзләре ачык зәңгәр — катыкура чәчәген хәтерләтә.

Аның әтисе өлкән зоотехник булып эшли. Көзге яңгырлар димәс, язгы юл өзеге димәс — көне-төне мотоциклына атланып чабар.

Әнисе һәм бәләкәй сеңлесе белән Ленар (киемнәреннән прәннек исе аңкып торган малайның исеме шулай) безнең колхозга әле күптән түгел генә күчеп килгәннәр. Көзен сигезенче «А»да укырмы Ленар, «Б»дамы — анысы киләчәк эше. Бүгенгесе кызык бит әле аның.

Әтисенең мотоциклы арыш арасына кереп күмелгәнче, олы юлга карап торды ул. Юк инде, тәти егет, монда килеп капкач, тиз генә ычкына алмассың, әтиең киткән юлларга карасаң-карамасаң да, лагерь тормышына күнегергә туры килә.

Сезнекеләрдә ничектер, ә безнең лагерьда тормыш шартлары шактый кырыс. Мәми авызларны, йокы чүлмәкләрен яратмыйлар безнең лагерьда. Шуңа күрә «хезмәт һәм ял лагере» дип атала да инде ул. Монда килүчеләр су буенда арка кыздырырга гына исәп тотып кузгалмыйлар туган йортларыннан. Әнә чөгендер җире сиңа, әнә кукуруз басуы. Утырт, чәч, тәҗрибә үткәр, тәрбиялә, үстер... Лагерьга синнән алда килгәннәрнең эшен дәвам ит, үзеңнән соң килүчеләр турында уйла!

Төшке ашка утырыштык. Кызлар, әдәп саклап, ирен-нәрен чапылдатмыйча ашарга тырышалар. Ә без, малай-

лар, алай кәнфитләнергә яратмыйбыз, булса, солдатларча, ирләрчә булсын безгә. Ипине умырып кабабыз, итле борчак ашын кашык тутырып чөмерәбез. Шулай булмый теге... Төштән соң кукуруз чүбенә барасы ла... Анда ныгытып ашап барсаң да таманга килә әле.

Бакчы, ашау белән мавыгып, яңа малайны онытып та җибәргәнбез бит.

Карагыз әле, кара! Нишли ул? Ипи кисәген бәләкәй-бәләкәй генә сындырып каба. Кашыкны иреннәренә тидергәнче тәлинкә читенә куеп торгандай итә. Әгәр дә берәү такта стенаның теге ягыннан тыңлап торса, кашык белән аш ашый дип уйламас иде моны, ант әгәр, пумала белән кыштыр-кыштыр рәсем ясый дип уйлар иде. Бөтенләй ашау ләззәтен белми бит бу. Әллә тамагы тук микән?

Безнең өстәлдәге малайлар Ленарга мыскыллы көлемсерәп күз аткаласа, кызлар, киресенчә, сокланып, бераз көнләшкән сыман караштыргалап утырдылар аңа. Хәтта үзидарә комиссары Айгөлнең дә күзләре гел шул якта булды.

Ярар, табын янында чын актер икәнсең син, Ленар иптәш. Басуда нишләрсең икән менә, карап карыйк...

Яндыр, кояш, әйдә, яндыр! Кызганма эссе нурларыңны! Татлы прәннек исләрен ялап-ялмап ал шул малайның киемнәреннән!

Әһә! Бирешә бугай тәти егет. Инде хәзер бездән бишалты адым арткарак калып утый. Кызарган бит алмаларында да, борын очында да бөрчек-бөрчек тир тамчылары ялтырап күренә. Шуларны яшерер өчендерме, зәңгәр пилоткасын әледән-әле терсәк белән баскалый, маңгаена шудырып төшерә.

Быргычы Самат, юл читенә чүп үләннәре чыгарган булып, тегенең эш сыйфатын күзәтеп килде. Килеп үз рәтенә иелгәч, сытык чырай белән ике генә сүз әйтте:

— Утый белә...

Кызларын әйтерең бармы тагын! Үзләренә тиешле кишәрлекне утап чыккач, шул малайның алдыннан әйләнеп керделәр. Күр инде, кызлардан да гарьләнми, ичмасам, авызын ерып, рәхмәт әйткән булып тора. Имеш, менә карагыз, мин нинди әдәпле малай... Лагерь начальнигы Фәнәви дә, вожатый Сәлимә апа да шул малай тирәсендә бөтерелә... Шундый хәлләр менә.

Көн җиләсләнде. Утлы нурларын җиргә коеп бетергәч, кояш сабырланып, юашланып калды, шактый вакыт инде нишләргә икән дип уйланып торгандай тоелды. Аннары көндез шулкадәр кызып китүе өчен кемнәндер оялгандай, кинәт кенә комачтай кызарып, ашыга-ашыга офыкка таба тәгәрәде.

Лагерьга кайтышлый, гадәттәгечә шау-гөр килеп, су

буена чабышып төштек. Өс-башларыбызны ничек кирәк алай чишенеп атып, бер-беребездән уздыра-уздыра, төнбоеклар арасына сикерештек.

Ленар безгә иярмәде. Киемнәрен ничек кирәк алай салып атмады. Тәртибе белән чишенде. Башта киемнәренең тузанын какты, тыплап кына төреп, чиста үлән өстенә куйды. Аннары гына суга чумды. Гомерендә күрмәгән, белмәгән елгага... Йә, йә, ярый, чумдың, ди... Чалкан ятып та, колач салып та йөзеп күрсәттең, ди. Ай-яй, бик шаккаттык инде сиңа, хараплар хәйран калдык...

Судан чыгып, киенеп, кичке ашка йөгердек. Безнең тәти егеткә шул юыну гына җитмәде, ахрысы, палаткасыннан исле сабын, сөлге алып чыгып, юынгычлар ягына юнәлде. Кызлардан уздыра бит бу... Нәсимә урынына лагерьның санитары итеп сайлап куячаклар моны, болай булса...

Табын янында янә шул кыяфәт, шул хәрәкәтләр. Болай да оялып ашый торган кызларны бөтенләй тамактан калдыру, ахры, моның нияте.

Тиле дигән саен тигәнә буе сикерсәң, шулай була бит ул. Бермәлне мактанчык Ленарыбызның кулыннан кашыгы төшеп китмәсенме. Капкан ризыгын йотып та җибәрә алмый, кире дә чыгара алмый — тик тора үрдәк кебек кылкынып. Зәңгәр күзләре төссезләнеп китте, йөзенә күләгә җәелде.

— Тамагыңа сөяк утырдымы әллә, үскәнем? — дип, ак халатын җилфердәтеп, аш пешерүче Бибинур апа килеп җитте.

Башын гына чайкый Ленарыбыз.

— Ни булды алайса, әллә бер-бер төшең авыртамы?

Аның тәлинкәсенә сузылып караган малайларның кайсыдыр:

— Черки, — диде.

— Кайда, нинди черки?

— Әнә ашына төшкән.

Без дәррәү көлеп җибәрдек. Бибинур апа көлмәде. Авыз эченнән генә нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана, Ленарның ашын алыштырып килде.

Әмма Ленар бу ашка да орынмады. Теләр-теләмәс кенә чәй белән ипи капкалады да, кесәсеннән кулъяулыгын алып, ишеккә юнәлде. Кыланчык! Бер-ике көн ач тотасы иде моны...

Кич, учак ялкыннары күккә үрли башлагач, уңыш бәйрәмендә куелачак концертка репетиция ясадык. Яңа малай баянны бик яхшы сайрата икән. Үзе күңелле көй уйный, ә үзенең күзләрен яшь пәрдәсе томалаган сыман. Учак яктысында шулай моңсу күренәдер, бәлки, аның күзләре. Баян тавышы тынып торган арада, нарат урма-

ны ягыннан арыш дулкыннары шаулап килүе, кайдадыр якында ялгыз бытбылдык өзгәләнүе ишетелеп китә.

Без Айгөл белән бүген дә башкорт биюен биедек. Айгөл толым очларына ак тасма кушып үргән. Туктале, сборларга гына үреп килә иде түгелме соң толымнарын ак тасма белән ул? Бәйрәм дә түгел бүген, генеральный репетиция дә... Әллә Айгөлдән дә прәннек исе килә инде?!

Бию уңаенда Айгөлнең алсу итәкләре, җилфер-җилфер килеп, учак ялкыннары белән кушылып китә яза. Маңгай чәчендә ак ромашка балкый, тешләре баян төймәләре кебек җемелди... Әй, карасана, карамагаең!.. Харап инде, барысы да шаккаттылар шул малайга! Нәфисә эби әйтмешли, тәмам мөкиббән киттеләр. Нигъмәтуллин Нәҗипне бөтенләй төшеп калганнардан дип уйлыйлар инде әллә болар?

Көзләр җитеп, дәреслекләрне кулга алыйк әле менә. Кем турында күбрәк сөйләрләр икән мәктәптә? Нәҗип турындамы, әллә шул малай турындамы? Әле хәзер баянга башын кыңгыр салып, янтаеп утыра да бит, математиканы ничек сайратыр икән? «Теге мәсьәлә ничегрәк чишелә, бу тигезләмә ничегрәк төзелә?» — дип, иң беренче кем янына килер икән Айгөл, карап карарбыз... Ә хәзер биергә кирәк. Сер бирергә ярамый. Җир тетрәтеп биергә кирәк. Менә шулай... менә шулай басалар бездә... Их!..

Күзләрен утлы күмерләр кебек елтыратып, Айгөл бии, мин биим. Кемнәндер көнләшкән, кемнедер үртәгән сыман, учакта ереле-ваклы ялкыннар бии. Ә баш очындагы алтын бизәкле Җидегән йолдыз чүмеченнән күксел томан ябынган арыш басуына бертуктаусыз йомшак нур коела...

...Иртәгесен мине әллә нинди генә яшерен сөенеч төртеп уятты. Палаткада нишләптер ялгызым гына калганмын. Бәләкәй тәрәзәдән одеял читенә алтын нур баганасы сузылып төшкән. Ә-ә! Экскурсиягә барабыз бит әле без бүген. Раифа заповеднигына. Ял атнасы башланды бит инде безнең.

Торып һавага чыктым. Иксез-чиксез зәңгәрлек. Су өстенә тияр-тимәс кенә, нарат очларыннан көмеш очкыннар чәчрәтеп, ялгыз акчарлаклар очып бара.

Аннары Ленарга күзем төште. Ак шорты белән зәңгәр майка киеп җибәргән. Ике зирек арасына бау бәйләп маташа. Кызлар кер юганнар икән. Шуларга булышуы икән инде моның. Артист! Иртүк кәефне бозмасаң, ашыңа черки төшкере...

Ашханәдә, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, тавыштынсыз гына ашап-эчтем. Автобус әле соңрак киләсе икән. Аннары юл кирәк-яракларын, кием-салымнарны әзерләп куярга куштылар.

Җыенып-әзерләнеп беттек дигәндә, безнең палатка ишегендә Айгөл күренде. Ул ым белән генә мине тышка чакырып чыгарды һәм, ниндидер яшерен сере бар кеше шикелле, иреннәрен колагыма ук куеп:

— Әйдә, Нәҗип, автобус килгәнче, Ленарга Кизләү аланын күрсәтеп кайтабыз, — дип пышылдады.

— Шул малайгамы?! — дигән төксе сүзләр ычкындыруымны үзем дә сизми калдым.

— Нишләп алай әйтәсең? Ленар бик инсафлы малай ич.

— Барыгыз соң алайсам шул инсафлы малай белән.

— Барасың килмәсә, барма алайсам, — диде Айгөл, минем тавышка охшатыбрак. — Рәүфкә әйтәм алайсам, Рәүф тыңлар әле...

Айгөл «алайсам» сүзен юри шулай басым ясап әйтте.

Миннән дә ихтыярсыз кеше бар микән дөньяда! Сүзләрем тагын уйларымнан җитезрәк булып чыкты:

— Барам инде алайсам...

Ленарны арыш арасындагы сукмакта куып җиттек. Сез килмәсәгез, үзем генә бара идем, үзем генә таба идем Кизләү аланыгызны, дигән сыман тоелды миңа анын кыяфәте.

Күк йөзе нәкъ Ленар күзләре төсле. Айгөлгә карамаска тырышам. Ләкин барыбер, күпме генә тырышсам да, арыш басуы өстендәге рәшә дулкыннарына кушылып, күзләремә анын шәүләсе үзеннән-үзе агып керә...

Менә инде безнең каршыбызда Кизләү аланы. Тездән биек сусыл үлән дисеңме монда, лепелдәшеп утырган төз усаклар, карт карамалар, яшь зирекләр дисеңме...

Ак кофталы Айгөл, кулларын акчарлак канатлары кебек җәеп, дөя өркәчедәй кабарып торган яшел түмгәк өстенә сикереп менде һәм кинәт җан ачысы белән кычкырып җибәрде:

— А-аһ!.. Үләм, малайлар, елан чакты, — диде ул без килеп җиткәч, бөтенләй ят, хәлсез тавыш белән.

Мин коелдым да төштем. Босоножкасын салып атып, ике кулы белән бармакларын чытырдатып кысып, калтыранып утырган Айгөл тирәсендә таптанып тора башладым.

— Бау, — дип кычкырды кинәт Ленар, мине төртеп җибәреп, — йөгер тизрәк, юкә каезлап кил!..

Мин, үз-үземне белештермичә, зирек куаклары янына ташландым. Ләкин каушавымнан бернәрсә дә эшли алмадым. Күз алдымдагы агачлар барысы бергә буталды, яшел ябалдашлар дөм кара булып күренде.

Кайсыныңдыр:

— Нәҗип, — дип кычкырганын ишетеп, яңадан Айгөл янына атылып килдем.

Айгөлнең чәчләре тузгыган, аягы ике җирдән ак тасма белән кысып бәйләнгән иде. Ленар бер җирдә дә күренми.

— Анда ул, — диде Айгөл, баягыдан да хәлсезрәк тавыш белән, — кешеләр чакыр... Елан агуын авызы белән суырды... Елгага йөгерде... Анда ул... Кешеләр чакыр...

Автобус Айгөлне дә, Ленарны да больницага алып китте. Аларны озата барган санитар Нәсимә төш җитәрәк «икесенә дә куркыныч янамый, икесе дә тиздән терeләчәк» дигән сөенечле хәбәр алып кайтты. Баш врач Василий Петрович: «Уртаклашкан кайгы кайгы түгел, уртаклашкан агу агу түгел», — дип көлеп тә куйган ди хәтта...

Су буенда мин ялгызым гына.

Үземне ниндидер бер бик кадерле әйберне җуйган яисә әманәтен үти алмаган кешедәй хис итеп, нарат урманы артыннан күпереп чыккан куе кара болытларга, офыкларны иңләп ялтырашкан яшен кылычларына карап утырам. Чиләкләп бозлы яңгыр койса да, җир өстендә яшен шарлары тәгәрәшеп йөрсә дә, тиз генә кузгалмаячакмын әле мин моннан.

Миңа уйларга, бик күп уйларга, уйларга кирәк...

# ЕРАКТАМЫ, ЯКЫНДАМЫ?

Әллә кайчаннан бирле эленеп тора инде сыңар бияләй өрәңге ботагында. Юл буйларын көрт күмгән көннәрдә узгынчыларның иңбашларына тияр-тимәс тирбәлеп кала иде ул. Хәзер урамнар кардан арчылды. Бияләй күзгә күренеп биегәйде.

Тәрәзәдән карап утыра торгач, үзе өчен кызыклы бер яңалык ачты Илгиз: агач ботагындагы биялэйгә балачагалар, кызлар, егетләр һәм эти кешеләр бөтенләй диярлек игътибар итмиләр. Әниләр генә... Кызларын яисә улларын җитәкләп биек йортлар эргәсеннән салмак кына атлаучы әниләр генә... Өрәңге төбенә килеп туктыйлар да теге яктан карыйлар биялэйгә, бу яктан... Мондый чакларда һәр әни янындагы баласыннан: «Синеке түгелме?» — дип сорый сыман тоела Илгизгә.

Ә бит өрәңге ботагындагы биялэй Илгизнеке. Моны берәү дә белми. Илгизнең әтисе дә, әбисе дә белми. Илгиз хәтта үзеннән дә яшерергә тырыша биялэйнең үзенеке икәнен.

Шулай бервакыт чана шуганда күрше кызы Фирүзәнең елап торганын күрде Илгиз. Күрде дә юату нияте белән баштанаяк карга буялган Фирүзәгә якынрак елышты. Ә-ә-ә! Әнә эш нәрсәдә икән! Әнисе орыша икән Фирүзәне. Фәлән дә фәсмәтән, ачык авыз, ди, кулайсыз, җебе-

гән, ди. Борынын тарткалап, Фирүзәне кызганып торганда төшенеп алды Илгиз: сыңар бияләен җуйган икән Фирүзә. Шуның өчен дөнья бетереп битәрли икән аны әнисе.

Фирүзәләр кайтып киткәч, кар өемнәренә типкәләп, югалган бияләй табылмасмы дип, байтак өметләнеп йөргән иде Илгиз ул чакта. Әмма бияләй табылмады. Шунда өметле уй янына сөенечле уй да килеп өстәлде: кара, Илгизнең үз бияләйләре дә нәкъ Фирүзәнеке төсле ләбаса. Аннан соң Илгизнең яңа күн бияләйләре дә бар. Кыскасы, әтисе белән дә, әбисе белән дә киңәшмәде Илгиз — мәсьәләне үз белдеге белән хәл итте дә куйды.

Илгиз чыгарып ташлаган сыңар бияләй берничә көн Фирүзәләр тәрәзәсе каршындагы сукмак буенда яртылаш карга күмелеп ятты. Ләкин аңа кагылучы да, орынучы да булмады.

Беркөнне кичкырын Илгиз бәхетсез бияләйне Фирүзә йөри торган сукмакка куеп калдырды — иртәнгә кадәр, аннары иртәдән кичкә кадәр яткан урынында ята бирде бияләй. Берничә көннән Илгизгә үз бияләе бик кызганыч булып тоелды. Карга катып, бозланып беткән бияләйне ул өйгә алып кереп җылытты, киптерде дә Фирүзәләр йорты каршындагы өрәңге ботагына чыгарып элде.

Әнә шул көннән бирле ботакта тирбәлә дә тирбәлә сыңар бияләй.

Дөрес, апрель урталарында — күләгәле урыннарда кар атаулар агарып ята иде әле — Фирүзә дә тотып карады бияләйне. Әнисе алып бирде аны Фирүзәгә. Илгиз, тәрәзә рамына ябышкан көе, нәрсә була инде дип уйлый гына башлаган иде, Фирүзә нәрсәдер әйтте дә, тегеләр бияләйне үз урынына элеп, ипи кибетенә таба киттеләр. Берберсенә карап сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә киттеләр. Илгиз, тырнак очын кимерә-кимерә, алар кибет борылышына кереп күздән югалганчы, артларыннан карап калды.

Әллә үзен, әллә бияләен кызганып елады инде Илгиз ул көнне. Үзе, еламыйм, еламыйм дип уйласа да, яңаклары буйлап тәгәрәгән кайнар тамчылар, елыйсың, елыйсың, дип үртәделәр аны һәм тагын да ныграк елыйсын китерделәр.

Илгизләр дә шулай җитәкләшеп йөрерләр иде микән, әнисе исән булса. Илгиз әнисен бөтенләй хәтерләми. Үлгән Илгизнең әнисе. Авырган да үлгән. Әбисе дә, әтисе дә әйбәт инде әйбәтен Илгизнең. Беркайчан да нахакка рәнҗетмиләр аны, җил-яңгыр тидермиләр. Аннан соң «үлгән» дигән салкын сүз белән ахырынача килешеп җиткәне дә юк әле Илгизнең. Ничек инде «үлгән»? Олы кешеләрнең

эниләре үлә. Ә Илгиз бөтенләй кечкенә бит әле. Юк, үләргә тиеш түгел аның энисе!

Янында энисе булса, бияләй турында әйтер иде микән Илгиз аңа? Әйтмәс иде, мөгаен. Эниләр алар усал була торганнардыр, ахры. Әнә бит теге чакта, бияләен югалткач, Фирүзәне ничек орышып ташлады энисе. Аннары урамга уйнарга чыккан саен күрә Илгиз: иң шаян, иң шук малайлар да эниләрен күргәч шым булалар. Эниләр янында малайлар басынкыланалар, юашланалар. Аларның йөзләренә кызлар кыяфәте чыга.

Фирүзәгә дә энисе рөхсәт итмәгәндер әле, мөгаен, агач ботагындагы бияләйне алырга. Әгәр дә Фирүзәнең үз кулына тапшырса Илгиз бияләйне? Синең бияләең югалган иде кыш көне, синең бияләең бу, мин табып элгән идем агачка, дисә? Хәзер көннәр җылы, хәзер бияләй киеп йөрмиләр инде йөрүен. Шулай да кызганыч бияләй. Өр-яңа бит әле ул. Аннары бик йомшак та. Нигә генә ошатмады икән соң Фирүзәнең энисе? Бик тә, бик тә Фирүзә кулында күрергә теләгән иде Илгиз бияләйне. Теләге кабул булмады, ахры.

Ә бүген бияләен өйгә алып керү нияте белән чыккан иде Илгиз урамга. Тегеләй әйләнде өрәңге тирәсендә, болай әйләнде һәм һич көтмәгәндә Фирүзә белән очрашты. Фирүзә, бер кулы белән яшел башлык эченнән тузып чыккан маңгай чәчләрен рәтли-рәтли, өрәңге ботагындагы сыңар бияләйне күзәтә иде. Илгиз, чигенә-чигенә, өрәңге төбеннән ераклаша да башлаган иде инде, тик Фирүзә кычкырып өлгерде:

— Исәнме, Илгиз!

Илгизнең исәнләшергә дип ачылган авызы ябылмыйча калды, Фирүзә чәтер-чәтер тезәргә кереште:

— Синең бияләең ич ул, Илгиз. Кыш көне безнең тәрәзә алдында аунап ятты, инде менә кемдер агач ботагына киертеп киткән. Буең җитә ич, ал, Илгиз.

— Минеке түгел ул, синеке түгелме соң? — дип, бияләйгә бер генә күз сирпеп алды да Илгиз, кызарып, башын түбән иде.

Фирүзә Илгизнең йөзенә текәлебрәк карады. Фирүзә эченнән генә көләдер сыман тоелды бу минутта Илгизгә. Ул башын тагын да аскарак иде.

— Минем бияләйнең сулы югалган иде шул, ә бу уң бияләй, — диде Фирүзә, очлы күзләрен һаман да Илгизгә текәгән килеш. — Ә синең кайсы бияләең югалган, Илгиз?

— Минемме? Минем югалмаган.

Менә эш нәрсәдә икән? Их, тиле Илгиз, тиле Илгиз!.. Бияләйнең уңы һәм сулы булуын бөтенләй исеңнән чы-

гаргансың бит син! Менә шулдыр инде ул — сукыр тавыкка бар да бодай...

— Кем бияләе икән соң алайса?.. Мондый бияләйләр синең белән миндә генә дип уйлаган идем мин тагын.

— Белмим...

— Синекедер, Илгиз. Син оныткансың гынадыр. Әниең булса, исеңә төшергән булыр иде, бәхетең, әниең юк...

Кинәт кенә Илгизнең бөтен тәненә ут капты. Яңаклары гына түгел, колаклары, маңгае, күкрәкләре дә яна иде аның хәзер. Шулай да телен көчкә әйләндереп:

— Минем яңа бияләйләрем бар, — дип әйтә алды.

— Әниең булса, күрсәтер иде сиңа яңа бияләй! Әниең булмаганга күрә иркенләп йөрисең әле син. Өеңә караңгы булгач кайтсаң да орышучы юк сине, бияләй югалтсаң да сүз әйтүче юк.

Илгиз сискәнеп куйды, капылт кына башын күтәрде, тырнакларын уч төпләренә батырып, Фирүзәгә таба атлады. Кызның ваемсыз-матур күзләрен үпкә катыш нәфрәт уты белән көйдерде. Аннары, кисәк кенә борылып, яфракка бөреләнгән өрәңгеләр арасыннан юлсыз-нисез йөгереп китте.

Сулышы кабып, әлсерәп, шәһәр читенә килеп чыккач кына туктады Илгиз. Әле һаман да язылмаган йодрыклары белән дымлы керфекләрен сыпырып алды. Күз карашы талганчы офыктан офыкка җәелеп изрәп яткан язгы серле киңлекләргә сихерләнеп карап торды.

Булырга тиеш лә Илгизнең әнисе, булырга тиеш!..

Битне йомшак җил сыйпый, күзгә саф, садә яшеллек агып керә, күңелне тып-тын күгелҗем ераклыклар ымсындыра...

Бар ла ул Илгизнең әнисе, кайдадыр яши. Яши һәм һәрдаим Илгизне күзәтеп, аның кайгы-шатлыгын уртаклашып, аңа яхшылык теләп тора. Тик ерактамы ул, якындамы — шунысын гына тәгаен белми Илгиз.

## ХЫЯНӘТ

Язын, көннәр җылынып, калку урыннар ала-колалангач, таугa менеп, узган елгы чирәмгә яланаяк басып торганыгыз, шул чирәмгә ятып тәгәрәгәнегез, әле кояш нурлары сеңәргә өлгермәгән җир исен иснәп кинәнгәнегез бармы сезнең?

Гадәттә, чирәмнең уртасы гына коры, ә читләре, перламутрдай ялтыр кар диңгезенә барып тоташкан урын-

нары дымсу була. Иелебрәк карасаң, кар астыннан җем-җем килеп нәни ерганаклар тибеп чыкканын да күрәсең. Күз яшьләре кебек елтырап агып чыгалар да, алар иңкүлекләрдә көмеш күлләвекләр хасил итәләр. Төбендәге чирәмнәренә кадәр үтә күренмәле күлләвекләрдә әле бер генә бөҗәк тә, бер генә җан иясе дә юк. Чөнки бик иртә бит әле — инешкә ташу да төшмәгән.

Каршы тау безнең авылның буеннан-буена сузылган. Һәркемгә мәйдан җитәрлек монда уйнарга. Әнә бит, Түбән оч малайлары, киек казлар кебек тезелешеп, Карт карама аланына менеп киттеләр, ә без монда, Каршы тауның урта бер җирендә...

Билгеле, тырай тибеп йөрер өчен генә менмибез инде тауга. Кыш буе караңгы, салкын абзарларда интеккән кәҗә-сарыкларны алып менәбез. Авыз тутырып утларлык булмаса да, узган елгы чирәм чемченергә ярап куя бит малкайларга, әй! Җир исен алар да сагынганнардыр, күрәсең, — башларын да күтәрмиләр.

Бездән ерак түгел бәләкәйрәк чирәмлектә кулларын тезләренә кушырып, авыл ягынамы, авыл артында йокымсырап яткан басуларгамы күзен текәп, көтүче Исламгәрәй абый утыра. Без аңар күнеккән инде, игътибар да итмибез. Гадәте шул аның — карлар эреп бетеп, көтүләр чыкканчы Каршы тау буйларын айкап кайта. Әллә җәй көне генә басу-кырларда йөреп туймый инде шунда. Кайчагында ул безгә матур-матур әкиятләр дә сөйли сөйләвен, әмма кайчагында таш сын кебекката да кала. Эндәшсәң дә җавап бирми. Катыкура чәчәге төсле ачык зәңгәр күзләрен зур ачып, ерак офыкларга текәлгән килеш оеп утыра да утыра шулай бер көе. Исламгәрәй җырлар чыгара икән, дип тә сөйлиләр авылда аның турында. Ләкин безнең беркайчан да Исламгәрәй абыйның җырлаганын ишеткәнебез юк...

— Самат, Самат! Кемгә әйтәләр!

— Миңа әйтәсеңме, Рафил? Мин хәзер...

Рафил урта урам малае, безнең чирәмлеккә әле икенче көн генә менә. Яшькә дә өлкән, буйга да зуррак булгач, без аны командир итеп сайлап куйдык.

Булдыклы малай икән — командир булырга өлгермәде, приказлар да бирә башлады. Миңа катыкура сабаклары җыеп килергә кушты. Җиренә җиткереп үтәдем аның боерыгын... Бер кочак катыкура сабагы җыеп килдем. Нәҗип тау итәгеннән корыган чикләвек куаклары сындырып менде...

Кар диңгезе уртасындагы чирәмле атауда көлгә күмеп пешерелгән бәрәңгедән дә тәмлерәк нәрсә бар микән дөньяда тагын? Тауга менәргә дип әзерләнеп йөргән-

дә үк тоя башлыйбыз инде без аның тәмен. Тауга менгәч, учак кабызырга коры-сары җыйганда да, учакта ялкыннар дөрләгәндә дә китми бәрәңге тәме авыздан. Кайчан күмер төшәр дә, кайчан күмәрбез бәрәңгеләрне...

Арырак Исламгәрәй абый учагы төтен яулыгын болгый, ә тагын да арырак, ботаклары әкияттәге гыйфрит кулларына охшаган карт карама аксыл күк читен күтәреп торган якта, түбән очлар учак яга булса кирәк — җил аннан да төтен исе китерә.

Рафил бик еш карады бүген шул якка. Арпа башагы төсле кызгылт-сары кашларын көндәгегә караганда ешрак хәрәкәтләндерде, йә булмаса, йөзен учакка якын китереп, кирәксә-кирәкмәсә дә кисәү башларын рәтләштергәләде. Нигә шулай кылана икән дип торсак, бәрәңге бирмәгәннәр, имеш, моңа бүген өендә. (Ул авыр елларда — сугыш елларында, бәрәңге табынның патшасы иде, дисәк тә хата булмас.) Нишлисең инде, бүген Рафилга бирмәгәннәр икән, иртәгә Нәҗипкә йә миңа бирмәсләр. Югы уртак, бары бергә, дидек инде Рафилга. Рафил, командир буларак, әлбәттә, моны гадәти хәл дип кабул итте. Аны-моны дәшмичә, кесәләребездә йөри-йөри агач шарлар кебек шомарып, ялтырап беткән бәрәңгеләрне учак төбенә тезеп салды... Барысы унбер бәрәңге икән. Нәҗипнеке — алты, минеке — биш... Ничек бүләрбез икән инде унберне өчкә? Бәрәңгеләрне көл белән күмгәндә дә, көл өстенә утлы күмерләрдән юрган япканда да мине шул сорау борчыды.

Учакны яңадан дөрләтеп җибәргәч, Рафил сары кашларын рәттән берничә мәртәбә сикертеп алды, томанлы күзләрен кысып бетерә язып, безнең кызарып чебиләнгән аякларыбызга карап торды. Аннары, учак каршысына кибәргә куелган калын олтанлы итекләребезгә ымлап, кискен тавыш белән:

— Киенегез, разведкага барырсыз, — диде.

Без, сыннарыбызны турайтып, Рафилга текәлдек.

— Түбән очлар лагеренда ничә кеше икәнен белеп кайтырсыз.

Нәҗип:

— Кар астына су төшкән бит, — дип, киез итекләренә кызганыч караш ташлады.

— Приказ үтәлергә тиеш! — диде Рафил, берәгәйле итеп. — Бәрәңге пешкәнче кайтып җитәргә!

Барыргамы-юкмы дигәндәй, селкенер-селкенмәс тора идек — «бәрәңге» сүзе утлы күмергә баскандай үрле-кырлы сикертте безне. Итекләребезне, бишмәтләребезне киеп, агач мылтыкларыбызны асып, өсте челтәрләнеп җемҗем килеп торган кар диңгезенә кереп киткәнебезне сиз-

ми дә калдык. Рафил безне бармакларын түгәрәкләндереп ясаган «биноклен» күзләренә куеп озатты.

Башта итекләребезгә кар тулып тинтерәтте. Берничә тапкыр салып селкегәч, без аңа игътибар итмәскә булдык. Әмма кар тирәнәйгәннән-тирәнәйде. Карт карама төбенә барып җиткәндә, аякларыбызны көчкә-көчкә генә сөйрәп чыгара идек инде. Караманы узып, эскерт урынына җиттек дигәндә, Нәҗипнең итеге бөтенләй суырылып калды. Мин, карны казып, итекне эзләп тапканчы, Нәҗип, ялангач аягын өскә күтәреп, кар өстендә ятып торды. Менә шунда ачты инде ул разведчик хәйләләренең берсен.

— Малай, — диде ул, кар яктысы төшкән күзләрен бәхетле елтыратып, — түш белән генә шуып барыйкмы әллә? Яткач, кар батмый икән бит...

Юлның калган өлешендә шулай эшләдек тә. Болай аякларга кар да керми, су да үтми, кешегә дә күренмисең. Тез башлары белән терсәкләр чылана инде чылануын. Нишлисең бит, сугыш корбансыз булмый.

Бардык шулай түш белән шуышып, корыган әрем сабаклары арасыннан башларыбызны аз гына калкытып санадык түбән очларны. Биш малай, ике кыз. Бермә-бер артык боларның көчләре. Кызларны исәпләмәгәндә дә бишәү. Учаклары да ике җирдә яна...

Нәҗип белән үзара ым кагып кына сөйләшеп-аңлашып алдык та кайтыр якка борылдык. Сөенеч зур: приказ үтәлде. Бик кыйммәтле мәгълүматлар алдык бит инде түбән очларның лагереннан.

Уңышлы разведка күңелебезне күтәрдеме, салкынга, юешкә күнегеп җиттекме — кайтыр юл килгәндәге кебек читен булмады...

Кисәү башлары сизелер-сизелмәс кенә төтәп яткан учак күренгәч, «ура!» кычкырып, алга ташландык, йөгергән уңайга су сеңеп авырайган итекләребезне чирәм өстенә селкеп ыргыттык... Тик кайда соң әле безнең командир, кайда соң Рафил?.. Үзе дә юк, сарыклары да. Учак тирәсендә бәрәңге кабыклары гына таралып ята. Мин, аптырап, Нәҗипкә карадым. Аның күзләре яшьләнгән иде. Икебез дә берьюлы учак көлен актарып ташладык — ник бер бәрәңге калсын!

Булган хәлгә ышанмыйча, тагын тирә-юньне күзәтеп чыктык. Күк гөмбәзе һаман да ап-аяз, офыклар һаман да көмешсу, авыл һаман да үз урынында — тик учакта бәрәңге генә юк.

Исламгәрәй абый күптән күзәтеп утырган, ахры, безне, кул изәп, үз янына чакырып алды. Без, походларда бергә йөргән турылыклы иптәшләре дошманга әсир төш-

кән солдатлар сыман, атлар-атламас кына Исламгәрәй абый янына барып бастык. Исламгәрәй абый күк төсле күзләрен зур ачып елмайгандай итте, учак янына утырырга ишарәләде, беркемне дә гаепләргә теләмәгән йомшак тавыш белән:

— Алдандыгызмы? — диде.

Без аны-моны дәшмичә, борыннарыбызны тарткалап, җил өреп кызарткан күмерләргә генә карап утырдык.

Исламгәрәй абый, көл астыннан икешәр бәрәңге алып, безнең алга куйды, шырпы тартмасындагы тозын безнең яккарак этәрде.

— Ашагыз.

Җитте бит, әй, икешәр бәрәңге безгә. Ашыйсы килү дә басылгандай булды, эчкә җылы да керде...

Бераздан без, дөньядагы иң шат, иң гамьсез балалардай, кояшлы чирәм өстендә тәгәрәшеп уйнарга тотындык...

Хәер, дөресрәге, шат күңелле, гамьсез булып бер-беребезгә күренергә генә тырыша идек бугай без. Нәҗипкә күтәрелеп караган саен, аның күз алмалары миңа учакта кара көйгән вак бәрәңгеләрне хәтерләтәләр иде. Бермәлне, карашларыбыз очрашкач, Нәҗип, сискәнеп, артка тайпылды — бу минутта минем күз алмалары аңа да учакта кара янган вак бәрәңгеләргә охшап күренгәндер, мөгаен.

## ДЕМОНСТРАЦИЯ

*(Бәйрәм хикәясе)*

Уйларың язгы күктәй чалт аяз, хыялларың иген кырларыдай иксез-чиксез киң, өметләрең чишмә суларыдай саф, ә инде әниеңнең куллары кояш җылыткан яшь юкә яфракларыдай җып-җылы, йоп-йомшак... Кайсы көн соң әле бу?.. Нинди онытылмас иртә? Ә, бәйрәм бит, Май бәйрәме иртәсе...

Һаман да шулай якты, нурлы, җылы, куанычлы булды микән Май бәйрәме иртәсе? Балалар һаман да шулай дәртләнеп, шау-гөр килеп, күңелле җырлар җырлап урам йөрделәр микән Май бәйрәме иртәсендә?..

Барабанчы Госман бу хакта озак уйлап тормады — урыныннан торып юынгач, өстенә ак бүз күлмәген киеп, култыгына калай табак кыстырып, кесәсенә агач кашык тыгып, мәктәпкә йөгерде. Урамнар яп-якты. Кая карама — анда кызыл флаглар җилферди. Бөтен авылга чәчәк исе, майлы ботка исе таралган. Тәмле дә пешерә инде Гаилә абыстай ботканы. Быргычы Наил инде әллә кайчан мәктәп ихатасында. Быргы башына өргәләгән була.

Җиң очы белән быргының әле бер җирен, әле икенче җирен ышкып ала. Ә күзләре аш бүлмәсе тәрәзәсендә. Госман да табагын Гаилә абыстайга биреп, барабанын асып чыкты. Ниндидер көй чыгарырга теләгәндәй, ара-тирә барабанына бәргәли-бәргәли, аш бүлмәсе каршында тулганырга тотынды. Яшел чирәм борынлап килгән ихатада муеннарына кызыл галстук таккан яисә кызыл яулык бәйләгән малайлар, кызлар ишәйгәннән-ишәйде.

Урамның каршы ягында, зур кулларын аркасына кушырып, Зәбих агай киләп сарып йөри. Күкрәгендәге медальләре малайларның күзләрен яндырып ялт-йолт килә. Сугышка кадәр дә урман каравылчысы булган ул. Хәзер дә урман каравылчысы. Мәктәп халкы ияләшеп беткән инде аңа. Җил дими, яңгыр дими, бәйрәм җитте исә, таң тишегеннән авылга төшеп җитә. Балалар белән бергә урамда йөри, балаларга кушылып җырлый. Ә менә ни өчендер ботка ашарга керми. Башта аны Гаилә абыстай, аннары укытучы Хәлимә апа чыгып чакыра. Зәбих агай барыбер керми. Зур кулы белән ияген генә ышкып күрсәтә. Тамагым тук, янәсе. Шундый тәмле ботка исенә ничек түзеп тора булыр, шайтан белсен. Барабанчы Госманга исә, Гаилә абыстай пешергән ботка булмаса, бәйрәмнең бер яме дә булмас кебек. Сугыш беткәч, ашауэчү иркенәя, дигәннәр иде дә... Юк шул әле. Өлкәннәрнең әйтүенә караганда, әрем баскан кырларда байтак тир түгәсе бар икән. Аннары гына туйганчы ипи ашап була, ди.

Балаларны ашарга чакырдылар. Госман әдәп саклап иң арттан керде. Бусагага аягын куйгач, урамга күз ташлап алды. Зәбих агай олы юлдан читкә китеп коймага сөялгән иде. Тәмәке тарта, ахры — буылып-буылып йөткергәне ишетелә.

Мәктәп эчендә башта бик каты шаулаштылар. Аннары тынлык урнашты. Бераздан калай табакларга бәрелеп кашыклар тупырдашты. Барабанчы Госман булса кирәк — берәү табагыннан ниндидер көй чыгарырга тырышып шыкылдата. Тагын бераздан урындыклар дөбердәде, ишекләр шыгырдады. Яшел чирәмгә шау-гөр килеп балалар ташкыны агып чыкты.

Байрак йөртүчеләр берничә адым алгарак басты. Аннан соң барабанчы Госман белән быргычы Наил һәм эреле-ваклы плакатлар, яшь тал ботаклары, флагчыклар тоткан малайлар, кызлар тезелештеләр, Хәлимә апа белән Зәбих агай, гадәттәгечә, иң артта калды. Ул да түгел, дүртенче класс укучысы сипкелле Сара җыр башлады.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Су буенда коенгач...

Икенче класс кызлары җырны бераз нечкәртеп тәмамладылар.

Безнең мәктәптә күңелле,
Аңлы тәртип куелгач...

Кызыл байрак горур җилфердәде. Госманның борын тартуын барабан дыңгырдавы күмеп китте. Аңа тантаналы җиз тавыш белән быргы кушылды. Быргычы Наилнең яңаклары футбол тубы кебек кабарып чыкты. Койма ярыкларына, рәшәткә араларына юеш борынлы, сары чәчле ыбыр-чыбыр бала-чага килеп сарылды.

Кузгалдылар. Олы сандаллар, җеп башмаклар, чебиле аяклар бердәм хәрәкәткә килде, бер көйгә атлады.

...Без төнлә туктаган чагында,
Ул егет бер җыр җырлады.
Аттылар дошманнар ягыннан —
Җырның ахыры булмады.

Монысын инде урман каравылчысы Зәбих агай башлады. Җырны Хәлимә апа күтәреп алды. Малайлар да, кызлар да төрлесе төрле тавыш белән җырга кушылдылар. Зәбих агай бәйрәм саен шул җырны җырлый. Аны тыңлаганда Госманның күзенә һәрвакыт яшь килә. Кызганыч. Барабанчы егет сугыш кырында үлеп кала.

Зәбих агайның тавышы нинди көр. Әллә урманда яшәгәнгә микән. Кибет тыкрыгына җитәрәк, Госман артына борылып карады. Зәбих агайның керфекләре дымланган кебек күренде аңа. Күзләре уйчан-уйчан инде аның, әнә инде ул җырлаудан да туктады. Хәлимә апа җырына колак салып кына атлый. Аңламассың, ни өчен бәйрәм саен укучылар белән урам йөридер дә, ни өчен бер үк җырны җырлый торгандыр. Аннары капылт кына нигә уйга бата торгандыр.

Ә Зәбих агай бу минутта барабанчы Госман турында уйлый иде. Бәйрәмнәрдә авылга төшкән саен, барабанчы Госманга караган саен, бер үк күренеш күз алдына килеп баса иде аның. Кулбашлары, терсәк турылары сизери башлаган ак бүз күлмәк, солдат каешы белән буып куелган олы чалбар, очкынланып торган күзләр... Шул бит инде Зәбих агайның бала чагы... Ул таңнар ерак калса да онытылмый...

Ул иртәдә Зәбихләр яшәгән урам корт иле кебек гөҗләп торды... Гомерендә күргәне юк иде Зәбихнең шулкадәр халыкны... Забастовка, диләр. Әтисе эштән ачык йөз белән кайтты. Шул ук вакытта нигәдер дулкынланган иде ул. Өс-башын алыштырып ашык-пошык кына капкалап алды да, Зәбихне беркая да җибәрмәскә кушып, урамга чыгып китте. Утыртырсың мондый көндә Зәбих-

не өйдә! Әтисе артыннан ук чыгып тайды малай. Әй, анда халык, әй, анда халык! Җырлары да әкәмәт җырлар. Авыз тутырып:

Бетсен патша,
Янсын тәхет... —

дип җырлыйлар.

Менә бәхет — Зәбихнең әтисе иң алгы сафта. Кулына кызыл байрак тоткан, Зәбих кешеләр арасыннан әтисенә якынлаша башлады. Әллә нәрсә генә булды шул чагында. Сафлар кинәт сөрлегеп китте. Кемдер итек белән Зәбихнең аягына басты. Таш йортларга шартлау тавышы килеп бәрелде дә, тоныкланып, халык диңгезе өстенә җәелде. Урам кычкырулар, янаулар, ыңгырашулар белән тулды. Зәбих бер минутка гына әтисен күздән җуеп торган иде. Бераздан аның киң аркасын тагын күрде. Әтисе кулындагы байрак ни өчендер кыйшаеп авып барадыр сыман тоелды Зәбихкә. Байрак аумады. Аны икенче берәү, фуражкасын күзләренә үк батырып кигән мыеклы кеше тотып өлгерде. Ә менә Зәбихнең әтисе ауды. Бер кулы белән күкрәген кысып, икенчесен әллә ничек бик җайсыз рәвештә һавада селкеп чалкан ауды ул.

Тирә-юньдәге тавышларны да ишетмәде Зәбих, кылыч айкап сафлар өстенә ташланган атлы казакларны да күрмәде. Ике кулын йодрыклап урам ташына тезләнгән килеш әтисенең байрак кебек кызарган күлмәгенә карап катты да калды...

...Барабанчы Госман, авыл башына җитәрәк, тагын артына борылып карады. Җырга Зәбих агай да кушылган иде инде. «Аңламассың кешене, — дип уйлады Госман, карашын яшәреп килгән каен башларына күчереп,— үзе безнең белән ботка да ашамый, ә үзе бәйрәм саен безнең белән җыр җырлап йөри...»

## БЕРЕНЧЕ КАР

Атна буе салкын җил исте. Инешләр туңды, уҗым басулары, түгәрәк урман артында диңгездәй җәелеп яткан сазлык туңды. Корыган камышлар ачынып сызгырыштылар. Агач ботакларына эләгеп калган сары яфракларны рәхимсез җил бер селтәнү белән коеп төшерде дә ерак кырларга очырып китте.

Ә көннәрдән бер көнне җил тынып калды. Һава ничектер җылынып, дымсуланып китте. Биектә-биектә, өер-өер булып, каядыр ашыккан болытлар, тизлекләрен ки-

метеп, бер көчкә укмаштылар, авырайдылар, түбәнәйделәр, аксыл төстән болганчык-көлсу төскә керделәр. Ябалак-ябалак кар ява башлады. Ә бер ява башлагач, ул ишепишеп, бурап-бурап яуды, атна буе яуды. Өй түбәләренә ак мамык өйде, агачларга ак кием бөркәде, сукмакларны, юлларны күмде. Тирә-юнь ничектер яктырып, матурланып китте.

Ял көне иде. Фәрит йокысыннан уянганда, әнисе мич тирәсендә кайнаша. Өйгә май исе җәелгән. Диванда Фәритнең сеңлесе Миләүшә йоклап ята. Ә аның аяк очында, күзләрен кысып, мыекларын селкеткәләп, бохар песие мырлап утыра.

Фәрит юрган астыннан чыгу белән, гадәтенчә, физзарядка ясады. Салкын су белән юынды. Аннан соң тәрәзә янына килде. Кар тагын да калынайган, бакча рәшәткәсенең яртысына җитә язган! Азрак салкынайтып та җибәргән бугай. Тәрәзәләрнең аскы өлгеләренә төрле-төрле бизәкләр, чәчәкләр төшкән...

— Авыл тирәсендә ата күрмә, улым, мылтыгыңны, ишетсен колагың, — дип кисәтеп калды капкадан чыкканда Фәритне әнисе.

Хуҗасының кай якка китәсен чамалап алган Сигнал, карга бата-бата, алдан йөгерде.

Сигналның аяклары тез тиңентен сап-сары. Әйтерсең лә читек кигән. Ә калган җирләре ап-ак. Кар кебек. Бик сөйкемле, бик акыллы, бик сабыр эт. Һич кенә дә юккабарга өрмәс. Тавык-чебешләрне, каз-үрдәкләрне рәнҗетмәс. Мәчеләр яныннан башын югары чөеп кенә, үзенең дәрәҗәсен төшермичә генә узып китәр.

Кое янында су алып торган хатын-кызлар белән: «Исәнмесез!» — дип исәнләшеп узды Фәрит. Тегеләр дә үз чиратларында: «Бик исән әле, акыллым», — диештеләр.

Авылны чыккач, Фәрит артына борылып карады: чаңгы эзләре зәңгәрсу тасма булып еракка сузылып киткән. Шул эзләрдән болайга таба алпан-тилпән тагын бер чаңгычы килә. «Кем булыр бу? — дип уйлады Фәрит һәм туктап көтә башлады. — Карасана, классташы Сабир түгелме соң? Шул, җир йотсын, шул. Физкультура дәресләреннән парта асларына, мич артларына качып кала торган Сабир кырга чыгарга ничек җөрьәт иткән?» Кыш буе мич башыннан төшми, диләр ләбаса аны.

Менә Сабир мышный-мышный килеп тә җитте. Чаңгы таякларын култыгына кыстырып, кулларына өргәләп алды. Күз чите белән генә Фәритнең мылтыгына карап куйды.

— Ай-яй салкын бүген, малай, ә? — диде ул, ниһаять, ни әйтергә белми байтак кына торганнан соң. — Бармакларым өшеп төшә дип торам.

— Үзең тирләгәнсең ич, — диде Фәрит, көлмәскә тырышып.

— Кул туңды,— диде Сабир һәм, бияләйләрен салып, бармакларын угаларга керәште.

— Кайларга юл тотмыш соң болай?

— Менә синең мылтык асып узып киткәнне тәрәзәдән күреп калдым да... чыктым әле. Әти дә әрли. Бар инде, бар, азрак җилләнеп кайт, йә мич арасындагы лаканга егылып төшәрсең, ди.

Фәрит түзәлмичә пырхылдап көлеп җибәрде.

— Соң, шуннан!

— Апбар әле, Фәрит, мине дә, ә...

— Кая?

— Кая булса да.

Фәрит азрак уйланып торды. Аннары, җитди кыяфәткә кереп, болай диде:

— Түлке кара аны, ишетсен колагың, кайтыйк, кайтыйк, дип, вакытлы-вакытсыз колак итемне ашамассың, ярыймы?

— Ярар, ярар, — дип шатланып риза булды Сабир.

Әнә инде алар өчәүләшеп ерактан әллә нинди серле кыя булып күренгән Түгәрәк урманга якынлашып киләләр. Чаңгылар чаж да чож, бүрек колаклары җилфер дә җилфер.

Бөтен күк гөмбәзен тутырып торган болытлар каядыр китеп югалды. Ялтырап кояш чыкты. Кышкы урман малайларның күз алдында бөтен матурлыгы белән балкып китте. Ботакларында энҗе утлар җемелдәшкән агачлардан бөтен тирә-якка зәңгәрсу күләгәләр сузылган. Әйтерсең ниндидер күзгә күренми торган рәссам ак полотнога урман рәсемен ясап калдырган. Бер караганда, урман тыптын. Бер генә дә җан иясе юк сыман. Ә яхшылабрак карасаң, дикъкать беләнрәк күзәтсәң, алай түгел. Урман яши. Урман үз дөньясы белән тереклек итә. Әнә карасу яшел чыршы ылыслары тибрәнешеп куйдылар. Тиен шулай селкетә ылысларны. Үзе күренми. Үзе ылыслар арасында. Әнә, куллары белән биленә таянып торган баһадирдай, юан имәннең очында ук кызыллы-сарылы чәчәкләр — кызылтүшләр күренгәләп китә. Сайраулары нинди матур. Гүя кайдадыр ара-тирә көмеш акча чылтыраталар.

Фәрит тирә-якның гүзәллегенә сокланып торган арада, шабыр тиргә батып, кызарынып-бүртенеп, Сабир да килеп туктады. Ул берни дә күрми, берни дә ишетми иде, ахрысы, бүреген баш түбәсенәрәк чөеп, як-ягына каранды, күзләрен шарландырып: «Нәрсә бар?» — дип сорады.

Фәрит, шаулама дигән мәгънәне аңлатып, бармагын иреннәренә куйды. Анда-санда, ахак тамчыларыдай, туң-

ган җимешләре ялтырап күренгән миләш агачына ымлап күрсәтте:

— Ишетәсеңме?

— Кошлар ич, — диде Сабир, исе китмичә генә.

— Ә нинди кошлар?

— Чыпчыклардыр, нинди кошлар булсын.

— Син үзең чыпчык,— диде Фәрит ачуы чыгып. — Бүздәкләр... Кыш җиткәч, безнең урманнарга төньяктан очып киләләр. Әнә болыт булып югары күтәрелделәр. Алары нинди кош?

— Белмим, — диде Сабир, борынын тартып.

— Алары чәчетләр. Ишетәсеңме, әч эт, әч эт, дип кычкыралар. Безнең Сигналны үртәүләре инде бу аларның...

Сабир, беренче мәртәбә күргәндәй, Фәриткә шаккатып карап торды. Аннары, соклануын яшерә алмыйча, әйтеп куйды:

— Син боларның барысын да каян өйрәндең, малай, ә?

— Урман китабыннан.

Шул чагында Сабирның күзләре агач төбенә төште.

— Фәрит, Фәрит, — диде ул каушый-каушый, — әнә, карале, нинди эзләр икән ул, бүре-мазар йөргән микән әллә?

— Бүре, чыннан да бүре эзләре, — диде Фәрит, агач төбенә борылып карагач.

Уен-көлкене аңламаган Сабир куркуыннан калтырана ук башлады. Үзе, телен чак-чак кына әйләндереп, болай диде:

— Әйдә, малай, сызыйк моннан яхшы чакта.

— Хәзер эләктерәбез ул бүрене, — диде Фәрит елмаеп. Үзе җәһәт кенә иелде дә кар астыннан бармак буе тычкан тартып чыгарды. — Менә ул бүре.

— Һе, — диде Сабир, авызын кыйшайтып, — шаяртасың, тычкан эзе ничек шултикле олы булсын?

Фәрит сабыр гына аңлатып бирде:

— Тамагы ачыккач оясыннан чыккан да ул бөтен гәүдәсе белән йомшак карга чумган. Кар базыннан сикереп котылдым дигәндә, тагын төшеп киткән. Тагын сикергән, тагын төшеп киткән. Әнә, шулай итеп, кар өстендә зур-зур эзләр ятып калган.

Бераз баргач, Сабир, бик белдекле кыяфәт белән, кар өстендәге чылбыр сыман эзләргә төртеп күрсәтте.

— Менә моннан да тычкан узган.

— Бусы төлке абзаң эзе инде, — диде Фәрит, Сабирга карамыйча гына. — Әнә, күрәсеңме, койрыгы белән эзен ничек бутап бетергән. Куа килүчеләр булса, кем икәнен белмәсеннәр, янәсе... Арыдыңмы әле?..

— Арыдым, — диде Сабир, ихлас күңелдән, — бот төпләрем авырта, аяк табаннарым кызыша.

— Менә шуның өчен дә чаңгыда күбрәк йөрергә кирәк. Ничу көне буе мич башында ятарга. Солдат буласы кеше ич син.

Сабирның зур кара күзләрендә шатлык очкыннары балкып китте.

— Чынлап та, малай, — диде ул, хыялга бирелеп. — Армияләргә китәселәр бар бит әле безнең. Сине сразы офицер итәрләр инде анда, име?

— Ник?

— Ник дип, соң... төз атасың, яхшы йөзәсең, чаңгыда таяксыз да әнә ничек җилдерәсең...

— Кыш буе минем белән йөрсәң, мин сине чын солдат итәрмен, — диде Фәрит, кинәт аяк өстенә басып.— Ә солдат, Суворов әйткәнчә, болан үтәлмәгән җирләрдән дә үтәргә тиеш... Алга!

Сабир да: «Алга!» — дип сикереп торган иде дә, гәүдәсен күтәрәлми, яңадан көрткә барып төште.

Мәһабәт чыршылар, кулларын сузып, малайларны сәламләде. Озын толымлы каеннар аларның өстенә энҗе бөртекләре сипте, кояш алтын нурларын койды. Кышкы урман әкият дөньясыдай матур, якты, серле иде.

— Әнә, күрәсеңме? — диде Фәрит, тагын бераз баргач.

— Күрәм, межа баганасы, — диде Сабир шыпырт кына.

— Ә аның башында?

— Кар...

— Хәзер шул карны әфсен укып һавага очырыйммы?

Сабирның кызарган, тирләгән йөзенә курку катыш кызыксыну билгеләре җәелде.

— Йә, — диде ул, ниһаять, күзләрен челт-челт йомгалап.

— Әфсен-төфсен, очып төшсен, — дип такмаклый-такмаклый, чаңгыларын бер урында шапылдатып тора башлады Фәрит. — Әфсен-төфсен, очып китсен, әфсен-төфсен!..

Багана башындагы кар йомгагыннан кинәт ике якка ике канат үсеп чыкты, карасу-кызгылт аяклар күренде һәм кар йомгагы, канатларын салмак кына җилпеп, карамалар арасына кереп югалды.

— Кар ябалагы, — дип аңлатты Фәрит, Сабирның карга сыярлык булып ачылган авызын күрмәмешкә салышып. — Тычканнар, чыпчыклар белән туена. Куяннарга һөҗүм итәргә дә күп алмый.

Ул да түгел, берничә йөз метр алга китеп өлгергән Сигнал ярсып-ярсып өреп алды. Берничә мәртәбә чинады. Тагын ярсый-ярсый өрергә кереште.

— Ура, дошманның эзенә төштек, — дип кычкырды

Фәрит һәм, мылтыгын алга төбәгән килеш, Сигнал өргән якка ташланды.

Тәмам хәлдән тайган Сабир да аның артыннан җитәргә тырышты. Ләкин ул атлаган саен каршылыкка очрады: әле бүреге чыбык очларына эләкте, әле чаңгы таяклары төшеп калды. Җитмәсә, баш очында гына, Сабирны үртәгәндәй, берөзлексез саесканнар тыкырдады. Сигнал тавышы ераклашканнан-ераклаша, урман куерганнан-куера, кар тирәнәйгәннән-тирәнәя. Ачу килә, елыйсы килә, әчәсе килә.

Ниһаять, алда бик зур ачыклык күренде. Фәрит иелгән дә кардагы эзләрне тикшереп маташа. Мылтыгын агач ботагына элеп куйган.

Сабир, аның янына килеп җиткәч, чаңгыларын да салмыйча ухылдап, карга ауды. Авызына йомарлап кар капты. Әмма Фәрит җитез хәрәкәт белән аның кулындагы карны бәреп төшерде һәм болай дип кисәтте:

— Әллә син, тирләгәч, кар ашарга ярамаганны да белмисеңме?

— Тамак кипкәч...

— Авызыңны ачып йөрисең, шуңа кибә ул тамак.

Сабир дәшмәде. Кулларын як-якка җәеп, күзләрен йомып, кар өстендә ята бирде.

— Тор, учак ягабыз.

Сабир теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды. Еламсырап кына: «Учак?» — дип сорады һәм тагын да төшенкерәк тавыш белән: «Кыш көне ничек якмак кирәк аны, учакны», — дип шыңшыды.

Фәрит, «утыра бир алайса» дигән мәгънәне аңлатып, кулын селкеде. Кар ерып, аланлык читенә китте. Башта ул карт каен кәүсәсеннән туз каезлап алды. Аннары наратларның аскы ябалдашларыннан чыбык-чабыклар җыйды. Әле анда, әле монда тырпаешып торган корыган зирек куакларын сындырды.

Берничә минуттан тип-тигез итеп тапталган кар өстендә аксыл ялкын телләре биешә иде инде.

Ялкын кызуында Сабир тыгып чыккан каз ботын һәм Фәрит кесәсендәге ипи телемнәрен җылытып ашагач, яньчелеп беткән бәләкәй кружкада чәй кайнатып эчкәч, малайларның кәеф яхшырды. Бигрәк тә Сабир канатланды.

— Рәхәт икән монда, — диде ул, як-ягына каранып.— Икенче ялга тагын киләбез, яме, Фәрит!

Фәрит, ризалык белдереп, баш какты.

Бераздан малайлар учак күмерләрен кар белән күмеп сүндерделәр дә тагын юлга чыктылар.

Кояш инде күкнең көнбатыш читенә тәгәрәде. Күләгәләр куерды. Агач башларыннан, кар коеп, кичке сал-

кын җил узды. Урман ешлыгында кемнәрдер ухылдады, нәрсәләрдер кыштырдады.

Көмеш кебек ялтырап яткан иксез-чиксез кырга килеп чыккач, җиңел сулап җибәрде Сабир. Бүреген баш түбәсенәрәк этәрде, чаңгы таякларын җәһәтрәк айкарга керешге.

Менә алар үр астына шуып төштеләр. Офыктагы сары кояшны челтәрләндереп күрсәткән урман полосасына керделәр.

— Шунда көтәбез, — диде Фәрит, яшь каеннар арасындагы эреле-ваклы эзләргә ымлап. — Озакламый Сигнал теге кылыйны монда куып китерәчәк.

Малайлар, сүз берләшкәндәй, икесе берьюлы йомшак карга чумдылар. Фәриткә куянны атар өчен бик уңай туры килде: нәкъ аның каршында кардагы эзләргә аркылы ауган каен ята иде. Мылтыгыңны куй да гөрселдәт кенә.

Бик озак көтәргә туры килмәде. Кайдадыр ерактан Сигналның ачы тавыш белән өргәне ишетелде. Аннары кырда тагын тирән тынлык урнашты. Ара-тирә каен тәлгәшләрен сыйпаштыргалап, кыр өстендә көмеш тузаннар күтәргәләп, шаян җил генә узгалап торды. Бер ераклашты Сигнал тавышы, бер якынайды. Яисә бөтенләй бетте.

— Күпне күргән тәҗрибәле куян булырга тиеш, — дип фикер йөртте Фәрит эченнән генә һәм Сабир ягына борылып:

— Сизәсеңме, кылый ничек эзен югалтырга тырыша, — диде.

Сабир дәшмәде. Болай салкын карга күмелеп яту аның эчен пошырды. Туңдырмаса да, әллә ничек, чиркандыра иде. Кояш та инде офык артына төшеп китте. Кыр күңелсезләнеп, төссезләнеп калды. Малайларның баш очыннан гына урманга таба ала каргалар очып узды. Менә хәзер өерләре белән бүреләр килеп чыгар сыман тоелды Сабирга. Менә бермәлне аның аяк очында кар шыгырдады, полоса буеннан ниндидер кара шәүлә шуып узды. Кемдер берничә мәртәбә, мыш-мыш килеп, сулап та куйды. Бар хәлгә кычкырасы, сикереп торасы килде Сабирның. Әмма кыюлыгы җитмәде. Бәлки, ул аюдыр?! Шулай уйлап та бетермәде Сабир, аның аягыннан ниндидер җанвар тешләп тартты.

— Әни, — дип чәрелдәде Сабир һәм, сикереп торып, үз-үзен белештермичә алга ташланды. Аягы теге ауган каенга эләгеп, тагын мәтәлеп китте. Бары тик артында Фәритнең шаркылдап көлүен ишеткәч кенә борылып карады ул. Сигнал икән, иблис. Арттан шыпырт кына килгән дә, уйнаган булып, Сабирның итеген тешләгән. Кара ничек шатлана. Эт булып эт көлә Сабирдан. Шүрләгәнеңне кешегә түгел, эткә дә сиздермә икән.

— Әллә нигә эчем авыртып китте,— дигән булды Сабир, эчен угалап. Үзе күз кырые белән генә Фәриткә карады. Ышана микән, янәсе.

Әмма Фәрит нигәдер бик ашыга иде.

— Әйдә, тизрәк, — диде ул, Сабирны да ашыктырып,— анда теге кылый ниндидер бәлагә юлыккан, Сигнал безгә шуны әйтергә килгән.

Шабыр тиргә баткан Сабир чаңгыларын киеп бетергәндә, Фәрит белән Сигнал урман полосасы буйлап әллә никадәр җир киткәннәр иде инде.

Чаңгыларын киеп алгач, Сабир да ашыккан булды. Үзе әледән-әле артына борылып карады. Бары тик урман полосасының аргы очында, чүгәләп, нәрсәдер эшләп маташкан Фәритне һәм нигәдер сөенә-сөенә сикергәләп йөргән Сигналны күргәч кенә йөрәге азрак урынына утырды. Ә тагын да якынрак килгәч, ике күзе дүрт булды Сабирның: Фәрит аяк астында зуп-зур ап-ак куян сузылып ята иде. Хәер, апак түгел икән. Колак очлары һәм арт аяклары саргылт.

— Аттыңмыни? — диде Сабир, бөтен эче-тышы белән куанып.

— Аттым сиңа... Кайсы юньсезедер капкын куеп киткән. Килеп җитмәсәк, харап була икән, бичара.

Сабир каушады, кабаланды һәм тотлыга-тотлыга әйтеп салды:

— Теремени? А-атыйк тизрәк.

Фәрит җавап урынына Сабирга томырылып карады да тагын кылыйның кул тигән саен дерелдәп киткән тәннәрен сыпырырга кереште.

Менә куян дерт иттереп торып утырды. Колакларын торгызды. Иреннәрен мимылдатып куйды. Коткаручысына рәхмәт әйтүе иде инде бу аның. Аннары кинәт каеннар арасына сикерде һәм пыр тузып йөгереп китте.

— Ат инде, ат, — дип ыгы-зыгы килде Сабир.

Сигнал, сырт йоннарын кабартып, ачулы ырылдады. «Тотып килимме?» дигәндәй, бер Фәритнең күзләренә, бер ераклашып барган куянга карады.

— Тик ят,— дип кизәнде аңа Фәрит.— Егылганны түбәлиләр димени?

Сигнал, башын аякларына куеп, карга сузылып ятты. Гүя ул: «Ихтыярың-мәйлең», — дип, хуҗасы белән ризалашты.

Сабир да башка: «Ник атмадың?» — дип төпченеп маташмады. Фәритнең әлеге шелтәсе Сигналга гына түгел, үзенә карата да әйтелгәнен яхшы аңлады ул.

Малайлар авыл башындагы салам эскертләренә кадәр сөйләшмичә кайттылар. Кырга эңгер төште, авыл ягында утлар ялтырады.

Эскертләрне узгач, Фәрит борчулы тавыш белән сорап куйды:

— Әниең ачуланмас микән инде, Сабир?

— Ачуланмас, — диде Сабир, эчке бер күтәренкелек белән. — Мин аңа барысын да сөйләрмен.

Күктә, биектә-биектә, бер-бер артлы йолдызлар кабына башлады. Яшелле-кызыллы утларын җемелдәтеп, авыл өстеннән самолет очып узды.

## ЯҢА ЕЛ КИЧЕНДӘ

Салкын. Офык ничектер томанланып һәм аз гына алсуланып тора. Мөгаен, кояш баеп баргангадыр инде. Кояш үзе күренми. Бары тик әнә шул кызгылт офык кына аның барлыгын, кайдадыр көлсу болытлар, салкын томаннар артында яшәгәнлеген раслый.

Салкын. Әллә утыз өч градус диләр инде, әллә утыз биш. Ишекне ачарга өлгермисең — борын очларына утлы энәләр кадала, тын кысыла, иреннәр туңа.

Самолет Казанга ярты сәгать элек очып киткән. Бәләкәй аэропортның залында өч-дүрт авыл агае һәм мин — самолеттан калган «бәхетсез» кешеләр.

Туры килде бит көне дә. Шофер никадәр генә куса да, самолетка килеп өлгерә алмадык. Әй, командировкадагы кешенең хәлләре! Тегендә, Казанда, гаиләң, бала-чагаларың көтеп ята, янәсе, әттәләре яңа ел бүләкләре төяп кайта. Ә монда... Әллә гостиницага кайтып китим микән? Алай дисәң, Казаннан өстәмә самолет бирмәгәйләре дигән хәбәр йөри.

Инде эңгер дә төшеп килә. Ишектән башны тыгып карасаң, иксез-чиксез карлы кыр өстендә өермә бөтерелә дә,— кемнедер куып җитәргә теләгәндәй, җәяүле буран йөгерә.

Аэропорт начальнигы кайтып китте. Соңгы стакан чәен йонлач бүрекле, салынкы мыеклы агайга эчерткәч, буфетчы кыз да, өстенә мутон тунын киеп, ишеккә юнәлде. Ишектән бөркелеп салкын һава керде. Тышта басынкы гына, карлыгып кына машина моторы гыжылдый башлады. Машина бермәл ишек төбендә генә тырылдап торды. Бераздан аның тавышы ерагайды, сүрелде, сүнде...

Авыл агайларына нәрсә! Яңа ел бәйрәмендә бөртек тә кайгылары юк. Әйтерсең шушы салкын, ялангач бинага гомергә килгәннәр. Чемодан-капчыкларын бер күчкә өеп куйганнар да рәхәтләнеп гәпләшәләр. Янәсе, тормышлар тоташ бәйрәмгә әйләнде хәзер. Янәсе, көн дә бәйрәм, көн

дә туй. Элек заманда халык Казаннан Мәскәүгә җәяү йөргән. Бер караңгыдан икенче караңгыга тикле басуда эшләгән. Әңгәмә байтак кына шул рәвешле акты. Түшәмгә төтен алкалары күтәрелде. Капчык-чемоданнардан мич төбендә тәгәрәтеп пешерелгән калачлар, салкын каз итләре, ат казылыклары чыкты. Ризыкның валчыгын да исраф итмичә, тәмен белеп кенә ашадылар агайлар. Аннан соң янә әңгәмә корып җибәрделәр. Янә тәмәке кабыздылар. Әмма өстәмә самолет булмаячагы тәгаен мәгълүм булгач, гәпләшүчеләр дәррәү тынып калды. Әле генә бәйрәмнәрнең күплегенә зарланып утырган агайларның тәмам кәефләре кырылды.

Мин дә, башымны яка эченә яшереп, урындык аркасына терәлебрәк утырдым да күзләремне йомдым. Күзләремне йомуга, мине көтә-көтә зарыгып беткән балаларым күз алдыма килеп басты. Түрдә, бөтен тирә-якка нурлар чәчеп, балкып-яктырып чыршы утырадыр инде. Кунаклар килгәндер. Минем хакта уйлап борчылалардыр...

Шул чагында кайдадыр якында гына «әни» дигән тавыш ишетелгәндәй булды. Күзләремне ачсам — шәрә зал уртасыннан сигез-тугыз яшьлек малай узып бара иде. Башында олы бүрек. Озын бишмәтенең билен солдат каешы белән буган. Әһә, әнисе аэропортта җыештыручы булып эшли икән. Бер кулына бәләкәй балта, икенче кулына көрәк тотып, ишектән чыгып бара. Улы да аңа ияргән. Бераздан әлеге малай, бер кочак утын күтәреп, янә залга килеп керде. Битләре борыч кузагыдай кызарган, күзләре очкынланган иде аның. Аңа карагач, минем, ихтыярсыз, бөрешеп утырган урынымнан сикереп торасым, урамга чыгып, тирләп-пешеп кар көрисем яисә утын ярасым килә башлады.

Малай караңгы почмактагы бүлмә ишеге янына җиткәч, тирә-юньдәге йокымсырау катыш борчылып, тирән уйларга күмелеп утырган агайларны сискәндереп, «Фирдәүсә» дип кычкырды. Почмактагы ишек ачылып китте дә бусагада бәләкәй кулларына әрчелә башлаган бәрәңге тоткан биш-алты яшьлек кыз күренде. Малай артыннан ишек ябылды. Идәнгә дөбердәп утын төшкәне ишетелде. Малай, карлы бияләйләрен селки-селки, тагын зал буенча йөгереп узды. Тагын утын күтәреп керде. Бераздан, авыз эченнән генә нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә, малайның әнисе дә залга үтте.

Башта зал уртасында утырган калай тышлы түгәрәк мичкә утын тутырып, ут тергезеп җибәрделәр.

Малайның исеме Фирдүс икән. Ике сүзнең берсендә Яңа елны телгә ала. Олтан салган олы киез итекләре белән нык-нык басып, зал буенча йөри. Агайларның сорауларына бик теләп, бик кыю җавап бирә.

— Әтиең кайда соң синең, Фирдүс?
— Командировкада.
— Ничәнчедә укыйсың?
— Икенчедә инде.
— Бәйрәмгә ни пешерәсез соң?
— Ит белән бәрәңге пәрәмәче.

Әнисе, «күп сөйләнмә инде» дигәндәй, малайга ачулы караш ташлап ала. Ләкин бу болай гына. Тиз уза торган, эчкерсез ачу.

— Ә безнең ёлка бар, — ди малай тагын бераздан, озын колаклы бүрек кигән агай янына елышып.

— Чынлапмы?— дигән була теге агай һәм, зур куллары белән кесәләрендә актарынып, озын гына сыбызгы тартып чыгара.

— Менә сиңа сыбызгы, — ди агай, Фирдүснең аркасыннан сыйпап, — аю баланыннан ясаган идем. Аннан теләсәң нинди көй чыгарырга була, башкорт кураеннан бер дә ким түгел.

Малай икеләнеп кенә сыбызгыны кулына ала. Әнисенә шикле караш ташлый. Ниһаять, сыбызгыны авызына каба. Буп-буш салкын зал һавасыннан әллә нинди генә кош сайравын хәтерләтеп, матур тавыш тирбәлеп уза.

Мичтә ялкын телләре биешә. Фирдүснең әнисе, сипкелле хатын, әле үз бүлмәсенә керә, әле залга чыгып, кыска саплы тимер кисәү белән мичтәге утыннарны айкый. Ул ишекне ачкан саен, залга бөркелеп-бөркелеп тәмле исләр чыга.

Фирдүснең кулында инде сыбызгы гына түгел, агачтан кисеп ясалган кызыл койрыклы төлке, әтәч конфет, минем сумкадагы уенчык автобус.

Моңарчы сүзсез генә йөргән сипкелле хатынның да йөзе ачылып китте. Ара-тирә залдагыларга сүз кушкалый, аларның хәлләренә керә... Килмәде бит самолеты да... Әй, юлның хәлләре! Безнеке дә шулай бер-бер җирдә боегып утырадыр инде, ди. Бүген бик көткән идек югыйсә, ди.

Бермәлне җыештыручы хатын белән Фирдүс бүлмәләреннән озак кына чыкмый тордылар.

Тын. Мичтәге күмерләр сүрелү белән бергә, юлчыларның йөзләрендәге җанлылык та сүнә.

Түшәмдәге ялгыз лампаның яктысы залның иң якын почмагына да барып җитә алмый. Бәсле тәрәзәләргә буран ышкылып уза. Җил, нәрсәгәдер ачулангандай, түбә кыегын дөбердәтә.

Ләкин мондый эчпошыргыч халәт күпкә бармады. Озакламый залда Фирдүснең:

— Әйдәгез, абыйлар, чәй эчәргә кирәгез, пәрәмәч пеште, — дигән яңгыравыклы нәзек тавышы ишетелде.

Фирдүс артыннан, сипкелләрен балкытып, хуҗа хатын үзе дә килеп чыкты. Әдәп белән генә безне чәй эчәргә чакырды.

Юлчылар бер-берсенә караштылар, кайсылары «рәхмәт, рәхмәт, эчәсебез килми» дип карасалар да, Фирдүс: «Әйдәгез инде, абыйлар, аннары бергәләп ёлкалы уйнарбыз», — дигәч, урыннарыннан кузгалыша башладылар. Беренче булып: «Җәмәгать, аштан олы булмыйк», — дип, чал сакаллы агай аяк өстенә басты. Аннары — калганнарыбыз.

Өс киемнәребезне залда чишенеп калдырдык. Бүлмә бәләкәй булса да, җылы, якты иде, кай ягы беләндер үз өебезне хәтерләтә иде.

Фирдүс ут малай булып чыкты. Әллә кайдан гына нарат бүкәннәр тәгәрәтеп чыгарды, залдан озын такта сөйрәп керде... Берничә минуттан без, өстәл тирәсенә тезелешеп утырып, пәрәмәч ашый идек инде.

Кайнар чәй эчеп, тәнгә җылы йөгергәч кенә, бүлмә почмагында торган чыршыга күзем төште. Теге чал сакаллы агай да чыршыга карап утыра икән. Фирдүс, башкаларга сиздермичә генә, аның янына барып сыенды.

— Әйдә инде, ёлкалы уйныйк, син Кыш Бабай бул,— диде.

— Бер дә Кыш Бабай булганым юк шул минем, олан, ничегрәк булалар соң аны?— дип сорады агай елмаеп.

Мин, шәһәр кешесе буларак, азрак чыршы бәйрәменең рәтен белә идем. Чал сакаллы агайга эшнең асылын төшендереп бирдем. Башка юлчыларның да кайберләре уенга катнашырга ризалык белдерделәр.

Залга чыгып, чал сакаллы агайга озын колакчынлы бүреген киерттек тә кулына таяк тоттырдык, аркасына капчык астырдык. Ә бүләкләр һәркайсыбызның сумка-чемоданнарыннан, рюкзакларыннан мул гына чыкты. Кыш бабайның капчыгы прәннек-конфетлар, каклаган каз ите, пешкән күкәй, «куян күчтәнәче», тәбикмәк кебек ризыклар һәм төрле-төрле уенчыклар белән тулды. Юлчыларның кайсылары, туннарының эчке ягын әйләндереп киеп, төлке булдылар, кайсылары аюга яки бүрегә әверелделәр. Бәләкәй Фирдәүсәнең марлядан тегелгән күлмәге бар икән — ул кар кызы булды. Фирдүс белән безгә кичәне алып бару бурычы йөкләнде.

Бераздан тирә-юнь гөр килә иде инде. Аюлар, төлкеләр, бүреләр җитәкләшеп чыршы тирәли әйләнеп йөриләр. Кыш бабай курайда уйный. Ап-ак кар кызы Фирдәүсә бертуктаусыз чырык-чырык көлә. Хуҗа хатынның да, тамашачы булып утырган башка юлчыларның да йөзләрендә елмаю, шатлык.

Ә тышта дәртле курай көенә салкын буран бии.

# КАРЛЫГАЧЛАР КИЛГӘЧ

Галимә әби иртә белән ишегалдына чыкса, шаккатты. Дулаган иде аны төнлә, юкка булмаган икән: җил лапас түбәсен каерып аткан. Галимә әби ашыгып лапас янына барды. Җирдә аркылы-торкылы яткан такталарны күздән кичерде. «Тавыкларымны харап итмәдеме икән инде?» дигән уй йөгереп үтте аның башыннан. Юктыр, ахрысы. Әнә ич чуаркае да, бүрекле тавык та, чебеш әнкәсе дә... Галимә әби: «Тукта, Сәмигуллага кереп әйтим әле», — дип, күршеләре ягына борылган иде, басма алдында йокылы күзләрен уып, киерелеп торган оныгы Илдарны күргәч, туктап калды.

— Нигә бик иртә тордың әле, улым?

— Әби, — диде тегесе, сузынкы тавыш белән, — что анда происходит?

— Менә җил, улым, җимереп ташлаган. Бик дулады бит. Тагын әллә нинди бәла-казалар китергәндер әле ул, Аллам сакласын.

— Әби, ә карлыгачлар?

Галимә әби бары тик шул чакта гына баш өстендә кызганыч тавышлар чыгарып очкан карлыгачларга игътибар итте. Карлыгач оялаган иде бит аларның лапасларына. Харап кына булганнар икән, бичаралар. Ярый инде бала чыгарып өлгермәгән булсалар... Шулай да Илдарга сиздермәскә кирәк. Ә Илдар шыңшый ук башлады.

— Әби, жалко.

— Кайгырма, улым, кайгырма, — дип юатты оныгын Галимә әби. — Менә Сәмигулла абыең төзәтеп бирер, Алла боерса. Ә карлыгачлар яңа оя корырлар. Элеккесеннән дә матуррак итеп корырлар, улым. Корырга ярата торган кош ул карлыгач.

Галимә әби кызыл эчле галошларын лыштырдатып капкага юнәлде. Илдар, гәрәбәдәй сап-сары итеп юылган басма тактасына утырган килеш, дымлы күзләрен һаман да фирүзә зәңгәрлекне телеп-телеп очкан карлыгачлар артыннан йөртте. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кисәк кенә торып, лапаска таба йөгерде. Лапас янына барып җитте дә, такталар астыннан күренеп торган ялтыравык әйбергә карап, катып калды. Такталарны таратып ташласа — исе китте Илдарның — мандолина... Әйе, әйе, чып-чын мандолина. Кайдан килгән икән бу әбисенә? Илдар шулай уйларга өлгермәде, артында әбисе тавышы ишетелде:

— Бүген гәрүчигә бара икән Сәмигулла абыең. Иртәгә кереп төзәтеп чыгармын, диде... Син нишлисең әле монда, улым?

Илдар, ап-ак тешләрен елтыратып, кычкырып җибәрде:
— Әби, мандолина.
— Мандолина шул, — диде әбисе, ни өчендер авыр сулап. — Ватылган ул, улым. — Галимә әби мандолинага үрелде: — Китер әле, улым, аны монда, югалмас борын чормага алып менеп элим. — Галимә әбинең тавышы калтыранып китте. — Бабаң ядкаре ул...
— Бирмим, бирмим, — дип сикергәләде Илдар, мандолинаны күкрәгенә кыскан килеш. Ул сикергән саен, мандолина кыллары моңлы тавыш чыгарып зыңлый иде. Галимә әби бөтенләй каушап төште:
— Китер, дим, улым, нигә ул сиңа?
— Ружье ясыйм.
— Ниткән ружье ди ул?
— Сугыша торган.
— Ни сөйлисең син болай? — Галимә әби ачуланып оныгына таба бара башлады. — Ну, зимагур малай, кайткач, атаңа әйтим әле менә мин сине.
Илдар шүрли калды.
— Әби, безнең бабай настоящий сугышта, танкта янып үлде, име? — дип сузды ул, ялагай тавыш белән.
Галимә әби сискәнеп китте. Керфексез күзләрен кыса төшеп, оныгына озак итеп, сагышланып карап торды; көрсенде һәм борылып китеп барды.
— Әби, әби, — дип өтәләнеп йөгереп килде аның артыннан Илдар, — ружье ясамыйм... Ну, әби, прости, икенче не буду... Әби, хочешь, төзәтеп бирәм бабайның мандолинасын... Мин городта музыкальнаяга йөрим бит, әби... Скрипкада да, мандолинада да уйный беләм...
Галимә әби оныгының башыннан сыйпады.
Бераздан Илдар өйгә кереп җылы сөт эчте, май ягып кабартма ашады. Әбисе кермәде. Тавыкларга җим сибеп йөртә торган җилпучын янына куеп, лапас буендагы бүкән өстенә утырып калды. Ашап туйгач, Илдар, кулына кораллар ящигын тотып, ишегалдына чыкты һәм, яңа гына шытып килгән йомшак бәбкә үләне өстенә утырып, мандолина төзәтергә кереште. Үзе, авырыймы икән әллә дип, әледән-әле әбисе ягына караштыргалап алгалады.
Юк, авырмый иде Илдарның әбисе. Болай гына, уйларга чумган иде ул... Кара инде, исең китәр бу тамашага. Тач бабасы бит бу малай... Артка каерылыбрак торган колак яфраклары, озынчарак кылыч борын, куе керфекле соры күз, киң маңгай... Тавышы да Гәрәйшаныкы. Тик менә сөйләшүе генә. Әйтер идем әти-әнисенә. Бала ана телен бөтенләй оныта язган. Әле ярый, җәй саен берәр ай әбисе янында торып китә. Малае Хәбир дә,

килене Асия дә бигрәк эшем кешеләре шул. Хәбир сыннар ясау буенча бөтен тирә-юньдә дан тота. Ә Асия балалар больницасында баш кеше. Тормышлары да ару. Әмма Галимә әбинең шул кала дигәннәренә барса, нигәдер тыны кысыла, аннан тәмам сырхау булып кайта. Соң, шулкадәр тавышка. Гөж-гөж трамвай да машина... Баш очыннан гына улап аэропланы оча. Кичкә керсәң, телевизоры тагын... Концерт-театры ярый инде. Ә теге футбол дигәннәре. Колак тонып, башлар түнеп бетә... Урамнарда халык, халык. Берәр җиргә барырга чыксаң, ырыперып йөрер хәл юк... Шәһәрне макта, авылда тор инде...

Галимә әбинең уйларын бүлдереп, капка шыгырдады. Күтәрелеп караса, күршесе Сәмигулла икән. Үзе генә түгел, Кәбир малае Габделхәй белән. Икесе дә иңбашларына такта күтәргән, икесенең дә җиңнәре сызганулы, йөзләре якты. Керә-керешли үк чирәм өстендә утырган Илдарның башыннан сыйпап уздылар, бөтен ишегалдын тутырып сәлам бирделәр. Галимә әби, каушыйкаушый урыныннан торып, керүчеләр белән исәнләште.

— Калган эшкә кар ява, диләрме әле, Галимә әби... Әйдәле, мин әйтәм, бүген үк төзәтеп чыгыйк. Председательгә әйткән идем дә, җырчы Галимәгә булгач, нигә сорап торасың, ди. Әнә ярдәмгә Габделхәйне дә җибәрде...

Галимә әби, керек-керек килеп, бер урында тыпырдап калды. Тегеләр алъяпкычларын бәйләп, җиңел кулдан эшкә керештеләр. Баздан каймак алып чыкканда да, табага йомырка салганда да, самоварын гөжләтеп җибәргәндә дә Галимә әбинең башында бер генә уй булды. Кара син, ә, аның җырчы булганлыгын онытмаганнар икән әле авылда... Ие шул, бар иде заманнар... Үз авылларында гына түгел, күрше авылларда да концертлар куеп йөри иде алар. Галимә җырлый, ә Гәрәйша — кара мыеклы Гәрәйша тирбәлә-тирбәлә мандолина чиртә... «Зиләйлүк», «Ашказар», «Карурман», «Салкын чишмә»... И кул чабар иде инде халык аларга. Бөтен зал гөр килеп торыр иде... Ә көндез икесе дә колхоз кырында. Авылда беренче тракторчы иде Галимә әбинең Гәрәйшасы. Әлеге мандолинаны тракторга укырга барган җиреннән алып кайткан иде... Аннары бер-бер артлы балалар туа башлады. Концерт куеп йөрүләр сирәгәйде...

Самовар пар бөрки башлагач, Галимә әби осталарны чәйгә чакырды. Әмма тегеләр эшләп бетермичә кермибез, диделәр.

Сәмигулла эш арасында Галимә әби белән сөйләшергә кереште.

— Баганалары таза икән моның.

— Шулаймы? — диде Галимә әби шатланып. — Имән баганалар алар... Сугышка китәсе елны үзе кисеп кайткан иде...

— Ие шул, куллары алтын булган, диләр Гәрәйша абыйның.

— Оста, оста, бик оста иде. Бөтен эш килә иде кулыннан. — Галимә әби көрсенеп куйды. — Менә шушы йортны өчәүләп эшләделәр... Мисбах белән Шамилне тәмам өйрәтеп җиткергән иде балта эшенә, мәрхүм... Хәбире генә атасы юлыннан китмәде... Югыйсә бу лапасны ул төзәтергә тиеш иде дә бит...

— Ничава, Галимә әби, сүз әйтмә Хәбиргә. Ул тоже төшеп калганнардан түгел. Теге Йолдыз мәйданында Ватан сугышы батырларына куелган һәйкәлне күргәнең бармы синең? Шәп бит, ә... Хәбир ясаган икән аны... Әле бая председатель Исмәгыйль әйтә, Хәбирне чакырып кайтарып, сугышта һәлак булган авылдашлар истәлегенә зур һәйкәл ясатам, ди... Күп бит алар бездә... Җитмешкә якын.

— Шулай диме?.. — Галимә әби сүзен әйтеп бетерә алмады. Көтмәгәндә генә аның колагына әллә нинди, йөрәк тетрәткеч авазлар килеп керде. Карчык башта ни булганын аңламый торды. Аннары артына борылып карагач һәм башын бер якка кыңгырайтып мандолина чиртергә керешкән Илдарны күргәч, тынып калды.

— Кара син аны, бөтен шартын китереп сиптерә... Музыкант икән оныгың, Галимә әби, — дип кычкырды түбә такталарын кадакларга керешкән Сәмигулла.

Олы кеше авызыннан чыккан мактау сүзләре Илдарны бөтенләй канатландырды, ахрысы. Ул, мандолинага кушылып, малайларга гына хас нәзек, ләкин моңлы тавыш белән җырлап җибәрде:

Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында...

— Кычкырыбрак җырла, кычкырыбрак, — дип куәт бирде Габделхәй, түбә такталары арасыннан башын чыгарып.

— Могу кычкырып та, — диде Илдар, аяк өстенә басабаса. Үзе байтак вакыт кирәкле авазларны югалтып интекте. Аннары, гәүдәсен катырып, мандолина чиртә-чиртә, тантаналы тавыш белән җырлый-җырлый, әкрен генә боларга таба килә башлады.

Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында.
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә и Дунай ярында...

Галимә әбинең күзләренә яшь бәреп чыкты. Ул, каушый-каушый, оныгына таба атлады. Аны мандолинасыние белән кочып аркасыннан сөйде. Мандолина кыллары өзек-өзек авазлар чыгарып шыңшыдылар, ә Илдар шырык-шырык көлде.

Сәмигулла белән Габделхәй лапас түбәсеннән: «Ай, молодец, вай, молодец, Илдар», — дип, мактау сүзләре яудырып тордылар.

Әллә ни генә булды шул чагында Галимә әбигә. Берничә дистә еллар уйналмаган мандолинаның телгә килүеме, оныгының шундый матур, чиста итеп татарча җырлый белүеме шулай дулкынландырды аны... Бәлки, сугыштан кайтмаган солдатлар турындагы җырдыр?.. Юк, алар гына да түгел... Нигә соң алайса, нәрсә? Галимә әбинең җиңелчә генә башы әйләнеп китте... Әйе, әйе, шул бит бу, шул... Галимә әби, алъяпкыч итәген кулы белән йомарлый-йомарлый, ашыгып өйгә кереп китте. Өйгә кергәч, кеше-фәлән юкмы дигәндәй, алан-йолан каранды да басынкы тавыш белән җыр башлады:

Дошманнарны җиңгәч,
Карлыгачлар килгәч,
Кайтырбыз без, иркәм, кайгырма.
Йортлар төзербез без,
Илне бизәрбез без
Матуррак итеп тагын да.

Галимә әби, бүлем тактасына сөялгән килеш, шул бер үк җырны кабат-кабат җырлады. Шул бит, шул... Югалган көй... Ходаем, каян, ничек хәтергә килеп төште соң әле бу?..

Алар өчесе дә бер көнне, бер ачылган ишектән чыгып киткәннәр иде... Ишегалдына чыккач, Гәрәйшә матур итеп мандолина уйнады, ә Мисбах белән Шамил, аның каршына басып, кочаклашып җырладылар. Ул җырның сүзләрен дә үзе чыгарган иде Гәрәйшә, көен дә... Калган сүзләре онытылган... Кайчан соң әле? Ә, әйе... Теге буранлы төндә... Хәбир йоклаган. Галимә үзе мандолинада әлеге көйне чыгарырга тырышып утыра... Шунда кинәт ишек ачылды... Бусагада баштанаяк карга чумган почтальон малай тора иде. Аның йөзенә карагач ук, барысын да аңлап алды сизгер күңел; мандолинасы идәнгә төшеп зыңлады, үзе хәлсезләнеп урындык читенә тотынды... Әйе, почтальон Гәрәйшанең үлгән хәбәрен китергән иде... Курск каласы төбендә бик каты сугыш булган икән. Шунда Гәрәйшанең танкына снаряд тигән. Олы улы Мисбах — Белоруссия җирендә, уртанчысы Шамил Днепр буенда ятып калдылар... Ә төпчеге Хәбирнең җырга

да, музыкага да һәвәслеге булмады... Кечкенәдән үк шул балчык сыннар эшләргә ярата иде ул. Менә, ичмасам, оныгы бөтенләй башка. Төсе-бите белән генә охшамаган икән ул бабасына, эчке фигыле белән дә охшаган икән...

Осталарны ашатып-эчерткәч, Галимә әби оныгын өйгә чакырып кертте. Иң йомшак урындыкка утыртты. Үзе дә аның каршысына килеп утырды:

— Әйдә әле, улым, өйдә уйна. Кеше барында мактарга да яхшысынмадым үзеңне. Бик матур уйныйсың, улым, рәхмәт. Йә әле, йә, тагын нинди көйләр беләсең?

Илдар кыстатып тормады. Белгән көйләрен уйнап күрсәтте.

— Ә менә мондый көйне беләсеңме, улым?

Галимә әби, дулкынлана-дулкынлана, баягы җырны көйләргә кереште.

Малай башын чайкады:

— Юк, белмим.

— Отырга тырыш син бу көйне, улым. Бабаң мәрхүм чыгарган көй бу... Әйдә, мин җырлыйм, син уйнап кара.

Җил-давыллар анда,
Хәтәр юллар алда...

Түбәннәнрәк, улым, түбәннәнрәк... менә болай:

Лилә-лилә, лилә,
Ли-лә, ли-лә, лә-лә...
Ватан өчен керәм ялкынга...

Тәмам алҗыганчы җырлады Галимә әби: оныгының шаян күзләренә карап, көлә-көлә, елый-елый җырлады. Ахырда, тәмам хәлдән таеп, урынына барып ауды... Төшендә ул Гәрәйшаны күрде. Тракторчы киеменнән мандолина уйный-уйный тау чаклы ялкын эченә кереп бара, имеш. «Көен өйрәт әле, Гәрәйша, көен генә өйрәтеп калдыр җырыңның», — дип, елый-елый йөгерә икән аның артыннан Галимә әби. Әмма Гәрәйша борылып та карамый. Арыш кыры кебек тә шунда. Югарыда тургай да сайрый сыман, ә мандолина тавышы һаман ераклаша бара. Гәрәйша ераклашкан саен, ялкын да кечерәя, имеш...

Галимә әби, уянып, тирә-ягына каранды. Бүлмә караңгы иде. Мандолина тавышы каяндыр урам яктан ишетелә. Галимә әби идәнгә төште. Илдар караватының буш икәнен күргәч, ашыгып ачык тәрәзә янына барды. Аның борынына шомырт чәчәге исе килеп бәрелде. Бүлмәгә әлеге үзәк өзгеч җыр — Гәрәйша җыры ургылып керде... Юк, көе генә шул, сүзләре бүтән иде җырның.

Галимә әби, башын тәрәзәгә тыгып, урамга карады.

Ай яктысы су кебек. Тимерче Гарифлар капка төбендәге бүрәнәләр өстенә бер төркем яшүсмерләр тезелешеп утырган. Бәләкәй буйлы Илдар, аларның каршысына басып, мандолина чиртә. Бер кыз йомшак тавыш белән җырлый:

…Сөю сүрелмәсә,
Сүрелмәсә сөю,
Берни түгел җилләр, давыллар…

Галимә әби икенче тапкыр уянганда, тәрәзәдән кояш карый иде инде. «Озак йоклаганмын икән, — дип уйлады ул, Илдар караватына күз ташлап. — Әллә бөтенләй кайтмаган инде бу малай? Алай дисәң, мандолинасы карават өстендә ята...»

Галимә әби яулыгын бәйли-бәйли ишегалдына чыкты. Анда аны, сөенечле тавыш белән кычкырып, Илдар каршы алды:

— Әби, карлыгачлар яңа оя кора.

Галимә әби, күзләрен кыса төшеп, лапасның яңа түбәсенә, аннары шатлыклы авазлар чыгарып пыр да пыр очкан карлыгачларга карады.

— Әйттем бит мин сиңа, улым, яңадан ясарлар, дип... Кайгыларга бирешә торган кош түгел алар, карлыгачлар.

# ЭЧТӘЛЕК

Тылсым дөньясында. *Рушания Шәфигуллина* 5

**Повестьлар**

Ак маңгайлы бүреләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Бер малай, өч аргамак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36

**Хикәяләр**

Солдатлар кайта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Кәҗәмөгез йолдызлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Кырмыска турында баллада . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Тамгалы бүре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Актәпи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Кызыл мәрмәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Эльмира . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Исемең Ләйсән булыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Әти тәти . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Фирүзә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Җир малае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Әнкә күркә һәм аның балалары . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Чикләвек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Тау битендә күләгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Мин дә үсәрмен әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Кыр казы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Сизгәк тәкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Төгәллек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Ликандр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Әнфисә кемгә елмая? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Сугышчан бурыч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Нишләргә тиеш идем? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Акбай белән Карабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Командир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Буранга — шах! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Язарга кәгазь беткәнме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Урман аша юлларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Ерык авызлы энекәшем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Акмөгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Верочка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Каен яктысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Авылым сандугачы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Бал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Зәңгәр шугалак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Дезертир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Ике тиен акча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Ислемай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Миңа уйларга кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Ерактамы, якындамы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242

Хыянәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Демонстрация . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Беренче кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Яңа ел кичендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
Карлыгачлар килгәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264

Литературно-художественное издание

*Шафигуллин Фаиль Хафизович*

**МАЛЬЧИК И ТРИ СКАКУНА**

Повести, рассказы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *И.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.04.2005. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 14,28 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 15,54. Нәшер-хисап табагы 15,22 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ А-304.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.